


# КАЗАН УТЛАРЫ

4
АПРЕЛЬ
1980

## Владимир Маяковский

...Яшен, син атылма!—
дияр көч юк җирдә.
Һәм
кукрәуләр көчен син
богаулый алмыйсың!
Ленинның
яктыга
өндәүле сүзләре
Ни әйтеп
мәңгегә
күкрәвен аңлыйсың.
...Ул пульс
сыешсыз
секундлар санына.
Һәм нигә градусник?
Юк аның кирәге!
Октябрь исемле
тынгысыз күкрәктә
Мәңгегә тибәчәк
Ленинның йөрәге.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

4

АПРЕЛЬ
1980

## Бу санда

ДАҺИ ЮЛБАШЧЫ — ИЛҺАМ ЧИШМӘСЕ

Ш. ХАММАТОВ. В. И. Ленин татар матбугатында . . . 3
Н. АРСЛАНОВ. Ярдагы һәйкәл. Шигырь . . . . 12
Ә. МАЛИКОВ. Адашырга безгә мөмкин түгел. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 13
С. БАТТАЛ. Поэма тәрҗемә иткәндә. Шигырь . 13
Г. ЛАТЫЙП. Байрагыбыз безнең Ильичлы. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Ш. МАННАПОВ. Чигенү юк. Шигырь . . . . . 15
М. ХӘБИБУЛЛИН. Яктыра кешелек таңнары. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Г. ГАЛИЕВ. Без сикерткән шобагалар. Хикәя . . 17

ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘН, ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘН

С. СМИРНОВ. Апрель. Шигырьләр . . . . . . 23
Д. ТАРВА. Бөек кеше. Шигырь . . . . . . . 23
А. ВОЗНЕСЕНСКИЙ. «Лонжюмо» поэмасыннан өзек . . . . . . . . . . . . . . . . 24
М. ЛЬВОВ. Бөек якташ. Шигырь . . . . . . . 24

БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 35 ЕЛЛЫГЫНА

М. МӘҺДИЕВ. Ут чәчәге. Повесть . . . . . . 26

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Соңгы монолог. Шигырь . . 78
Г. АФЗАЛ. Чулман ярында уйланулар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 79

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Н. ИХСАНОВ, М. СКОРОХОДОВ. Йөзгә-йөз. Повесть . . . . . . . . . . . . . . . . 82

Г. РӘХИМ. Табылдыклар өстәле. Шигырьләр . . 113

ОЧЕРКЛАР

И. НИЗАМОВ. Ул кабызган маяклар . . . . . 117
И. ЗӘБИРОВ. Ленин шоферы . . . . . . . . 130

ДУСЛАР ҖЫРЫ

С. КУДАШ. Кошлар ашатам. Шигырьләр . . . . 136
Я. КОЛМЫЙ. Салават янында. Шигырьләр . . . 138
С. ӘЛИБАЕВ. Сигезьюллыклар . . . . . . . 139

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН

**Ш. МОСТАФИН.** **Солдат дәфтәреннән.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 141
**Р. ШӘРИПОВ.** **Чиксезлеккә манып.** Шигырьләр . 143
**Ә. ФӘТХЕТДИНОВА.** **Гөрләвекләр.** Шигырь . . 144
**З. ДӘҮЛӘТШИН.** **Горурланам.** Шигырь . . . . 145
**Х. БАТЫРОВ.** **Кыр чәчәге** . . . . . . . . . . 145

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**И. НАДИРОВ.** **Лениниананың гүзәл бер сәхифәсе** 146
**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** **Тирән катламнарны ачканда** . 152

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**М. РӘХИМКУЛОВА.** **Юл башында** . . . . . . 159
**Г. ЛОТФИ.** **Соңгы еллар** . . . . . . . . . . 160

## КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. МОСТАФИН.** **Жанр тойгысы** . . . . . . . . 169
**М. АБДУЛЛИН.** **Татар тарихы турында китап** . . 173

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Г. Толымбайның тууына 80 ел** . . . . . . . . . 174
**Н. ЮЗИЕВ.** **Илдус Ахунҗановка 50 яшь** . . . . 175
**Л. ХӘМИДУЛЛИН.** **Таһир Нурмөхәммәтовка 50 яшь** . . . . . . . . . . . . . . . . 177
**Р. ГӘРӘЙ.** **Абдулла Сәләхетдиновка 50 яшь** . . 179

**Укучы сүзе** . . . . . . . . . . . . . . . . 181

**Мәсәлчеләр мәҗлесе** . . . . . . . . . . . . 185

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**Х. ВӘЛИӘХМӘТОВ.** **Ул ачкан дөнья** . . . . . 187

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова** (җаваплы секретарь), **Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 27/XII-1979 ел. Басарга кул куелды 26/III-1980 ел. ПФ 09009. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94 000 экз. Заказ Ц-499. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1980 ел.

# ДАҺИ ЮЛБАШЧЫ — ИЛҺАМ ЧИШМӘСЕ

**Шәмси Хамматов,**
тарих фәннәре кандидаты, доцент

## В. И. ЛЕНИН ТАТАР МАТБУГАТЫНДА

**«Без—яшь ленинчылар,**
**Ленин байракларын**
**Безгә киләчәккә илтергә.**
**һәм укырга,**
**Ленин кебек!**
**Көрәшергә,**
**Ленин кебек!**
**Ленин кебек,**
**Бөек эшкә хезмәт итәргә!**
**Ленин партиясенә —**
**Дан!**
**Бөек Ленинга —**
**Дан!»** [1]

Бу — КПССның XXIII съезды трибунасыннан даһи Ленинга пионерларның олы хөрмәт белән әйткән ялкынлы тәбрик сүзләре. Киләчәк буын яшьләренең Ильичка биргән анты. Без, партия съезды делегатлары, коммунистлар һәм эшчеләр партияләре вәкилләре, пионерларны тыңлап һәм алкышлап, Владимир Ильичка тугрылык хакында уйландык. В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу юбилеен каршылаган һәм үткәргән көннәрдә шушы ук фикер тагын рухландырды. Юлбашчыбызның мәңге сүнмәс идеяләре, үлемсез образы аңа багышланган әсәрләр, күңелгә тиз һәм тирән үтеп керә, чиксез дулкынландыра, съездда балалар тәбрикләве онытылмаган кебек, мәңге истә кала. Аның гаять зур эшчәнлегенә багышланган китаплар, җыентык, шигырь, поэма, нәсер, истәлек һәм публицистик мәкаләләр, башка халыклар иҗатындагы кебек үк, татар матбугатында да иң хөрмәтле урынны били. Нигә шул рухи байлыкны, культурабызның нигез ташларын тәшкил иткән хәзинәне барлап чыкмаска.

Россиядәге беренче революция елларында ук Ленин мәкаләләре, аның «Искра», «Пролетарий», «Вперед», «Новая жизнь», Казан большевикларының «Рабочий» кебек ленинчыл газеталардан алып басылган әсәрләре, ана телебезгә тәрҗемә ителеп, листовка һәм газеталар аша татар пролетариатына, хезмәт ияләренә, интеллигенция вәкилләренә җиткерелә. Бу җаваплы, җитди эшкә большевикларның Казан комитеты члены Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә революционер Галимҗан Сәйфетдинов, әдипләрдән Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал, прогрессив интеллигенция вәкиле Мөхетдин Корбангалиев, журналист Гариф Латыйпов һ. б. катнаша. Инде егерменче елларда Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Фатих Әмирхан, Һади Такташ, Сәгыйть Сүнчәләй, Вәли Шәфигуллин, Муса Җәлил, Мәхмүт Максуд, Гомәр Гали, Гомәр Толымбай, Шамил Усманов һәм башка әдипләребез аның мәңге сүнмәс йол-

[1] XXIII съезд КПСС. Стенографический отчет. т. I, Политиздат, М., 1966, 437 бит.

дыз булып балкыган һәм балкыячак эшчәнлеген яктырткан әсәрләр, публицистик мәкаләләр язалар.

В. И. Ленин үлгәннән соң, 1924 елның февраль башында ук Һади Такташ, юлбашчыбыз истәлегенә багышлап, тирән фикер, ялкынлы хис белән сугарылган «Гасырлар һәм минутлар» дигән лирик-публицистик поэмасын язып өлгерә.

—Ул үлмәде,
Ленин мәңге бар!
Ленин—без ул!

—дип белдерә шагыйрь ул авыр хәсрәтле көннәрдә.

Алардан соң килгән буын әдипләренең бөек юлбашчыбызга атап язган әдәби хезмәтләрен, Ленин хакындагы әсәрләрнең геройларын халкыбыз яратып кабул итте һәм шулар белән рухланып яши.

60 нчы еллар ахырында — 70 нче еллар башында Татарстан китап нәшрияты татар әдипләренең, журналистларының, җәмәгать эшлеклеләренең Ленин турында төрле елларда газета-журналларда, китапларда басылган әсәрләрен, Ильич булган урыннарга барып язган очерк һәм репортажларны җыеп, лениниана сериясен чыгарды. Аларны чыгару Бөек Октябрьның 50 еллыгы, В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм Татарстан АССР төзелүгә 50 ел тулу бәйрәмнәренә туры китерелде. Әдәби ленинианаНЫ төзүдә Мөхәммәт Гайнуллин, Мөхәммәт Садри, Илбарис Надиров (һәркайсы берәр томнан) һәм Зәки Нури (3 томын) зур көч куеп эшләделәр. Хәзер инде ул җыентыклар әдәбият һәм китап сөючеләрнең якын юлдашы, илһам чыганагы булып әверелде, Ленин васыятьләрен, аның җиңелмәс идеяләрен тормышка ашыруда партиябезгә ярдәм итә, Советлар Союзы һәм бөтен дөнья хезмәт иясе халыкларының интернациональ дуслыгына дан җырлый.

1920—1978 елларда татар телендә В. И. Ленинның аерым әсәрләре һәм җыентыклары ике ярым миллион тираж белән 350 тапкыр басылды, шул исәптән В. И. Ленин әсәрләренең 45 томлы басмасы дөнья күрде.

1970 елда «В. И. Ленин һәм Татарстан»[1] дигән документлар, материаллар һәм истәлекләр җыентыгының икенче басмасы чыгарылуы (беренче басмасы 1964 елда эшләнде) ленинианага кыйммәтле өлеш булып кушылды. Ул — барлык идеология работниклары, шул исәптән журналистлар һәм язучылар өчен бик зур файдалы кулланма. Ана телебездә Татарстан китап нәшрияты чыгарган «К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында»[2] дигән китап рухи тормышыбызда, һичшиксез, зур вакыйга булды. Җыентыкка марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгатькә караган хезмәтләре, әдәбият һәм сәнгатьнең җәмгыять үсешендә тоткан урыны турындагы фикер-карашлары тупланган. В. И. Ленин хезмәтләренең тәрҗемәсе нигездә 45 томлык «Әсәрләр»нең татарча басмасыннан алынган, ә К. Маркс һәм Ф. Энгельс хезмәтләре бу җыентыкка беренче мәртәбә тәрҗемә итеп кертелгән. Марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгатькә караган хезмәтләрен аерым бер җыентык итеп татар телендә бастырып чыгару, сүз дә юк, лениниана үсешендә яңа бер үр ул.

Ленинианаы үстерүдә, әдәбиятта, матбугатта халыклар дуслыгы көчен күрсәтүдә «В. И. Ленин, КПСС пролетар интернационализм турында»[3] дигән җыентык та зур роль уйный. Аңа кергән документлар В. И. Ленинның бу өлкәдәге гаять зур иҗади эшчәнлеге, илебездә социализм һәм коммунизм төзү чорында партиябезнең Ленин идеяләрен ничек үстерүе турында сөйли.

Мәгълүм ки, лениниана — революция даһиенең тормышын һәм эшчәнлеген, көрәштәшләре һәм варисларының Ильич идеяләре белән рухланып яшәүләрен һәм көрәшүләрен әдәбиятта, матбугатта төрле жанрларда чагылдырган әсәрләр җыел-

---

[1] В. И. Ленин һәм Татарстан. Документлар, материаллар һәм истәлекләр җыентыгы. Төзәтелгән һәм өстәлгән икенче басма. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1970. Редакцион коллегия: Г. С. Жук (баш редактор), А. И. Лебедева, М. К. Мөхәррәмов, Ш. Х. Хамматов.

[2] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, күләме 560 бит. Төзүчеләре һәм редколлегия члennары: философия фәннәре кандидаты М. М. Мусин, филология фәннәре докторы М. З. Зәкиев, филология фәннәре кандидаты А. Г. Әхмәдуллин, Н. К. Габитов.

[3] В. И. Ленин. КПСС пролетар интернационализм турында. Документлар һәм материаллар җыентыгы. 1894—1976 еллар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел. Төзүчеләре һәм редколлегия члennары: философия фәннәре докторы К. Ф. Фасеев, тарих фәннәре кандидаты М. Р. Булатов, философия фәннәре кандидаты К. Т. Гизатов, И. А. Беляев.

масы. Укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган бу хезмәттә татар телендә лениниананың үсеш этаплары күздән кичерелә. Башта сүз Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәрге чор турында барачак.

Егерменче йөз башы. Россиядә дәһшәтле 1905 еллар революциясенең давыл булып якынлашуы сизелә. Казан һәм аның партия оешмасы белән тыгыз бәйләнештә торучы В. И. Ленинның чит илдә чыгарган «Искра» газетасының «Очкыннан ялкын кабыныр» дип чакырулары илебезнең иң ерак төбәкләрендәге эшчеләргә, хезмәтчел крестьяннарга, алдынгы карашлы интеллигенциягә бик зур йогынты ясады. Ленинның «Искра» газетасында басылган мәкаләләре, Казан комитетының рус һәм татар телендә чыгарган листовкаларында чагылган идеяләре пролетариатны, хезмәт ияләрен царизмга, буржуазиягә каршы изге көрәшкә өнди.

Азагына «Россия социал-демократ эшчеләр партиясе» дип кул куелган ул кәгазьләрне кем яза икән? Шуларның берсендә «Казан комитеты Ленин карашындагы «Искра»ны үзенә җитәкче орган саный» дип язганнар иде. Нәрсә соң ул «Искра»? Кем ул Ленин?..»[1] Юныс бай башыннан әнә шундый уйлар үтә, дип язды Кави Нәҗми 1948 елда «Совет әдәбияты» журналында. Булачак «Язгы җилләр» романында басылган вакыйгалар ленинчыл «Искра» идеяләренең, искрачыл прокламацияләрдәге чакыру сүзләренең татарлар арасында да тарала башлавы, изүче сыйныф вәкилләрен шик-шөбһәгә салуы шулай күрсәтелгән. Роман басылып, аңа Дәүләт премиясе бирелгәч, «Правда» газетасы: «Әдип Ленинның үлмәс сүзләрен романның гомуми художество тукымасына зур осталык белән керткән. Юлбашчының мәкаләләре хәрәкәтнең һәр яңа этабында, көрәшнең үзгәргән яңа шартларында эшчеләргә барасы юлны яктыртты»,[2] дип язды.

«Язгы җилләр» романын кулыма алсам, мәрхүм әдипнең якты образы алга килеп баса. Бүгенгедәй хәтердә: Кави аганың ялкынланып тарихи роман язып йөргән чагы. Шуның өстенә «Совет әдәбияты» журналының җаваплы мөхәррире дә. Мәскәүдә Югары партия мәктәбен тәмамлап, «Кызыл Татарстан» газетасы редакторы урынбасары булып эшли башлаган вакытымда Кави ага 1905 елгы революция чоры вакыйгалары, аның матбугаты белән кызыксынуымны каяндыр белеп алган бит. Бервакыт мине очратып:

— Бик кирәк эшкә тотынгансың, энем. Халык күңеле шундый борылыш, кузгалыш елларында аеруча ачылып китә ул, — диде. Җыйган материалларны билгеле бер рәвешкә кертеп, «Совет әдәбияты» журналына язарга тәкъдим итте.

Атаклы әдип һәм журналистның бу кайгыртуы мине рухландырып җибәрде. Илһамланып «Искра», «Пролетарий», «Вперед», «Новая жизнь» газеталары тегелмәләренә кереп чумдым. Ленинчыл революцион матбугатта Казан эшчеләре тормышының, губернада булган чуалышларның киң яктыртылуын күреп исем китте. «Совет әдәбияты» журналында «Я. М. Свердлов Казанда», «Ленинчыл «Искра» Казанда»[3] дигән күләмле мәкаләләрем басылып чыкты. Ә инде соңрак «Казан большевиклар оешмасы беренче рус революциясе елларында» исемле китабым чыккач, шул ук Кави ага мактау сүзләре әйтеп күңелне канатландырды.

Менә шул елларда күздән кичергән листовкаларның күчермәләрен янәдән актарып утырам, аларның үз чорында нинди зур роль уйнаганын күз алдына китерергә тырышам. Заманында Ленин революцион листовкаларны эшчеләр матбугатының башлангычы дип атаган. Ильич идеяләрен пропагандалаучы әлеге листовкалар татар матбугатында Ленин темасының, лениниананың беренче карлыгачлары була, дип расларга җирлек бар. Алар «Искра» газетасы идеяләрен татар телендә пропагандалый. 1900 елның декабрендә революцион социал-демократларның гомум Россия күләмендәге политик газетасы буларак чит илдә чыгарыла башлаган ленинчыл «Искра» революцион марксизм байрагын югары күтәрә. Ул, беренчедән, партияне идея ягыннан берләштерүне һәм, икенчедән, урыннардагы оешмаларның таркаулыгын бетерүне, үзәкләштерелгән партия оешмасы төзүне һәм партиянең II съезды хәзерләүне үзенең төп бурычы итеп куя.

---

[1] «Совет әдәбияты», 1948 ел, 6 сан, 36 бит.
[2] «Правда», 30 март, 1951 ел.
[3] Карагыз: «Совет әдәбияты» журналы, 1949, № 3, 117—130 битләр. № 5, 95—101 битләр.

«Искра» агентлары Ленин газетасы саннарын Россиядәге бөтен шәһәрләргә тараттылар. Казан социал-демократларының эшен искә алып, Ленин көрәштәше, революционер Н. А. Семашко болай дип яза: «...Безнең өчен «Искра»ның беренче номеры зур яңалык булды. Без аны үз оешмабызда ныклап тикшердек. «Искра»ның эшчеләр сыйныфының политик һәм экономик көрәшен бергә кушу турындагы тәгълиматы безнең үз эшебездә мөстәкыйль рәвештә, бик үк ачык төстә булмаса да, үткәреп килгән карашыбызга бик туры килә иде. Эшчеләр арасында «Искра» идеяләрен пропагандалау безнең өчен төп бурыч булып әверелде» [1].

«Искра» битләрендә Казан партия оешмасы һәм пролетариаты тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар да яктыртыла бара. Анда басылган хәбәрләр 1903 ел башында Казанда стачка хәрәкәтенең нык үсүен күрсәтә. Аларда шулай ук социализмны эшчеләр хәрәкәте белән кушу практикасы турында, Казан социал-демократик оешмасының пролетариат хәрәкәтенә җитәкчелек итүе, нәтиҗәдә эшчеләрнең экономик стачкаларының политик стачкаларга әверелүе турында һәм политик әһәмиятле башка бик күп мәсьәләләр турында языла.

«Искра» газетасы җәмгыятьнең башка катлаулары арасындагы политик чыгышларны да яктырта һәм аларга дөрес юнәлеш күрсәтә. Газета 1903 ел башында РСДРПның Казан комитеты төзелде, ул күп кенә прокламацияләр чыгара башлады, дип хәбәр итә. «Казан эшчеләренә карата язылган прокламация рус һәм татар телләрендә басылган. Бу прокламация эшчеләр тарафыннан бик теләктәшлек белән каршы алына, көтмәгәндә килеп чыккан «коткы»ны юк итәргә маташкан завод администрациясенең һәм полициянең зур көч куюларына да карамастан, эшчеләр аны укыйлар һәм җентекләп тикшерәләр. Татар эшчеләре үз телләрендә чыккан беренче прокламацияне, башкаларга караганда, полициядән ныграк саклыйлар. Татар телендә прокламацияләр чыгару кирәклеге турындагы фикерне Казан эшчеләре биргән. Алар предпринимательләрнең милли дошманлыкны бик нык үстерергә теләгәнлекләрен күрсәткәннәр. Татарларның үз телләрендә чыккан прокламацияләрне бик яратып каршы алулары комитетка шундый өмет бирә ки, ул листовкаларны бер үк вакытта ике телдә чыгару белән татар эшчеләре арасына аң-белем кертеп кенә калмас, бәлки хәзергә кадәр Казан капиталистлары өчен файдалы булган милли дошманлыкны да тамырыннан какшатыр» [2].

Татар телендә прокламацияләр язуда, тәрҗемә итүдә, таратуда, шулай ук «Искра» газетасының идеяләрен татар эшчеләренә җиткерүдә Хөсәен Ямашев һәм Гафур Коләхметов Казан комитеты җитәкчелегендә актив эшлиләр.

В. И. Ленин тарафыннан оештырылган һәм партиянең III съездын әзерләшкән «Вперед» газетасы ленинчыл «Искра»ның юнәлешен алга сөрә, барлык милләт пролетар массаларын алда торган революцион бәрелешләргә туплый. Ул да, «Искра» кебек үк, Россиянең төрле районнарындагы эшчеләр һәм гомум демократик хәрәкәтне киң яктырта. Бары 18 номер гына чыкса да, ул безнең төбәк турында дистәгә якын материал урнаштыра. Бу хәбәрләрдән РСДРПның Казан комитетының эшчәнлеген, пролетариатның активлыгы үсә баруын күзалларга мөмкин. «Вперед» газетасы 15 нче санында Казан партия оешмасы эшенә кыскача күзәтү урнаштыра. Ул, эшчеләрне революцион көрәшкә туплауда партия оешмасының күпьяклы эш алып баруын әйтеп, аның хезмәт ияләрен интернациональ рухта тәрбияләүгә игътибарны көчәйтүен дә күрсәтеп үтә. «Татарлар арасында эш шактый киң колач ала,— дип яза газета,— барлык листоклар да диярлек татар теленә тәрҗемә ителә. Комитет эшчеләрнең җыелышларын үткәрде» [3].

РСДРПның III съездыннан соң чыга башлаган һәм В. И. Ленин редакцияләгән «Пролетарий» газетасы да барлык милләт эшчеләрен һәм хезмәт ияләрен революцион көрәшкә берләштерүгә, милли мәсьәләгә зур урын бирә. Газета материалларыннан РСДРПның Казан оешмасының беренче революциягә әзерлек чорындагы эшчәнлеге шактый тулы булып күз алдына килеп баса. «Пролетарий» битләрендә без Казан губернасындагы хәрәкәтләр турында 20 ләп хәбәр укый алабыз.

«Пролетарий» газетасы җирле комитетның йогынтысы үсә баруын шатланып яза, татар эшчеләре арасында революцион эшнең көчәюен билгеләп үтә. «Хөкүмәт татар интеллигенциясен котыртырга бик теләр иде. Ләкин социал-демократик комитетның көчле йогынтысы нәтиҗәсендә ул моңа ирешә алмый. Әйтергә кирәк, комитетның бар-

[1] «Пути революции», Казан, 1922 ел, № 2, 18 бит.
[2] «Искра», № 35, 1 март, 1903 ел.
[3] «Вперед» газетасы, 1905, № 15.

лык прокламацияләре диярлек тәрҗемә ителеп, татарлар арасында таратыла. Алар бу прокламацияләрне зур кызыксыну белән укыйлар. Күп кенә эшче татарлар түгәрәкләргә һәм массовый җыелышларга йөри»[1].

1905 елның азагында чыга башлаган легаль большевистик газета «Новая жизнь»да ленинчыл матбугатның революцион традицияләрен дәвам иттерә. Ул үз битләрендә Россиянең төрле өлкәләрендә, шул исәптән Казан губернасында, киң җәелгән революцион хәрәкәтнең данлы елъязмасын бирә. Бу газетада Казан шәһәре эшчеләренең массовый чыгышлары, крестьяннарның көрәшкә кузгалулары турында вакыйгаларның кайнар эзеннән язылган байтак материаллар укырга була.[2]

Ленин идеяләрен пропагандалауда, пролетариатның бурычларын аңлатуда, прогрессив интеллигенция вәкилләрен тәрбияләүдә халык массаларының революцион активлыгын үстерүдә 1905 елның җәендә Я. М. Свердлов җитәкчелегендә РСДРПның Казан комитеты чыгарган «Рабочий» газетасының роле гаять зур була.

1903 елның мартында Ленин «Авыл ярлыларына» дигән популяр брошюра яза. Казан комитеты ул әсәрне кыскача бәян итеп листовка формасында рус һәм татар телләрендә бастырып чыгара. В. И. Ленин китабы эшчеләр партиясенең крестьян ярлыларына пролетариат белән бергә барырга кирәклеге гади дә, мәгънәле дә сүзләр белән аңлатыла. Бу хезмәт — популяр марксистик әдәбиятның гүзәл үрнәге — татар матбугатында басылган ленинианаьың беренче карлыгачы иде. «Социализм өчен көрәш,— дип яза Ленин,— бөек эш, һәм мондый эш өчен бөтен гомереңне бирү дә кызганыч түгел»[3].

Казанга «Пролетарий» газетасы белән бергә В. И. Ленинның, 1905 елның июнь-июлендә язылган «Өч конституция яки дәүләт төзелешенең өч тәртибе» дигән мәкаләсе листовка рәвешендә алына. Ул Х. Ямашев катнашында татарчага «Өч конституция» исеме белән тәрҗемә ителә. Тәрҗемә халыкның үз сөйләм теленә бик якын, аңлаешлы. Листовка:

**«Рассиски социал демократически партия**
**Кушылыгыз бөтен дөньяның пролетариесе»,**

дигән сүзләр белән башлана. Ул гарәп алфавиты белән язылган, шулай укыла:

Өч конституция яки мәмләкәт төзүдәге өч төрле юл:

эшне аңлаган, белгән рабочийлар, социал-демократлар ни телиләр? демократически республика;

иң либераль булган (ягъни хәзерге тормышны үзгәртергә тырышкан буржуалар нәрсә тели? көкеме, куәте чикләнгән нәселдән килгән патшалыкны;

палиция берлә чиновниклар нәрсә телиләр? Нәселдән килгән патшалыкны.

«Өч конституция» турындагы листовка митингларда таратылган[4].

В. И. Ленин хезмәтенең 1905 елда тәрҗемә ителгән варианты белән, хәзергесен чагыштыру өчен, 1956 елда Казанда басылган дүртенче басмага мөрәҗәгать итик.

«Өч конституция яки дәүләт төзелешенең өч тәртибе:

Полиция һәм чиновниклар нәрсә телиләр? — Самодержавиеле монархия;

иң либераль буржуалар (освобожденнечеләр яки конституцион-демократик партия) нәрсә телиләр? — Конституцион монархия;

аңлы эшчеләр (социал-демократлар) нәрсә телиләр? Демократик республика»[5].

Листовканың ахырына эре хәрефләр белән мондый сүзләр язылган:

«Рассиски социал демократически рабочий партиянең «Пролетарий» газетасының изданиесе (нәшире)

РСДРП Казан комитеты тәрҗимә кылып чыгарды».

Күрәсез, В. И. Ленинның «Өч конституция яки дәүләт төзелешенең өч тәртибе» дигән листовкасы татар телендә беренче тапкыр басылып, пролетариатка, интеллигенциягә самодержавие мәнфәгатенең халыкка каршы юнәлгәнлеген аңлата.

---

[1] «Пролетарий» газетасы, 1905, № 15.
[2] «Новая жизнь» газетасы, 1905, № 10, 20, 23, 25.
[3] В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 6 том, 414 бит.
[4] Кара: Х. Хәсәнов. Революционер-большевик Хөсәен Ямашев. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1959, 70—71 битләр.
[5] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 8 том, 561 бит.

Ул вакытта демократик матбугат, прогрессив интеллигенция эшчәнлегенә большевиклар, Ленин тарафыннан «Пролетарий», «Волна», «Вперед», «Эхо» исемнәре белән чыгарылган газеталарның йогынтысы бик зур була.

Большевиклар, бигрәк тә Хөсәен Ямашев тәэсире белән, Гафур Коләхметов, Мөхетдин Корбангалиев кебек демократ әдип-публицистларның катнашында Галиәсгар Камал 1906 елның 1 февралендә «Азат» дигән демократик рухлы газета чыгара башлый. Газета битләрендә марксизм идеясе белән сугарылган публицистик мәкаләләр, партия документлары һәм листовкаларның тәрҗемәләре басыла. Кара реакциянең каты һөҗүменә карамастан, «Азат» газетасында большевиклар партиясенең ленинчыл программасының тәрҗемәсе чыга. «Россия социал-демократларының максатлары» дигән мәкаләдә беренче мәртәбә татар телендә халыкка аңлаешлы итеп большевиклар партиясенең программасы турында сөйләнә.

«Азат» газетасында беренче тапкыр Владимир Ильич Ленин исеме атала, аның Петербургта Паниналың Халык йортында өч мең кеше катнашкан (ә анда катнашучыларның шактый өлеше эшчеләр була) митингта чыгыш ясавы турында хәбәр басыла. В. И. Ленинның чыгышыннан кыскача өзек китерелә, хәбәр газетаның 1906 ел, 19 май санында урнаштырыла. Ә аңа кадәр әлеге митинг турында меньшевикларның «Невская правда» (11 май, 1906 ел), большевикларның «Волна» (11 май, 1906 ел) газеталарында хәбәр ителә, В. И. Ленин речене кыскача эчтәлеге бирелә.

Ленинга чаклы митингта кадетлардан Водовозов, Огородников һәм башка партияләрнең вәкилләре чыгып сөйлиләр. Иң соңгы булып трибунага билгесез Карпов күтәрелә. Бу—Ленин була. Владимир Ильич кадетларның халык исәбенә самодержавие белән килешү политикасын аяусыз фаш итә. «Безнең бурыч, — ди Ленин, — оешкан пролетариатның яңа күтәрелеш вакытында да, котылгысыз булачак кискен көрәштә дә җиңүле революцион армия юлбашчысы ролен үтәвенә ирешү өчен бөтен тырышлыкны кую»[1].

«Азат» газетасы Паниналың Халык йортында булган митинг турында болай дип яза: «Петербургта графиня Паниналың народный домында митинга:

Инде хөрриятләр бер мәртәбә кулга кереп җитсә эшкә бик иҗтиһат белән керешеп, түгелки сәяси хокукларны гына алырга тырышу, хәтта социальный хокукларны да алырга тырышырга кирәк, бу фикерләрне думага кертер өчен һәм думада эшкә салу өчен кешеләо табылыр! дип хадип хәтбәсен тәмам итте.

Мондин соң мөнбәргә Ленин чыгып кыскача гына булса да үткен сүз сөйләп ала, Ленин сүзе буенча «кадетлар» думаны халыкның хокукларын ала торган машиналыгыннан чыгарып теләнчелек машинасына әйләндергән булып чыгалар... Ленин әйтә: «Дума бу рәвештә саилчелек кылса һичбер эш эшли алмас» дип, моннан соң берничә дәкыйклар вакыт тын гына үткәннән соң дума вәкилләреннән трудовой группа партиясеннән чыгып сөйли»[2].

Әнә шулай революцион-демократик газета «Азат» аша пролетариат юлбашчысы В. И. Ленин исеме хәбәр ителә, аның идеяләре пропагандалана.

Г. Тукайның иҗат эше рус һәм татар революцион-демократик матбугатында басылган социализм, марксистик-ленинчыл идеяләр белән танышудан башланган дисәк, ялгышмабыз. Ул Уральскида чакта ук революцион социал-демократлар, эшчеләр белән аралашып яши, илдә барган вакыйгаларны белеп тора, революцион прокламацияләрне, демократик-журналларны укып бара, үзе дә демократик юнәлештәге «Фикер» газетасында эшли, иҗаты белән дә бу басмада актив катнаша.

Революционер А. И. Бахның «Царь-Голод, экономические очерки» исемле революцион рухта язылган гаять политик әһәмиятле китабының Габдулла Тукай тарафыннан тәрҗемә ителүе — аның әдәби эшчәнлегенә югары бәя бирердәй зур факт. Ул Г. Тукай тәрҗемәсендә «Царь-Голод, Яхуд ачлык-падишаһ» дип атала. 1906—1907 елларда «Әлгасрелҗәдит» әдәби-политик журналында «Г. Тукаев» имзасы белән басылган. В. И. Ленин А. И. Бах хезмәтенә югары бәя биргән, аннан үзе дә файдаланган, эшчеләр арасында киң пропагандаларга кирәк дип тапкан[3].

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 10 том, 400 бит.
[2] «Азат», 19 май, 1906 ел, № 51, өченче бит.
[3] Карагыз: Габдулла Тукай. Әсәрләр дүрт томда. 3. Казан, Татарстан китап нәшрияты 1976, Искәрмә һәм аңлатмалар, 394 бит.

Казанда «Владимир Ильич якташ студентлар түгәрәгендә А. И. Бахның «Ачлык падишаһ» брошюрасы буенча беренче рефераты белән иптәшләре алдында чыгыш ясый. Бу брошюраның авторы, марксист булмаса да, К. Маркс «Капитал»ының аерым положениеләрен популяр рәвештә аңлатып бирә, царизмны гына түгел, бәлки капитализмны да бик нык фаш итә, эшчеләр сыйныфының авыр хәлен чагылдыра. Брошюра тормышны үзгәртеп коруга, социалистик хуҗалык итү нигезләрендә социаль стройны үзгәртүгә чакырды» [1].

«Царь-Голод» хезмәтен татарчалаштыручы Г. Тукай Карл Маркснын экономик тәгълиматының нигезләре белән таныш булгандыр, матбугатта пропагандаланган Ленин идеяләрен белгәндер дип әйтәсе килә. Чөнки шунсыз «Ачлык падишаһ»ны татар хезмәт ияләренә үз ана телендә гади, аңлаешлы итеп, халыкчан тәгъбирләрне, экономик билгеләмәләрне дөрес файдаланып тәрҗемә итеп булмас иде кебек.

Бу зур хезмәтне бастырып чыгару Г. Тукайның оста тәрҗемәче, ялкынлы публицист, журналист булуын исбатлый. Әнә шундый революцион, марксист рухтагы әсәрләрне халыкка җиткерү белән шөгыльләнү Г. Тукайның үзенең дә капиталистик стройга, самодержавиегә нәфрәтен көчәйтә. «Ачлык падишаһ»та Г. Тукай тәрҗемәсендә «капиталист белән эшче арасында бер дә өзелмәслек даими көрәш вә тартыш булырга тиеш»[2] диелә. Ул үзенең оригиналь әсәрләрендә дә халык интереслары өчен капитализмга каршы көрәшкә өнди бит. «Әйтергә мөмкин ки, 1905 ел революциясеннән соң татар матбугатында Тукай шикелле иң кыю һәм көчле публицист, татар җәмәгатьчелегенә аерата йогынты ясаган һәм халыкның тирән мәхәббәтен яулап алган икенче бер популяр шагыйрь һәм язучы булмады» [3].

Шул рәвешле, татар матбугатында марксистик-ленинчыл идеяләрне пропагандалап, Г. Тукай әдәбиятка революцион рух бирә, лениниана фундаментын коруга җирлек әзерләшә.

Ленинчыл газеталар йогынтысында, Россиядәге беренче революция хәрәкәтендә актив катнашкан Гафур Коләхметов пролетариат язучысы булып үсә. Ул, Ленин тарафыннан чыгарылган «Искра», «Пролетарий» һәм большевиклар партиясенең башка органнарын актив укып, Казан эшчеләре арасында пропаганда эше алып бара. Партиянең Казан комитеты, Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә марксистик әсәрләрне, ленинчыл рухтагы листовкаларны татарчага тәрҗемә итә. Г. Коләхметов 1906 елны чыккан революцион-демократик матбугатта большевикларның, Ленинның шул еллардагы тактикасын аңлаткан бик күп публицистик мәкаләләр бастыра.

Кара реакция елларында Гафур Коләхметов Ленин тәгълиматы, Максим Горький әсәрләре тәэсирендә «Ике фикер», «Яшь гомер» драмаларын иҗат итә. Аның иҗатында Ленин идеяләренең көче чагыла, пролетариатның җиңелмәс куәте тасвирлана. Г. Коләхметов әсәрләренең, шулай итеп, татар матбугатында, әдәбиятында ленинианага турыдан-туры катнашы бар.

«Революцион вакыйгалар тәэсирендә, бу елларда татар демократик матбугаты туды. 1905 елның 27 ноябрендә Уральскида шушы юнәлештәге беренче газета «Фикер» дөньяга килде. 1906 елның июлендә «Азат халык» газетасы чыга башлады. Шул ук елның җәендә һәм көзендә «Карчыга» һәм «Уклар» журналлары барлыкка килде. Демократик юнәлештә барлыгы 6 газета һәм журнал чыга иде. Демократик матбугат башында социал-демократлар йогынтысында торган милли интеллигенциянең алдынгы вәкилләре (Г. Тукай, Г. Камал, Ш. Мөхәммәдов һ. б.) торды!» [4]. Бу газета-журналлар царизмның, буржуаз җәмгыятьнең чын, кабәхәт йөзен фаш итә, татар халкының рус һәм башка халкылар белән дуслыгын ныгыту өчен көрәшкә өнди.

Казан большевиклары ленинчыл «Пролетарий» газетасыннан бай материал өйрәнә. Аерым алганда, «Пролетарий»ның 1906 ел, 23 ноябрьда чыккан санында В. И. Ленинның «Дәүләт Думасына кемнәрне сайларга?» дигән листовкасы кушымта итеп бирелә. Казанда таратылган бу листовка, Ленин үзе әйткәнчә, өч төп партия— карагруһлар, кадетлар һәм социал-демократлар турында плакат була. Владимир

[1] Казанский университет 1804—1979, очерки истории, издательство Казанского университета, 1979, 88 бит.
[2] Габдулла Тукай. Әсәрләр дүрт томда, 3. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 136 бит.
[3] Г. Халит, Х. Хисматуллин, Б. Гыйззәт. XX йөз башында татар әдәбияты. Очерклар. Казан, Таткнигоиздат, 1954 ел, 138 бит.
[4] Татарстан АССР тарихы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1970, 282 бит.

Ильич анда революцион социал-демократиянең максатларын һәм бурычларын, алпавытлар һәм буржуазия партияләренең сыйнфый асылын ачып сала. Ул халыкны сайлауларда РСДРП кандидатларын яклап тавыш бирергә чакыра.

1907 елның 4 январенда Оренбургта большевистик «Урал» газетасы чыга башлый. Ул ленинчыл «Искра», «Вперед», «Пролетарий», «Новая жизнь» газеталарының революцион традицияләрен дәвам итә.

«Урал» газетасы битләрендә Х. Ямашев публицистикасының төп темалары большевикларның Думадагы тактикасы бурычларын аңлатудан һәм патша хөкүмәте политикасының халыкка каршы характерын фаш итүдән, карагруһчылар һәм эре буржуазия партияләрен тәнкыйтьләүдән гыйбарәт була. «Уң партияләр» дигән мәкаләсендә «Урал» газетасы «Рус халкы союзы»н эшчеләрнең һәм крестьяннарның дошманы дип атый. Х. Ямашев мәкаләләрендә октябристлар, кадетлар партияләре тәнкыйть ителә.

Революцион социал-демократик партиянең максатлары һәм бурычлары белән таныштыру йөзеннән «Урал» газетасы 1907 ел, 10 январь санында В. И. Ленинның «Дәүләт Думасына кемнәрне сайларга?» дигән мәкаләсен тулысынча игълан итә. Мәкаләдә: социал-демократ эшчеләр партиясе—Россиядәге барлык халыкларның аңлы эшчеләре партиясе, ул барлык хезмәт ияләренең интересларын яклый, диелә.

Тәрҗемә стилен һәм телен, Ленин фикерен аңлатып бирү осталыгын күрсәтү өчен берничә мисал китерик. В. И. Ленин хезмәтенең III бүлеге «Төп өч партия нәрсәгә ирешергә тырыша?» дип атала. «Урал»да ул «Бу олугъ өч партиянең һәркайсы нәрсә булдырырга тырышалар?» дип атала. Бу сорауга В. И. Ленинның җавабы түбәндәгечә тәрҗемә ителгән:

«Кара груһлар иске тәртипне һәм халыкны хокуксыз (правасыз) итеп, помещикларның, чиновникларның, полициянең халыкка бөтенләй баш булуын калдырырга тырышалар.

Кадетлар мәмләкәттә башлыкның либераль буржуалар кулына күчүе өчен тырышалар. Монархия, полиция һәм гаскәргә баш булып калып, капиталистларның эшчеләрне һәм авыл халкын таларга хокукларын (праваларын) яклау тиешле.

Социал-демократлар мәмләкәттә бар башлыкның халык кулына күчүе өчен тырышалар. Ирeклек социал-демократларга социализм өчен, хезмәтне капитал золымыннан коткарыр өчен кирәк».

Шуны күрсәтеп үтү кызыклы, В. И. Ленинның бу мәкаләсе аның татар теленә тәрҗемә ителгән һәм большевистик «Урал» газетасында урнаштырылган беренче әсәре була. Шулай итеп, Урал, Идел буе, Баку, Себер, Казагыстан төбәкләрендә, шәһәрләрендә, авылларында таралган «Урал» газетасы Ленин идеяләрен пропагандалауга, татар матбугатында, публицистикасында ленинчыл фундаментын салуга зур өлеш кертә.

КПСС тарихы дәреслегендә бу хакта болай диелә: «Большевиклар татар телендә «Урал» газетасын азербайҗан телендә «Коч-девет» һәм «Текамюль» газеталарын чыгардылар, алар аша Идел буе, Закавказье һәм Урта Азиянең җәберләнгән халык массалары арасында Ленин идеяләрен тараттылар» [1].

1917 ел. Гасырлар буе халыкны изеп килгән патша власте сееберeп ташланды. Февраль революциясе җиңде. Илдә большевистик, демократик матбугат үсеп китү өчен уңай шартлар туды. Казанда Ленин шәкерте, правдачы М. Тихомирнов җитәкчелегендә 1917 елның мартында большевиклар «Рабочий» газетасы чыгара башладылар. Аның икенче санында ук В. И. Ленинның «Ерактан хатлар»ыннан берсе басыла. Анда Россиядәге революцион вакыйгаларга тулы анализ ясала, большевистик тактика аңлатыла. «Рабочий» газетасы, В. И. Ленинның чит илдән Россиягә кайтуын котлап, болай дип яза: «Без үзебезнең идея юлбашчыбызны кайнар тәбриклибез... Иптәш Ленин «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән элекке, данлы лозунгыбызны нык яклады» [2].

---

[1] История КПСС, издание второе, дополненное, М., 1962, 96 бит.
[2] «Рабочий», 1917, № 3.

«Рабочий» газетасы, татарча большевистик матбугат булмаганлыкны исәпкә алып, ленинчыл идеяләр белән сугарылган аерым материалларны татарча бастыра. Бу—пролетар интернационализм, халыклар дуслыгын ныгытуның конкрет һәм матур күренеше.

Ленинчыл матбугатның йогынтысы белән 1917 елның апрель башында күренекле революционер, публицист Шәһит Әхмәдиев җитәкчелегендә «Аваз» газетасы чыга башлый. Аның беренче битенә «Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре! Берләшүдә, көрәшүдә табарсыз үз теләкләрегезне!» дип язылган. Газетага бәя биреп, «Рабочий» газетасы болай ди: «Күп кенә мәкаләләрендә газета татар пролетариатының сыйнфый аңын үстерә һәм, эшче сыйныф карашыннан чыгып, Вакытлы хөкүмәткә, сугышка мөнәсәбәтне ачыклый.

Газета хәзерге татар пролетариатының интересларын яклаучы берләнбер орган булып тора» [1].

«Аваз» газетасы үзенең битләрендә В. И. Ленин әсәрләрен бастыра. Атаклы яла ягучы, провокатор Алексинский 1917 елның 4 июлендә Ленин Германия файдасына шпионлык итә дигән мәкерле хәбәр тарата. Бу ялган хәбәр бульвар тибындагы «Живое слово» дигән газетада басылып чыга. «Правда» газетасы Вакытлы хөкүмәт тарафыннан тар-мар ителгән авыр көннәрдә, политик шантажчыларга, яла ягучыларга җавап итеп В. И. Ленин «Новая жизнь» редакциясенә хат белән мөрәҗәгать итә. Ул хатта мондый юллар бар: «Безнең партия газетасының чыгудан туктатылып торырга мәҗбүр булуы сәбәпле сезнең кунакчыллыкка мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез, иптәшләр. Мәгълүм төрдәге газеталар, шпионлыкта һәм дошман хөкүмәт белән мөнәсәбәтләрдә гаепләп, безгә каршы ярсулы яла ягу алып бардылар.

Бу яла ягуның ни дәрәҗәдә моңарчы күрелмәгән... җиңел уйлау (бу—кулай сүз түгел, бик тә йомшак сүз) белән алып барылуын түбәндәге гади фактлар күрсәтә. «Живое слово» башта, Ленин — шпион, дип басып чыгарды, ә аннары хәлне үзгәртми торган «төзәтмә» сылтавы белән, ул шпионлыкта гаепләнми, дип белдерде!» [2]. В. И. Ленин үзенә, большевикларга усал ният белән ягылган яланы фаш итә. Бу хат «Новая жизнь» газетасының 11 июль, 1917 ел санында басыла.

Буржуаз властьларның Ленин исеменә пычрак аткан, юлбашчы артыннан кабәхәтлеге ягыннан тиңе булмаган эзәрлекләү җәелгән бер чорда урындагы большевистик органнар, «Азат» газетасы үзләренең нәфрәт сүзләрен әйтәләр. «Аваз»ның 20 июль санында «Ленинның вә иптәшләренең мәхтүбе» (хаты) турында белдерү ясала.

Кара реакциянең һөҗүм иткән көннәрендә «Аваз» газетасы Ленин тарафыннан язылган хатның эчтәлеген халыкка җиткерә, ул буржуаз матбугатта басылган материалларның ялган икәнлеген фаш итә. Күргәнебезчә, газета үз ана телендә Ленин идеяләрен яклап, хезмәт ияләрен, прогрессив интеллигенцияне политик яктан тәрбияләүгә бик әһәмиятле өлеш кертә.

Шулай итеп, Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәрге чорда ук революцион-демократик татар матбугатында Ленин исеме атала, аның әсәрләре басыла, аның идеяләренә һәм эшчәнлегенә теләктәшлек күрсәтелә. Бу хәл революцион-демократ язучылар, публицистлар, журналистлар иҗатына уңай йогынты ясый. Аларның әсәрләре самодержавиенең череп таралуын чагылдыра, халыкны якты, бәхетле тормыш өчен көрәшкә өнди. Ленин идеяләре белән сугарылган беренче тәрҗемә листовкалар, революцион-демократик матбугат һәм большевистик «Урал» газетасы татар телендә лениниана булдыру өчен ныклы нигез әзерлиләр.

---

[1] Р. Нуруллина. «Кызыл байрак» газетасы. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 12—13 битләр. «Рабочий», № 12, 1917, 5 май.
[2] В. И. Ленин. ПСС, 34 том, 6 бит.

## Нури Арсланов

### Ярдагы һәйкәл

Миллион еллар буе аккан Идел,
Ә диңгезгә ташып китмәгән.
Яшьләр түгеп, канга баткан илем,
Ничек туфан басып китмәгән?!.

Җир сеңдерә барган туфрагына
Барлык шомны, бәла-казаны;
Бер рәхимле булган улларына,
Бер аяусыз булган — җәзалы.

Яулар килгән монда — илләр янган:
Берәү баскан, берәү таланган,
Кем җиңелсә — шул коллыкка калган,
Кем җиңсә — шул хуҗа саналган.

Бәхет эзләп чыккан һәрбер ирнең
Богауланган аяк-куллары,
Яраларын бу кыйналган җирнең
Юалмаган Идел сулары...

Бөек Ленин туган шул Иделдә,
Шул ярларда үскән — үрләгән,
Күтәргән ул илне киң иңендә...
Андый ирне дөнья күрмәгән!

Бөек якташ тора әнә алда,
Киңлекләрне күздән кичереп.
Әйтерсең лә, агар юлы тарга
Ак дулкыннар килә ишелеп.

Кинәт туа гаҗәп бер горурлык,
Давылларга күңел ашкына!
Акчарлаклар уйный дулкын куып
Юлбашчының аяк астында.

## Әдип Маликов

### Адашырга безгә мөмкин түгел

Һөҗүм беткәч, яңа биеклеккә
Байрак кадый кемдер арадан.
Вакыт артмый махра көйрәтергә,
Кузгаласың алга яңадан.

Алындылар күпме биеклекләр,
Ориентерлар уртак, бер иде:
Азат итү ерткыч тырнагыннан
Хур ителгән туган җиреңне.

Байрак зурлык җиргә тез чүгәргә,
Йөрәк белән аны капларга...
Хуҗа булып һәрбер түмгәгенә,
Киләчәген илнең сакларга!

Җиргә хуҗа, Илгә хуҗа булу —
Гади түгел аның мәгънәсе.
Саклап тора тарих ышанычын
Миллионнарның үле гәүдәсе.

Кызыл байрак! Сиңа ант китердек
Биттә бала йоны чагыннан.
Адашырга безгә мөмкин түгел,
Ориентирлар күптән табылган.

Безнең кулда — Ленин биргән байрак,
Девизы бер аның: «Җиңәргә!»
Подваллардан космос түренәчә —
Дәшеп бара яңа үрләргә!

## Салих Баттал

### Поэма тәрҗемә иткәндә

Өсләремдә — авыр җаваплылык.
Тәрҗемәгә бөгәм билемне —
Иң зур хезмәт критерие булган
«Владимир Ильич Ленин»ны.

Мин имтихан бирәм. Сынау авыр:
Һәр строфам минем — бер дәрес.
Башкарырмын — остаз ярдәм итәр —
Маяковский белән бергә без.

Аның поэмасы белән бердәм
Тормыш үзе кайный якында.
Сизеп торам аны, ул бит минем
Юка гына кәгазь артында —

Ленин идеясе тулы тормыш.
Шуңар ачам сүзләр ишеген.
Һәм ачармын аны тулы итеп
Һәм күренер Ленин! Юк шигем.

## Галимҗан Латыйп

### Байрагыбыз безнең Ильичлы

Малай чагымнан ук әткәемнең
Сүзе кереп калган колакка:
— Озакламый Ильич кайтып килер,
Хәзергә ул, улым, еракта.

Әйтерсең, мин киңәшчесе аның,
Төшендермәк була, аңлата:
— Беләсеңме, ул бит Сембернеке,
Бу якларны белә, ярата.

Ул Октябрь алып килде безгә,
Богауларны өзде, җимерде.
Вакытында сугу кирәк диде,
Суытмагыз кызган тимерне...

Шул көннәрдән алып төшемдә дә,
Өнемдә дә күрәм мин аны.
Кайгырта ул, гел күзәтеп тора
Дөреслеген безнең кыйбланың.

Дәшә Ильич безнең күзгә карап,
Барысын да алдан кисәтә:
Гөнаһлар да, изге гамәлләр дә
Үлчәнелә — төгәл исәптә.

Уйламагыз, кайчан булса бер көн
Кырын эшләр ярлыканыр диеп.
Бу дөньяның киләчәге якты,
Дөреслекнең идеаллары бөек.

Белә дөнья, таный, күреп тора
Ничегрәк киерелгән җәяң?
Сүздә түгел, кылган гамәлеңдә
Синең бөтен бәяң.

Эшең, көчең шатлык, кайгыларың
Булса әгәр бергә халкың белән.
Язачаклар исемеңне синең
Калканыңа уеп, алтын белән.

Ильич чәчкән кырлар уңдырышлы,
Бакчалары аның җимешле.
Байрагыбыз безнең җилфер-җилфер,
Байрагыбыз безнең Ильичлы.

## Шамил Маннапов

### Чигенү юк

Мәскәү янындагы мәгърур урман
Хәтеремдә шаулый әле дә ник?
Хыялымда һаман солдат булып
Кабат кайтам шунда әйләнеп.

Постта торган урыннарга кайтам,
Дорохово, Можай шоссесы:
Очрый анда үлән арасында
Чәрдәкләнгән фашист каскасы.

Панфиловчы батыр якташларның
Карап йөрим окоп эзләрен.
Алар әле дә шунда ята кебек
Көнбатышка борып йөзләрен.

Политрук Клочковның тавышы
Ишетелә сыман колакка:
«Рәсәй зур да, артыбызда — Мәскәү,
Чигенергә урын юк башка!»

Һәр нәрсәнең чиге булган кебек
Чигенүнең дә була бер чиге.
Артта Мәскәү булса, чигенү юк! —
Бу хакыйкать — Ленин хакыйкате,
Шушы безнең тормыш принцибы.

...Күп гасырлар башын күтәралмый
Газапланган михнәт эчендә
Җир уллары бүген безгә карап,
Шул хакыйкать серенә төшенә.

Үз өлешен даулый — бирмәсәләр,
Тартып ала барыбер ул аны.
Хезмәт кешесе — Җирнең чын хуҗасы
Үз кулына ала дөньяны.

...Бер-береңә юл куешу диган
Зур төшенчә бар ул барын да,
Дөреслекне яклаганда тиеш
Тугры сүзең ташны ярырга.

Һәр өлкәдә шулай: җәмгыятьтә,
Мәхәббәттә, эштә, дуслыкта.
Хакыйкатьтә чигенү була алмый —
Шундый закон безнең тормышта.

Бу хакыйкать безгә бик күптәннән
Мирас булып калган Лениннан.
Шушы хакыйкатьне кояш итеп,
Без барабыз җиңү юлыннан...

...Шаулап торган Мәскәү урманнары
Хәтеремнән чыкмый әллә ник.
Хыялымда һаман солдат булып,
Кабат кайтам аңа әйләнеп.

Кабат кайтам — әнкәм киңәшедәй
Тормыш хакыйкатен тыңларга.
Артка юл юк — юл тик алга гына
Йөрәкләрдә Ленин булганга.

## Мизхәт Хәбибуллин

### Яктыра кешелек таңнары

Торган саен яктыра дип
Кешелекнең таңнары —
Гаҗәпләнмим. Нурлар өсти
Аңа Ленин томнары.

Ireккә, зәңгәр киңлеккә
Омтылганга юллары,
Ленинча көрәш сафына
Баса дөнья уллары.

Ярсытып хак теләкләрне,
Сугыла мәгърур чаңнар.
Һәм дөнья атлый Ленинга —
Яктыра бара таңнар.

**Гариф Галиев**

# БЕЗ СИКЕРТКӘН ШОБАГАЛАР



Безнең малай чакларыбыз бик тынычсыз заманга, бик шау-шулы, ыгы-зыгылы чорга туры килде. Язмыш безгә бигүк рәхимле түгел иде, сез бәләкәйрәк әле дип, аркаларыбыздан сыйпап тормады, авыр тормыш эченә туп-туры кертеп җибәрде. Ягъни дөнья куу өчен муеннарыбызга калын камыт кидерде дә, «тартыгыз инде, авыр булса да тартыгыз, тизрәк чын ир булыгыз, чын хуҗа булыгыз, бөтен терәк сездә» дигән шикелле катгый әмер бирде.

Язмышның бу кискенлеге бик табигый иде. Чөнки безнең бөтенебезнең дә әтиләребез, ә кайберләребезнең абыйлары 1914 елгы каһәр суккан герман сугышына киткәннәр, шунда һәлак булганнар. Ул чакта ил өстен кара болыт каплаган, кая карама анда ачлык-ялангачлык, бөлгенлек хөкем сөрә иде. Шунлыктан без әле егет булып җитмәгән булсак та, ике аягыбыз белән нык итеп җиргә бастык, ялына тотынып булса да атка атландык. Тора-бара бу атларны кирәк чакта, башкаларның ярдәмен көтмичә, үзебез җигә, үзебез туара торган булдык. Кулыбызга чүкеч тотып кирәк урынга кадак кактык, шпиль суктык. Балта тотып утын кистек, утын ярдык, яргычка да, тегермәнгә дә без, малайлар, үзебез барып арбадагы капчык-капчык игенне күтәреп йөртергә гадәтләндек. Өстебезгә төшкән бу авырлыкларны күреп олылар кайчакларда бик борчылалар һәм үзара «бу балакайларга бигрәк михнәтле заман туры килде шул» дип безне кызганалар да иде. Әмма коры кызгану белән генә калмыйлар, авыр бүрәнәләрне арбага яки чанага ничек җиңел итеп салырга, чокыр-чакырлы, сикәлтәле юллардан ничек итеп бәла-казасыз үтәргә өйрәтәләр. Нинди агачтан, ничек итеп арба тәртәсе бөгәргә, чана тәртәсе каерырга кирәклекне үзләре эшләп күрсәтәләр. Атны чыбыркы белән түгел, ә солы белән куарга киңәш бирәләр иде.

Без, малайлар, өлкәннәрнең шулай бик якын итүләренә шатлана һәм алар өйрәткәнчә эшләргә тырыша идек. Тик менә аларның безне кайчакларда кызганып куюларына риза түгел идек. Чөнки кызганыч буласыбыз килми иде. Ә менә шул елларда герман сугышыннан сыңар кул белән кайткан Абдулла абый безгә башкачарак карый кебек тоела иде. Безне өлкәннәр барысы да яраткан кебек, Абдулла

абый да якын күрә, хәтта артыгы белән якын итә-ярата иде. Ләкин әлеге кызгану дигәнен сиздерми. Безгә гел батырлык, үткенлек, өлгерлек, сер саклау турында сөйли. Аның һәр сүзе җир-суга, урманнарга, әрәмәлекләргә, тау-ташларга бәйле була һәм беренче карашка тиз генә аңлый алмаслык сәер нәтиҗәләр китереп чыгара иде. Ләкин шул көзне булган бер вакыйгадан соң без аның сөйләгәннәрен нишләптер бик җиңел аңлый башладык.

Моңа кадәр гаскәр күрмәгән безнең авылны бер көнне арбаларга төялгән, иярле атларга атланган ак чехлар басты. Авылга керү белән үк алар мунчалар яктырдылар, тавыклар суйдырдылар, өсбашларын юдырттылар. Үзләре, лапасларга кереп, көн караңгылана башлаганчы пулеметларын сүтеп ашыга-ашыга тазартты, шомпол дигән тимер чыбык белән мылтык көпшәләрен чистартты, атларын кыргычлады, арба тәгәрмәчләрен майлады. Аннары инде мунча керергә төрлесе төрле йортка таралырга торганда гына, урам буйлап кинәт атка атланган бер офицер кычкыра-кычкыра чабып үтте:

— Атларга атланырга. Арбаларга төялергә!

Солдатлар арасында курку, каушау башланды. Алар ашыгаашыга өс-башларын кияргә, абына-сөртенә әйберләр җыйнарга тотынды. Берсе монда, берсе тегендә таралып яткан пулеметларны, мылтыкларны ничек туры килсә шулай арбаларга төяп, тизрәк авылдан ычкыну ягын карадылар.

Яккан мунчалар да, казанга салган тавыклар да, кайнаган самаварлар да аларга булмый калды. Кыскасы, аклар инде кирәкмәс тавыш-гауга куптарып, арбаларны бер-берсенә ордыра-ордыра, көч-хәл белән авылдан чыгып чаптылар.

Мәгълүм ки, мондый, ата улны, ана кызны белмәслек дәрәҗәдә буталган чакта, арбалардан капчык-капчык азык-төлекләр һәм төрле әйберләр дә төшеп кала. Аклар качканда да шундый хәл булды. Әле анда, әле монда капчык-капчык шикәр, һәртөрле корал сыман нәрсәләр аунап ята, хәтта кайберсенең нәрсә икәнен тиз генә белеп тә булмый иде. Аклар үткән юлдан без тапкан сары футляр нәкъ шундый әйберләрнең берсе иде. Юл буенда бер чокырда төшеп калган бу өр-яңа һәм бик пөхтә футляр безне бик кызыксындырды. Без, малайлар, аны шунда ук кулга алып, җентекләп карый башладык. Аның эчендә ике пыяла күзле бер нәрсә ята иде. Бөтен әйберләрне якынайтып күрсәтә торган бер хикмәтле нәмәстә һәм аның бинокль дип аталганын кайчандыр ишеткәнебез бар иде. Бу менә шул бинокль булып чыкты.

Бинокль бер өзлексез кулдан-кулга күчә. Әй кызык та, әй күңелле дә соң безгә!

Аннары төрле бәлаләргә дучар булмас өчен бинокльне чиратка куйдык. Аны саклауны беркайчан да каушап-куркып калмый торган, сабыр холыклы, белсә дә белмәмешкә салышып йөри торган Миңлехан исемле малайга тапшырдык.

Күпмедер вакыт үткәч, арабыздан Гәбдерәхим исемле малай,— ул яшькә дә бездән зуррак һәм кыюлык ягыннан да бездән күп алда иде,— әлеге бинокльне бишмәт эченә яшереп, безне мәчет манарасына алып менде.

Манарага менеп җитү белән кисәтеп әйтте:

— Берегез дә манара араталарына башын тыкмасын, чүгәләп кенә торыгыз!

Ул, үзе дә шунда чүгәләп, пәке белән манара тактасын тиште һәм әлеге бинокльдән тирә-якны карый башлады. Ә үзе: «Һәй, моннан әллә кайдагы, бик еректагы җирләр күренә икән», дип сөйләнеп ала.

Бинокльнең ике трубкасы уртасындагы шөрепне бора-бора һаман күзәтүен дәвам итә. Сирәк-мирәк безгә дәшә:

— Малайлар, менә Сафун боярының урманы! Әнә, әнә, безне җиләк җыйганда бер кисендектән куып чыгарганнар иде бит, әнә, шул кисендек гел алдыма килеп басты, валлаһи!.. Әнә, әнә, билләһи, шул кисендек. Мәгез әле, сез дә карагыз! — дип бинокльне безгә суза.

Бинокльне иң элек Рахмай ала һәм ул да безгә дәшә:

— Малайлар, малайлар, менә Метри бояры җирләре! Менә Кәримулла хаҗи урманы! Менә Ибәт имәнлеге. Менә Гатаулла бай усаклыгы. Шул арада аңа Мөхәммәтша исемле дустыбыз сорау бирә:

— Рахмай, Рахмай... ә үзегезнең җир күренәме?

Рахмай, бинокльдән аерылмыйча гына бик кимсенгән һәм юаш тавыш белән:

— Безнең әти гомер буе уртакка чәчте бит. Үз җиребез булмагач, ничек күрим мин аны. Мә,— ди аңа бинокльне сузып, — син күр үзегезнең җирегезне!

Мөхәммәтша теләр-теләмәс кенә:

— Бәй, безнең дә җиребез бер түтәрәм тары чәчәрлек кенә икән бит,— ди.

Шулай булса да, ул, бинокльне алып, күзләре белән бөтен тирәюньне айкап чыга:

— Ай-яй, шәп нәрсә икән бу нәмәстә! Җирләр, урманнарны гына түгел, еракгагы җәяүле кешеләрне дә күрсәтә. Әнә Абдулла абый каяндыр кайтып килә. Әнә, атын басу капкасы янында чирәмдә калдырып, үзе болай таба атлый.

Мөхәммәтша шулай дип әйтү белән Габдерәхим безгә карап:

— Әйдәгез, малайлар, моннан төшик тә, Абдулла абый каршына барыйк. Барыйк та, безнең әтиләребез ни өчен җирсез дип сорыйк.

Без аның сүзләрен күтәреп алабыз һәм бер-беребезгә:

— Әйдәгез, әйдәгез! Киттек!

Габдерәхим, бишмәт куенына яшергән бинокльне капшап карыйкарый:

— Шауламагыз, малайлар! Аска төшү белән мәчет артындагы коймага таба берәм-берәм атлагыз! Анда койманың тактасы купкан бер урын бар, шуннан чыгып ычкынырбыз да тыкрыкка таба таярбыз. Абдулла абый үз өенә шуннан кайта ул, — ди.

Без Абдулла абыйдан аз гына да шүрләми, аңардан бер нәрсә дә яшерми идек. Хәер, без яшерсәк-яшермәсәк тә, ул барыбер безнең бинокль тапканыбызны да әллә кайчан ук белгән, мәчет манарасына менеп шул бинокльдән карап торганыбызны да сизгән икән.

Шуңа күрәдер инде, тыкрыка кайтып җитү белән ул үзе сүз башлады:

— Һа-а, минем дусларым! Я, сөйләгез, бинокльдән ниләр күрдегез?

Без бер-бер артлы сөйли башладык:

— Сафун урманнарын!

— Алпавыт Кәримулла җирләрен!

— Бояр Докшин җирләрен!

— Ибәт имәнлекләрен!

Абдулла абый безнең шау-шуларыбызны бик игътибар белән тыңлап торды да:

— Ә үзегезнең җирләрегезне күрдегезме?— диде.

— Юк!— дидек без, аптырабрак калып.

— Булмагач...— дип тотлыгып торды да Габдерәхим сүзен дәвам итте: — Юк әйберне ничек күрәсең инде аны...

2*

— Ә нишләп сезнең әтиләрегезнең җирләре булмаган? — Абдулла абыйның карашы сораулы иде.

— Без үзебез дә синнән нәкъ шул турыда сорашмакчы идек.— Аның янынарак килеп бастык.

— Патша заманында җирнең күбесе һәм иң яхшысы алпавытлар, боярлар кулында булган,— дип сөйли башлады Абдулла абый. Ул җир өчен барган көрәшләр, Пугачев яулары һәм ул яуларның безнең шушы тирәдән үтүләре турында бик тәфсилләп сөйләде һәм кинәт безгә карап:

— Ә сез Чатыр тавын беләсезме?— диде.

— Белмиме соң, беләбез, беләбез!

Арадан кемдер:

— Минем анда әллә ничә тапкыр булганым да бар,— дип өстәде.

— Бинокльдән дә күренә бит ул. Мин бүген үзем күрдем аны,— диде икенче малай.

Абдулла абый:

— Чатыр тавында әнә шул Пугачев явы ялга тукталган, — дип, баягы сүзләрен ялгап китте.

Ул вакыйгаларны бик аңлатып, бик әзлекле итеп сөйләде. Без аны авыз ачып тыңладык.

Ул шулай сөйләде-сөйләде дә, әчке бер куаныч белән:

— Хәзер инде сез беркайчан да Сафун урманнары, алпавыт Кәримулла җирләре, Метри бояры басулары дип сөйләмәгез. Алар барысы да бетте!

Без гаҗәпләнеп:

— Ничек?— дидек.

— Хәзер җиргә дә, урманнарга да алар хуҗа түгел.

— Ә кем хуҗа?

— Бүгеннән башлап бөтен җиргә, бөтен урманнарга без, сез, сезнең әтиләрегез хуҗа. Мин менә волостьтан кайтып киләм... Җир турында декрет чыккан. Ул декретны Ленин чыгарган. Үзе кул куйган... Сезнең Ленин турында ишеткәнегез бармы?

Без бер-беребезнең сүзен бүлә-бүлә:

— Бар, бар!— дидек.

— Аны бит ярлылар яклы кеше диләр.

Арабыздан беребез:

— Ленинны беләбез. Ә декреты нәрсә соң аның?— дип сорады.

Абдулла абый бу юлы үзе дә аптырабрак калды:

— Декретмы... Декрет ул декрет инде... Безгә җир бирү дигән сүз. Анда алпавытлар, боярлар кулындагы бөтен җирләрне, урманнарны крестьяннарга бирергә диелгән. Декрет ул җирсезләрне җирле итү дигән сүз. Аның исеме «Җир турында декрет» дип аталган бит... Менә шулай. Тагын нәрсә дим...— Ул бераз уйланып торды. Аннан: — Иртәгә безнең авылга шуны аңлатырга волостьтан кеше килә. Халыкны җыеп, шул декретны укыячак. Җыенга сез дә килегез.

— Киләбез, киләбез!— дип куаныштык без.

Аннары Абдулла абый да өенә кайтып китте, без дә таралыштык.

Икенче көнне таякка таянган бер абый капка саен туктап:

— Пожар сарае алдына җыенга барыгыз, җыенга! Волостной писер килгән! — дип кычкырып үтте.

Көндезге аш вакытында пожар сарае алдын халык каплап алган иде инде. Анда зур өстәл һәм урындык куелган. Урындык янында муенына аш тәлинкәсе хәтле түгәрәк калай таккан староста басып тора.

Озак та үтмәде, аның янында култыгына нindидер калын катыргы кыстырган җирән сакаллы бер ят кеше күренде. Бу волостьтан килгән Василий булып чыкты. Ул шунда ук урындыкка басып өстәлгә менде һәм русча берничә сүз әйтте, әлеге катыргы эченнән кечкенә генә бер сары кәгазь алып укый башлады. Аны һәркем йотлыгып тыңлады.

Халык арасында:

— Ленин чыгарган декрет, шул, шул!

— Җирне крестьяннарга бирергә дигән!— дип, үзара сөйләшкәләп тә алдылар.

Декретны уку озакка сузылмады. Мәгәр халык тиз генә таралмады. Декретта язылганнарны Абдулла абыйның татарча сөйләп бирүен кирәк таптылар. Аякларына озын куныччлы калын тула оек белән киң башлы чабата, өстенә берничә ямау салынган кыска бишмәт, биленә кысып кызгылт билбау бәйләгән, ачык чырайлы, беркадәр серлерәк карашлы бу абыйны бөтен авыл үз итә иде. Менә халык аны урап алды.

— Я, Габдулла туган, әйдә, мен өстәл өстенә, башла!— дигән тавышлар ишетелде.

Абдулла абый, өстәлгә менгәч, якаларын ычкындырды, билбавын бушатыбрак куйды, шул вакыт аңа волостьтан килгән кеше әлеге сары кәгазьне — декретны сузды. Абдулла абый анда язылганнарны бик тәфсилләп халыкка аңлатып бирде. Халык шау-гөж килде. Өстәл өстеннән төшүенә аны бөтенләй сырып алдылар:

— Болай булгач, Габдулла туган, булды бу — җир безнеке! Безнеке, безнеке!

— Җәмәгать, җирне кайчан өләшәбез!— дигән тавышлар яңгырады.

Өлкәннәр белән үзара киңәшләшкәннән соң, ягъни шактый вакыт сүз алышкач, көннәрнең суытуын, тиздән кар явып кыш башланачагын искә алып, җир өләшүне язга калдырырга булдылар. Ләкин җыен таралмады. Кешеләр һаман таптанып торган хәлдә үзара сүз алып бардылар. Күп тә үтмәде, берәү кинәт өстәлгә сикереп менеп, бик кискен итеп халыкка кычкырды:

— Җәмәгать, булган булган, булсын инде, старостаны да алыштырыйк.

— Дөрес, дөрес,— дип, аның сүзен якладылар.

— Кемне куябыз, кемне?

Халык арасыннан ишетелгән бу сорауга шул ук халык үзе бертавыштан җавап бирде:

— Габдулланы, Габдулланы!

Бу турыда киңәш-табыш итүнең кирәге дә юк кебек тоелды. Халыкның фикере әллә кайчан тупланып куелган икән инде.

Өстәл янына элекке старостаны китереп бастырдылар. Аның муенындагы түгәрәк калайны алып ыргыттылар да:

— Чыгар түгәрәк печатьне!— дип, кискен тавыш белән әмер бирделәр.

Староста, куркуга калып, җилән кесәсеннән авызы урый-урый бәйләнгән озын киндер янчык чыгарды.

Бөтен халык бер тавыштан:

— Ал печатьне, Габдулла! Бүгеннән башлап авылга син хуҗа,— диде.

Инде караңгы төшә башлаган иде. Җыен тәмам булды, халык әкренләп таралды.

Ул кичне кучкарлардагы «сукыр» лампалар да, асылмалы бишле лампалар да озак яндылар. Җыеннан кайтып, кичке аштан соң да кешеләр Җир турындагы бу зур хәбәрне үзләренең гаиләләренә

сөйләделәр. Эшчеләр белән крестьяннарны кайгыртучы Ленин дигән бик башлы кеше барлыгын һәм декретны шул Ленин чыгарганлыгын кат-кат телгә алдылар. Иң ахырдан алдагы язда авылның җир өләшергә чыгачагын да әйттеләр.

Ниһаять, җир өләшер чаклар җитте.

Безнең авылда Абдулла абый кебек ундүртенче елгы сугышта яраланып кайткан тагын бер кеше бар иде. Олылар аны Ильяс Дәүләтшасы дип йөртәләр иде. Ә без, малайлар, аңа Дәүләтша абый дип дәшәбез. Ул да, Абдулла абый кебек, безне якын күрә, нәрсәсе беләндер үзенә тарта. Өстәвенә ул авылыбызда «ике каләмле» бердәнбер кеше иде. Ягъни татарча да яза, русча да сукалый, номерлар суга белә, таракан йөргән кебек булса да адреслар да яза, тагын шундый вак-төяк язу-сызуларны үзенә күрә оста сырлый.

Абдулла абый җир өләшү өчен хуҗалыкларның исемлеген төзү, басу кенәгәләре булдыру, шобагалар ясауны шушы Дәүләтша абыйга йөкләде, безгә бу эшләрдә аңа булышырга кушты. Безнең арада да язу-сызуны аз-маз тырмый торган өч-дүрт малай бар иде.

Без бу эшләрне өч-дүрт көндә тәмам иттек. Җир өләшүнең көне билгеләнмәгән иде. Халык моның өчен җомга көнне кулай күрде. Шул көнне бөтен авыл басу капкасына таба юнәлде. Нәкъ шул вакыт еракларадан яңгыр болытлары кабарып чыкты, сирәк-мирәк кенә кабатланып торган туп тавышларын хәтерләтеп берничә тапкыр күк күкрәп алды, яшен яшьнәде һәм эре-эре тамчылар төшкәли башлады. Кешеләр, чыланудан сакланып, басу читәннәренә, карт өянке төпләренә ышыкландылар һәм тынып калдылар. Шунда җылы яңгыр сибәләп үтте. Җир үзенең күкрәгендәге кешеләрне кырга дәшкән кебек булды:

— Кузгалабыз! Кузгалабыз!

Халык яңадан басу капкасы янына җыелды. Иң элек һәм иң алдан кулларына сажен токткан кешеләр, алар артыннан шобага тутырылган эшләпә һәм җир кенәгәләрен кулга нык кысып без кузгалдык. Безнең арттан халык төркеме, ә халык төркеме артыннан тамгалы имән чөйләр, чәй кайнату өчен чиләкләр, таганнар һәм ашамлык төйнәгән кызыл ашъяулыклар белән тулган арбалар кузгалды.

Халык төркеме Куышлы басуы дип йөртелгән җиргә аяк басу белән туктап калды һәм өлкәннәрдән берәү:

— Җәмәгать, башлыйбыз!— дип кычкырды.

Шобага тутырылган эшләпәне тотып йөртүне дә, шобага сикертүне дә һәм аны кычкырып укуны да борынгыдан килгән гадәт буенча алдан ук безгә, малайларга, тапшырганнар иде. Әлеге өлкән агай безнең якка күз сирпеп алды да мөмкин кадәр көчле тавыш белән тагы кычкырды:

— Малайлар, сикертегез шобаганы!

Халык бу сүзләрне күтәреп алды һәм бердәм кабатлады:

— Сикертегез шобаганы, малайлар!

Бөек Ленинның безнең якларга килеп җиткән Декреты кечкенә генә саргылт кәгазьгә басылган кебек, безнең әтиләребезнең исемнәре дә шундый ук сары шобагаларга язылган. Озынча итеп бөтерелгән шул кечкенә шобага кәгазьләре эчендә безнең зур өлешләребез ята иде. Әйе, бу шобагалар гасырлар буе көтелгән, чын мәгънәсе белән безнең шобагалар, безнең өлешләребез иде. Шуңа күрәдер дә, без киң читле, зур гына ак эшләпәгә салган шул шобагаларны сикертә-сикертә, җиргә каты баса-баса зур адымнар белән атлап басу түренә таба менеп киттек.

## Сергей Смирнов,

рус шагыйре

### Апрель

●

Җир яңадан сабан эшен көтә.
Агымнарның кыю, тиз эшләре.
Кар көртләре салкын якка чигенә... —
Шулай куша апрель тезислары.

●

Бар шундый бер кеше —
бар шундый туган көн,
Әйтерсең, ул —
бөтен табигать бәйрәме —
Кояшлы зур көчтән
нәкъ менә шул чакта
Кар һәм боз юк була
агымга әйләнеп.
Бар шундый бер кеше —
Планета, синеке!
Синдәге богауны
һәркайда өзә ул.
Кем яклый яктыны,
кем эштә тир түгә,
Шуларга кул биреп
илләрне гизә ул.

Бар шундый бер кеше
йөрәккә күз сала,
һәммәбез без аның
туганы, җирдәше.
Без бергә йөрибез
күкләрдә, суларда
Киләчәк көннәргә
өндәүле эндәшеп.
Бар шундый бер кеше —
яктының яктысы!
Үткен ул, кыю ул,
гадел ул, зирәк ул.
Һәр кеше
һәм горур,
һәм камил булсынга
Ул — җирдә мәңгелек,
мәңгегә кирәк ул.

## Далантайн Тарва,

монгол шагыйре

### Бөек кеше

Ишетәбез якын исем — Ленин!
Иксез-чиксез далаише ул.
Дөньядан да киң ул!
Галәм диеп
аталырга лаек кеше ул.

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре.

## Андрей Вознесенский,

рус шагыйре

### «Лонжюмо» поэмасыннан өзек

Инде үсеп олыгайгач, кул селтәп ыгы-зыгыга,
Гүя рентген бүлмәсенә — керәбез без Мавзолейга,
Калдырып бүрекне, онытып гайбәт, әкият, күз буяуны — барсын...
Беләбез Ленинның рентгендай үтәли безне яктыртасын.
Караңгыдан киләбез, тынлыкта кыштырдавыдай киноленталарның:
«Әйтегезче, Ленин... без соң — сез көткән кешеләрме, Ленин?»
«Әйтегез, Ленин, нидә безнең җиңүләребез, булса — ялгыш, нидә?
Ваклыклардан җуелмадымы әле олы чынлык бездә?!
Була кыенлыклар... Әмма, Кояш кебек һәрчак
Балкып, юл күрсәтә безгә сезнең йөз — иң якты чыраг!»
«Әйтегез, Ленин, без соң тап төшермәдекме сезнең идеягә?»
Һәм Ленин аңлата безгә...

Барлык сорауларга да Ленин җавап бирә!

**Рәдиф Гатауллин тәрҗемәсе.**

## Михаил Львов,

рус шагыйре

### Бөек якташ

Ленинны эшче Казан
Гел үзенә караткан:
Казанда булган Ленин,
Казанда торган Ленин,
Казанны бик яраткан.

Күңеле булган ачык,
Халык белән киңәшкән,
Рус туганы янында
Татар белән сөйләшкән.

Чиркәүгә өндәмәгән,
Кушмаган баш ияргә;

Ярсынган җаны белән
Богауларны өзәргә.

Заманага төшенгән
Казан буйлап йөргәндә,
Эшен дәвам итәргә
Яшьлек антын биргәндә.

Ленинның карашында,
Кыса төшкән күзендә,
Ачык, якты йөзендә
Охшашлык бар безнең дә.

Кичерәм зур горурлык,
Бәхет балкый аңымда:
Ленин белән якташ мин
Кадерле Казанымда!

Сембердә туып үскән,
Якташ ул сембердегә,
Шушенскийда чактан
Якташ ул себерлегә.

Иделнең дә якташы,
Идел белән дус булган;
Париж халкы ярата,
Ул анда да күп торган.

Якташ ул һәр кешегә,
Ул Җир шарында туган!
Ленин белән яшим мин,
Ул яшәгән дөньяда —
Йөзе алтын нур сибә
Зөһрә йолдызында да!

Әйе, ул җир якташы,
Кешесе җир йөзенең,
Әмма галәмгә җитте
Даһилыгы үзенең!

Галәмгә, биеклеккә
Җитте даны күрәштә.
Ә мин җирдә үз итеп
Йөртәм аны йөрәктә.

**Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе.**

## БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 35 ЕЛЛЫГЫНА

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# УТ ЧӘЧӘГЕ

ПОВЕСТЬ

I



Чү! Кояшлы рәшә, еракта тугай артында ук сузылып яткан зәңгәрсу тау бите, үлән исе, тыгыз җил, сез кинәт кенә күңелне кузгаттыгыз. Тукта, исмә, җил, син, болын, җир исе алып киләсең дә, тын юлларын кытыклыйсың, хәтерне тирәнәйтәсең, элеккеге кадерле минутларны, йөрәк җәрәхәтен яңартасың... Ул вакытта ничек дип җырлыйлар иде әле?

Минем ямансы көннәрем,
Сайрама, кош, исмә, җил...

Кайда сез, ул кызлар? Кайда сез, ул егетләр?

Фельдшер-акушерлык мәктәбе кызлары үзләренең күршеләрен — педучилище һәм урта мәктәп егетләрен чыгарыш кичәсенә чакырганнар иде. Училищеның тулай торагында урта мәктәптән дә унлап егет яши иде. Егетләрнең күбесе кичәгә барудан баш тартты: кайсының костюмы юк, кайсының ботинкасы адәм рәтле түгел иде. ФАШ кызлары, нинди чыганаклары бардыр, мөмкин булганча затлы киенәләр үзләре. Ташлытау шәһәрчегендә зона «мода»сын шулар алып бара, шулар тота иде. Тулай торакта кечке якта барган зур бәхәстән соң алты-җиде егет — училищены яки урта мәктәпне тәмамлап, әлегә мендәр-матрацларын тапшырмыйча, аттестат алуны көтеп йөргән унсигез яшьлек егетләр, шулай да, кызлар чакырган җиргә барасы иттеләр. Кичке җиделәр тулып китсә дә, әле кояш җылыта, «кичәгә бару» дигәне караңгы төшкәч кенә була дип ышанып яшәгәнгә күрә, ашыгучы күренмәде, егетләр җай белән генә көзге чыгарып, вак-төяк сакал-мыек бөртекләрен йолыккаладылар, әлегә кадәр аларның берсендә дә бритва юк иде, алай гына да түгел, «бритва» сүзен кулланучы, әйтә белүче дә юк иде, «чәч пәкесе» яки «пелитуа» дип кенә телгә алгалаучылар бар иде. Егетләр сары фанер чемоданнарының тар авызын ачып аннан чиста күлмәкләрен чыгардылар, «Тройной», «Караново», «Жасмин» кебек одеколоннар белән муеннарын, битләрен хушландырып алдылар.

Алар килеп кергәндә, кичә башланган гына түгел, тантаналы өлеше тәмамланган һәм художество өлешенә күчкәннәр икән. Анда-санда

буш калган урындыклар табып, караңгы залда таралышып урнаштылар. Сәхнә алдын яшькелт-зәңгәр марля белән каплап рампадан эчкә нур көлтәләре юнәлткәннәр. Сәхнә артыннан икеме-өчме баянда уйныйлар һәм музыка көенә салмак хәрәкәтләр белән бер төркем кыз бии иде.

Асаф кешеләрнең тез башларына бәрелә-бәрелә эчкә узып, буш калган шыгырдавык терәкле бер урындыкка утырды һәм шуннан соң гына сәхнәгә күз салды. Сәхнәдә моңарчы ул күрмәгән гүзәллек иде. Беркадәр вакыт үткәч ул сәхнә артыннан залга агылган моңны да тотып алды: Пушкинның «Кышкы кич» шигыренә язылган көй икән. Моны җыр дәресендә өйрәткәннәр иде, бу музыкага кушылып җырлыйсы килә иде.

Буря мглою небо кроет...

Әмма кышкы кичне музыка гына искә төшерә иде. ФАШ студенткалары анда су кызлары булып биләр икән.

Монда икенче дөнья, тормышка, матурлыкка бөтенләй икенче төрле мөнәсәбәт иде. Асаф үзенең яңакларын учлары белән каплап уйга чумды. Өч ел буе ул үз авылларына кайтып, лесник булып эшләү турында хыялланды. Аның дус егетләре укыган педучилищеда тәртип-әдәп кагыйдәләре бик каты куелган иде, кызлар бик кырыс, инде беренче курстан ук иреннәрен кысып әдәп-әхлак нормаларын катгый саклауны үзләренә бер норма иткәннәр, шуның белән горурланалар, төзек җөмләләр белән дөрес итеп кенә сөйләшәләр, кул сузып үрелгәләгәнне бер дә гафу итмиләр (ә үрелгәләсе килә), ике мәгънәлерәк итеп сөйләшкәнне дә класс җыелышына кадәр күтәреп чыккалыйлар иде. Матурлыкка, хискә, ашкынуларга омтылган күңел исә үзенә юл эзли, тыпырчына, дулый иде һәм дулап арыгач туган авылына, болын-урманнарына алып кайтып китә иде. Ә монда? Гаҗәеп дөнья, бөтенләй икенче дөнья...

Музыка яшькелт марля артындагы сәхнәгә сыя алмыйча, залга ургылып чыга, кемнәрдер, ниндидер ысуллар белән электр нурын дулкынландыралар һәм сәхнәгә су төбе рәвешен бирәләр. Ә кызлар түгәрәкләнеп басканнар да салмак кына чайкалып биләр. Алар озын чәч толымнарын җилкәләренә таратканнар, тез башларына төшеп җитмәгән яшькелт-зәңгәр төстә бик юка ефәк күлмәкләре итәктән чачаклаnып ертылган һәм таралып, бөтерелеп кызларның йомры шома аяклары тирәсендә шуып әйләнә. Кайвакытта алар куллары белән тотышып башларын артка ташлап иеләләр, аларның ялангач беләкләре яшел нурда уйнап тоташ әйләнә хасил итә, бөгелгәндә аларның тарау чәчләре идәнгә кадәр салынып җәйге җилдә дулкынланып утырган бодай басуына охшап кала иде — ФАШта татар, рус, мари, удмурт, чуваш кызлары укый, бер кара чәчлегә әллә ничә сары толым туры килә иде...

Арада иң гүзәле — Асаф моны әллә ничә пар беләк, әллә ничә көлтә сары, коңгырт толымнар арасыннан танып алды — арада иң гүзәле, әлбәттә, күрше авыл кызы Сылу иде. Асаф аның белән еш кына бергә юл йөри, атна саен диярлек аның белән юлы туры килә, әмма, ни гаҗәп, башка кызлар янында иркен генә теләсә нинди уен-көлке сөйли торган егет Сылу белән очрашканда телсез кала, тирләп чыга, каушый иде. Сылу Ташлытауга алар авылы аркылы узып йөри, Асаф исә аның узганын күргә ашыгып кына юлга әзерләнә башлый һәм бер-ике чакрым киткәндә аны куып җитә иде. Юл озынлыгы белән күп сүз сөйләнә, бигрәк тә Сылу медицина китапларындагы, авырулар галәмендәге төрле гаҗәп хәлләрне сөйли — юл узганы сизелми дә кала иде. Ташлытау юлын кыскартыр өчен олы юлны калдырып, болын сукмагыннан да йөргәлиләр иде, водокачка янындагы басмадан чыкканда Асаф,

йөрәге туктаганны тойган хәлдә, бер-ике мәртәбә Сылуның беләгеннән тотып чыкты, әмма кыз басмадан чыгуга шома гына итеп беләген ычкындыра белә иде.

Әмма... Чикерткә бер сикерер, ике сикерер, өченчесендә кулга керер, дип әйтергә ярата иде Асафның әтисе — урманчы Фәисхан.

Чү... Кояшлы рәшә, ерак тугай артында ук сузылып яткан зәңгәрсу тау бите, үлән исе, тыгыз җил, сез кинәт кенә күңелне кузгаттыгыз... Кайда сез, ул кызлар? Сез бәхетлеме, сез үзегезгә ир таба алдыгызмы? Безнең яшьтәшләр — егерме өченче елгылардан һәр ун кешенең тугызы сугышта ятып калды бит. Сез исәнме, теге кичәне сез дә хәтерлисезме? Сез инде үзегездән-үзегез канәгать юантык хатыннармы, әллә чәчәк ата алмыйча сулган өлкән кызлармы? Әллә ир назын бер-ике генә мәртәбә тойган кәе калып, сагыш эчендә көйгән толлармы? Әллә үзегезгә тиң егетләр яу кырларында ятып калгач, ир булсын өчен генә, теләсә кемгә күз йомып кияүгә чыгып, мәхәббәт хисен сагынып газаплы көннәр-төннәр кичерәсезме?

Ул көннәр, ул кичләрдәге кайнар хисләр... Ул көннәрдә дөньяда нәкъ шушындый зәңгәр рәшә, баллы тыгыз җил һәм мәхәббәт кенә бар иде. Ул мәхәббәт хисе тынны буа, башны әйләндерә, тамак төбен киптерә иде.

Хәзер менә утыз елдан артык вакыт узгач — шул ук җил, шул ук рәшә, шул ук тау башы, әмма йөрәк акыл белән, ритм белән тибә, тамак кипми, сулыш тигез. Кызык — теге вакытта болай тигез сулап булмый иде...

Чү... Күңелгә кагылмагыз!

## II

Ишектә таләпчән озын кыңгырау тавышы ишетелде. Кыңгырауны мондый итеп, гадәттә, чит кеше генә баса. Асаф өйдә ялгыз иде, дымлы апрель киче караңгылык белән төрелеп ята икән, форточка ачык, урамнан гөрләвек тавышы ишетелә, өйгә бүрткән тополь бөреләре исе кергән иде. Кыңгырау тагын зыңгылдады, малай әнисе белән универмагка, чыгарылыш кичәсенә костюм өчен материал сайларга киткән иде. Алар универмагка әле барып кына җиткәннәрдер. Өстәл янында укып-язып утырган кешене бүлдергән телефон, ишек кыңгыравы, башка мәшәкатьләр сәнгать-әдәбиятка күпме зарар сала икән? Язучының, галимнең, композиторның үзе үлгәндә эшләп бетерелмәгән хезмәте, тәмамланмаган әсәре калган икән, моңа бары тик дуслар, танышлар гына гаепле. Дошман синә килми, сине бүлдерми, сиңа чылтыратмый. Дошман кыйный гына, ул хәл белешми.

Унсигез яшеннән хәрби хезмәттә булып, хәзер отставкага чыккан һәм үткән сугыш турында истәлекләр язарга керешкән илле биш яшьлек офицер — икенче ранг капитаны Асаф Рәимов, — җиңелчә генә атлап ишеккә килде. Ризасызлык белән генә ачты. Хатын өйдә юк — иҗат өчен иң кадерле, иң кыйммәт вакыт, бу вакытка тигән, кагылган кеше чәчәкле аланга кирза итеге белән килеп кергән мәгънәсез адәм...

Баскычтагы утны яндырмаганнар, ишек ачылуга өчме-дүртме егет (чәчләр озын, балаклар киң — коридордан төшкән яктылыкта болар барысы да күренде, берсенең бите чыпчык ташы кебек бетчәле иде) Асафны күргәч кире чигенделәр, этенделәр. Чыпчык ташы төслесе алга чыгып:

— Илдуска дома? — дип сорады.

Болар, чама белән, тугызынчы-унынчы класс малайлары, Илдусның яшьтәшләре, классташлары булырга тиеш иде.

— Илдус өйдә юк шул. Ә нәрсә дип әйтергә?

Егетләр беразшыбырдашып алдылар, чыпчык ташы яңадан алга чыкты. Татарчага күчте.

— Ә сез яшермисезме? Может, ул өйдә?

Асафның йөрәгє артык бер тибем ясады.

— Берәр нәрсә булмагандыр бит? Юк, өйдә түгел.

— Ә без аны лупить будем. За предательство.

Тамак төбенә нәрсәдер утырды. Тын кысылды. Күздән әллә нинди мамык бөжралар коелды.

— Нәрсә дисез? Нинди хыянәт? Кемгә хыянәт иткән? Сез кемнәр? Укучыларымы?

— Юк, без «Новый» поселогыннан. Без аны хәзер проучим. Кайтканын көтеп торабыз.

— Нәрсә булды? Нигә тик торганда тавыш чыгарасыз?

Асаф ситуациянең котылгысыз икәнен аңлап алды. Тукта...Ниләр эшләп була? Болар дүрт түгел, өчәү икән. Икесе бик сыек. Чыпчык таш калын, саллы күренә. Боларны хәзер үк, менә шушы ишек янында ук көл итеп изәргә була. Хәер, яшьләр, бравадага тартылган вакытлары, пычаклары булуы мөмкин. Я, изден ди, аннан нәрсә? Илдус бит әле берни дә белми. Болар үч алачаклар. Нишләргә? Болар бит болай да инде үч алырга дип килгәннәр.

— Яшьләр газетасына безнең исемнәрне тыгып мәкалә язган кеше Илдускамы? Стадионда безобразие ясадылар дип? Шулмы? Шулмы? Ул бар иде бит анда, без эчкәндә. Без аңа да әйтеп карадык. — Чыпчык ташы төсле егет читкә бер төкереп алды.— Вот менә без аны хәзер проучим. Кайда ул? Бирегез аны безгә. Барыбер ул качып котыла алмый... — Чыпчык ташы читкә таба тагын бер төкереп алды. — Беркайчан да!

Асафның башындагы кан түбәнгә, йөрәккә коелды. Аннан аякларының хәле китте. Аң югалып-югалып алды. Ул ишек янагына сөялде. Әйе, Илдус кичә генә сөйләгән иде: стадионда «Новый» поселогы малайлары аракы эчкәннәр. Илдуслар классыннан берничә малайга бәйләнгәннәр. Кызлар аркасында. Сугыш чыккан. Милиция килгәндә качып таралышып беткәннәр. Шулай да кемнәр икәне беленгән. Бу инде бер ай чамасы элек булган икән. Моның турында кичә генә яшьләр газетасында бер материал басылып чыккан дип сөйләде Илдус. Кичә генә дәрестән кайткач борчылып әйтеп куйды:

— Кайсыдыр бер бездельнигы минем фамилиямне куйган, — диде. Малай бик борчулы иде. Аның үз гомерендә бер кая, бер юл мәкалә язганы юк иде.

Берничә секунд эчендә ниндидер бер карарга килергә кирәк иде. Малайның язмышы шушы берничә секундта хәл ителергә тиеш. Асаф күзләрен ачты, тын алды. Яле, дип ныгытты ул үзен, син бит фашист белән кара-каршы бугазлашкан кеше. Чолганыштан ничек чыкканыңны оныттыңмыни? Нигә сузасың?

— Ә-ә, аңладым, — диде Асаф, җиңел сулап. — Аңладым. Мәкалә бит бөтенләй Илдусныкы түгел. Милиция идарәсенә теге көнне мине чакырдылар. Шулай, шулай, син яза торган кеше, диделәр, давай яшьләр газетасына бер материал, диделәр. Сезнең исемнәрегезне атадылар. Менә ике көн инде Илдус минем белән сөйләшми. Ул йортны ташлап чыгып китте. Миңа әйтте: син, диде, хыянәтче. — Асаф күзләрен йомды. — Әйе, шулай диде. Мин хәзер. Өстемә дә киеп тормыйм. Аякка гына элэктерим дә... Илдус әйтте: син, диде, минем яшьтәшләргә хыянәт иткәнсең...

Баскычтан җыелышып, шыбырдашып түбәнгә таба атладылар. Асаф өендә эшләп утырганда кия торган пуловердан, спорт чалбарыннан иде, аякларына нидер элэктерде. Каршыга икенче катта яшәүче архи-

тектор очрады. Бәләкәй кызын җитәкләп кайтып килә иде. Тыныч кына исәнләшеп узыштылар. Белсә иде ул күршесенең кая барганын! Беренче катта яшәүче пенсионерка апа чүп түгеп керә икән, Асаф стенага елышып аны да уздырды. «Хәерле кич, апа...» «Исәнме, Асаф, ни хәлләр?»

Дымлы балчык исе таралган бер кич икән. Сөйләшмәгән көе генә өрәңгеләр белән томаланган чокырлыкка киттеләр. Стадиондагы динамиктан сугыш тәмамланган чагында бик популяр булган җыр яңгырый иде.

Помирать нам рановато —
Есть у нас еще дома дела...

Моны сугыш беткән елларда Асафлар дивизиясендә, үзгәртеп, болай җырлыйлар иде:

Помирать нам — рановато,
Есть у нас еще дома жена —
И не одна!
Эх, путь-дорожка фронтовая...

Өрәңгеләр арасында юеш, караңгы иде. Боларның кастетлар юкмы икән? Пычак белән үк уйнамаслар бит? Арттан гына кадамасыннар. Теге икесе мондый эштә беренче катнашалар сыман. Әмма чыпчык ташы тәҗрибәле күренә. Чыдарга! Тик башка, бавырга гына типмәсеннәр. Чыпчык ташы агачлар ышыгына килеп керү белән Асафның аяк астына сукты. Асаф чайкалып өрәңге ботагына барып сыланды, теш казналары яңгырап алды, әмма яман түгел: бөтен баш, аяк, авыз җылынды, авызны тозлы тәм басты. Калын аслы ботинка агачлар арасыннан төшкән яктылыкта автомат стрелка сыман селтәнде дә, Асаф күкрәгенә тиеп алды. Өрәңге ботагы шартлап сынды, Асаф тәгәрәп бозлы балчыкка борыны белән барып кадалды. Чыпчык ташы булса кирәк, аны озаклап һәм вәгазь укып кыйнады.

— Падла! Мин сине өйрәтермен ничек язарга? Менә моннан соң язарсың... Фрайер! Менә сиңа! Менә сиңа! Фрайер!

Тик башка гына типмәсеннәр иде. Тик бавырны гына эштән чыгармасыннар иде. Менә туктадылар да бугай. Газаплы, авыр бушлыкка таба күчеш башланды. Каядыр түбәнгә, түбәнгә, караңгы чокырга, упкынга акрын гына очты ул. Тик очкан саен сулыш алуы кыенлаша, авызга, борынга балчык исе тула, тынны буа. Инде сукмыйлар да, сүз дә әйтмиләр. Тик теге бушлыкның төбенә генә төшеп җитеп булмый... Мондый хәл кайчандыр булган иде, бу — таныш халәт. Кайчандыр, ни өчендер ул шундый бушлыкка тәгәрәгән, очкан һәм вакыт белән пространство тойгысын югалткан иде. Аңа ул вакытта наркоз биргәннәр иде бугай. Наркоз белән аңны югалту җиңел икән, тәнеңә пычак кергәнне, сине телгәләгәнне сизмисең дә икән, дип сөйлиләр иде. Яшьләр сөйли иде, кырык бернең июль-август айларында, диңгез пехотасының минерлар курсында укыганда сөйлиләр иде. Әмма кырык беренче елның көзендә бик күп әкиятләр белән берлектә мондый әкият тә очты, гамәлдән чыкты. Наркоз белән аңны югалту авыр, бик газаплы. Моны үзең сынап карарга кирәк. Тормышта, гомумән, кешеләргә ни дә булса әйтер өчен, ул «ни» не үзең сынап карарга кирәк. Тукта, нигә әле бу упкынның төбе юк? Нигә шулай газап белән төшелә? Нигә бик озак? Нигә авызга берөзлексез тоз тутыралар? Нигә су салмыйлар? Әллә авызга елан керәме? Имеш, авызга елан кергәндә йокыдагы кеше шулай саташа, әчәсе килә...

...Апрель төненең ай янындагы бер йолдызы җем-җем итеп өрәңге ботаклары арасыннан Асафны күзәтә иде. Бары тик аны гына. «Тор, Рәимов! — ди аңа өй янындагы йолдыз, — тор! Син һаман үзең булып калдың. Син бүген дә кеше өчен көрәшеп кан түктең. Тик монысы —

үз. улын. Син аны саклап калдың. Хәер, теге вакытта да син бик күп улларны, бик күп кызларны саклап калдың. Ул вакытта да аңыңа килгәндә беренче булып сиңа мин дәштем. Мин — һаман шул йолдыз бит әле! Сез, кешеләр генә, аз яшисез дөньяда... Ә без, йолдызлар, галәмдә йөзәр миллион, унар миллиард еллар яшибез! Тор, Асаф, синең йолдызың сиңа кешеләр бәхете, кешеләр иминлеге өчен көрәшергә, кан түгәргә гел юл куя. Син — бәхетле!»

Стадионда әле дә булса музыка уйный, әле төн узмаган икән. Музыка будкасында утыручы кеше тәгаен генә Асафның замандашыдыр. Шулай булмаса, ул кырыгынчы еллар музыкасын куяр идемени? Бүгенге озын чәчлеләр кырыгынчы еллар музыкасын тыңлау түгел, аны телгә дә алмыйлар. Аларга магнитофон язмасында инглизләр, гарәпләр, французлар, зеландиялеләрнең карлыккан, тузган тавышлы жырчылары кирәк. Аларга «Христос воскрес» операсыннан өзекләр, карлыккан, тамагын ертып «Хей! Хелоп! Хей! Хелоп!» дигән ритмнар кирәк. Ә стадион динамигыннан Асаф яшьлеге агыла, кан сауган йөрәгенә бу көй шифалы дару булып ята.

Асаф үзенең өенә кергәч куркынган хатынына да, улы Илдуска да драманың асылын ачмады.

— Бер танышым белән аңлаштык, — дип көчәнеп елмайды. Карават башында утырган җитү чәчле малаена карап куанды.

Һәм улының кулыннан тотты. Аның кан тибешен тойды. Рәхәт булып китте. Улының күзендә яшь ялтырады.

— Әти... Син әгәр сине кемнәр шул хәлгә төшергәнен әйтмәсәң, мин с уйма сойду... — Улы дерелди, әмма еларга гарьләнә иде.

Асаф аның кулын хәл кадәренчә кысыбрак тотты. Тавышы йомшаганны сизеп, шулай да бирешмәскә теләп, каты булырга тырышып, болай диде:

— Илдус! Без синең белән — ирләр. Мин барысын да сиңа әйтә алмыйм. Фронтта вакытта чолганыштан чыкканда бер иптәшемә карата гаделсезлек эшләгәнмен. Үзем белмичә. Шул мине эзләп тапты. «Исән вакытта исәп-хисапны өзәсем килә», диде. Мин аңа юл куйдым. Ә син дәресеңә утыр, мин ике-өч көн ятыйм.

Тәрәзәдә апрельнең төпсез кара төне күренә, форточкадан балчык, җир исе керә иде.

### III

Күп уйлар уйланылды. Баксаң — мең тугыз йөз кырык беренче елның июненнән бирле бер генә көн дә, бер генә сәгать тә тормыш турында уйларга туры килмәгән икән. Дөрес, госпитальләрдә, кыр лазаретларында ятулар, йокысыз үткәргән сызланулы көннәр-төннәр булды, наркозлар, уколлар күп булды, әмма ул ятуларның бер генә сәгатендә дә тормышның шул халәтеннән читкә чыгу булмый иде, палатадагы иптәшләр, аларның биографиясе белән бергәләп, коллектив яшәү, коллектив дәвалану була иде ул вакытта. Ә монда — ходай бирде! — бөтен биографияне чигереп, баш мие аппаратыннан кабат уздырырга, аерым кадрларга бәя бирергә мөмкинлек туды. Каян башларга икән? Участок врачы аңа кыймылдамаска, укымаска, язмаска кушты, ә хәтерләмәскә дип әйтмәде. Тыймады, димәк, мөмкин. Ә әйе... Сәхнәдә чәч толымнарын таратып кызлар биегән теге кичтән башланды биография...

Әлбәттә, ул төнне Асаф йокысыз уздырды. Юк, картлар йокысызлыгы түгел иде ул. Ул — беренче ашкыну иде. Кичә беткәч, Асаф, тыны кысылган хәлдә, Сылуны ишек янында көтеп торды. Иптәш егетләре кайсы кая таралгалап беттеләр, рус егетләре кызларын култыклап болынга таба юнәлделәр, берсе двухрядкасын гөрләтеп җибәрде, чәрел-

дек ачы тавыш белән берсе частушка башлады — русларның асат, аларда берни дә гаеп ителми, ә менә Асаф качкын шикелле посып клуб ишегенең күләгәсендә тора һәм Сылу чыкканын көтә. Асафның йөрәге типкәнгә клуб чоланы селкенгән сыман иде.

Ишек төбендә кыюсыз гына басып торган Асафны күргәч, Сылу елмаеп куйды. Чолан өстендәге сыңар лампочкадан төшкән яктылыкта аның алгы тешләре чагылып китте.

— Син.. сез.. бик матур биедегез, — диде Асаф, аңа карамаска тырышып кына. — Әллә без дә болын тирәсеннән бер әйләнәбезме? — Ул саклык белән генә Сылуның беләгенә кагылды. Кызыйның беләге кайнар, җиңсез юка күлмәге аркылы таза яшьлек ыргылып тора, толымга үрелмәгән куе чәче бөтен аркасына таралып, бил батынкылыгын каплаган, ул чәчләр хәрәкәт итеп әйләнә-тирәгә электр тогы чәчәләр, магнит кыры ясыйлардыр кебек иде.

Сылу үзен кыю тотты, Асаф елышыбрак атлады, алар клуб рәшәткәсе буйлап салынган таш сукмактан түбәнгә — базар урамына таба атладылар, рәшәткә башларыннан үрмәләп чыккан сирень, гөләп агачларының чәнечкеле үрентеләре кызыйның тәнен җәрәхәтләр дип курկып, Асаф койма ягына чыкты. Бакчада чикерткәләр чурлый, агачлар арасыннан ургылып-ургылып куе роза исе чыга, агачлар, чәчәкләр, чикерткәләр бу төндә ашыга-ашыга сулыйлар, яшиләр һәм үз мөмкинлекләрен тереклек дөньясына күрсәтеп калырга тырышалар сыман иде.

Бакча почмагына җитеп ташлы урамга чыгуга, биткә коры һава, тузан, җылы таш исе бәрелде, Асаф әлеге сихри дөньядан кинәт кенә аерылгач сискәнеп, дерелдәп алды. Шундый ук хәлне Сылу да кичерде булса кирәк, чылдырап сөйләшеп килгән уңайдан ул да кинәт айнып китте, тынып калды һәм тузанлы юлга аяк басканда ничектер беләген ычкындырды да, бакча почмагына карап куйды. Авылдан килгән гадәт буенча, ул борылып карагач, Асаф та борылды һәм рәшәткә почмагыннан урамга салынган сирень куагы астында өч нокта күрде. Ноктаның берсе кызыл иде — тәмәке уты — моны аңлавы кыен булмады, әмма шуның өстендәге ике нокта июнь аеның караңгылы-яктылы төнендә Асафның миен бораулап алды; күзләр кызыгу, көнләшү чәчеп елтырый иде.

Куак астында елтыраган күзләр Асафның якташы, Ташкичү егете Габделнурныкы иде. Бу мизгелдә Асаф та, Сылу да көтелмәгән бу очрашуның киләчәктә нинди газап-хәсрәтләр китерәчәген уйларына да алмыйлар иде. Шулай да, адәм баласында үзе аңлап, белеп бетермәгән нindидер алдан сизү көчләре бар. Нәрсәдәндер шикләнеп, Сылу болынга төшүдән баш тартты һәм үзен ике катлы агач йорт — тулай торакка кадәр озаттырды. Асаф иртәгә авылга кайту турында аның белән сүз кузгатмакчы иде, Сылу «мин хәзер чыгам» дип, йөгереп торакка кереп китте. Күпмедер минутлар узгач, ул әйләнеп чыкты. Өстенә җиңсез юка халат, аягына артсыз чүәкләр элгән иде, тулы ай яктысында Асаф аның тешләреннән чагылган нурны тагын тоеп алды, юк, алай гына да түгел, Сылуның ике күзендә ике ай кабынып алды бугай.

— Кызлар барысы да болында, әйдә, верандага кереп утырабыз,— диде ул елмаеп.

Веранда — икенче катта, шыгырдап торган такта идәнле, ачык тәрәзәләреннән тополь ботаклары бәреп утырган, эченә тополь сагызы исе тулган кечкенә генә бер бүлмә иде.

— Иптәш кызым белән без өч көн инде менә шушында йоклыйбыз,— диде Сылу идәннең бер кырыенда, почмакта җәелгән урынга күрсәтеп. — Бүген тагын кайтмый инде ул. Аның Андрюшасы — син аны беләсеңме? — кышын чаңгы буенча укучылар арасында беренче урынны алган озын малай — хәрби училищега китәргә әзерләнә. Таня үзен кая куярга белми, Андрюша офицер булып алса, ташлар дип курка...

Асаф тәрәзәдән кергән тополь ботагын борынына якын китерде дә, Сылуны әллә тыңлады, әллә тыңламады. Бүлмәгә ай нуры тулган, тополь яфракларының күләгәләре зур кульяулык булып идәндә тибрәнәләр иде.

— Ә без Таня белән ай нурында коенырга яратабыз,— диде Сылу һәм хәйләкәр елмаеп, юка халатын салып ташлады.— Ә синең ай нурында коенганың бармы? Ә егет кешенең мускуллы беләкләре, куәтле җилкәләре ай нурында ничек матур булырга тиеш! Безгә кеше тәненең матурлыгы турында фән укыттылар...

Беренче мәртәбә аңын шул мизгелдә югалтмадымы икән Асаф? Ничек булды соң әле? Башта аның күлмәге, майкасы идәннең бер почмагына очты. Тополь яфрагы аның ялангач аркасын кытыклады. Берничә секундтан аның сөякчел җилкәләренә кайнар йомшак беләкләр уралды. Тагын берничә секундтан аның күкрәге тирәсендә мең-миллион бөртектән торган чәч көлтәсе чайкалды, дөнья кайнар, бик кайнар булып китте. Ай нурында ул Сылуның тыгыз дерелдәвек тәнендә шуып-уйнап торган зәңгәр-яшькелт ефәк эчке күлмәген тойды, үзен-үзе белмәгән хәлдә берөзлексез шул күлмәк аркылы аның тәнен сыйпады. Ефәк шома, бик шома иде. Шул ефәкме икән, тамакны буып әллә ниткән, моңарчы әле таныш булмаган куәт белән беләккә, күкрәккә көч куа иде, әмма ниндидер бер мизгелдә бу куәт аяктагы көчне каядыр суырып алды, күк йөзендәге ай кинәт кенә югарыга ыргылды, тәрәзәгә бәрелеп торган тополь дә кинәт ауды. Тагын бер мизгелдә Асаф бу сихри кызның кайнар йомшак аякларын, шома тез башларын тойды, аның һаман да тыны бетте, бу саташулы ләззәт аны моңарчы билгесез булган башка бер дөньяга алып китте, тагын аңына килгәндә ул һәр бөртеге аерым хәрәкәттә булган чәч көлтәсе белән авызы, борыны томаланганны, кайнар беләкләр белән муены буылганны, үзенең сөякчел кулбашларының йомшак чәчләр белән чорнап алынганын төшенде.

Бераздан ул вакытны сиземләү сәләтен югалтты...

Аерылган вакытта Сылу пышылдап:

— Иртәгә, юл аермасында, нәкъ сәгать унда,— диде.— Икәү генә кайтабыз.— Үзе елмайды, үзенең авызында чәч шпилкасы, үзе сихри ак беләкләрен күтәреп, чәчләрен рәтли, артка таба җыя иде.

Тулай торакка Асаф исерек килеш кайтып ауды. Шуннан бирле үз гомерендә ул күпме генә эчемлекләр авыз итмәде, кырык бишенче елның тугызынчы май көнендә фронт штабыннан хәбәр китергән командующий адъютанты аңа калай кружканы тутырып чиста спирт эчергәне булды — әмма теге вакыттагы кебек Асаф беркайчан да исерә алмады. Нәрсә хәтерли ул? Берәм-берәм малайлар кайтып аудылар. Берсе — Шәрәф исемлесе—качырып кына папирос тартып ятты. Кояш чыгар алдыннан гына тулай торакның бакчага караган ачык тәрәзәсеннән Габделнурның ясалма көр, әмма ни өчендер куркыныч тавышы яңгырады. Егет җырлый иде:

Тор, әй, иптәш,
Таң яктырды,
Ал мылтыгың кулыңа;
Өйрәнәек Ворошиловча
Төз атучы булырга.
Әйдә каршы, әйдә
Дошман явына;
Әйдә бөтендөнья
Инкыйлабына...

Никельле караватта июнь кояшының кызыл нурлары чагыла башлаганда, Асаф гаҗәеп татлы, рәхәт, кыска бер йокыга талды. Бу рәхәт йокының, бу ләззәтнең үз гомерендә соңгысы, иң соңгысы икәнен ул әле, әлбәттә, башына да китерми иде...

## IV

Сәгать сигезләр тирәсендә тулай торак егетләре фанер чемоданнарын, биштәрләрен хәстәрли башладылар. Кемнәрдер базарга барып, инде юлаучылар белешкәннәр, кемнәрдер инде базарга килгән авылдашларының арбаларына әйберләрен илтеп тә кайтканнар, күбесе инде комендантка урын-җирләрен тапшырган, тулай торак бүлмәсе урыннан кузгатылган ялангач тимер караватлар, ишекләре ачылган ике катлы тумбочкалары белән ятим булып калган, акшарлы стенадагы кара кәгазьле радио тәлинкәсеннән концерт ишетелә. Асафның авыр әйберләре авылга күптән озатылган иде, таралышыр алдыннан җыелышып, ялангач караватларга утырдылар. Габделнур ачык тумбочка төбеннән калай кружка һәм ике шешә портвейн алып такта өстәлгә куйды. Әйе, бу минутка әлеге алты малай күптән әзерләнгәннәр, берәр тәңкә акча җыеп, Габделнурга өченче көн үк тапшырганнар иде.

Сүзне ул алды:

— Кайда гына эшләсәк тә, кайда гына булсак та, бер-беребезне онытмаска сүз бирик, — диде. — Без, — диде,—өч ел буе бергә укыдык, бер бүлмәдә яшәдек, безнең арада ирләрчә дуслык яшәде. Кемнәрдер армиягә китәр, кемнәрдер гашыйк булыр, өйләнер, бала-чагасы булыр. Но шушы дуслыкка беркем дә аяк чалмасын, дуслык дәвам итсен иде.

Калай кружкадагы эчемлек җылы, әчкелтем иде. Адреслар язышу, вәгъдәләр бирешү, кунакка чакырышу китте, Асаф аларны я ишетте, я ишетмәде.

Базар эчендә акрынлап бер-берсен югалттылар. Базар калын иде, Пошалым яклары базарының алгы өлешен кул арбалары, бизәкләп эшләгән бәби арбалары, көянтәләр, тәпәннәр белән тутырганнар, Казаклар авылының озын буйлы ирләре такта сата, Ключище руслары чүлмәк төяп килгән иде.

Базар тарала башлаганчы юлга чыгарга кирәк иде, Асаф вакытны чамалап Ташлытауның олы юлыннан читкә аерылып кергән ат юлы чатына таба юнәлде.

Сылу нинди икән хәзер? Аерылышканга әле нибары җиде-сигез сәгать, шул гомер эчендә ул ниләр уйлады икән? Асаф үзенең иренендә, борын төбендә аның муенынннан йогып калган, тын юлын кытыклый торган исне әле дә тоя иде, ул ис, ахрысы, кичәге бакчадан бөркелеп торган роза чәчәкләре исенә охшаш иде — ничек кенә булмасын, исерткеч, бик көчле исерткеч иде. Портвейн — аның янында болай гына — әчетке генә икән...

Сылу юл буендагы чирәмдә тезләрен кочаклап аны көтеп утыра иде.

— Я, выпускник иптәш, унынчыны тәмамлап кайту көнең белән сине тәбрик итәм, — диде ул, шат елмаеп. — Ә син—мине. Мин бит үзебезнең участокка мөдир итеп билгеләндем. Әнием исән булса, шатланып туя алмас иде...

Асаф кичәге шашкын хисләрнең тагын уянуыннан куркып, чынлыкта исә шуларның кабатлануын теләп, Сылуның сумкасын кулына алды. Буйга алар пар килгәннәр икән. Асафның өстендә җиңен сызганып кигән ак күлмәк, соры габардин чалбар, аякларында чибәр генә арзанлы полуботинкалар иде. Сылу гап-гади җиңсез ак кофта кигән, беләгенә шакмак сәгать таккан (председатель кызы!), аякларында өсте шнурлы спорт тапочкалары иде.

Кеше йөрми торган юллардан, авыл артларыннан, болын читләреннән, колхоз межаларыннан июньнең ак кояшы астында Симетбашка таба бер пар атлый, аларның бәхетеннән табигать көнләшеп бер мәлгә тынып калган, күк йөзендә — бик биектә ертылып калган берничә ак болыт кисәге дә туктап аларны күзәтә иде. Симетбашка таба аккан сай

гына елга буйларындагы тау битләрендә кояштан әлсерәгән дегет чәчәкләре, сандугач тәпиләре, су кырыендагы ут чәчәкләре көн үзәген күтәп калгандай, хәрәкәтсез, тынсыз утыралар, тау битләрен җиләк, баллы куәт исе баскан иде.

Тау битеннән төшеп болын буйлап барганда сукмак аларны кечкенә генә бер күлгә алып чыкты. Камышларга сыенып күл буенда ут чәчәкләре томаланып утыра иде. Сылу, ниндидер бер дәрт белән очкынланып, сазлыкка таба атлады да, ут чәчәкләре өзеп алды. Урман артында күк гөрелтәгәне ишетелде, кинәт кенә дымлы җил исте, шаян дымлы җилгә ут чәчәкләре шом белән бөтерелделәр, камышлар ыңгырашып куйды.

Сылу кулындагы чәчәкләрнең берсен Асафка бирде дә, икенчесен күкрәгенә эләктерде.

— Бүгенге очрашуның истәлеге итеп сакла, — диде.

— Өеңә алып кайтма, ярамый, — диде аңа каршы Асаф, әллә чынлап, әллә ни әйтергә белмәүдән.

— Ә нәрсә була?

— Шуны да белмисеңмени? Безнең әни әйтә, ут чәчәген, давыл чәчәген өйгә кертсәң, борчулар алып килер ди.

Сылу авыр сулады:

— Безнең әни менә бер дә ут чәчәге, давыл чәчәге кертмәгән иде әле өйгә — өч баласын калдырып үлеп китте.

Асафның мондый күңелсез темага керәсе килми иде, үзенең сөйләшә белмәвенә үкенде.

— Да-а, — дигән булды, олыларча сөйләшергә кирәк иде, ә унсигез яшендә кайсы егетнең олыларча сөйләшә алганы бар? Кайсы егетнең яшь кыз белән ялгызга-ялгыз калгач акыллы, төпле сүз сөйләгәне бар һәм кирәкме әле ул? Асаф боларны аңлый иде, аңлаган саен аңа үзүзен тоту кыенлаша иде. Ә Сылу сөйләшү дигәндә — искиткеч кыз.

— Безнең әни үз гомерендә бер сәгать ял иттеме икән? — дип, күзләреннән сагыш коеп сөйләде ул басу межасыннан атлаган көйгә.

Ат арбасы белән бу межадан кемдер узган һәм межада озын булып үскән алабай чәчәкләренең саплары арба күчәренә эләгеп дегеткә буялганнар иде. Кызыйның балтырында Асаф дегет таплары күрде.

— Авыр тормышта үскән кыз. Егерме икенче елда безнең Ташкичүгә кунак булып килгән. Икәү килгәннәр—Зәбир абыйларга. Кунак булып килгәннәр, Зәбир абыйның балдызы шунда егет белән танышкан да — Габдрахман абыйны беләсеңме? — тоткан да кияүгә чыккан. Минем әни кунакка килгән җиреннән ялгыз кыз булып калган. Ялгыз кайтырга да ерак. Ул — Башкортстанның Агыйдел ягыннан. Елаган да елаган. Ул арада армиядән минем әти булачак кеше кайтып төшкән. Әни күп бала тапкан. Бик күбесе үлгән. Ул бала табарга яраткан. Тик соңгы баладан гына чирләп калган. Әни җиде бала тапкан, менә без өчәү исән.

Межа белән кайта торгач авыл басуы түрендәге имән урманына килеп чыктылар. Урман почмагыннан караганда астарак Симетбаш, аннан бер генә чакрым түбәндә су буенда Ташкичү күренә иде.

Урман почмагындагы аланлыкта карт имәннәр күләгәсенә кереп утырдылар. Асаф күккә карап сузылып ятты. Күкнең иң түбәсендә ертык ефәк яулык сыман болыт кисәге акрын гына көнчыгышка таба шуыша иде. Җир гөмбәсе, җылы имән кайрысы, җир җиләге исе, бал исе белән буталып борынга ургылып-ургылып керә, канны уйната иде. Тып-тын тымызык көн булуга карамастан, имән очлары шаулый, мәһабәт шау белән күңелгә шом сала иде. Асаф үрелеп Сылуның муеныннан кочаклады, кызый әчке бер бәхет белән сагышлы елмайды да аның йөрәк турысына колагын куеп ятты. Озак та үтмәде, ике йөрәк

бер ритмга тибә башладылар, тик бу тигез ритмнан икесенең дә куллары калтырый иде.

— Мине армиягә алачаклар көзгә, — диде Асаф. — Менә бит: ничә ел хыялланып йөрдем армиягә китәсем килеп. Ә хәзер сине ташлап китәсем килми. Беләсеңме, миңа нинди хыянәтчел уй керде бүген иртән?

— Әле син хыянәт итәргә дә өлгердеңмени? — Сылу чәч толымының очы белән егетнең битенә сукты. — Шаярма минем белән! Шаярма! Миндә башкорт каны! Ирек, азатлык яратучылар каны!

— Юк, Сылукай, алай түгел. Беләсеңме, ни турында уйладым? «Тарас Бульба»ны узган идек без рус әдәбиятыннан. Хәтерлисеңме, анда Тарас картның улы Андрей бер поляк кызына гашыйк була. Шул кыз аркасында һәлак була?

— Безнең ни катнашыбыз бар әле ул сатлык җанга? Син Андрей түгел, мин полячка түгел.

— Анысы шулай. — Егет берөзлексез кызның йомры, тулы аркасыннан сыпырды. Аркасын икегә бүлгән озынча уентык буйлап бармакларын йөртте — кызга да, аңа да чиксез рәхәт иде бу вакытта... — Анысы шулай. Тик менә шул кыз урынында син булсаң? Ә мин — Андрей түгел, Асаф ди. Ни диярсең? Ул вакытта нишлибез? Чыннан да, менә син хәзер берәр илнең шпионкасы булып чыктың ди. Әйтик, Япония империализмының разведкасына эшлисең ди. Мин моны хәзер генә белдем ди. Үземнең яратуымны нәфрәткә әйләндерерлек көч бармы миндә? Әллә мин мәми авызмы?

Кыз дәшмәде, тулы иреннәре белән егетнең йомшак төк баскан битен кытыклады да, аннан авызын томалады. Егет аның тәнендәге кан йөрешен ишеткәндәй булды. Тынсыз калган бу рәхәт минутлар күпмегә кадәр сузылгандыр, юл буеннан чатыр чабып килгән ат-арба тавышы ишетелде. Кыз сискәнеп китте һәм сикереп торып итәкләрен рәтләде. Асаф та ашыкмыйча гына торып басты.

— Үләм, әтинең районга барышымы әллә дип торам, — диде Сылу, тын алгач.

Юл якын иде, җан-фәрманга такта арбада чабып килүче — Ташкичүнең бердәнбер насыбай салучы кешесе — киез эшләпә, киндер ыштан кигән черек тешле Минҗан карт икән. Аның аты арт санын күтәреп кушаяклап чаба, аның саен Минҗан карт дилбегәсен бөкләп кизәнеп ат сыртына суга иде. Үлән арасыннан торып баскан егет белән кызны ул тиз күреп алды һәм атын тыя төшеп, ямьсез авызыннан төкерекләр чәчеп кычкырды:

— Әй, сез, зиначылар! Анагызның кабер тактасын... Сугыш башланган, сугыш!

Сүзнең мәгънәсен, әлбәттә, аңламадылар. Шулай да, ниндидер гадәттән тыш хәл булганын сизеп, Асаф юлга таба йөгерде, ат каршына чыкты. Ябык алаша тиз генә ризалашып туктарга булды, камыты күзенә килде, ыңгырчагы алга әйләнде, эмма ат инде туктаган иде.

— Ни дидең? Нәрсә әйттең, Минҗан абзый?

— Анаңның фәләне дип әйттем! Колагыңа таш кергән мәллә, оятсыз! Зиначылар! Сугыш! Немец белән, аңладыңмы? Ә, әле син Фатыйма малаемыни? Сугыш!

— Шаяртмыйсыңмы? Чынмы?

— Һәй-й, алла, сезнең белән авыз чайкап торырга! Карчыгым Ташлытауга киткән ие. Печәнгә төшкәнче дип! «Чынмы» тагын! — Ул селтәнеп атына дилбегә очы белән салды, ат ничек кисәк туктаса, шулай кисәк алдырып китеп тә барды. Минҗан карт такта арбасында артка борылып кычкыра-кычкыра китте.

— Шаярып сугыш башлыйлармыни, атагызның башы! Сугыш булгач чын булмый димени, анагызны корт чаккыры...

Юлда сузылып тузан калды.
Аннан егет белән кыз үзләре дә аңышмастан авылга таба йөгерделәр. Асаф кызның сумкасын тотарга да онытты. Үз кулындагы портфельне селти-селти йөгерде. Аның артыннан Сылу чак-чак кына өлгерә иде. Әйтерсең, сугышның барышы-тукталышы боларның тиз кайтып житүенә бәйле иде. Бераздан Сылуның тыны капты. Ул Асафның кулына ябышты.
— Йөгермик, акрын кайтыйк, — диде ул, чак тын алып.
Алар бу юлы да межадан гына кайттылар. Межага язгы чәчүдән бирле аяк басучы булмаган, анда исле үлән, алабай чәчәкләре, арыш читләрендә күк чәчәк иде.
— Бу сугыш, беләсеңме, нигә башланган? Юкмы? Мине бәхетсез итәргә! Мине! Мине! — Сылу буылып елый башлады. Егет аның сумкасын кулына алды, хәл кадәренчә тынычландырырга тырышты, әмма үзенең тавышы калтырый иде.
— Я, нигә инде алай уйлыйсың? Әле болай гына атыш башлап карагаННардыр. Хасан күле буендагы кебек бәреп чыгарырлар әле. Бер атналык эш инде ул безгә...
— Юк, күңелем сизә. Без беркайчан да кавыша алмаячакбыз. Сине миннән аерыр өчен генә башланган сугыш бу! Я син, я мин үләчәкбез...
Межа авыл читенәрәк алып төшә иде, алай әйләнеп йөрергә вакыт юк иде, ат дугасыннан үскән, инде серкә очырырга әзерләнгән яшел арыш басуына ярып керделәр дә чаж-чож атлый башладылар. Арыш басуы аларны тышкы дөньядан аерып куйган сыман булды. Дөньяда тагын бер мизгелгә алар икәү генә калдылар, анда-санда пырылдап күтәрелгән тургайлар бу ялгызлыкка комачау итмиләр иде. Сылу яшьле күзләрен мөлдерәтеп егеткә карады, аны туктатты, муенына сарылды.
— Соңгы тапкыр, — дип пышылдады һәм Асафны суырып үпте — егет аның кабарынкы иреннәрендә исерткеч тоз тәмен тойды, ул да онытылып аны иркәли, сыйпый иде.
— Китик, — диде кызый, — башкасы, шуннан артыгы — хәзер жинаять. «Хәзер» дигәнне ул аерып әйтте. Асаф аның сумкасы белән үзенең протфелен тоткан көе озын арышларга буталды, чаж-чож атлап китте. Сылу аның белән рәттән, үзенә аерым юл ярып барды. Менә ул кемгәдер, нәрсәгәдер үпкәләгән сыман, тыйлыга алмыйча елый башлады, ниндидер кискен хәрәкәтләр белән житез генә кофтасын салып беләгенә элде. Асаф аның ялангач шома тәнен, аркадан тарттырып эләктереп куйган ике ак сәдәфне күреп алды, әмма кызый бернинди ир заты да булдыра алмый торган хикмәтле бер хәрәкәт ясап, сул кулы белән аркасына үрелде һәм күз ачып йомганчы гәүдәсен сәдәфләрдән, элмәкләрдән азат итте. Асафның мондый сихри сынны бер генә картинада да, бер генә репродукциядә дә күргәне юк иде, һәм ул әлегә кадәр дөньяда андый исерткеч, баш әйләндергеч гүзәллек булуы мөмкин дип уена да китерә алмый иде, аның башы, йөрәге, рухы кинәт ачылган бу гүзәллекне кабул итәрлек, сеңдерерлек дәрәжәдә түгел иде. Сылу аннан ераклашты, бер үзенә яңа сукмак салып юл ярды, ачу белән каты басып атлады. Куе яшькелт арыш төбендә юл-юл булып чәчкеч эзләре сузылган, төбеннән саргая башлаган арыш куе рәт, дивар булып кайшалып үсеп киткән һәм аның тыгыз башаклары сөтле-баллы орлыклар белән авырайган, арыш чәчәге — серкәсе белән чукланган иде. Күкрәк тутырып баллы ипи, салат исен сулап барган уңайдан Асаф кинәт кенә әкият кызына әверелгән сихри бу гүзәлгә күз ташлады: Сылу ачу катыш атлый, күзләрен еракка төбәгән, арыш чәчәге яшь аккан битләренә ябышып чуарлаган, авыр яшькелт башаклар аның өлгергән миләш кебек күкрәк очларына лысылдап китереп бәрәләр һәм аның саен ул кызурак атлый, куерак жирне сайлый иде. Куе арыш башакла-

рын ялангач күкрәк очлары белән ярып, ашкынган, ярсыган, бәхетле дә, бәхетсез дә бер гүзәл авылга таба атлый, аның аякларына бәрелгән арыш сабагыннан «чаж-чож» дигән тавыш чыга, бу тавыш Асафка «сугыш, сугыш» дип ишетелә иде.

Колхоз әвеслеге янында алар аерылыштылар. Сылу берсүзсез киенде, сумкасын алды.

— Мине күрмичә китмә, ике бала анасы булып калачакмын, — диде. — Әти белән сиңа — сугыш! Сугыш! Берегез дә исән кайтмаячаксыз! Ә мине — медсестраны, балалар аркасында сугышка алмаячаклар! Ах, әнием булса иде! Иртәгә иртүк мин синең белән военкоматта булыр идем! Сау бул, бәхетем минем! Сау бул, бәхетсезлегем минем! Ә бәлки өч бала анасы да булырмын әле мин!

Авылда, ни өчендер, чаң сугалар иде.

Сүзләрнең соңгы өлешен егет аңламады.

## V

Алар авыр аерылыштылар.

Авылда беркем дә, гомер иткән ир-хатын да, егет белән ата-ана да алай авыр аерылышмаганнардыр. Егерме бишенче июньнең җилле, болытлы бер киче иде. Асаф Ташкичүгә төште. Авыл арасы — бер чакрым, су буйлап йөргәндә араны чакрымлап исәпләмиләр дә — бердән дә кими. Әнисе — Фатыйма апа — юлга май күмәче пешерергә, оекбаш бәйләргә, киткән солдатка гадәт буенча ике бармаклы перчатка бәйләргә дип ыгы-зыгы килеп калды. Перчаткаларны бәйләргә колхоз идарәсендә табельщица булып эшләүче Гаделия керергә тиеш иде, Фатыйма апа белән аларның дуслыгы (житкән егете булган ананы кайсы кыз гына соң якын итми; житкән кызы булган ата белән кайсы гына егет соң исәнләшми?) соңгы елда бик ныгып алган иде...

Җил иде, ара-тирә яңгыр тамчылары да төшкәли иде, тузан исе, тополь яфраклары исе, ява алмый йөргән болыт исе авыл урамнарын баскан иде. Асаф белән Сылу авыл күпере янында очраштылар да, ындыр артына, бәрәңге бакчалары башына чыгып киттеләр.

Яктырганчы бәрәңге бакчаларының башында клевер басуы кырында йөрделәр. Вәгъдәләр бирүе кыен иде — сугыш иң көтелмәгән хәл булып чыкты. Сылуның әтисе броньнан баш тарткан, бернигә карамыйча фронтка китәргә җыена. Хәер, тол калгач, ул гел сугышмы — нәрсә, гадәттән тыш бер әйбер чыгуны көтеп яшәде. Аның өчен яшәүнең мәгънәсе беткән иде бугай. Мөкаддир агай хатынын яратып, тормыштан тәм табып яшәде, бала туган саен сөенде, әмма утыз тугызынчы елның язгы су вакытында хатыны Зәкиянең өч баланы калдырып гүр иясе булуын башына берничек тә сыйдыра алмады. Күрше авылдан карт кыз — укытучы Хәлимәне димләп карадылар, Сылу ул вакытта ФАШның беренче курсында укый иде, Мөкаддир абзый йорттагы бердәнбер олы кеше — Сылу белән киңәш итте.

— Минем өчен түгел, Зәкиядән башка беркем дә миңа кирәк түгел, энеләрең өчен кирәк, — диде. — Сиңа авырга киләчәк, укуыңны өзмәгәең дип куркам.

Сылу әтисе белән гомумән ачыктан-ачык сөйләшеп үскән иде, монда да югалып калмады.

— Әти, син олы кеше, акыллы кеше, — диде. — Бар, сөйләш. Синең хакка мин әллә кемнәр белән дә уртак тел табарга риза. Тик теге украинский күлмәгеңне генә өлгертим.

Сылу әнисеннән чигәргә өйрәнгән иде һәм ике юллы украин күлмәге өлгергәч тә әтисе Хәлимә янына зур йомыш белән барырга тиеш иде, ләкин сузды, сузды. Колхоз идарәсеннән арып-талып кайтып керә

иде дә, кухня якка уза, балалар белән бергә аш пешерә, сөйләшә, уйный-көлә, бергә ятып йоклый, төнлә өсләрен яба, Хәлимә дигән карт кыз янына барырга, украин кулмәген кияргә тәки йөрәге дә җитми, вакыты да калмый иде. Менә нәрсәне көткән икән ул... Балалар ятимлекне сизмәсен өчен ул һәрвакыт йортка күтәренке күңел белән кайтып керә, кичен ашап, йокларга идәнгә тәгәри башлагач балаларын уйната, көлдерә, җырлата иде. Бигрәк тә марш атлатып йөртергә ярата, бу вакытта үзе дә җырлый иде.

Инде Сылу ике бала белән калырга әзер. Ә Асаф? Симетбаш урманчылыгында лесник булып эшләргә документ алган иде. Тормыш — ал да гөл булачак иде. Дөрес, Асафның да әтисе моннан берничә ел элек бәлага дучар булган, бердәнбер малаен, йортында зур бакчасын, урман хуҗалыгын, ун баш умартасын калдырып дөньялардан шәһит китеп барган җан иде.

Асаф бүген таңда военкоматка китәчәк, әнисе янында утырырга кирәк иде дә, әмма үз теләгең белән бу өч-дүрт көнлек бәхеттән аерылу мөмкинме? Ул ике ут арасында калды.

Кайчан башланды соң бу халәт? Ахрысы, утыз тугызынчы елның язынннан. Сылу, син кар астыннан чыккан ылыслар, ботак өемнәре, утын штабельләренең исен сизәсеңме? Май башында урманның сулышын тоясыңмы? Имән, карт чыршы башларына гына кагылып узган һава дулкынының тавышын сизәсеңме? Апрель ахыры иде бит, хәтерлисеңме? Бөтен авыл халкын ботак яндырырга чакырдылар. Умырзаялар чыккан, бөтен агачлар бүртеп утырган вакыт иде. Анда син, мин, Ташкичүдән тагын ничә кыз, Габделнур бер аумакта эшләдек. Өч авыл халкы шунда иде. Утны без бергә кабыздык. Син шул көнне миңа аерым бер генә сүз дә дәшмәдең. Хәтерлисеңме шуны? Бер генә сүз дә. Ахырдан, көлгә күмелгән бәрәңгеләрне ашап эшкә тотынгач, мин бөтен шау-шу арасыннан гел синең тавышны гына аерып алдым. Хәтерлисеңме, син гел бер җырны көйләп йөрдең?

Үтте инде, үтте ул вакытлар,
Башка инде синең уеңда...

Син моны болай гына, шул елда пластинкада чыккан модалы җыр булганы өчен генә җырладың. Ә теге сүзләр минем йөрәгемә уелып калды: үтте инде, үтте ул вакытлар... Хәтерлисеңме, ул көнне — без ботак җыйганда — күк тә чалт аяз иде, җил юк, салкынча бер көн иде? Ул көнне бөтен урман шау-у-у-у итеп тора иде. Мин шунда уйлап куйган идем, мин аны сиңа әйтмәдем, чөнки сез учак янында Габделнур белән шаярыштыгыз, мин нәрсәдер сизгән идем: җилсез көнне, чалт аязда агач башлары шаулау күңелгә шом сала. Минем шул тавышны ишеткәндә гел йөрәгем селкенә иде.

Таң атты, тузаннан күбенгән юлларны сирәк яңгыр тамчылары шадралады, Сылу белән Асаф бер-берсенә сыенган хәлдә ындыр артындагы киртәгә сөялеп торалар иде, ләкин теге — беренче төннең рәхәте, ашкынуы, тәннәрнең бер-берсенә ыргылуы ни тегесендә, ни монысында юк, сизелми иде. Ни хәл итәсең? Кинәт килгән бәхеттән югалып калган кебек, кинәт килгән аерылышудан да алар югалып калганнар иде.

Асаф өенә көтү кугач кына кайтты. Мич янында йокысыз төн уздырган Фатыйма апаның күзләре кызарган иде, ул малаена рәнҗүле караш ташлады. Гаделия дә барысын да аңлады: тирән йокысыз күзләреннән үпкә катыш бер караш сирпеде дә, өенә кайтып китте. Военкоматка барасы ат капка төбенә килеп туктаганда Асаф әнисе каршына утырып нибары бер чынаяк чәй эчкән иде.

...Кырык беренче елның салкын ноябре көнне Фатыйма апага килгән өчпочмаклы бер хатта мондый сүзләр язылган иде: «Әни! Өйдән

чыгып киткәннән бирле кайларда гына булмадым, нинди генә шартларда яшәмәдем. Монда өс бөтен, тамак тук — ул яктан барысы да кайгыртылган. Тик шунысы гына үзәкне өзә: нигә теге сөтле чәйне тагын бер генә чынаяк эчмәдем икән?»

## VI

Кырык беренче ел октябренең яңгырлы, юеш, кеше эт куып чыгармаслык караңгы бер төне иде. Сылу ян сәкегә, агач караватка балаларны тәгәрәтте дә (хәер, алар инде балалыктан чыгып баралар, өченчедә, бишенчедә укый торган малайлар) җиделе лампа яндырып әтисенә хат язарга утырды. Балалар мышнап йокыга киттеләр, ыңгырашасөйләшә, әйләнә-әйләнә йокладылар.

Эре яңгыр, җил белән бурый-бурый, тәрәзә яңакларына, чоланга, түбә кәрнизләренә бәрелә-бәрелә сеңдереп яуды. Конвертлар, маркалар саклана торган китап тышының эчендә элек килгән хатлар, иске җыр дәфтәрләре, адреслар, алачак-бирәчәкләр язылган кәгазьләр бар иде. Сылу шуларны актарып уйга калды. Әнисенең кәгазьләрен, эче пошканда төрткәләп куйган җырларын, гәрчә боларны күңелдән белсә дә, кабат укыды. Әнисе гомер буе Агыйдел ягын сагынып яшәгән. Бу якта аны, әлбәттә, чын мәхәббәте, балалары гына тоткан. Югыйсә, үләсе елны кеше шулай дип язып куяр идемени?

Агизелкәй һыузы кискән сакта
Тирән ере минең билемдән;
Биленләп [1] үк оскан кошкай кеүек
Сыгып кына киттем илемдән.

Җир йөзендә нигә шулай хәсрәт күп? Нигә гел йөрәк яна? Бу борчулар нигә?

Асаф китеп берничә көн үтүгә, Габделнурга да повестка килде. «Әтиеңнәр әле Казанда гына яталар, нинди йомышларың бар, тапшырам», дигән булып, бер көнне кич Габделнур килеп керде. Мөкаддир абзый киткән көннәр иде, өйдә ятимлек, күңелсезлек иде. Сылу иңенә кофтасын салып, Габделнурны озата чыкты, егеткә олы чырай, ирләрчә уйчанлык кергән иде.

— Су буена төшеп аз гына сөйләшеп утырыйк, — диде Габделнур. Сылу ялындырып тормады, тыкрык буйлап төшеп киттеләр. Габделнур пиджагын чыклы үләнгә җәйде, тончыга-тончыга папирос тартты. Сүз башлый алмады, ах та ух килде һәм шактый вакыт шулай газаплангач, авыр сулап әйтеп куйды:

— И-их, Сылу... Аңламадың мине. Кемгә алыштырдың? Ә бит бары бер кавыша алмаячаксыз...

Сылу зур күзләрен әсәртеп аңа карады:

— Нигә алай дисең? Болай да йөрәгем урынында түгел! Бу сугышта кем исән каласын кем белгән?

— Ә мин исән кайтырмын кебек. Әйткән ие диярсең. Мин кайтам. Яраланып булса да...

— Син соң яраланыр өчен генә барасыңмыни?

— Юләр булма. Илнең язмышын Симетбашның Асафлары, Ташкичүнең Габделнурлары хәл итми.

— Ә кемнәр соң?

— Техника, командирлар хәл итәчәк. Без түгел.

— Ә бөтен кызылармеец шулай уйласа? Мин хәл итмим, техника, командирлар, дисә...

---

[1] Биленләү — куркып качу. Кош-корт, терлеккә карата әйтелә.

— Теләсәң нәрсә әйт, бу сугыштан исән кайтырмын кук мин. Әгәр исән кайтсам, минеке буласыңмы?

Сылу дерелдәп куйды:

— Асафны үтердеңмени инде?

— Үтермәдем. Ул үзе үләчәк.

— Нигә?

— Юаш ул. Әрсез түгел. Бу сугышта юаш кешегә урын юк. Армиядә юаш кешегә гомумән урын юк. Беренче атнада ук беренче пуля астына башын куячак ул...

Сылу тагын калтырап куйды, урыныннан торды.

— Кешегә үлем теләмә. Икегез дә исән-сау кайтыгыз.

Аерылышу монда да авыр булды. Габделнур аның кулларын учына алып озак ычкындырмый торды. Аннан читкә борылды да, кулъяулыгын чыгарды. Җилкәләре дерелди башлады. Егет елый иде. Сылу югалып калды: Габделнур әйбәт, ыспай егет, эшкә әрсез, сүзгә кыю. Сылуны ул күптәннән — җиденче класстан бирле яратып йөри, китап алып торган булып аның эченә мәгънәле цитаталар кыстырылган кәгазьләрне аз бирмәде. Ташлытауда укыганда да бер китабына «ялгыш кына» бер дәфтәр бите кыстырып җибәргән иде. Янәсе, сочинениедән бер кисәк, шунда китерелгән цитата: «Я вас люблю, к чему лукавить...» Пушкин сүзләре бит ул, Габделнурның, янәсе, ни катнашы бар.

Кызый ул вакытта бу язуларны аңламаска тырышты. Педучилищеның икенче курсында укыганда (Сылу да ФАШның икенче курсында иде) Габделнур тагын Евгений Онегинны эшкә җикте. Ничектер, шимбә көнне бергә кайтканда мәхәббәт турында сүз куерта башлады. Сылу сабыр гына елмаеп аңа балаларча болай диде:

— Безгә әле ул турыда сөйләшергә иртәрәк бит... Әле без балалар гына бит...

Ә берничә көн узгач, үзеннән алып торган китап эчендә Сылу шәмәхә кара белән чуарланган «онытып» кыстырылган шакмаклы дәфтәр бите табып алды. Ярты бит кәгазьдә Габделнурның «Евгений Онегин»нан татарчага тәрҗемә ителгән бер өзеген укыды. Князь Греминның «Любви все возрасты покорны, ее порывы благотворны» дигән сүзләрен егет үзенчә, Ташкичүчә тәрҗемә иткән иде: «Мәхәббәткә маңка мешәйт итми...»

Яраткан өчен кешене ничек гаеп итәсең?

Ике арада мәхәббәт җепләре сузыла алмаганга рәнҗеп, Габделнур бервакыт Сылуның китабы арасына «Ромео һәм Джульетта»дан да бер тәрҗемә кыстырып җибәргән иде. Ул, гомумән, тәрҗемә итәргә ярата һәм шигырьләр дә язгалый иде. Әмма соңгысын аңлый алмыйча Сылу иза чикте:

«Рамай белән Җәмилә турындагы хикәядән дә хәсрәтлерәк хикәя дөньяда юк...»[1].

...Алар авыр аерылыштылар. Китап тышындагы кәгазьләр арасыннан әлеге тәрҗемә дә килеп чыкты. Хәзер Сылу янында Асаф та, әтисе дә, Габделнур да юк. Ян сәкедә, агач караватта тәгәрәп мыш-мыш килеп яткан ике малай гына бар.

Шыбырдап яуган яңгырның чолан ишегенә бәргән тигез тавышына ниндидер шыгырдау, шакылдау кушылды. Кемдер сак кына ишек кага иде. Сылу китап тышындагы кәгазьләрне җыеп япты, утны күтәрә төште һәм чоланга чыкты.

— Бу — мин, кызым, курыкма...

Портка манма сулы юка пальто, сукно кепка кигән, олайган, йончыган әтисе килеп керде. Кепкасын какты, юеш, авыр пальтосын кы-

---

[1] Нет повести печальнее на свете,
Чем повесть о Ромео и Джульетте.

зына бирде. Тәгәрәшеп яткан балалар янына узды, юеш кулларын чалбарына сөртеп, балаларның өсләрен япты, битләреннән сыпырды, тәпиләрен каплады. Аннан Сылуны кочагына алды, аны башыннан сөйде.

— Мин, кызым, ике генә сәгатькә, — диде.

Ата белән кыз ике сәгать буе чәй эчтеләр. Сөйләшкән тавышка балалар уяндылар да, тагын йокыга киттеләр. Олысы тормакчы да булып карады, әмма иләмсез, шыксыз көзге яңгыр шавы стенага бәреп торганда җылы өйдә йокы бик-бик тәмле иде. Кечесе дә уяныл карады, этисе чәй яныннан килеп битләреннән сөюгә елмайган сыман кыяфәт чыгарып, тагын йокыга китте. Ата кеше карлыккан тавыш белән сөйләде:

— Олысы сиңа иптәшкә калыр. Кечесен балалар йортына җибәрәләр. Военком шулай диде. Балалар йортында аңа әйбәт булыр. Ташлытау ерак җир түгел. Броньда калдырыйк дип тагын бәйләнеп маташтылар. Райкомда да икеләнеп калдылар. Мин, кызым, кешеләр барган җирдә булыйм инде. Минем барыбер йөрәгем җәрәхәтләнгән. Авыр вакытта, ичмасам, ил белән бергә булыйм. Әниең үлгәннән бирле, барыбер, кояшны, язны, җәйне күрмәдем. Монда кала алмадым инде.

Әтисе әлегә резервта — Мари урманнарындагы вакытлы лагерьда ята икән. Часть командиры иртәнге сәгать сигезгә килеп җитү шарты белән аны балалары янына җибәргән.

Сәгать өчтә яңгыр басыла төшкән иде. Ата соңгы кат балаларының битләрен сыпырды, төпчек улының маңгаеннан үпте. Авыр итеп бер сулады да, Сылуга кулын бирде.

Ишегалдындагы караңгыда лачтыр-лочтыр иткән тавыш ишетелде, бүрткән капка саңгырау гына ачылды да, лыскылдап ябылды. Мөкаддир агайның аяк тавышларын чолан баганасына сөялеп Сылу тыңлап торды. Атаның җылы өйдә бихәбәр яткан сабыйлары белән дә, буй житкән акыллы, сөйкемле Сылуы белән дә актык күрешүе иде бу...

## VII

Габделнур иртән шәһәр военкоматының ишегалдында Асаф белән очрашты. Әллә шатландылар күрешкәнгә, әллә юк, әмма нык кына кул кысыштылар, бер-берсенә сыендылар. Озак сөйләштеләр. Сылудан башка бөтен кеше телгә алынды. Кичкә таба аларның икесе дә бер командага эләккәнлеге мәгълүм булды...

Аларны колоннага тезеп иртәнге шәһәр буйлап вокзалга таба алып киттеләр. Строй кырыеннан шәһәр егетләренең туган-тумачалары, бала күтәргән яшь хатыннар, карт-коры атлап барды. Арада ак киндер алъяпкыч япкан, мескен бүрек кигән, камыт аяклы бер карт та бар иде. Алгы рәттә двухрядка тарттылар. Ачы тавышлы берәү җыр башлады.

Расцветали яблони и груши...

Вокзалда ташкүмер исе, маневр паровозларының ухылдавы, су алып торган паровозның чыжылдавы, гармун, җырлау, елау, команда тавышлары иде. Кызгылт-сары теплушка эченә кереп капчыкларны сәкегә куюга хәрби тормыш башланды. Кая алып баралар? Сугышның үзенәме? Әллә бераз өйрәтергәме? Ташлытауда өч ел укып винтовкадан нибары бер мәртәбә атып караган ике егетне алда ниләр көтә? Моны берәү дә белми иде.

Әмма сигез көн буе пошкыра-пошкыра чапкан состав команданы нарат урманы эчендәге бер тупикка китереп туктатты. Команда минерлар хәзерли торган Аерым Инженер Диңгез батальонының кыска сроклы курсларын үтәргә тиеш булып чыкты.

Соры стеналар эчендәге биек түшәмле казармаларга килеп кергәч ике катлы караватларга урнаштылар. Өч ел буе тулай торак шартларында яшәгән егетләргә беренче солдат ашы, кәҗүнни мендәрләр, простынялар гаҗәп булып тоелмады. Килеп урнашкан көннән үк төштән соң дәресләр башланды.

Монда дисциплина каты иде, июнь аендагы зәңгәр кичләр, гүзәл кызлар, кояшлы иртәләр, матур планнар — барысы да дөньяның теге ягында калды. Дөнья, тормыш ике өлешкә бүленде: аның беренче өлеше егерме икенче июньгә кадәрге чордан тора. Анысы — матур төш. Икенче өлеше — Ташлытау военкоматыннан тимер юл станциясенә чыгып киткән сәгатьтән соң. Анысы — өн. Анысы — реаль. Хәзер әнә шул матур төшне хәтерләп чынбарлыкта яшәргә кирәк. Чынбарлык исә — кырыс, гадәттән тыш кырыс.

Курслар начальнигы, кара кителенә алтын нашивкалар теккән кырык яшьләр чамасындагы кеше, строй каршына басып, кыскача гына бурычны аңлатты:

— Дошман корал белән килә, — диде. — Сезнең барыгыз да алтыжиде класс белемле егетләр. Арагызда урта белемлеләр дә бар. Сезне тылда бәлки, винтовкадан төз атсаң, дошманны җиңеп була, дип өйрәткәннәрдер. Винтовкадан төз ату — яхшы нәрсә һәм кирәкле. Әмма дошман танклар, мотопехота, су асты көймәләре, минометлар, авиация белән килә. Куәтле техникага каршы винтовка — көчсез. Безнең бурыч — миналарны өйрәнү. Туган кырларыбызга, диңгезләргә дошман аяк басмасын өчен аның юлына шартлаткыч миналар кую. Ә мина — бик мәкерле корал. Акыллы кеше кулында ул — куәтле иптәш, ярдәмче. Ачык авыз кулында мина — һәлак иткеч көч, ул үзеңне дә, иптәшеңне дә, бөтен бер взводны да бетерә. Мина, шуның өстенә — психологик корал. Дошман гаскәре синең иген басуыңны, болыныңны таптап кергән вакытта алдында бер мина шартласа — арттан килүчеләрнең масаюы бетә. Юлга, күпергә, тимер юл шпалы астына куелган бер мина кайвакытта шәһәреңнең, меңләгән халкыңның, бөтен полкның язмышын саклап калырга мөмкин. Сез ике атна эчендә әнә шул көчне, кешегә дус та, дошман да була ала торган көчне өйрәнергә тиешсез. Әмма үзебезнекен генә түгел, сезгә дошман коралын да өйрәнергә туры киләчәк...

Арада бер генә олы кеше дә юк, барысының да шинельне өсләренә беренче кат киюләре иде. Иртәнге алтыдан төнге унбергә кадәр бер генә минут та буш вакыт калмый, төннәрен тревога белән күтәрәләр, марш-бросоклар ясаталар иде. Иң авыры, әлбәттә, төнге тәмле йокыдан уяныл сикереп тору, аннан-моннан киенеп стройга басу иде.

Асаф төннәрен еш кына гаҗәеп татлы төш күрә, шуңа күрә хәрби хезмәтнең авырлыкларына чыдамрак, сабыррак карый, аларны җиңәргә үзен өйрәтә иде. Казармада күзеңне ачу белән Устав кагыйдәләре синең баш миеңә бәреп тора. Кая карама — кырыслык, кырыслык.

Әмма Асаф янына ак күбәләк булып очып килгән Сылу боларны белми иде. Асаф янына ул төн урталарында килә, аның белән ничәдер секундка гына гаҗәеп кыска, сихри бер очрашу булып ала иде. Төннең шуннан соңгы өлеше инде бөтенләй кирәксезгә, мәгънәсез сәгатьләргә әйләнә. Төннең ул өлешен ни эшләтсәләр дә, егет риза иде... Тик шунысы кызганыч, бөтен тәненә рәхәтлек биреп ай нуры төсле эчке күлмәк кигән ялангач аяклы, ялангач җилкәле, кайнар тәнле бу әкият кызы калын тарау чәчләре белән солдатны чорнап, аның тынын кысып, билгесез, газаплы, әмма рәхәт дөньяга алып киткәндә генә нигәдер уяныла, кавышып булмыйча кала иде. Һәр очрашуда, нигәдер, гел шулай — ул кызның бөтен тәненнән ай нуры — яшькелт көмеш нур бәреп тора, еш кына егет шул нур эчендә колач җәеп йөзә, кыз

янына килеп житә, сихри ләззәткә чума һәм нәкъ шул мизгелдә уянып китә иде.

Бер дөньядан икенче бер дөньяга кинәт күчү, әлбәттә, авыр иде. Бүген дә шулай булды. Сылу әллә нинди, гомердә аңа хас булмаган тавыш белән көлде дә көлде — алар яшькелт нур эчендә бер-берсенә каршы йөзәләр, имеш. Ләкин кыз берни дә әйтми, бары тик чылдырап көлә генә... Менә, менә алар якынайдылар, менә, менә бер-берсенең кулларыннан тотыштылар, йөзеп килгән уңайдан егет аның шома, түгәрәк җилкәләреннән кочып алды, ә Сылу һаман көлде: чылдыр-р-р, чылдыр-р-р. Бу көлүне тыңлау нигәдер бик газаплы иде, бу көлү Сылуның елмаюын, аның табигыйлеген үтерә, мондый ясалма көлү тавышы ишетелгәндә Сылу белән сөйләшеп булмый иде...

— Тревога! Тревога! Тревога!

Казарманы селкетеп электр кыңгыравы зыңгылдый икән...

Күзгә төртсәң күрмәслек, яңгырлы, бозлавык бер төн иде. Кая алып баралар, нигә? Моны берәү дә белми, тик алга таба атлыйлар, таялар, егылалар иде.

— Отомкнуть штыки!

Рота командиры капитан Якушевның кискен, карлыккан тавышы ишетелде. Ахрысы, кемдер егылган да, штык очы белән кемгәдер төрткән. Якушев алдан үзе бара, кызу атлый, вакыт-вакыт колонна сузыла, арттагыларга усал команда яңгырый:

— Подтянись!

Тагын йөгерү, приклад, затвор тавышы, бозлы җиргә кодырдатып баскан йөзләгән итек, ботинка тавышы, мышкылдау, уфылдау, йөткерү — колонна бер сүз дәшмичә алга бара иде. Сәгать ярым баргач, урман кырыенда туктадылар. Ун минутка ял игълан ителде. Егетләр мышкылдаган, бит-башларыннан пар бәрә, җилкәләре бер күтәрелә, бер төшә иде. Еракта, кара болытларны авыр кызгылт төскә буяп, газапланып таң атып килә иде. Киргә таба кайтканда да марш-бросок белән кайттылар. Рота казармага кергәндә иртәнге подъем уйныйлар, хәрби хезмәт көне башланып кына килә иде.

— Юк, мин икенче частька күчерүләрен сорап язам, — диде Габделнур, иртәнге ашка барганда. Ул авырдан сулый иде. — Бушка йөгереп йөрер вакытмыни хәзер? Бу — ниндидер корткычлык. Минем урыным — алда, фронтта. Я минем кулыма корал бирсеннәр дә, дошманга каршы җибәрсеннәр, я...

Анысын ул әйтеп бетерә алмады, ашханә ишегеннән кергәндә строй таралды.

«Я» нәрсә? Нәрсә ул «я»? Асаф шул турыда уйланды. Габделнур аз сөйләшә, үз эченә батып йөри, читтән карап торганда бу ике егетне өч ел бүе бергә укыган, гомер буе аралашып яшәгән ике күрше авыллыкылар дип әйтү кыен иде.

Икенче көнне иртән казармада ыгы-зыгы булып алды. Иртәнге приборкага тотынганнар гына иде, аскы яруста йоклаган юаш кына белорус малае Марчукның соры одеялы өстән юеш булып чыкты. Тикшерү китте. Өске ярус Габделнурныкы иде. Военврачны чакырдылар.

— Ие, минем шундый гадәт бар, мин гел шулай, — диде Габделнур, врач каршына килеп.

Асаф шул вакытта аның күзләре белән очрашты. Егет бөтенләй үзгәргән иде. Асафка ул ялвару катыш нәфрәт белән карады.

Ул көнне Габделнурны аскы яруска күчерделәр. Инде миналар кую, кырны-урманны минадан чистарту буенча практик занятиеләр башланган иде. Егетләрнең үз өйләреннән аерылгач бер кат ябыгып, тәннәренә кәжүнни ит — солдат мускулы сала башлаган көннәре иде.

Габделнур бер тәүлек эчендә тагын үзенә ике тапкыр игътибар юнәлттерде. Аркага противогаз, винтовка, көрәкләр асып ун чакрымга

марш-бросок ясаганда, ул кинәт кенә стройдан чыгып читкә тәгәрәде. Капитан Якушев аңа карап маршны туктатмады, бары тик колонна ахырында баручы ике курсантны гына стройдан чыгарып, Габделнур янында калдырды. Монысында да төнге тревога белән чыкканнар иде. Иртәнге сәгать өчтә генә кайтып караватларга егылдылар, тирән тәмле йокыга чумдылар. Әмма иртәгесен бүлмәдә приборка ясаганда Габделнур караваты астына керүдән курсантлар баш тартты.

Курсларның старшинасы мичман Кравец килеп керде. Габделнур күз дә йоммыйча аның каршында бер генә нәрсәне тукып торды:

— Менә мин шулай, иптәш мичман. Мин гел шулай. Мин өйдә дә шулай идем...

Курсантлар күзләрен читкә бордылар.

Особый отделдан килгән өлкән лейтенант ярты көн буе курс начальнигының бүлмәсендә утырды. Асафны да чакырттылар.

— Сез Минҗанов Габделнурны ни вакыттан бирле беләсез? — дип сорады битеннән кан качкан, ябык йөзле тикшерүче.

— Болай беренче класстан алып ук. Безнең авылларның арасы бер генә чакрым. Аларныкы — Ташкичү, безнеке — Симетбаш.

— Ә тегеләй ничек?

— Тегеләй өч ел бергә укыдык. Бер бүлмәдә яшәдек, ул укытучы булырга дип әзерләнгән иде.

Тикшерүче Габделнурның әти-әнисе, бабалары турында сорашты. Хәер, бу мәгълүматлар аның өчен яңалык түгел иде бугай, ул бер уңайдан Габделнур Минҗановның якташы Асаф Рәимовны да тикшерде.

— Беләм Минҗан абзыйны. Гомер буе трубка тарта. Безнең якын тирәдә трубка тартучы юк бүтән. Аны белмәгән кеше юк. Ярлы гына семья. Сыер асрамыйлар. Колхозда төрле эштә йөри. Ат җигеп.

Асаф тикшерүченең алдындагы кәгазьгә күз кырые белән карап алды: тикшерүче тырышып-тырышып трубка капкан кеше башын ясый иде...

Октябрь ахырында курсларның эшен ашыгыч рәвештә йомгакладылар. Курс тәмамлаучыларның бер группасын Аерым Диңгез Бригадасы карамагына җибәрделәр. Алар арасында Асаф белән Габделнур да бар иде.

Бригада штабы куе ылыслы урман эчендә, Онега буендагы бер хуторда иде.

Унсигез яшьлек «салагалар»ны инде ут эчендә булып өлгергән өлкәннәр — диңгез пехотасы матрослары ярым кызгану, ярым мыскыллы караш белән үз араларына кабул иттеләр. Монда тәртипләр икенчерәк, матрослар бушлат, күн итек кигән, сакал җибәргәннәр, монда төймә ычкындырып йөрергә дә, стройга басмыйча йөрергә дә, теләгән вакытта җыелышып утырып тәмәке төреп алырга да мөмкин иде.

Әмма кешеләрнең йөзләрендә шатлык юк, уен-көлке юк, бары тик ниндидер — яшьләргә әлегә билгесез — киеренкелек, гадәттән тыш җитдилек, сүзсез җитдилек бар иде.

Бомба тавышлары әлегә монда ишетелми, ләкин комсоставның ашыгыч, ыгы-зыгы килеп йөрүенә карап, зур хәлләрнең инде ерак түгеллеген чамалап була иде. Сугыш, үлем, яралану, курку—барысы да якында гына һәм котылгысыз иде. Әмма, нәрсә ул сугыш, яра нәрсә, сугышта ничек үләләр, курку никадәрдән никадәргә була ала — боларны әле беркем дә күз алдына китерми иде. Беренче көнне үк яшьләр алдында чыгыш ясаган өлкән политрук Тихвин, Волхов янында канлы сугышлар барганын, Олонец ягыннан дошманның бик көчле группировкасы һөҗүм белән килүен, Ладога—Онега арасындагы Лодейное Поле га чыгып, Ленинградка көнчыгыштан бәреп керергә җыенганын сөйләде.

— Бөтен көчне хәрби хәзерлекне арттыруга, техниканы өйрәнергә куярга, сезнең хәрби хәзерлегегезнең сыйфатына Ватанның язмышы бәйле, — диде. — Дошман безгә каршы зур көч белән, безне бетерергә дип килә, сүз — фронтның теге яки бу участогында дошманны тоткарлау турында гына бармый, аны бәреп чыгару, бетерү турында бара, чөнки безнең яшәү яки яшәмәвебез үлчәү тарелкасына куелган.

Ылыслы урман эчендәге хуторга, бозлы-комлы юлларны казып, үкерә-үкерә техника килә, кием-салым, азык-төлек төягән машиналар агыла, дивизия зур һөҗүмгә әзерләнә иде...

## VIII

Минҗан карт тышкы кыяфәте белән бик ямьсез кеше иде — яньчек борынлы, йөнтәс кашлы, черек тешле, чыгынкы яңакларына йон үскән, чепи күзле мондый иләмсез адәм якын-тирә авылларда берәү генә һәм Ташлытау базарында да моны белмәгән кеше юк, «Ташкичү Минҗан» дигән сүз картның кыяфәтен бөтен район халкының күз алдына китереп бастыра ала иде. Табигать тарафыннан аның болай кимсетелеп тууының сәбәбен дә сөйлиләр иде. Аның әти-әнисе әүвәл бай сәүдәгәрләр нәселеннән булган. Бабалары Минзәлә, Эрбет ярминкәләрендә эш йөрткәннәр, пар ат белән ярминкәдән кайтып кергәндә басу капкасын ачкан балаларга прәннек өләшә торган гадәтләре булган. Үсеп буй җиткән малайларына — яңача эш итәргә өйрәнеп килгән сәүдәгәр егеткә—күрше баеның кызын алып биргәннәр. Имеш, Ташкичү җыенына парлап килгән яшь бай үзенең калфаклы, ефәк шәлле, шыртламалы озын кунычлы ботинкалар кигән яшь кәләше белән урам уртасыннан бара икән. Чирәмле урам уртасында уйнап йөргән балалар янына килеп, яшь бай аларга чикләвек өләшкән. Шул вакытта байлар кабык көймәле арбада йоклап яткан бер сабыйга күз төшергәннәр. Үзләренең дә бала көткән һәм, һичшиксез, малай көткән заманнары булган бу. Малай тусын дип мендәр астына балта салып яткан көннәре булган. Шуңа күрә кабык көймәле бала арбасы яныннан болай гына узып китә алмаганнар алар.

Озын керфекләре белән түгәрәк күзләрен каплап, матур алсу гәрәбәдәй борынын дерелдәтеп «мес-мес» килеп йоклап яткан бу сабыйның гүзәллегеннән ай белән кояш көнләшерлек булган. Бай мәгънәле итеп бикәченә карап алган: янәсе, менә берничә айдан син дә шундый бер асыл зат белән мине сөендерерсең...

— Бу углан кемнеке? — дип сораган бай.

Авылның иң фәкыйрь бер кешесенең исемен атаганнар. Бай авыр сулап, үзенең яшь бия кебек уйнаклап торган тулы тәнле, мут күзле хатынына караган һәм болай дигән:

— Бу фәкыйрьләрдән дә шундый гүзәл бала тугач, безнеке нинди булыр икән ул? — дигән.

Күрәсең, бай көфер сүз сөйләгән...

Колак артында уч төбе кадәр миң белән туган балага — Минҗан дип исем кушканнар. Миң баланы калдырмаган, заманнар узгач, ул миңгә инде җыерчыклар сызылган.

Минҗан картны күргәч этләр дә өреп кала иде. Ләкин карт моңа инде ияләнгән һәм ул берәүдән дә яшермичә трубка тарта, берәүдән дә тартынмыйча шәп итеп сүгенә белә иде.

Минҗан картның Гаделиясе — семьяда бердәнбер кыз бала һәм семьяны алып баручы төп көч тә иде. Җиде классны тәмамлагач та ул Симетбашта колхоз идарәсенә табельщица булып урнашты, кайтып-килеп йөрергә ара бер генә чакрым булса да, Симетбашта ялгыз хатын Мәүгыйзәгә фатир төште. Теләсә куна, теләсә — өенә — Ташки-

чүгә кайтып йөри иде. Әтисе рәтсез кеше булды, каралты-кураны карамады, сыер асрамады. Сыер асрамаган кешенең авылда бер дә дәрәҗәсе юк иде. Абыйсы Габделнур белән Гаделия бу хәлгә бик кимсенәләр, авыл яшьләре кич урамда, капка төбендә утырганда сыер, сөт-май турында сүз чыгарсалар, Гаделия моны үзен мыскыллау өчен башланган сүз дип кабул итә, эчтән генә елый иде.

Кичен көтү кайткач авылда җылы тузан басыла, урамга агачлар, капка-коймалар аркылы батып барган кояшның нурлары төшә, көндезге эсседән йончыган авыл рәхәт кенә тынып кала. Капкалардан терлек-туар кереп беткәч, ишегалларында чиләк, кәстрүл зыңгылдаганы ишетелә, урамда адашып йөргән аңгыра сарык бәтиләре чиләк-кәстрүл тавышы килгән хуҗалыкларның капкаларына барып мөлдерәтеп карыйлар, юеш танауларын капкага төртеп, ачы тавыш белән кычкыралар. Нечкәләп тыңлаган ул тавышта ятим баланың «әтием кайда? Кайда әнием-м-м?» дип тыпырчынып елаганын ишеткәндәй буласың. Ә бу вакытта ишегалларында җәйге кич өчен генә хас булган җыр тарала, хатын-кызның «түгәнәй», «түчә!» дип сыерларга кычкыргалап алуы ишетелә, аннан инде бөтен авыл сөт сауган тавышка күмелә: көтүдән туеп кайткан сыерларның тыгыз җиленнәреннән чиста чиләк төпләренә «тез-з-ө, тез-з-з» итеп сөт бәрә, бу тавыш һәр ишегалдыннан ишетелә, бу тавыш, иминлек, бөтенлек, тазалык, житкелек билгесе булып, бөтен авылда ләззәтле, бары тик крестьян гына аңлый торган бер музыкаль әсәргә әйләнә — ир затлары канәгатьлек хисе белән шыңгырдатып капка ачалар, бер дә кирәкмәскә урамның ике ягына да карап алалар да, кереп китәләр, ә ишегалдында рәхәтлектән күшәп торган сыердан чиләккә сөт агыла. Чиләктә сөт ишәйгән саен сөтнең тавышы үзгәрә, сыер да инде савучыга караштыргалап ала. Йорт хуҗасы ир — зур канәгатьлек белән сыерына да, күбекләнеп тулып килгән ак чиләккә дә күз сала. Таза ботларын иркенләп җәеп чүгәләгән юантык беләген сызганып ике куллап сөт тарткан хатынына да сокланып, мактанып карап ала, сыер имиен тарткан саен хуҗа хатынның аркасындагы чәч толымнары селкенә, калын таза күкрәкләре кул уңаеннан әле бер, әле икенче якка йөри...

Аннан, киемнәрен алыштырып, хатын-кыз түбән очтагы Мәүгыйзәгә — колхоз сепараторын тотучы хатын йортына таба атлый. Сөт күтәреп урам буйлап сепараторлы йортка бару — авыл хатыннарының сәхнәгә чыгулары. Кемдә нинди көянтә-чиләк? Кемдә нинди күлмәк, нинди алъяпкыч? Кем ничек атлап бара? Менә безнең сыер нинди — ике көнгә бер көянтә-чиләк сөт! Менә минем чиләкләрем, көянтәм нинди! Без — таза тормышлы. Менә мин ничек җиңелдән атлыйм! Менә мин ничек, ирләр күзен әсәртерлек, аларны исәрләндерерлек итеп атлый беләм, тик алдан түгел, арттан карап калыгыз. Ирләрнең атлавын алдан бәялиләр, ә хатын-кызның аяк атлавының матурлыгы бары тик арттан гына күренә.

Гаделия әнә шулай кызыгып яшәде, сыер алмыйча ике-өч кәҗә асрап көн иткән рәтсез әтисенә мәңгегә рәнжеде. Симетбашта идарәдә эшли башлагач та сыерлы хатынга фатир төшүне үзенә максат итеп куйды һәм шуңа иреште дә. Әмма Мәүгыйзә ялгыз иде, аның сыеры гына әле тормышны бизи алмый, бәхетле булу өчен әле тагы да нәрсәдер кирәк иде. Нәрсә кирәк? Гаделия моны әле аңлап бетерми, тик ялгыз башына сыер асраучы Фатыйма түтинең Габделнур белән бергә укып йөргән бердәнбер улы Асаф еш кына аның күңеленә керә һәм шул егет турында уйлаганда, ни өчендер, Гаделиянең йөрәге ургып-ургып тәнгә кан куа, сулышын томалап ала иде. Нигә икән ул? Кайвакытта Гаделия гап-гади генә итеп уйлап куя, менә бер бәхетлесе бу түтинең килене була инде, дип кемгәдер кызыгып, көнләшеп, авыр сулап ала, аннан үз-үзеннән оялып, бу фикерне тизрәк читкә куа иде.

...Асафка дип адресланган повестканы Гаделия хат ташучыдан үз кулы белән алды. Идарәдә ялгыз иде. Нәрсәдер булды, нидер өзелде. Әлегә яшәү өчен өмет бар иде. Дөрес, сугыш башланган көнне этисе Минҗан карт кичен баскыч төбендә трубкасын суырып утырганда әйтеп ташлаган иде:

— Бу Фатыйма малаеның Мөкаддир кызы белән борчаклары пешә бугай. Урман буенда имән төбендә... Тфү! Аналарын орыйм...

Моңа этисенең ике ягында утырган Габделнур да, Гаделия дә сискәнделәр. Тик кәҗә савып утырган әниләре генә битараф калды.

Шулай да повестка бөтенесен дә үзгәртте. Ничек? Асаф, әле генә укуын тәмамлап Симетбаш урманына эшкә кайткан Асаф, хәзер сугышка чыгып китәргә тиешме? Әле бит көзгә Октябрь бәйрәменә спектакль куясы булыр иде. Яшь урманчы белән идарәдә эшләүче кыз оештырмаса, кем оештырсын аны? Их, уйнарга иде бер Галиябану — Хәлил булып!

Ә повестка рәхимсез!

Әйе, теге төнне ул үзе белеп Фатыйма түтигә ярдәмгә — төн эчендә жылы оекбашлар бәйләп бирергә дип килгән иде. Оекбашлар бәйләнде, әмма сөйкемле егет ятлар кулында булып чыкты. Минҗан картның сөйләгәне дөрес икән. Башкорт каны катышкан хатын-кыз ирләрнең ниндиен, ничек эләктерәсен белә шул ул. Без белгәнне алар инде әллә кайчан чыгарып элгән. Димәк, соңгы төнне ул фельдшерица Сылу янында уздырды.

Хатын-кыз кешеләрдәге бөтен кимчелекләрне, кешеләрнең аңа салган бөтен зарарын гафу итә ала, әмма бер кешегә карата аның хөкеме катгый. Монда ул беркайчан да, беркемне дә гафу итми: мәхәббәтенә аяк чалучы — хатын-кызның гомерлек дошманы. Ул әле Асафны да гафу итәр иде, чөнки әлегә бернинди вәгъдәләр бирелмәгән, әлегә сөйләшү булмаган, егет ирекле иде. Сугышка китеп бармаса, егетне әле каратырга мөмкин булыр иде. Әмма Сылуны берничек тә гафу итеп булмаячак. Чөнки ул Гаделиянең иң газиз хисләрен таптады, аның тормышына бәхет җырын җырларга дип тартылган иң нечкә кылларны өзде, шул кыллар өзелгәннән бирле Гаделия өчен тормышның бер кызыгы да калмады. Сугыш башланды ни, бетте ни...

## IX

Октябрьның шыксыз тоташ яңгырларыннан соң кинәт кенә аязды, коры жылы көннәр башланды. Көзге саргылт кояш нурында җылынган яфраклар ботакларыннан берәм-сәрәм өзеләләр дә, тиккә генә һавада бөтерелеп, кыштырдашып җиргә төшәләр. Бәхет яки бәхетсезлек төшенчәсе яфраклар өчен дә бардыр ул. Менә аның берсе үз агачының кәүсәсе тирәсендә генә бөтерелә-бөтерелә дә, шуның төбенә генә ята. Анда аның иптәшләре, жылы, хисләргә бай җәйне бергә уздырган дуслары, ул шулар белән берлектә көзге салкыннарны уздырырга, бер-беренә сыенып кар астында калырга риза, аннан бергәләп череп ашлама булырга, үзен тудырган агачның тамырларына керергә һәм кояшта җылынган кәүсә буйлап өскә таба үрмәләргә, яңадан бөре булырга өметләнә. Көннәр үтәр, кояш белән җылынган бөреләр бер көнне ачылырлар, яфрак үзенең якты сыек элпәсе белән тышка үрелеп карар һәм шатланудан үз туганнарына беренче авазын салыр:

— Исән-сау әйләнеп кайттыгызмы?

Бу тавышка бик күп яшь яфраклар кушылыр.

— Саулармысез! Ничә елдан соң күрешәбез!

— Безнекеләр бар да мондамы?

— Хәтерлисеңме теге елны? Ул ел безнең беренче туубыз иде... Ә нигә башкалар күренми?

Тик карт агач кына дәшмәс. Ул яна туган балаларын тибрәтер генә. Салмак кына шаулар, аларга бишек жыры жырлар.

Башкалар нигә күренми? Моны карт агач кына белә. Б а ш к а л а р көзен өзелеп җиргә төшкәндә очраклы рәвештә узгынчы һава дулкынына эләктеләр, алар кәүсәдән ераграк төштеләр, ә ул урын аязлык иде, ул урыннан еш кына шаян җил уза иде, теге яфраклар — б а ш к а л а р — әнә шул шаян җил белән читкә киттеләр. Анда аларның кайберләре чыршы, нарат төбенә түшәлде, кайберләрен инде усал җил күреп алды һәм салкын, ялангач кырга алып чыгып китте. Җилләр көзге сары яфракны шулай әнисеннән аердылар.

Адәм баласы, син дә шулай түгелме соң? Синең дә язмышың әнә шундый шаян җилләр, явыз җилләргә бәйле түгелме соң? Тормышка аяк типкән, җирнең, яшәешнең бөтен рәхәтен, гүзәллеген әле генә тойган бу баланы да әнә шундый шаянмы, явызмы бер җил каядыр читкә алып ташламыймы икән соң?

Кайда икән ул, т е г е вакыттагы, т е г е агач төбе? Кайсы имән төбе иде соң ул? Нигә генә бүген шулар искә төште соң әле? Хәер, Ташлытауда райздрав бүлегеннән эш бетереп чыккач, йөрәк, үзенә урын таба алмыйча, сикерә башлаган иде. Сылу шул вакытта үзен тулысынча хисләр карамагына тапшырды. Ул үзе өч ел яшәгән тулай торак бинасы янына барды, күзләре әллә күрде, әллә күрмәде — шул тирәдә йөрде. Тулай торак бинасы үзгәргән, бик нык үзгәргән иде, анда инде көләч йөзле кызлар тавышы чыкмый, аның бүлмәләрендә жыр, көлү авазлары яңгырамый — монда Сылулар заманыннан берни дә калмаган иде! Ташлытау урамында саргылт, тын кояш нуры, кешеләр сөйләшмиләр, бары тик түбән карап, алга таба атлыйлар гына.

Ташлытауның яшел тимер рәшәткәле бакчасы эчендәге сары алтын гөмбәзле ак чиркәү дә, ике катлы агач тулай торак та, еракта җәйрәп яткан болын да, зәңгәр күк белән тоташкан саргылт камыллы монсу кырлар да шөбһә-шик белән зыңгылдыйлар, адәм баласының нервларын актык чиккә кадәр киерәләр. Бу шомлы тынлыкны бөтен тән сизә, моның тәэсиреннән чыга-ычкына алмыйсың, шунда каядыр чыгып китәсе, моннан котыласы, азат буласы килә, бәлки урманга, болынгадыр, бәлки урылмый калган сабан ашлык басуынадыр, әмма мондый зыңгылдавык тынлыкта озак торып булмый...

Сылу аптекага кереп дарулар алгач, шулай кырга-юлга ашыкты. Нәрсәдер мәңгегә югалган иде, бәлки ул кыйммәтле әйбер менә шушында — егерме икенче июнь көнне көндезге сәгать уникеләрдә Асаф белән алар бергә күккә карап яткан урында — имән төбендә калгандыр...

Кинәт... Кинәт... Сылуның йөрәге урыныннан ычкынып җиргә китте, аның күз алдында билгесез томаннар, бөҗралар йөгерде... Карт имән төбендәге саргайган, корыган үлән арасында кипкән ут чәчәге бәйләме ята иде... Әйе, Асаф ул көнне әйткән иде:

— Ут чәчәген өзмә, ул чәчәк йортка бәхетсезлек китерә, дип әйтә минем әни, — диган иде. Ул аны шаярып әйткән иде. Хәер, ул көнне алар гел шаярып кына сөйләштеләр һәм Минҗан карт килеп чыкмаса һаман шаярасылар, бәхетле буласылар иде...

Ут чәчәгенең таҗ яфраклары коелган, сабаклары нечкәреп көйгән, тик шулай да бик истәлекле, бик кадерле булып, Сылуны көтеп ята иде ул бәйләм.

Корыган сабакларны кадерләп аралап алды да, гыйшык тоткан, авыр заманның бөтен авырлыгын үз өстенә алган кыз бала истәлекле юл буйлап кайтырга чыкты.

Урман почмагыннан Симетбашка кадәр ике чакрым юл иде. Юлның ике ягын да сөргәннәр, атналар буе яуган яңгырны сеңдергән җир күпереп, майланып калган, күзге саран кояшта ул җылынып пар бәреп утыра иде. Юл туп-туры авылга таба түбән төшә, тузанның заты да юк, туры юл тапталган һәм табадай шомарган иде. Соңгы атналар, соңгы кояш, соңгы җылылар инде бу, кара балчык күпереп яткан басу өстендә тургай тавышлары да юк, чикерткәләр дә сайрамый, инде пәрәвез дә очмый, көзге карлы-бозлы яңгырлар, кырыс җилләр башланыр алдыннан кырның-яланның кешеләр белән моңсу гына аерылышуы инде бу. Кояш та инде теге вакыттагы кебек җете кыю түгел, ул да үзенең хәлсезлегеннән кыенсынып, капка төбенә чыгып моңсу елмаеп торган авыру хатын кебек, җирне җылыта да, җылытмый да кебек...

Менә авыл ягыннан берәү юлга чыкты, хәзер каршыңа кем килсә дә уңайсызланасы, чәч-битләрне рәтлисе юк, кем генә каршы килсә дә, ул — хатын-кыз булыр, ашыгучы булыр. Хәзер юлда акрын йөргән кешене күрмәссең, элек кенә ул, юл йөрү — бер сәнгать, зәвык эше итеп карала иде. Егерме икенче июньгә кадәрге хатын-кыз күрше авылга, Ташлытауга барасы булганда юлга бер көн алдан әзерләнә иде.

Чыга хатын-кыз юлга, җәйге җиләс көнне уҗым арасыннан сузылган чикерткәле-тургайлы басу юлыннан килә, караучы бармы аңа, юкмы, барыбер, әмма хатын-кыз шул юлда көяз атлап күрше авылга йомыш белән бара. Атлаган саен җәйге шаян җилдә аның алъяпкыч канатлары, җилфер-җилфер килә, чәч толымнарындагы авыр талир тәңкәләре чалтыр-чолтыр итә, төз, көяз туры муенын селкетмичә генә баш өстендә ак төенчек алып бара ул, бу барышның, бу атлауның үз ритмы, үз көе бар, бу — атлау гына түгел, бу авылдан теге авылга бару гына түгел, бәлки матурлык, көязлекне күрсәтү, юлда беркем дә булмасын, әмма әнә шушы сәламәтлекне, көязлекне, ыспайлыкны җил, кояш, тургайлар, чикерткәләр күрсен, күк гөмбәзендәге тилгән күрсен... Талир тәңкәләр чыңласын, аларның бәрелешеп чыңлавына атлау үзе бер рәхәт, шулай калын чәч толымнарында чыңлый-чыңлый ул тәңкәләрдәге патша башлары инде шомарып беткән, ул патша башлары әнә шул көяз, ыспай татар кызларын, киленнәрен гасырлар буе инде кайларга гына озатып йөрмәгәннәр...

Әмма ул элек — егерме икенче июнь көненә кадәр шулай иде. Авыл ягыннан Сылу каршысына килүче хатын-кыз исә алай көязләп тормый иде, ул ашыга иде, һәм баш түбәсендә ак төенчеге дә юк иде аның, канатлы алъяпкычы да юк иде. Аның башында өчкелләп маржача бәйләнгән яулык, өстендә кыска җилет, кулында портфельме, сумкамы — нидер бар, үзе ашыга иде, күрәсең, эш белән Ташлытауга бара.

Сылу бу истәлекле юлдан атлаганда дөньядагы башка әйберләр турында һични уйлый алмый, аның күз алдында җылы җилле, сөрмәле теге көн, юл буендагы тыгыз башлы куе арыш һәм балавыз исе сыгылып чыккан шул арыш башакларының аның дәрт тулы, яшәргә ыргылган, беренче ашкыну дулкыны белән шашкан ялангач күкрәк очларына лыс-лыс бәрелүе һәм кичә табып бүген югалтачак булган сөякчел тәнле, куе кара чәчле, аз сүзле, буйчан яшь егет иде. Шул минутлар аның бәгырен телгәли, бу кыр, бу ялан аны хыял дөньясына гына алып китә иде. Газаплы, татлы хыял эчендә адымнарын ялгыштыргалап атлый торгач, Сылу, каршысына килгән хатын-кызны танып, сискәнеп китте: портфель тоткан, өчкелләп яулык бөркәнгән кыз Гаделия икән. Гаделияне күргәч, Сылу матур хыялларыннан айнып китте һәм туры карап аның каршысына таба атлады. Ара — ике йөз адымнар чамасы иде. Сылу үзенең хыяллары белән бәхетле иде һәм каракаршы килеп сөйләшкәндә ул үзенең шул хыялларының бер өлешен генә Гаделия белән уртаклашасы иде. Хатын-кыз үзенең хәсрәтен, үз

борчуын, кара кайгысын беркем белән дә уртаклашмыйча үз эчендә тота ала, әмма шатлыклы серен, бәхетен, гыйшкын кеше белән уртаклашмыйча булдыра алмый. Бәхет, шатлык әнә шулай уртаклашкан саен арта бара кебек тоела аңа.

Ике йөз адым, йөз туксан адым — авыл халкы мондый араны «бер җир буе» дип атый. Әйе, нәкъ бер җир буе ара калганда Гаделия, җиргә кадаклагандай, кинәт туктап калды һәм тамак астындагы яулык төенен буш кулы белән бераз тегеләй-болай итте, ахрысы, тамагын да кырды. Хыялы белән бәхетле Сылу, көләч елмаеп, һаман әле алга таба атлый иде. Атлый иде...

Гаделия исә кырт кына янга борылды да, сөрелгән йомшак җир эченә кереп китте, аның аякларында нәрсә булгандыр, һәрхәлдә, бутый да, резин итек тә түгел иде, әмма ул бата-бата читкә таба керде һәм юлдан егерме-утыз адым ераклашкач алга таба юнәлеш алды...

Сылуга башта бу гаҗәп тоелды, әмма бәхетле хыялыннан аерылуга ул айнып китте: кеше өлешенә кул сузганмын? Ярабби! Минем ни гаебем бар? Яраткан кеше, гомумән, гаепле буламы? Мин бит яратуымны корбаннан башлаган кеше! Я, син шуны эшли алыр идеңме? Минем бит хакым зур! Нигә алай кара коеласың? Әгәр исән-имин кайтса... Кайтсын иде, нәзер итеп әйтәм: исән кайтса, мин аны сиңа бирер идем. Ә бит исән кайтмаса — сиңа да түгел, миңа да түгел. Тик исән генә кайтсын иде...

Сылу әле белми иде: мең тугыз йөз кырык дүртенче елның кышынача алар әле — колхоз хисапчысы Гаделия һәм авыл Советы каршындагы медпункт мөдире — ул — район, авыл юлларында бик күп тапкыр очрашачаклар һәм һәр очрашуда Гаделия үзенең итек, ботинка, бутый кунычларына бик күп кар, былчырак, су тутырачак иде, һәм алдагы очрашуларда Гаделия аны җир буе арадан түгел, бәлки бер-ике чакрымнан танып, бер-ике чакрым кар, былчырак, су ерачак иде.

Дөньяда иң куәтле хис, иң озак гомерле, үзгәрмәс хис нәрсә? Ул — хатын-кыз көнчелеге.

## X

Сылу күңеле белән генә түгел, тәне белән дә үзен тол хатын итеп тоя, шулай тою аңа ничектер газаплы ләззәт китерә иде.

Кырык өченче елның алтынчы ноябрь кичендә Симетбаш клубында авыл яшьләре «Ак калфак» драмасын куярга тиешләр иде. Халык инде сугыш хәлләренә ияләнеп килә, ни гаҗәп — кырык өченче елның буена авылга бер генә үлем хәбәре килмәде. Халык күңелен тетрәткән авыр хәбәрләрнең соңгысын Фатыйма апа алды. «Сезнең улыгыз лейтенант Асаф Рәимов авыр сугыш вакытында батырларча һәлак булды» дип язылган иде кәгазьдә. Шулай, хатлар туктады. Авылда кемдер сөйләгән иде: Асаф белән Габделнур икесе бер частьта икән, бер окопта яталар икән, имеш. Әмма исән вакытта Асаф бу турыда Сылуга үзе бер сүз язмады. «Исән-сау, сугышабыз, тиздән шатлык белән күрешүне теләп...» Габделнур бәлки ни дә булса язгандыр? Тик бу турыда Гаделиядән ничек сорыйсың? Менә бит бер ай репетиция барды, ике арада ләм-мим бер сүз юк. Ярый әле, әсәрдә боларның рольләре каракаршы сөйләшә торган булмады.

Көзге коры салкын кич иде, авыл өйләреннән төшкән саран гына яктылыкта юл каткаклары, бәскә уралган агачлар җемелди иде, халык клубка ашыкты. Тук вакыт, колхоз бәрәңгедән мул уңыш алды, каз-үрдәкләр суелган, солдаткалар кичләрен бер-берсен дәшеп, өчле лампа яктысында кабак бәлеше ашап, моңаеп җырлап йон эрләгән,

оекбаш-биялэй бэйлэгэн, кулдан-кулга йөреп таушалган соңгы хатларны укып, елашып-жырлашып утыра торган кичлэр иде. Төш юраулар, багулар, сүнмэгэн өметлэр көзе иде ул. Төшлэр барысына да диярлек бер төрле керэ, хэбэрсез югалган яки үлгэн солдат ак күлмэкыштаннан күренэ, бик күбесе тальян уйный, бу инде, бер дэ шиксез, исэн булуга ишарэ, тальян уйнау, бер дэ шиксез, юл төше инде ул, исэндер, исэндер, тик хат язарга жае гына чыкмыйдыр. Озак утыргач, өчле лампа яктысында күзлэрне йокы баскач кына, багу, юрау башлана, гэзит яки иске китап битлэрен алалар да, караңгы мич алдында шуны яндыралар, аның ялкыныннан мич көймэсендэге корымга ут үрли, корымда кечкенэ ут бөртеклэре йөгереп-йөгереп йөрилэр дэ сүнэлэр, элегрэк, тыныч елларда, мич томалаганда көйрэгэн мондый ут бөртеклэренең корымда йөгерүен «маржа кызлары жилэк жыя» дип балаларга аңлаталар иде — хэзер алай түгел. Хэзер берничэ ут бөртеге мич көймэсендэ йөгерэ башласа — энэ һөжүмгэ киттелэр, энэ сугышка керделэр, дип күзлэрен текэп карап торалар, ут бөртеклэре бер-берсенэ бэрелешэлэр, бер-берсен сүндерэлэр, ахырдан берсе кала — энэ шул инде, шул инде йортның хужасы, энэ ул сүнэр алдыннан зур итеп бер яктырып алды, мич авызына битлэрен тыккан тол хатыннарга кызгылт нур сибеп алды — исэн икэн, исэн икэн, хэбэре генэ килеп житэ алмый икэн...

Сылу энелэрен балалар йортына урнаштырган елны ук Симетбашка күчеп килеп, медпунктның өске катындагы бүлмэгэ урнашкан иде. Авыл Советы утынга өзмэде, жыештыручы Бибижамал түти медпунктта яккан да аның да бүлмэсенэ яга, өй һэрвакыт жылы була иде. Бүлмэ иркен (элеккеге авыл баеның кызыл кирпечтэн салынган ике катлы йорты, элек өстэ яшэгэннэр, аскы катта тимер ишекле кибет булган), сырлап ясалган матур баскычтан югарыга менсэң — киң генэ уңайлы бүлмэ, бүлмэ түрендэ теге заманнан ук калган кызыл агачлы зур көзге, иске, затлы сэгать келт-келт йөреп, гомер агышын саный, моңсу да, тыныч та, куркыныч та була иде.

...Спектакль бетэргэ якынлашып килэ иде, ак калфак, затлы туфлилэр, ефэк күлмэк кигэн бай кызы Хэмдия көтүче Бакыйның мэхэббэтен аңлый алмыйча кире кагып торган киеренке бер момент иде, нэкъ шул вакытта клубның артында ыгы-зыгы башланды, этештелэр, кемнедер сүктелэр, эрлэделэр, спектакль өзелү алдында иде, эмма Хэмдия-Сылу күреп алды: халыкны ерып, сэхнэгэ таба медпункт караучы Бибижамал түти килэ, яулыклары артка шуган, кызыл чэчэкле күлмэге өстенэ таушалган бэрхет камзулын гына кигэн, үзенең сулышы капкан иде.

— Кызым, кызым! — дип кычкырды ул, сэхнэдэге Хэмдияне танып алгач. — Төш эле, йөгер медкумпытыңа! Йөгер! Анда бер солдат килеп утырды баскыч төбенэ... Капчыгын аскан, үзе аксак! Эллэ Асафмы дим!

Халык бер мэлгэ тынсыз калды. Сэхнэдэге киеренкелек белэн залда туган хэл, медпункт баскычына килеп утырган солдат хэле, эгэр ул чыннан да Асаф икэн — Сылуның хэле — барысы бергэ алганда катлаулы һэм бу хэллэрнең кайсын аерып беренче урынга чыгарырга — моңа берэүнең дэ зиһене житэрлек түгел иде.

Эмма халыкның гына зиһене житмэде. Сылу исэ биш-ун секунд эчендэ барысын да аңлады һэм калфагын гына салып, алдына тезлэнгэн Бакыйга тоттырды да, сэхнэдэн түбэнгэ очты. Клуб баскычыннан йөгереп төшкэндэ сөрлегүдэн аның үкчэле туфлилэре төшеп калды. Каткак урамнан ялан өс, ялан баш, юка оектан ул медпунктка таба йөгерде, аны беркем, берни дэ куып житэрлек түгел иде.

Медпункт чоланына терэп эшлэнгэн эскэмиядэ тэмэке уты күренде. Сылу эле тын алмаган иде, шулай да уйлап куйды: сугышта тэмэке

тартырга өйрәнгән икән. Үзенә таба очып килгән ак шәүлә якынлашкач, ут селкенеп куйды. Солдат аягүрә басты — ике бит бер-береннән кул яссуы ераклыкта тәмәке яктылыгында бер-берсенә текәлеп калдылар. Солдат үз алдында күкрәге белән селкенеп чак-чак сулыш алган, муенына көмеш сыман ялтыравыклы мәрҗәннәр таккан, зур, әсәренгән күзләре өстеннән карлыгач канатыдай сирпелеп, гаҗәпләнүдән югары ашкан буяулы кашларны, дерелдәгән, тулы дәртле иреннәрне күрде. Сылу исә шул ук бер мизгелдә эчкә баткан тоньк күзләр, ябык, сөякчел, кырынмаган яңаклар, пилотка эченә кереп сеңгән киң аксыл маңгай һәм эре, озын тешләрне күреп алды. Солдат та авырлык белән күкрәктән сулый иде, газаплы елмаеп, инде караңгыда дәште:

— Укол вакытым җитте. Дүрт сәгатьтән кирәк... Ампула үзем белән,— диде. Аннан шинеленең өске каптырмасын элэктерде дә, йөткереп, дерелдәп куйды: — Сине борчыдым, кызый, нишлим соң. Тагын ун чакрым атлыйсым бар, госпитальдән соң баш әйләнә. Военврач әйтте: ят тагын бер ун көн, терелэсең,— диде. Тыңламадым. Ялындым. Сугышка тагын кергәнче семьямны бер күрим дидем. Инде исән-сау кайтып бер күрешсәм, бер үкенечем дә калмый. Аннан Берлинга хәтле шуышырга да риза.— Ул авыр йөткереп алды һәм ишеккә таба борылды. — Дару үзем белән...

...Спектакльне сүлпән генә тәмамладылар. Сылу рухсыз гына уйнады, юл каткагына бәрелеп аның аяклары эштән чыккан, бармаклары авырта иде, туфлиләрен кия алмады, бай кызы сәхнәгә резин галошлар белән чыкты. Астагы халык спектакльнең соңгы моментында аһ орып утырды, Хәмдия дә, көтүче Бакый да, сөйгәне белән күрешәм дип талпынып алданган Сылу да кызганыч иде.

Яшьләр спектакльдән соң вечер уйнарга калдылар, Сылу төенчеге белән киемнәрен алды да, клубны ярып артка таба узды. Ишекне ачып караңгылыкка чыкканда гына клуб миче кырында зәңгәр сырмасының ян кесәләренә кулларын тыгып куырылып утырган Гаделиянен күзләре белән очрашты. Бичара кыз! Әйе,әйе, моннан ярты гына сәгать элек ул да ымсынган, ул да алданган иде бит. Ләкин ул хата хәбәр аңа газаптан башка берни дә бирмәде, ул Сылуның сәхнәдән аска очканына газап катыш кызыгып, көнләшеп калды. Солдатның башка кеше икәнен ишеткәч, Гаделия бер мизгелгә шатланып куйды, әмма бәхетсез, бик бәхетсез иде бу кичтә.

Фонарь тоткан Бибиҗамал түти, таягына таянып кыштыр-кыштыр атлап, медпункт ишегалдыннан чыгып килә иде, Сылуны айга-вайга карамыйча үзләренә алып китте:

— Иркенләп юын, эссесе бик каты, суы күп, җиделе лампа янып тора, — дип, аны ишегалды түрендәге мунчаларына озатты.—Башыңны юарга ачы катык та, селте суы да бар, рәхәтләнеп чабын, каен миллеге почмактагы ләгәнгә суга тыгып куйган булыр. Капка бикле, бераүдан дә шикләнмә, юынып беткәч киләсен әләргә онытма...

Мунча эчендә ачы катык, миллек, кер сабыны, мунчала исе парланып тора, тәрәзә төбенә утыртылган җиделе лампадан дымлы саргылт идәнгә җиз яктылык төшкән, ләүкә астында мунча сыерчыгы сайрый иде.

Чишенеп ләүкәгә менеп яткач, Сылу бүгенге кичне башыннан кире чигереп уздырды. Күз алдыннан теге ябык солдат китми иде. Әнә ул кеше рухы. Укол кадатырга кергән җирдән солдат аңа бер хакыйкатьне ачып чыкты: сугышка бер кергән кеше — зур әхлакый сынауны узган кеше. Шуннан соң бераүләргә бик куркыныч була, икенче тапкыр сугышка кермәс өчен кеше әлләниләр бирерлек була. Ә күпчелек өчен алай түгел. Сугыш халәтенә шул дәрәҗәдә иярәнәсең, инде солдат

үлем турында уйламый башлый. Теге заман, теге вакыт — ул төш кенә булган икән, кешенең чын тормышы менә шушы—үлем уены икән, бу—гадәти бер хәл икән, үлем инде куркыныч түгел, ул инде синең дустың да, дошманың да түгел, ул инде тоз тәме дә, бал тәме дә килми торган мәгънәсез бер зат икән.

— Үлемгә әнә шулай карый башлагач кына чын солдат — сугышчы ясалган була, — диде ябык яңаклы солдат, чалбар каешларын эләктерә-электерә. Аннан укол турында сөйләп китте:

— Ябык, юка кешегә бер чуртымы да юк аның, — диде. — Мин, — диде,— күпне күрдем. Кыр госпиталендә дә, шәһәр госпиталендә дә күп яттым. Нинди әзмәвер кебек егетләр була, граната тотып нимес танкысы каршына шуышып бара, аягы, кулы өзелә, әле һаман алга үрмәли. Ну инде, госпитальгә килеп кергәч әнә шул чебен... юанлыгындагы инәдән куркып кала. Бер сержант артына укол кадар алдыннан аклы-күкле булды да, гөрселдәп өстәлгә барып ауды. Ул өстәлдә күпме дару, күпме пыяла бар иде. Ә үзе кем диген? Шуышып барып, «Фердинанд» астына гранат ташлап, шул кабәхәт машинаның бер як гусеницасын струйдан чыгарган егет. Дуктыр инәсе шундый әйбер ул...

Мунчада озак, бик озак ятты Сылу. Теге солдат аның күңелен генә түгел, тәнен дә кузгаткан, ашкындырып киткән иде. Нигәдер сулыш кысыла, йөрәк кага, нидер эзләнеп, яшь гәүдә ләззәтле сыкрана, кинәт килгән бу ашкынудан рәхәт ойый иде. Соңгы елларда аның тәне тула башлады, сугыш вакытында, ачлык-ялангачлык ишек кагып торган бер заманда гәүдәнең тулуы бер дә килешә торган эш түгел иде. Сылу иртәнге өчләргә кадәр озак итеп, акрын хәрәкәтләр белән юынды, тәмам таралды. Ул өенә кайтканда сәгать дүртенче ярты иде. Җылы өйдә, чыбылдык артындагы йомшак караватына кереп ятты — күзен йокы алмады. Юк, Асафның үлүе мөмкин түгел. Моның төсле итеп сагынуга, көтүгә кешенең бер кайтмый калуы мөмкин түгел. Сылу бит аны күңеле, уйлары белән генә түгел, бөтен тормышы, сулышы белән сагына. Менә ничә ел инде аның төшенә бер үк нәрсә керә: яшькелт-көмеш ай яктысында, һава дулкыннарында тирбәлеп алар Асаф белән бергәләп йөзәләр. Аларга һәрвакыт ялгыз калырга кирәк була. Һәрвакыт шунда кемдер комачау итә. Менә алар тирбәлә-тирбәлә йөзәләр, аларның куллары, янбашлары, аяклары бер-берсенә тиеп китә, тәнгә әйтеп бетергесез рәхәтлек тарала, менә-менә комачау итүче теге кеше каядыр югала, алар ялгызлык рәхәтен тоеп бер-берсенең кочагына ыргылалар һәм нәкъ шул вакытта Сылу уянып китә.

Тәрәзә пәрдәсе кырыеннан ноябрь иртәсенең саран соры яктылыгы иренеп кенә бүлмәгә ашкан, керосин лампасының сап-сары яктысы бүлмәгә моң тутырган иде...

## XI

Көз иде, күңелсез, авыр көз иде.

Князевка станциясе өчен ике көн буе каты сугыш барды — бу станциядән көнчыгышка дошман техникасы уза иде. Ике көн буе станция тирәсендәге авыллар янды. Бигрәк тә зур авыл — Покровка янды. Дошман ягы авылны снаряд утына тотты, тоташ ут яңгырыннан соң авылның унлаган-егермеләгән йорты берьюлы кабынып, кызыл ут, кара-зәңгәр төтен булып күккә ашты. Дошманның мотопехотасы артыннан танк колоннасы бәреп керергә тиеш, офицерлар өчен бу инде мәгълүм иде. Разведка мәгълүматларын окоптагы солдатлар гына белми иде.

Покровка кара ут эчендә яна иде, иртәнге унда дивизия штабыннан икенче расположениегә — сазлыклы сирәк урманга таба чигенергә приказ булды.

Ут, кара төтен эченнән техника, обозлар, яралылар чигенде. Лейтенант Рәимов взводы авыл урамыннан урманга таба сузылган юлны саклый иде. Авыл артындагы үзәнлеккә инде миналардан пехотага һәм танкларга каршы перекрытие ясалган, алты-җиде метр чамасы киңлектә юл — коридор калдырылып, чигенүче гаскәр шул коридордан гына узарга тиеш иде. Авылдан бер чакрым ераклыктагы иске әвеслек янына урнашкан взводның бер отделениесе соңгы солдат, соңгы обоз узганны көтеп, блиндажда ята иде.

— Лейтенант! Сине комбат чакыра...

Әвеслек түбәсенә оялап, ут эчендәге авыл ягын бинокльдән күзәтеп яткан Рәимов блиндажга төште. Җир исе, самосад исенә тынчыган блиндажның түрендә снаряд ящигы өстендә үзенең хуҗалыгы белән телефонист утыра иде. Рәимов станциянең шомарган, күп чигенүләр, дәһшәтле һөҗүмнәр, ачу сүзләре, шатлыклар тапшырган авыр кара трубкасын кулына алып, рычагын кысты. Трубкада капитан Якушевның сабыр, әмма һәрвакыттагыча шөбһәле-акрын тавышы ишетелде.

— Лейтенант, т ә м ә к е ң бармы әле?

— Бар, иптәш капитан.

— Ничә пачка калды?

— Егерме пачка булыр.

— Яхшы. Ә ш ы р п ы г ы з?

— Анысы белән мактана алмыйм. Нибары дүрт кап. Калганнары сезнең карамакта.

Кырык беренче елның кышыннан бирле бергә сугышкан, камалган, чигенгән, зур өметләр белән бергә алга атлаган ике офицер бер-берсенең хәлен җиңел аңладылар. Рәимов карамагында нибары дүрт кеше. Аларның кулында перекрытие ясар өчен танкка каршы куела торган егерме данә мина бар. Юлны каплар өчен бу җитәрлек иде. Трубкада баздан чыккан кебек авыр, акрын тавыш кабатланды:

— Приказны беләсезме?

— Так точно, капитан!

— Иң соңгы сугышчы чыгып беткәч кенә, аңладыңмы? Иң соңгы обоз! Иң соңгы яралы узгач! Күзәтүне көчәйтергә. Яралыларны аерата нык күзәтегез. «Гроблар» көтелә. Үзәнлекне бик нык күзәтергә. Юл кыскартучы турыдан ярмасын, «тәмәке» басуына килеп кермәсеннәр. Беренче г р о б күренүгә юлга а р а т а! Аңлашылдымы?

— Аңлашылды, комбат! Монысын лично үзем башкарам.

— Дело хозяйское. Әмма шунысын әйтим: бу заданиенең сиңа тапшырылуы турында «б а б а й» үзе белә. Бер генә «гроб» та узмый, ишетәсеңме? Бер генә... Актык чутта дивизиянең язмышы — сез куячак киртәдә.

Трубкада өзек-тәтек зуммер тавышы ишетелде. Рәимов тышка чыкты, әвеслек түбәсендәге оясына урнашты да, биноклен авылга юнәлтте. Юлдан пехота, берничә атлы обоз шуыша, ара-тирә мотоцикллар уза иде. Менә полуторкага таккан сорокопяткалар күренде. Болар, ихтимал, соңгыларыдыр. Рәимов вак йомычкалы такта ящиклардан миналарны чыгарып яткан сугышчыларга күз төшерде. Егерме данә... Карап торырга бер-берсенә китереп каплаган соры-саргылт төстәге табалар. Мондый табада бәрәңге кыздыралар. Әнә тоткасы да бар. Нәкъ ләгән тоткасы. Бөтен ышаныч, бөтен өмет менә шуларда хәзер.

Рәимов кешеләрен дәшеп барлап чыкты.

— Ефрейтор Лукин! Кайсы яктан! Ничә балаң бар?

— Винницкая область, иптәш лейтенант. Авылым — Курашевцы. Холостяк. — Мур-Куроловецкий район. Өлгерә алмадым.

— Колодяжный! Кайдан? Семья хәлең?

— Барановичидан, лейтенант. Бер кызым бар иде. Исән булсалар, Өч яшендә.

— Минзянов! Да, ладно, барын да беләм. Радист! Балаханов!

Блиндаждан сары калын мыеклы, зур зәңгәр-аксыл күзләрен якътыга кысып каскасын кыңгыр салган кырык биш яшьләр чамасындагы кеше авыр шуышып чыкты.

— Рядовой Балаханов! Кай яктан? Ничә балаң?

Балаханов ашыкмады, тамагын кырды, каскасын рәтләде.

— Куйбышевтан мин, лейтенант. Телефон станциясендә эшләдем. Балалар? Мин бай, минеке — алты...

Шулай диде дә, нигәдер зур күзләрен тәгәрәтеп, Покровка ягына карады. Авыл инде тоташтан яна, юлдан әле һаман да боларга таба кечерәк кенә колонналар, мотоцикллар, атлы арбалар агыла иде.

Рәимов тамагына утырган төенне авырттырып йотты, тавышына кырыслык өстәде.

— Игътибар белән тыңлыйсыз; ефрейтор Лукин, сержант Минзянов, миналарны юл читенә ташый башлагыз. Мин сезнең белән. Балаханов, Колодяжный! Сез үзәнлекне — эвеслек белән юл арасын ябасыз. Ә хәзер болай: Минзянов! Лукин! Документларыгызны Балахановка бирегез. Живо! За дело! Балаханов! Колодяжный! Участокны ябуга— марш расположениегә. Ә без монда калабыз. Юлны ябарга.

Рәимов тиз генә шинель каптырмасын ычкындырды, күкрәк кесәсеннән чытырдавыклы юка майлы кәгазьгә төрелгән документларын алды. Ничектер бик авыр булып китте: партбилет, офицер кенәгәсе, өй адресы һәм... алтыга-тугыз зурлыгында фоторәсем. Ул рәсемдәге күзләр, маңгайдан бөтерелеп торган калын чәчләр, ул йөздәге сагыш аны бер секундка гына чынбарлыктан аерып торды. Болар белән аерылу нигәдер соңгысы һәм мәңгегәдер кебек тоелды.

Лукин, яңакларына сеңерләр йөгертеп, дәшмичә генә «Красноармейская книжка»сын сузды. Кенәгә тузган, таушалган иде.

Габделнур исә күкрәк кесәсен ача алмыйча азапланды. Асаф аның чыраена игътибар итте: Габделнурның йөзе кәгазь кебек агарган, иреннәре төссез, куллары калтырый иде.

Һәркайсы икешәр мина күтәреп юл буена чыгып киттеләр. Эвеслек белән юл арасындагы йөз метрлар чамасындагы кысыр басуда Балаханов белән Колодяжный калды. Асаф юл кырыена килеп урнашты, Лукин белән Габделнур миналар ташыдылар.

Юлдан узучылар сирәгәйде. Еракта артиллерия тавышы тынган, авыл өстендә ялкын сүрелә төшкән, уйнаклап искән җил белән каракургаш төтен авыл тирәсендә өерелеп, сөрелеп йөри иде. Асафның ничә тапкыр инде сынаганы бар: сугыш вакытындагы тынлык иң хыянәтчел тынлык. Монда да шулайдыр. Разведка мәгълүматлары буенча дошманның танк колоннасы көндезге сәгать уникедә Покровкада булырга тиеш. Якушев иртүк хәбәр иткән иде: «гроблар» төш уртасында «зират» эзләп кузгалачак, диде. Юл тар, туң әле калын түгел, тик менә үзебезнекеләрнең генә иң соңгысын уздырырга иде. Юлдан кулын бинт белән аскан ак чырайлы пехотинец атлый. Иягендә, бер колагында укмашкан кан. Юл буенда тыныч кына басып торган лейтенантны күргәч, газаплы елмая:

— Аягың-кулың исән булса, әйдә, топай, — ди. — Анда, авылның теге кырында, немецлар хәрәкәткә килде.

— Синең артта кеше бармы?

— Юктыр. Мине бәйләгән санитарка калды. Разрывной — эченә эләкте. Мине атып үтер дип үзәгемә үтте. Кузгатырлык түгел. Шуны

авыл читендәге әрәмәлеккә — ә-әнә тегендә — өстерәп керттем. Нишлим, калдырдым. Кыз бала — разрывной белән эчен — весь! Кузгатырлык түгел. Бәйләгән булдым.... Ул мине коткарды, ә мин аны калдырдым...

Солдат ачы итеп сүгенде.

— Әйдә, лейтенант, топай! Анда, минемчә, нибары ике-өч кеше калды.

— Атлый бир, браток, куып җитәрбез.

Солдат боларның нинди задание белән калганын шунда гына аңлады: Лукин белән Габделнур алабута арасыннан саргылт табалар күтәреп чыктылар.

Авыл артында гүләгән тоташ тавыш ишетелде. Бинокль окулярында акрын гына шуышкан бер полуторка күренде.

— Соңгысы, — диде Габделнур ачы, карлыккан тавыш белән. — Соңгысы! Тотыныйк!

— Лукин! Юлның сазлык янындагы тар урынын күрәсеңме? Ике посылка белән шунда! Урын әзерли тор! Маскировка ышанычлы булсын! Минзянов! Киттек, туганкай! Лукиннан егерме метрлап алга узабыз. Посылкаларны алдык!

Авыр йөкне күтәреп юл читендәге түбәнлектән йөгерделәр.

Полуторка килеп җитте. Тормоз бирде. Кабина ишеге шыңгырдап ачылды, юлга медицина майоры сикереп төште, кузовта бер капитан күренде. Капитан кырынмаган, бите-күзе кызарган, ачулы кыяфәттә иде.

— Лейтенант! Мать вашу! Сез нәрсә, немецне көтәсезме? Куктән төштегезме әллә?

Асаф җирдә яткан саргылт металл табаларга күрсәтте. Үзе майорга таба борылды.

— Иптәш майор! Авыл кырыендагы әрәмәлекне күрәсезме? Әнә шунда авыр яралы медсестра ята! Барып алыгыз! Яралы пехотинец кертеп салган... Үзе әнә — расположениегә китте.

— Никаких! Мин приказ бирәм! Мин соңгысы! Берәү дә юк хәзер анда! — Капитанның тамагы карлыккан, үзе яшькелт-зәңгәр тавышына буылып йөткерә иде. — Сез нәрсә, анагызның... Сары авызлар! Әллә беренче көн сугышасызмы?

Медицина майоры кулына Рәимовның биноклен алды. Әрәмәлеккә кадәр бер чакрым чамасы ара бар иде.

— Борылырга куш, капитан, — диде ул бик әдәпле тонда.

— Никаких!

— Анда безнең кеше! Кайчаннан бирле эле без солдат калдырып чигенә башладык?

— Машина минеке! Мин дивизия штабының приказын үтим. Безнең соңгысы.

— Капитан! Анда безнең бер кеше... Безнеке...

Капитан башын читкә борды. Икеләнде.

— Автомат белән бер солдатыңны бир, — диде карлыккан тавышын баса төшеп Асафка. Аннан сүгенде. — Сары авызлар. Шул сезнең кебекләр аркасында бу көнгә калдык инде без.

Асаф шатланып кычкырды:

— Лукин! Марш кузовка!

Шофер машинасын борып куйган иде инде.

Рәимов кузовка сикереп менгән капитанга дәште:

— Иптәш капитан! Тиз йөрегез! Сездән соң ябабыз! Тиз!

— Өйрәттең син дә! Мать вашу! Мин утыз тугызынчы елдан бирле ут эчендә...

Машина кинәт кузгалуга капитан чайкалып кузов эченә авып төште.

— Я, туганкай, — диде Асаф татарчага күчеп, — хәзер яба башлыйк. Син ПТРыңны кулдан төшермә. Киттек...

Юл катысының калынлыгы өч-дүрт сантиметр чамасы гына икән. Юлда инде хәрәкәт тукталган, ерактa полуторканың арты гына селкенеп күренә иде. Ашыга-ашыга казыдылар. Тегеләр әйләнеп кайтмыйча миналарны әле урнаштырырга ярамый иде.

— Танклар хәзер бәреп чыкса, нишлибез? — Габделнур аянычлы күзләре белән Асафка карады.

— Юлны ябабыз!

— Ә тегеләр?

— Нәрсә тегеләр?

— Алар ничек уза?

— Алар узсын дип юлны ачып торыйкмыни, юләр?

— Соң, үзең бит үлеп яткан бер сестра аркасында ничә кешене үлемгә җибәрдең? Дәшми калсаң булмый идемени?

Асаф ачу белән юл катысына кергән батырды.

— Үлемгә җибәрдең, имеш... Тизрәк казы! Үлемнең без синең белән кырык беренче елда ук каршысына чыгып бастык. Алар өлгермәсә, юлны ябабыз и баста! Аннан аларны ут белән сак астына алабыз. Җырны хәтерлисеңме? «... и десять гранат — не пустяк». Менә шул. Казы!

Көйгән, корыган тигәнәкләрне, әрсез алабуталарны селкетеп, кырыс җил исеп куйды, ул җил авыл ягыннан янгын исе, көйгән ит исе алып килде. Авыл читендә автомат тырылдап калды. Габделнур җилгә баскан иде. Автомат тавышы кабатланды.

— Беттек, крышка, — диде Габделнур, сөрлегеп Асаф янына килеп егылды. — Крышка! Синең аркаңда! Безгә нәрсә, кешедән күбрәк кирәкме әллә? Нигә син минем тормыш белән распоряжаться итәсең?

— Тик тор! — дип җикеренде Асаф. — Тик тор, дәшмә! Әнә ояларга мина ташы! Барысы да әзер булсын. Полуторка узуга взрывательләрен боевое положениегә куябыз да, маскировка ясыйсы гына кала. Тизрәк...

Авыл ягыннан чайкала-чайкала яшькелт полуторка килгәне күренде. Габделнур йөгерә-йөгерә йөрде, ояларны рәтләде, миналарны оя янына урнаштырды.

Авыл кырыенда тагын автомат чытырдап алды. Бу тавыш әшне бераз катлауландыра иде. Әвеслек белән юл арасын бикләп бетерүгә Колодяжный, Балаханов, бөкрәя-бөкрәя йөгереп, Асаф янына килделәр.

— Иптәш лейтенант, приказ үтәлде!

Балаханов гыж-гыж килә иде.

— Аппаратың кайда?

— Менә, хәзер юлга чыгарып куйдым.

— Икегез дә марш расположениегә!

— Ә сез? — Балаханов мөлдерәтеп карады.

— Приказны үтәгез! Үзебез ябабыз. Марш!

— Иптәш лейтенант!

— Марш! Бегом! Не рассуждать! — Асаф кобурасына тотынды. — Юлдан түбән төшеп! Без — исән калсак—ярты сәгатьтән.

Колодяжный белән Балаханов кысыр басу аша эре-эре атлап тылга таба йөгерделәр. Машина исән-сау килеп җитсә, аларны утыртып җибәреп тә булыр иде.

Автомат тынып-тынып ала, әмма һәр аткан саен куркыныч якынлаша иде. Машина да акрын килә.

— Ят! Каплан! — Асаф та карлыга башлаган икән, — кычкырып бетерүенә җир селкенеп алды, болардан дүрт йөз метрлар чамасы алда җирдән балчык баганасы күтәрелде. «Эш начар» дип уйлап алды

Асаф һәм, чыннан да, эш шәптән түгел иде. Акрын гына үрмәләп полуторка килеп җитте, аның арт баллоны изелгән иде, шуңа кызу бара алмый икән. Үкереп, чайкалып узганда капитан (бу юлы ул инде кабинада иде) актык тавышына кычкырды:

— Кызны алдык, ефрейторың яралы! Кузовта ике авыр яралы! Җитмәсә, баллонны тегеп алдылар, сволочьлар!

— Беркем дә калмадымы?

— Юк, юк, лейтенант! Ябыгыз!

— Безнекеләргә сәлам! — Асаф үзендә шаярырлык көч тапты.

— Тизрәк ябыгыз...

Бу — соңгы сөйләшү булды. Шуннан соң лейтенант Рәимовка озак вакытлар сөйләшергә туры килмәде...

Авыл читендә кисәүгә калган бер тәбәнәк йорт хәрәкәткә килде. Рәимов яткан җирдән биноклен шунда төрәде. Юл борылышындагы иске тигәнәкләр чайкалып окулярны каплыйлар иде. Тагын бер кисәүле йорт хәрәкәткә килде, чайкалды. Аннан тагын берәү. Икәү... Бишәү... Әһә, күзгә яшь тулган икән, балчыклы йодрыгы белән ул күзләрен сөртте һәм тагын карады. Хәрәкәт итүче кисәү йорт дигәне танклар икән. Рәимов гәүдәсе дерелдәгәнне сизде. Юл да дерелди иде бугай. Танк — хәтәр көч, солдатның егәрен ала торган көч. Асафның күзләренә яшь тулды. Ашыгып хәрәкәт итәргә кирәк иде. Ябарга! Юлны ябарга! Ул алга шуышты, оя янындагы минаны алып урнаштырды, шартлаткычын «боевое»га борды, өстенә йомшак балчык, аннан туң балчык салды. Тизрәк, тизрәк... Берәү булды, тагын икене урнаштырса, Габделнур да шул арада өчне куйса, аннан кысыр басудагы алабута арасыннан шуышырга. Урман ерак түгел, батальон хәзер шунда оборонага күчкәндер, хәзер боларның кулында дивизия язмышы... Менә тагын берәү, монысының оясы таррак ясалган икән, бераз чокырга туры килде. Шулвакыт Асаф, юл читенә төшеп, бөкрәеп артка таба йөгергән Габделнурны күреп алды. Ул нигә йөгерә икән? Ах, шайтан, кул калтырый, шартлаткычны борып булмый. Тынлык. Әмма танк моторларының тоташ гүләвен җил алып килә. Ниндидер тавыш. Кеше тавышы. Гаҗәп! Татарча. Әһә, Габделнур икән.

— Сиңа тагын бер йолдыз бирерләр! Мин үз бурычымны үтәдем! Әй, син, ишетәсеңме?

Асаф боларны ишетә, әмма аңламый. Өченче мина кайда? Әһә, арттарак. Ул шунда таба шуышты. Теге серле тавыш тагын ишетелде. Бу юлы кычкырган тавыш. Ялварулы.

— Алла хакы өчен дим! Булды! Китик! Китик! Я — бетәбез, я — немецларга эләгәбез. Алар юлны утка тотып барыбер проход ясыйлар. Китик, без инде бурычны үтә...

Аның соңгы сүзен ишетеп булмады, артта — йөз метрларда — снаряд шартлады, Асафның бер мәлгә тышкы дөньяны кабул итү сәләте югалып торды. Анысыннан һушына килгәнче тагын берсе җирне дерелдәтеп алды — монысы алда. Асаф секундның йөздән бер өлешендә хәлнең житдилегенә төшенде: «перелет», «недолет»тан соңгы өченче снаряд, гадәттә, синең өстеңә була. Ах, кабәхәтләр! Димәк, боларны күзәткәннәр. Әллә танклар якынлашамы?

— Кюветка! Тәгәрә! — дип кычкырды ул Габделнурны күрмәгән көе һәм гәүдәсен аска ыргытты. Кипкән тигәнәк, билчән битен сыдырды, биттән җылы юллар сузылды. Ул гыж-гыж килеп сулый, ә танкларның гөрелдәве һаман якыная иде. Әйләнеп карады — Габделнур күренми иде. Тукта... Әле бит миналар куелып бетмәгән. Ул каешына эленгән танкка каршы гранаталарны барлады — алар икәү иде — һәм өскә үрмәләде. Танклар хәзер ачык күренми, кара-каткак юлның үзәнле җирендә, борылышта алар үкерә-үкерә балчык изәләр иде бугай, әллә юлдан төшеп кысыр басудан килмәкчеләрме?

Өченче снаряд юлның икенче читенә, әмма Асаф яткан турыга ук төште, шартлау тынып күпмедер вакыт узгач, Асафның өстенә югарыдан бик күп туң балчык яуды.

— Юк, уздырмыйм, сволочьлар! — дип ыңгырашты Асаф һәм сикереп торып юлга күтәрелде, бөкрәйгән килеш үзенең кай турыда икәнен чамалады, танклар һаман эле үзәнлектә үкерәләр иде. Әһә, менә тагын ике оя бар икән, шуларны күмеп маскировка ясамыйча бу участоктан китәргә аның хакы юк! Балаханов белән Колодяжный расположениегә кайтып җиткәннәрдер инде... Ах, шайтан, янда тагын бер генә кеше булса иде, биш-ун минуттан моннан элдертергә булыр иде.

Ул карлыккан тавыш белән акырды:

— Минзянов! Прикрой меня! Прикрой? Кайда ПТРың? ПТР кайда? — Әмма Минзянов җавап бирмәде. — Син исәнме? Прикрой!

Соңгы ояга соңгы минаны урнаштырганда Асаф берөзлексез сөйләнде: сөйләнү, ахрысы, куркуны басар өчен кирәк иде бугай.

— Менә шулай, иптәшкәем, менә шулай... — Ул соры балчыкны өф-өф итеп учлап саргылт сырлы металл өстенә салды, кадерләп сыпырды, аннан нәкъ юл төсле каткак-кара балчык белән тигезләде, аның куллары дер-дер килә иде, хәзер аңа кюветка тәгәрәп төшәргә дә, эчкә кермичә, юл буендагы алабуталар арасыннан шуышып чигенергә кирәк иде. Тик эчкәре генә кермәскә кирәк, чөнки бу тирәдә алар иртәнге якта пехотага каршы миналар куйганнар иде, хәзер-хәзер. Бер секунд, ике, өч, хәзер тәгәрәргә. Әмма ул бер генә секундка соңга калды бугай, юл кырыена гына килеп төшкән снаряд балчык дамбадан зур киң багана күтәрде, тузанлы кайнар һава дулкыны Асафны каядыр алып атты, ни өчендер ул арка белән килеп төште, янбаш сөяге шытырдады — анда ике граната бар иде, күрәсең, шулар аска эләкте, арка җылынып китте һәм сугыш куркынычы шуның белән бетте дә шикелле. Күпмедер секундтан соң ул аңына килде, аның әйләнә-тирәсендә кипкән кәлшәләре белән күзге җилдә шелдерәп утырган саргылт сабаклы чүп үләне иде, ә күк йөзе — яп-якты, моңарчы беркайчан да булмаганча якты. Карале, моңарчы ничек беленмәгән, күк йөзендә әллә ничә кояш бар икән, менә ул кояшлар күзгә рәвешчә салкын, сары, моңсу кояшлар аның битен җылыталар, алар күп, бик күп. Вакыт-вакыт җирне ыңгыраштырып нидер үкерә, эшләп утырган су тегермәненең стенасы кебек җир акрын гына лепердәп селкенеп тора, ләкин берадан нәкъ арка астында гына ул җир ярыла да, Асаф тирбәлә-тирбәлә каядыр төшә башлый, теге кояшлар да берәм-берәм сүнәләр... Кояшлар сүнүгә күк йөзендә зур гына яшел ай калка, менә ул ай юан итеп яшькелт нурын Асаф өстенә коя, рәхәт, бик рәхәт булып китә, шулвакыт ай нурының юлыннан бер гүзәл кыз җиргә төшә башлый, төшкән уңайдан аның яшькелт-ак ефәк күлмәге җилферди, чәчләре тарала, менә ул Асаф янына төшеп йомшак кына аңа сарыла, кайнар иреннәре белән аның авызын томалый. Нинди гүзәл бу кыз, ә үзенең авызыннан гел тоз тәме килә, үзе көлә, үзе һаман бер үк сүзләрне кабатлый: мине үп, үп мине, минем иреннәремдә су бар, чишмә суы, эч шуны, эч-эч... ди. Асаф эчәргә тырышып карый, әмма тамак юлы ут булып яна, тамактан ашказанына кадәр булган юлга кемдер кайнар бакыр көпшә тыккан, ул бакыр кызып инде кызыл-җирәнсу төскә кергән, аны суытыр өчен иреннәр генә җитми, аңа чиләкле су кирәк...

...Пополнение белән ныгытылган батальон ике көннән соң прорыв ясап, дошманны чигенергә, Покровка авылын калдырырга мәҗбүр итте, тимер юл станциясен алу өчен авыр сугыш башланды. Томанлы иртәдә прорыв алдыннан миналы кырны чистарткан саперлар отделениесе юлдан биш-алты метрлар читтә кулына танкка каршы ата торган

граната тотып дамбага таба шуышкан хәлдә капланып үлгән яшь бер офицерны тапты. Кулыннан, биленнән гранаталарын алып, югга таба күтәреп чыгаргач, өлкән яшьтәге бер сапер офицерның кесәләрен әйләндерде — бернинди документ юк иде, гимнастерка эченнән кипкән кан, бозыла башлаган тәннең авыр, ухшыткыч исе борынга бәрелде. Әмма карт солдатның шул вакытта күзләре нурланып китте: гимнастерка кесәсен капшаган бармаклары белән ул офицер битендәге жылылыкны тоеп алды.

— Исән, — диде карт солдат, колагын аның йөрәге тирәсенә куеп. Ул калтырый-калтырый егетнең балчыкка каткан шинелен ычкындырды. — Исән! Братцы, озатырга кирәк, тизрәк... — Ул флягасын ачты.

Янындагы яшь ефрейтор миноискатель наушникларын колагыннан ычкындырып, әйтә куйды:

— Эх-х, батя... Юкка гына. Үлә алмыйча гына яткан инде ул. Разве исән кала мондый кеше?

— Алай димә, балакай. Чыкмаган җанда өмет бар, диләр. Әйдәгез, иплэп тотыгыз...

Асаф Рәимов боларны ишетә, әмма кем турында, нәрсә турында икәнне аңламый иде. Ул ике көн буе шулай үзен-үзенә туры китерә алмыйча, үзе турында чит кеше булып уйлап саташа, газаплана иде. Бу юлы да ул нинди дер бер кешенең әлеге авыр хәлдә, әмма исән икәнлеген төшенгән сыман булды. Һәм нәкъ шул вакытта ай нурына төрелгән теге кыз аның авызына чиләк белән салкын су койды. Тамактан туры төшкән кызыл-җирәнсу металл көпшә чыш-пыш килде, әмма моның кадәр рәхәтлекне Асафның үз гомерендә татып караганы, кичергәне юк иде әле...

Каракучкыл юлда һәм тигәнәкле кысыр басуда немецларның җиде танкысы туктап тынып калган иде.

— Герой бу! — диде карт солдат, шатланып. — Герой! Иплэп тотыгыз! Чү! Җайлап күтәр!

Асаф боларны ишетә, әмма кем турында, нәрсә турында икәнен аңламый иде.

## XII

Кышның гадәти салкын киче иде. Баштарак салкын бураннар үзәккә үтте, төнге сменада эвеслектә эшләүчеләр иза чиктеләр. Молотилкада ат куучы малайларның да эше авыр иде: ат абзарының буеннан-буена бер фонарь, караңгыда атыңны табарга, кереп алып чыгарга кирәк, ә караңгыда ат бер дә башын бирми, борыла, тыпырчына...

Минҗан карт трубкасын кабып ат абзарына килә, малайларга атларын тотыша, аннан якындагы эвеслеккә таба атлый, икенче сменага эшкә чыгу аңа да авыр, әмма ул беркайчан да бер мәртәбә дә көлмәгән, елмаймаган кебек, беркайчан да зарланмады да. Табигать, күрәсең, андый тойгылардан аны азат иткән. Тик ачы буранда эвеслеккә таба барганда яки битенә гади пыялалы зур күзлек кигәндә (ул барабанга көлтә бирә иде), күзлекнең каткан салкын каешлары кагылганда гына әйтеп куйгалый иде:

— Мондый көнне ашама, эчмә, тышка чыгып...

Төн урталарында ышык урынга җыелып бер ял итеп алалар, сугыш хәлләрен сөйләшәләр. Тиздән, госпитальдән чыгып Габделнур кайтырга тиеш иде, Минҗан карт әллә шатлана аңа, әллә барыбер — нәрсә уйлаганын ул кешегә бервакытта да белдерми иде. Ышыкта утырганда Минҗан карт барында яшь җилбәзәк төрле уен-көлке сөйли, сөйли торган уен-көлке дә әллә кем түгел, Минҗанчарак чыга иде.

— Ташлытау базарында булдыңмы бу атнада? — дип сорый бераү иптәшеннән.

— Юк, әнә Минҗан абзый барганые бугай, — дип ирештерә тегесе.

— Минҗан абзый, базар бәяләре ничек булды?

Карт трубкасын бармагы белән төйгечли, ашыкмыйча гына, җитди итеп сөйли башлый:

— Әйбер бәяләре бик үзгәргән, — дип сөйләп китә ул. — Күлмәкләр күтәрелгән, ыштаннар төшкән...

Сугыш чоры базарында законнар кырыс — ниндидер әйберне сатарга ярый, анысын базарга кертәләр, нәрсәнедер ярамый, анысын — кертмиләр. Минҗан карт аларын да үзенчә борып бетерә, ит, йомырка, йонны базарга кертү-кертмәү мәсьәләсен сөйләргә ярата иде.

Ямьсез, төк баскан яңаклы шушы картның, ни хикмәт, тормышның барлык күренешләренә үзенчә мөнәсәбәте, үз бәясе бар иде. Ул көлмичә генә сөйли ала иде.

— Ата үрдәк белән ана үрдәкнең ничек сөйләшкәнен беләсезме? — дип сорап куя ул ял иткәндә яшь хатыннардан. Үзе трубкасын төйгечли.

— Ничек? Ничек? — диләр солдаткалар, җанга якын ниндидер бер хикәят көтеп. Карт ялындырмый.

— Ана үрдәк муенын бөгә-бөгә бакылдый, теге яшел башка үпкәсен белдерә: «Көт-тем, көт-тем, кинил-мәдең, көт-тем, көт-тем, кинил-мәдең», ди. Яшел баш тегеңә каршы пышылдап кына болай ди: «Көткә-ә-ә-нсең пычак! Көткә-ә-ә-нсең пычак!»

Солдаткалар рәхәтләнеп көләләр. Минҗан карт канәгать. Кызып китә, әллә ниләр сөйләп бетерә.

Ташкичү басуындагы кибәннәрне февраль урталарында сугып бетерделәр, төнге смена шуның белән тукталды.

Заданиегә илтәсе бодай, арышны киптерергә кирәк, моңа бердәнбер сушилка өлгерә алмый иде, бодай-арышны хуҗалыкка тараттылар. Колхоз мичкә ягар өчен утын кертте, мичләрдә ашлык киптерделәр. Киму коэффициенты утыз процент иде. Минҗан карт өендә бодай киптерә башлады, ул моны бик яратып эшли иде, хәзер бураннар басылды, бүрәнәләр чартлатып хут суыгы хакимлек итә иде, мичеңне ягасың да, трубка тартып мич каршында җылынып тик утырасың. Тик аның карчыгы Маһи гына бу көннәрдә башкача уйлап, башка дөньяда яшәде: киптергән бодайны амбарга илткәндә ул аңа бер өлеш чи бодай куша да, коэффициенттан крестьянча иркенләп файдалана иде. Минҗан карт моны белми, әмма хатынның көн аралаш каты күмәч пешерүенә ул ризасызлык белдерә, чөнки көз көне алган уңыш (Гаделия үз хезмәт көненә тигәннең барысын төп йортка бирде) нибары капчык ярым иде. Көн аралаш каты күмәч, төче күмәч, таба ипие, пытырдавык (монысы Маһи карчык сүзе, юка күзикмәккә мичкә тыгар алдыннан пычак белән сызгалап кискәләсәң, пешкәч ул пытырдавык була) пешергән хатынына карап, ул ризасызлыгын әйтеп куя иде:

— Бар чагында бүре күк, юк чагында шүре күк инде без.

Әйе, февраль башлары, кышның гадәти салкын киче иде.

Габделнурны көткән Маһи карчыкның келәттәге каз түшләрен караштыргалап, туң майларын барлап, мичләрне агартып йөргән көннәре иде. Кичен ут алындыргач кына мунча керергә тиеш иде алар. Әмма бер дә юкка гына карты белән сүзгә килделәр дә, карчык мунчага ялгыз китте. Бу — элек-электән килә торган дипломатик бер алым иде, тәмсез сүз чыкканда Маһи карчык тел озайтмый, бары тик шул алымны гына кулланып, картны җәзалый — мунчага ялгыз китә иде. Картның да горурлыгы үзенә җитәрлек — Маһи карчык мунчада вакытта ул мич каршына килеп утыра да, тәмләп трубка суыра. Маһи

карчык ялгыз кергәндә мунчада озак тормый, нибары ике трубкалык вакыт узуга «ух-ах» килеп чыгып житә, «самавар куеп торучың да булмагач», фәлән-төгән дип мыгырданып, озын күлмәгенә буталып ләпер-лөпер йөренә, самавар, торба белән мәш килә, кирәгеннән артык идәнне шыгырдата, савыт-сабаны шалтырата иде.

Әмма бүген дүрт трубкалык вакыт узды, Минжан карт мич алдында гадәттәге ыгы-зыгыны, гадәттәге сүзләрне көтеп, әзерләнеп утырды — карчык кайтмады. «Бу юлы бик каты үпкәләде бугай кортка» дип, Минжан карт эскәмиядән карчыгы әзерләп куйган, юылып, сәке кашагасында сырлы бәләк белән төелгән чиста күлмәк-ыштанын алып мунчага китте. Кар диңгезенә чумган бакча башындагы кара мунчаның кечкенә тәрәзәсеннән җимерек киртәгә саргылт фәкыйрь ут яктысы төшкән иде. Карт, тамагын кырып, мунча ишеген ачты, салынган бозлы ишек авыр ыңгырашып шыгырдады, караңгы өйалдында миллек исе, иләгән тире, корым исе борынга бәрелде. Мунча эчендә тавыш юк иде.

— Син, дим, каттың мәллә? — диде Минжан карт, тунын-бүреген мунча өйалдындагы сәкегә ташлап. — Нәрсә озакладың? Кортламагандыр ич...

Тавыш килмәде. Карт калын бозлы ишекне ачу белән тартты һәм эчтән бәргән пар белән беразга сукыраеп калды. Ишектән ургылып кергән ак томан тәрәзә төбендәге сукыр лампаның утын җилфердәтте, лампа тынычлангач кына карт идәнгә капланып тынган ябык аксыл гәүдәне күреп имәнеп китте: Маһи карчыкның башы мич эчендә иде.

... Бодай киптергән көннәрдә колхоздан мул итеп имән утыны керткәннәр иде. Имән утынының мунча өчен хәтәр икәнен Маһи карчык белә иде, югыйсә. Халыкта беренче мунчага кергән кешеләрнең аратирә хәлен белеп, эндәшкәләп тору гадәте барлыгын Минжан карт та белә иде, югыйсә. Халыкта мондый сүз дә бар иде: ис тигән кеше беренче мизгелдә мунчадан чыгу юлын эзли һәм шуышып ишеккә таба барганда, ни өчендер, һичшиксез, башы белән эссе мичкә үрмәләп керә икән, дип сөйлиләр иде... Абзардан сарык алып чыккан бүредәй, ул карчыгының гәүдәсен төреп, җилкәсенә асылындырып, йортка алып кайтты. Сүнгән трубкасын суыра-суыра, карчыгының гәүдәсе янында сәкедә озак утырды.

Гаделиягә хәбәр итәргә кирәк иде. Бәрәр күршене чакырырга иде. Доктор кызга (кызмы, хатынмы шунда, ачуым килмәгәе, авылдагы бөтен ир хатынының тынычлыгын алып йөри!) хәбәр итәргә кирәк иде. Кая соң, кая соң, анасын корт чаккыры... Тапты үләр вакыт. Ярамаганмыни җәй көне, корырак, җылырак вакытта. Ике кулсыз итте бит, шыгырдавык...

Чоланда тамак кырган, аяк каккан тавышлар ишетелде. Ишек бикле түгел иде, белгән кешедәй өйалдыннан тиз узып, караңгыда ишек тоткасын тиз таптылар.

Сәкегә сузып салган энисенең мәете өстенә кулын аскан Габделнур кайтып төште. Хәер, кайтып төштеләр.

Габделнур янында мех якалы пальто кигән, тупырсык иренле, калку күкрәкле, арттан, бил турыннан аска инеп бетмичә пальтосы җыерылып калган сары чәчле, зәңгәр күзле бер яшь хатын да бар иде.

— Драстуй, старик, вот мы и прибыли, — диде Габделнур, кулын чигәсенә куеп.

Йортка таза бәдәнле хатын-кыз сулышы өрелде: салкын һава белән кершән-иннек, шәл исе таралды. Салкын, рәхәт, яшисе китерә торган саф һава керде.

Кызгылт төлке якалы соры пальтосын салган юантык яшь хатынга карап, Минжан карт сүнгән трубкасын ысылдатып суырды да, кызыгулы бер караш белән улына борылып авыр сулады:

— Берәү үлми берәү көн күрми шул, — диде.

Моны әйткәндә картның авыр сулап куюының күп мәгънәгә ия икәнлеген берәү дә аңламады. Әмма бер мәгънәне аңладылар:

— Отец! Когда это случилось! — дип, Габделнур «гөрес» итеп сәкегә, әнисенең баш очына утырды. Минҗан карт дәшмәде. Юантык маржа да каушап калды, анысы марҗача тиз, чын йөрәктән кычкырып елый ук башлады.

— Гаделияне алып кайтыгыз! Симетбашка менеп төшегез, — диде хәрәкәтсез калган карт.

Бурычның нинди икәнен тәрҗемәчесез дә аңлап алган килен тиз генә киенә башлады. Минҗан карт аның килешле, тулы гәүдәсенә тагын бер караш ташлады.

Яшьләр тиз киенеп, тиз чыгып киттеләр. Минҗан картның күңел түрендәге кителмәгән хәсрәт, борчу хисләре янына әллә ниткән, ул әле аңлап бетермәгән өр яңа бер хис кереп кунаклады. Ул гомернең гомер буена тулы тәнле хатын белән, кыйнаганда иркенләп, курыкмыйча тондырырлык, сөйгәндә кай төшеннән сөйсәң дә шапылдап тавыш чыгарырлык хатын белән торырга кызыгып яшәгән иде. Бүген генә мәңгелек йортка таба юл алган Мәһи карчыкның исә ни яшь вакытында, ни бала тапкач, тәненә ит кунмады: Минҗан картның өй идәне шикелле гомере буе шыгырдап торды. Гомере буе кайнар аш пешереп, самавар гөжләтеп, кара-каршы утыруның нәрсә икәнен белмәде. Гомере буе казан тутырып аш пешерер иде дә, шуны базга төшереп куяр иде. Кайткан бер кеше баздан үзенә кирәк кадәр салкын аш алып менеп, ялгыз шуны ашар иде. Юк, марҗа килен андый булмас... Бу-улмас, анасын корт чаккыры. Менә Габделнур, ә?

Укыган кеше укыган кеше шул. Идрит-кудрит...

Утны кыса төшеп, Минҗан карт ян сәкегә барып таянып торырга булды. Астына сары тунын салды да, сузылып ятты. Яшьләр әле бер сәгатьсез дә кайтып җитмәсләр. Тукта инде, ничек булды әле бу? Бер дә көтмәгән җирдән генә бөтенесе үзгәреп китә түгелме соң әле болай булгач?

Бу мут хатын монда тотмаячак малайны. Ул инде аны алып китәчәк үз якларына. Марҗага күңеле төшкән кеше аннан берничек тә арына алмый инде. Чибәр, шәп үзе килен. Оч-чень хураша, анасын корт чаккыры... Шуннан? Ялгыз калып, мин нишләрмен? Әнә безнең дәү абый әле җитмешкә җиткәч тә өйләнде бит. Миңа бит әле алтмыш кына... Алай-й... Чыннан да, нигә әле аптырарга. Үлгән артыннан үлеп булмый инде. Ә авылда тол хатыннар күп. Тик... бала ияртеп килә инде алар. Карт димәсәләр, ямьсез димәсәләр килерләр. Шулай булгач, бераз гына праваларны көчәйтеп алганда ярый икән. Әй-и... Алгач-алгач, аны әнә шундыйны — тәненнән дәрт бәреп торганны аласы иде. Авылда андыйлар да бар. Кара ул фиршел кызны. Әгәр аның кылларын тартып карасаң? Кызмы-хатынмы инде, теге вакытта, агач астында ятканда икесенең дә күзендә ат тояклары уйный иде. Фатыйма малае да бер рәхәт күреп үлде, ярый инде...

## XIII

Йортта итле шулпа исе таралган иде.

Камзулын чишеп, яулыгын чөеп җибәргән Бибиҗамал түтине — медпункт җыештыручы хатынны — чак-чак күндерделәр: авылда җиренә җиткереп дога, корьән укучы юк иде. Бибиҗамал түти бик авырлык белән генә риза булды, әмма укуын бер дә каушамыйча укый. Чөнки белә: күпме ватсаң да, хата табардай кеше юк. Аның тавышы моңлы.

— Бисмилляһиллязи ляйаззорры мәгы исмиһи шәйьин фил арзи вә ля фиссәмаи вәһвәс-сәмигыль газим-м-м...

Сугышта шәһит киткән лейтенант Рәимовның рухына дүрт хатын әнә шулай соңгы сәлам җибәрәләр, гадәтне үтиләр иде.

...Сораша килгән Фатыйма карчыкка Габделнур берни дә әйтмәде. Хәер, Минҗан картларның үз мәшәкатьләре зур булды: йорттан олы мәетне озату, керләрен юу, өчесен уздыру, җидесен уздыру кебек ыгы-зыгылар тынгач кына кызыл шәл .яулыгын плюш бишмәте өстеннән салындырып, Фатыйма карчык Ташкичүгә төште. Марҗа килен ду китереп өйдә эшләп йөри, Минҗан карт сәке кырында утырып тора иде. Фатыйма карчык килеп кергәндә Габделнур өйдә юк иде.

— Утыр, түргә уз, — диде карт йөзенә кара кайгы чыккан Фатыймa карчыкка. — Утыр, малай хәзер кайтыр.

Фатыйма карчык юылган, буяусыз урындыкны үзенә таба тартты, марҗа килен җәһәт кенә аның астына киез китереп салды. Минҗан карт, гадәттәгечә, сүзне турыдан башлады.

— Малайның сөйләшүендә бер дә рәт юк, — диде. — Татарчасын онытып кайткан. Килен дә әйтеп карады: ник миңа карыйсың, үз йортыңда әтиең белән, килгән кеше белән үз телеңдә сөйләш диде. Мин, диде, аңа ник әбиҗәтсә итим? Нигә кеше җафалыйсың ди, минем аркада ди. Хатын-кыз аңлый, ә тегесе — юк. Килен әйбәт, оч-чень хуруший жена.

Җиңел-җиңел атлап, йортка Габделнур килеп керде, өстендә таза шинель, башында фуражка, кулында бәйләгән зәңгәр перчаткалар, бит-башка бик таза, чибәр күренә иде.

— Привет, бабушка,— дип ул, елмаеп Фатыйма карчыкка кулын бирде. — Как живем?

Фатыйма карчык елап җибәрде.

— И бала, бала, бергә өч ел Ташлытау юлын таптадыгыз, бер атна эчендә киттегез... Ник минекен калдырып кайттың? Кайларда калдырдың? Сөякләрен күрдеңме, актык сүзләрен сиңа әйттеме?

Габделнур йөзенә борчулы кыяфәт чыгарды. Авыр сулап, шинелен, фуражкасын салды, ишек янындагы чөйгә элде, бөҗрага бәйләнгән кәҗә яныннан соры тышлы, төлке якалы хатын-кыз пальтосын күчереп элеп куйды. Көзге янына килеп, чәчләрен тарады, тарагына өрде, гимнастеркасын рәтләде.

— Мы отступали, — диде ул көзге тирәсендә үзенең җилкәләрен, муеннарын сыпыргалап, — он попал под танковый обстрел. В общем, он погиб. Через два дня наша дивизия перешла в наступление, прорвала оборону, вот видите и меня... Осколочное...

Фатыйма карчык күзләрен мөлдерәтеп Минҗан картка текәлде. Карт трубкасына тотынган иде.

— Нәрсә сөйли, нәрсә сөйли бу? Күргәнме баламны? Үлгәнен күргәнме? Күмгәннәрме?

Минҗан карт ризасызлык белән тамагын кырды.

— Татар түрә булса, атасын танымас диләр. Менә шул инде. Онытткан. Теге сугышта мин дә дүрт ел йөреп кайттым. Онытырсың, бар. Онытырсың. Телеңне онытырсың, бар.

— Нәрсә ди? Күрдем диме? Үзе күргәнме үлгәнен?

— Чигенгән вакытта үлде ди. Үзе күрмәгән. Ике көннән шул урыннан наступайт иткәннәр, күренмәгән ди. Син инде, килен, дога күндер улыңа. Әйбәт егет иде. Хуруши был баранчук... — Карт килененә дә аңлатканына канәгатьлек хисе белән почмак якка күз ташлады, килен анда самавар булдырып йөри иде.

Фатыйма карчык юл буе яшь түкте. Ташкичү тавын ничек менгәнен сизмәде, Симетбаш урамыннан узганда аның белән исәнләшкән кешеләргә эндәшмәде. Кара кайгысына батты.

Бер атнадан соң аның янына фельдшер Сылу керде. Бу йортка аның беренче аяк басуы иде. Фатыйма карчык улының сугыштан аңа хат язып торуын белә иде, шуңа күрә бу чибәр кызны ерактан гына күзәтеп, үз итеп яратып йөри иде, менә хәзер йортка үзе килеп кергәч, түзә алмады, барып кочаклап алды, чишендерде. Үзе самавар рәтләп йөрде, үзе йөрәк ачысы белән кызны күзләде, тикшерде. Бар икән мөлаемлык. Кызның чытыр ак халаты өстенә таралып төшкән калын чәч толымнарына, тулы калку күкрәгенә, астан гына катлам сизелгән иягенә, ап-ак тигез муенына һәм тамчылы гөл чәчәге кебек чәч арасыннан күренеп торган колак йомшакларына карап, Фатыйма карчык саташты, самаварын сусыз куя язды. Йортка дару исе, чиста, ап-ак бүлмәдә, ак халатлы, йомшак куллы хатын-кыз докторлар караган вакытта гына борынына килеп бәрелеп, яшәргә өмет бирә торган хлороформ исе таралды. Сылуның төпсез кара күзләре яшь белән капланган иде, байтак вакыт ул сөйләшмичә стенадагы карточкаларга карап торды. Фатыйма карчыкның исә йөрәге телгәләнде.

— Ярабби, шушындый асыл зат безнең нигез өчен үскән бит, — дип уйланды ул, өзгәләнеп. — Нинди бәхеттән мәхрүм итте бит бу сугыш... Нәкъ минем улыма, бәгъремә дип кенә ходай яраткан булган бит моны...

Булмады. Үлгән кеше дә, калганы да бәхетсез. Сылу әнә шул минутта ук Фатыйма карчыкның йөрәк түренә кереп урнашты. Ул аңа үз кызы итеп, үз нәселеннән чыккан асыл зат итеп карады һәм аркасыннан сыпырып, чәй янына утыртты.

Чәй янында Фатыйма карчык бер мөнаҗәт әйтте. Көйләп әйтте.

Чыгып китсә берәү илдин,
Аерылып туган җирдин,
Догасы мәкъбүл икән дип,
Харис вардыр пәйгамбәрдин [1].

— Булмады, пәйгамбәрнең догасы булмады, — дип елап алды. — Кешеләрне рәнҗеткәндер әтисе. Бик каты куллы иде, дәүләт урманы дигәндә бер кешегә дә бөгелмәде, рәнҗеш алгандыр. Рәнҗеш үзенә дә, баласына да төшкәндер. Аллаһы тәгалә әйткән, газизеңә бирермен дигән, газизеңә...

Габделнур белән Сылу авыл Советында көрешкәннәр икән. Габделнур аңа сугыш башланганнан бирле гел хат язган, гел бәйләнгән икән. Монысы ачыктан-ачык әйтеп язган: Асаф исән кайтса да, кайтмаса да, мин мәңгегә аныкы, дигән. Хатлар шуннан тукталган. Ә менә авыл Советында очрашкач Габделнур каушап калган, көрешкән вакытта күзләрен күтәреп Сылуга карый алмаган. Русча сөйләшкән.

— Күрдеңме үлгәнен? Сез бит бергә идегез. Асаф миңа гел язып торды бит. Күрдеңме? — дип Сылу аны сораулар белән бөтереп алган.

— Сугыш-сугыш инде ул, — дигән Габделнур, күзләрен читкә борып, — анда бер синеке генә үлми. Менә минем үземнең дә үч төбе нишләде. Осколочное.

Китәр алдыннан пальтосын кигәндә генә Сылу актыгын әйтте.

— Фатыйма апа! — дип өзгәләнеп сүз башлады ул. — Бу җирләрдә мин кала алмыйм. Әтием-әнием үлде, ике энем Уфада детдомда. Йөрәк җәрәхәтләп монда яши алмыйм. Асафың белән мин генә белгән бер серебез бар иде, ул серне белүчеләрдән дөньяда хәзер бер мин генә. Мин синең киленең идем. Сугыш кына аерды безне. Кырык беренче елның сентябрь ахырында минем өч айлык балам төште. Малай иде. Мин сиңа әнкәй дип, ул әби дип дәшә алмадык. Барысы да бетте...

[1] Мәкъбүл — кабул күрелгән; харис — яклаучы, сакчы (фарсы).

Фатыйма карчык, телсез калып, сәкесенә барып утырды.

Сылу чыгып китеп күпмедер вакыт узгач, ут алындырганда гына Гаделия килеп керде. Кулында төенчеге бар иде.

— Сине аш уздыра дип ишеткән идем, апай җаным, гаеп итмәсәң, минә шуны ал, — дип төенчеген тоттырды. — Күптәннән саклап килгән бодай оным бар иде, ике килога гына бетмәс, токмач җәярсең, — диде. Шулай диде дә, кинәт кенә Фатыйма карчыкны кочаклап елап җибәрде.

— Дөньяларның бер яме дә калмады бит, апай җаным, әллә башларымны харап итимме икән, — диде.

Аннан Габделнурдан зарланып алды.

— Асаф турында сораша башлаган идем, нервланып сүгеп ташлады. Әллә бу сугышта ул гына үлгәнме, нәрсә сез барыгыз да шуны гына сорашасыз дип дулый. — Әллә ди, мин кайтканга шатланмыйсызмы? Минем ди, бөтен теләгем сугыштан исән кайту иде, менә мин, бүгенге көндә исән кайттым, миңа бәйләнмәгез ди.

Чәйне озак эчтеләр. Гаделия чәйдән соң житез-житез генә малларны карап, төнгә ашарларына салып керде. Бу хуҗалыкның ул рәтен белә, күзләрен-кышларын килгәләп, кич утырып китк әли иде.

Керде, өстенә киде, чынаяклар юып яткан Фатыйма карчык янына кече якка чыкты да, йөрәк ачысы белән әйтеп куйды:

— И апай җаным, шушы йортларда бергә-бергә гөрләшеп яшәрбез, дип кенә дөньяда яши идем, актык өметләрем дә киселде, — дип мамык шәле белән авызын төреп елый-елый йорттан чыгып китте.

Фатыйма карчыкның башы авырта иде, аңгы-миңге килеп йөрде дә, барып ятты.

Дүрт кубометр утынына һәм иптәшлегенә кызыгып кыш башында гына квартирага керткән укытучы кыз Зәйтүнә дәфтәрләрен күтәреп кайтып кергәндә ул башын бәйләп ята иде. Хәлсез тавыш белән:

— Кызым, мичтәге ашны үзең ал, самаварны яңарт, кәефем шәп түгел, — диде.

Шулай да иртәгесен үзен кулга алды, йөгерде, бар булганын пешеренде һәм өч карчыкны чакырып, йола буенча улы алдындагы соңгы бурычын үтәде. Бибиҗамал карчык кыюланып китте, чын абыстайларча борын аша гына түгәрәкләде:

— Авыр туфраклары җиңел булсын, ахирәттә барча-барча туганнары, якыннары, сөйгәне белән кавышырга насыйп итсен, яшь җаннарны кыйган явыз Гитлерның кыямәт көнендә телләре авызларыннан чыгып җирдә сөйрәлеп йөрсен, аллаһе тәгалә ул Гитлерларны утлы табаларда ялан аяк бастырып торгызып җәзаласын, — диде.

Барысы да «амин» диделәр һәм стенадагы герле сәгатькә күз салдылар.

Мал карар вакыт житеп килә икән.

## XIV

Апрель ае эчендә Симетбаш авыл Советыннан дүрт кеше читкә китте.

Атна саен колхоз идарәсенә районнан телефонограмма килеп торды: сезнең колхоздан фәлән-фәлән җирләргә җибәрү өчен фәлән кадәр кеше бүленергә тиеш, үтәлүе турында хәбәр итегез.

Атна саен идарәгә, авыл Советына районнан оргнабор вәкиле килеп торды: шәһәр заводларына шуның кадәр кеше, Амур өлкәсенә шуның кадәр, азат ителгән өлкәләрнең хуҗалыгын торгызырга шуның кадәр, дип тукып торды.

Әмма Симетбаш авыл Советыннан чыгып китүчеләрнең нибары берсе — Гаделия генә оргнабор планы язылган графага «1» ле билгесе куярга ярдәм итте: Гаделия авыл белән эшне өзеп, язылды да китте. Шәһәрдә авиация заводына эшчеләр туплаган вакыт иде. Авылда әллә ни үзгәрешләр булып бетте: һич тә көтмәгәндә Симетбашта почта бүлеге ачтылар, авыл Советының бер бүлмәсенә калайлы зур ящик керттеләр, чыбыклар суздылар, тимер мич өстенә иске кәтилүк белән сургыч куеп кайната башладылар. Дусяның бәхет басты: сугышта да ул элемтәче иде, балага узмаган булса әле дә Украина җирләрен азат итеп, ил чикләрендә телефон аппаратыннан шатлыклы я ачулы приказлар алып, тапшырып утырыр иде. Тормыш менә шулай үзгәреп китте, Габделнур аны эшкә урнаштыру мәсьәләсендә гадәттән тыш зур житезлек күрсәтте. Хәер, үзе дә тиз урнашты ул: кул төзәлгәнче сугышның бетеп кую ихтималы да бар иде, киләчәкне кайгыртырга кирәк иде. Мәктәптә төрле фәннән унтугыз сәгать нагрузка табылды. Шул арада татарчага да өйрәнде. Бер дәрестә ул бака суйды, икенчесендә винтовкага өйрәтте, өченчесендә иң зур уртак ваклаучыны таптырды. Әлегә тормыш ярыйсы гына бара иде, эштән кайтышлый ул элемтә бүлегенә керә, анда кызыл-чиягә буялган такта барьер артында битенә тут йөгергән юантык Дуся утыра, печать баса, ябыштыра, яза. Дуся күзгә күренеп инде юаная иде, һәм күрше-күләнгә ара-тирә Минҗан карт әйткәләп куя иде:

— Безнең титарай сугышта да тик ятмаган; терекөмешне тегендә үк йөгерткән булган.

Киленне эчтән генә бик яратты Минҗан карт. Әмма кешегә мактарга ашыкмады. Тик бер генә нәрсәне аңлый алмый интекте ул: чәчен тарагач, килен чәчле тарагын өстәлдә калдырып китә иде. Киленнең үзе барында Минҗан карт әллә ничә мәртәбә таракны өстәлдән алып куеп карады, юк — файдасы тимәде. Трубка тартса да, бик чисталыклы кеше иде карт. Шуңа күрә, «килене ничек?» дип сораганнарга бер дә кистереп җавап бирмәде.

— Мактар идем — торганым бар, яманлар идем — торасым бар,— дип кенә эшне бетереп куя иде.

Габделнур хатыны янына кереп яңа килгән гәзитләр караштырып утыра, ара-тирә Дусяга ярдәм итә, дүрт авылга килгән хатларны таратыша иде.

Ах, кертмәскә иде барьерның бу ягына Габделнурны. Әгәр моның нәрсә китереп чыгарасын белсә, кертмәгән булыр иде аны беркатлы, сөйкемле Дуся. Хәер, тормышның, җайланып килгәндә генә кинәт чыгырыннан чыгуының сәбәбен Габделнур барыбер әйтмәде аңа. Бу — мәңгелек сер булып калды. Кинәт кенә бер көнне эштән бергәләп кайтканда Габделнур кибеткә кереп тәмәке эзләде (ул тартмый иде), юлда берни сөйләмәде, ах та ух килде, авыр сулады, кайткач этисеннән бер төрерлек тәмәке сорап алды, төнлә ятканда хатынының юантык биленә кулын салмады, Дусяның йомшак кулбашына, гадәттәгечә, авызын куеп йокыга куермады. Йокламады да, сәбәбен дә әйтмәде.

Ул көн Габделнурның бөтен яшәешен үзгәртте, аны тинтерәтте. Симетбашка килгән хатларны актарып утыра иде ул. Хат таратучы әле килеп җитмәгән, хатлардан әле саламлы чана, капчык исе килеп тора иде. Арадан өчпочмаклы бер хат аның күзләренә мина ярчыгы булып килеп бәрелде. Хатта «бесплатное» дигән өчкырлы штемпель басылган, «Раимовой Фатиме» дип адрес язылган, ә ахырында Асафның үз кулы беләнме-түгелме — «Р. Асаф» дип куелган иде.

Габделнурның башына кан йөгерде, хатны тоткан кулын яза алмады, тыны кысылды. Ике фикер анда нәкъ биш-алты секунд көрәште. Хат аның кесәсенә керде. Кинәт кенә торып чыгып, авыл Советы ишегалдындагы такта бәдрәфкә кереп бикләнде дә, дер-дер калтырап, кыс-

ка хатны укып чыкты. Һәр сүзе йөрәк бәгырен телгәләде, миенә авыр кургаш, кайнар ярчык булып тулды.

«Хөрмәтле Фатыйма апа!

Сезнең улыгыз лейтенант Рәимов белән без бер палатада ятабыз. Ул әлегә хат яза алмый, врач рөхсәт итми, ләкин инде савыгабыз, рәтләнәбез. Сез аннан хат алмагач борчылгансыздыр инде, әмма шатланыгыз: аңа сөйләшергә рөхсәт иттеләр, ул батырлыклар күрсәткән егеткә охшый. Бер ун көннән үзе хат язар. Мин Горький ягыннан, әнием хатыным, ике балам бар. Сәлам белән лейтенант Долгаршин Шәүкәт. 10 апрель, 1944 ел».

Асаф исән? Асаф — исән калган? Үлмәгән? Бу хатны ни эшләтергә? Бирергәме, юкмы? Бирмәсәң, нәрсә отасың? Барыбер бит хатлар киләчәк. Димәк, Асаф теге бәрелештә исән калган. Югыйсә, танклар хөҗүме вакытында ул участокта җирнең асты-өскә килгән иде. Фашистлар снарядын кызганып яудырмады ул көнне. Юл өстендә шуышып йөргән ике солдат өстенә күпме ут койды беренче танк. Асаф җан ачысы белән кычкырды ул вакытта:

— ПТР кайда? Ник атмыйсың? Ник ПТР белән мине сакламыйсың, гад! — дип юл өстендә тәгәри-тәгәри шуышты, соңгы минаны оясына урнаштырганда да ачы тавыш белән өзгәләнде.

— ПТР кайда? Кайда дим, шкурник!

Габделнур исә ПТРны алабута арасында калдырып, кюветтан артка таба йөгергән иде. Бер мина куелмаган дип башыңны ничек снаряд астына тыгасың? Сугышның язмышын бер мина хәл итәмени? Ул бит, җитмәсә, яралы да иде: сул кулының аркасына килеп кергән ярчыкны кыр госпиталендә, палатка эчендә ярып алдылар, шулай булгач, сугышчан бурычын үтәмәгән дип аны кем әйтә ала?

Бу хатны нишләтергә соң? Габделнур аны йомарлап уч төбенә кысты, яралы кулның уч төбе әлегә начар сизә иде, әмма хатны кыскач тирләп китте, сулык-сулык итеп сызлый башлады. Ул гаепле түгел бит монда... Танкларны ул чакырып китермәгән бит. Колодяжный белән Балахановны җибәрмәскә иде. Имеш, балалары бар. Димәк, Асаф үлемгә теләп барган. Иптәш булсын өчен Габделнур белән Лукинны үз янында калдырган. Үләргә дип... Лукинның авыр ярадан үлгәнен әйттеләр. Расположениегә кайткач аңына килгән. Үләр алдыннан сораган, имеш: лейтенант исәнме? Танклар узмадымы?

Юк, танклар узмады ул көнне. Ул участокта фашистларның җиде танкысы утырып калган шул вакытта.

Габделнур хатны почтага кире кертеп бирә дә, ташлый да алмады. Әмма иртәгесен Дусяны елатып-елатып район үзәгенә җибәрде: почта начальнигының рөхсәтеннән башка эшне болай гына ташлап китә алмый иде ул.

Минҗан карт малай белән киленнең кинәт кенә илдән чыгып китүенә әллә гаҗәпләнде, әллә гаҗәпләнмәде. Төенчекләр, багажларны ат чанасына төяп бетергәч кенә, Габделнур капка баганасына сөялеп торган әтисе янына килде һәм сугыштан кайтканнан бирле беренче мәртәбә татарча сүз кушты:

— Я, эти хуш, — диде, — без Ташкент ягына китәргә булдык. Как устроимся, мы тебе напишем.

Су тонып торган карлы-балчыклы урамнан лачтыр-лочтыр ат кузгалды, апрель кояшының нурында марҗа киленнең яшь бөртекләре ялтырап куйды.

Минҗан карт шикләнмәде: бу — малай белән актык күрешү, актык аерылышу иде.

Ат урам чатында күмелгәч, ул өенә кереп китте һәм иркенләп бер трубкасын тутырды. Бу соңгы ике ай дер селкетеп алды бит әле...

— Һи-и-и, миңа хәзер ике дөнья бер, уртасы — камыр. Майть якасына. Әйдә, китсеннәр, — диде. — Болай бер башым да, бер... Ни теләсәм, шуны эшлим. Үзем турында уйларга кирәк. Хәзер миңа, алла ирек биргән, патша билет биргән. Идрит-кудрит...

## XV

Майның соңгы көннәре — җирнең иркен сулап бер киерелгән, тыныч күктә тилгәннәр тирбәлгән, тал песиләрендә умарта кортлары гөжләгән беренче тыныч язның иртәсе иде.

Поезд дөбер-шатыр килеп тимергә тимерне чаңгылдата башлады — Идел күперенә кереп барышы икән. Асафның Идел күперен беренче күрүе, теге елны моннан төнлә узылган иде бугай. Купеларда халык күтәрелде, тәрәзәгә ябырылды. Борынгы анабыз, гасырлар буе халыкларны ашаткан-эчерткән, аралаштырган, моң булып җырларына кергән чал елга шушы икән... Ул, мәһабәт көмеш көзге булып, нур чагылдыра, аның уртасыннан кайчандыр узып киткән пароходның эзе әле дә таралмыйча сузылып ята, яр буендарак дүрткелле зур рамга корылган ятьмәне көймәсеннән төшереп-меңгереп бер агай балык сөзә иде. Күрше купеда берәү гармун тартып җибәрде. Асаф моның немец аккордеоны икәнлеген танып алды, бу аккордеонга кырык бишенче елның апрель-май айларында бик күп татар малае өйрәнде. Немец аккордеонында безнең татар тальянкасының моңы юк, әмма аның тавышында җиңү тантанасы, бөеклек, мәһабәтлек бар иде. Моннан бер ай чамасы элек кенә Берлин, Дрезден, Прага урамнарында бик күп егетләр бу гармуннан «Барыня» да, «Әпипә» дә, «Гопак» та, «Лявониха» да, «Лезгинка» да сытып чыгардылар. Асаф үз взводындагы малайларны бик яхшы беләм дип йөри иде, ә менә 9 май көнне иртән Дрезден урамында егетләр бер ящик француз коньягы табып кәефләнгәч, җырлый-бии башлаган солдатларны күреп, аптырый калды. Алты балалы карт Балаханов пилоткасын егетләрчә мут итеп рәтләп куйды да, Дрезден галереясы каршындагы мәйданның кызгылт ташына авыр кирза итекләрен чакылдатып бәреп, җырлап биеп китте.

Эх, пить будем —
гулять будем,
а смерть придет —
помир-ать буд-дем-м...

Хәер, Асаф үзе дә ул көнне «хорош» иде. Командующий адъютанты үзенең флягасыннан калай кружкага салып аңа спирт эчертте дә, кабарга бер телем «сәләми» тоттырды.

— Инглиш сәләми, үзеңә күрә генә,— диде. Аннан соң карт Балаханов үзенең командирын биергә чакырды. Асаф кругтагы солдатлар арасыннан кычкырып эзләде:

— Кто из Казани? Из Уфы? А ну, нашу татарскую!

Киңчә битле өлкән сержант уртага чыкты — җилкәсендә кызыл перламутр белән төрелгән тубал кадәр аккордеон иде, ул ике дә уйлап тормыйча, «Әпипә» не тартты — Асафка каршы чыккан сержант Колодяжный «Әпипә» көенә яраклаштырып җырлап биеп китте.

Шмат не трацім трацілу
На нямецкую скацiну:
Грамаў семдзесят зарад
Нi шчыць шмат гiтлеранят...
Заспявайце, хлопцы, песню
Самую вясёлую,
Як мы фрыцаў частавалi
Куляю свiнцоваю.

Инде аккордеон тавышы Идел кичкәндә яңгырады. Күрше купеда стаканнар чыңгылдады, татарча җыр башладылар. Өр яңа җыр, өр яңа моң — җиңү язы моңы иде. Җырлаучы — хатын кыз иде.

Өй артында шомыртымлай,
Тамыры җиргә китә шул,
Тамыры җиргә китә.
Төн йокылары йокламый,
Күңелем сине көтә.

Гармунчы бу көйне белеп бетерми икән, әмма бирешмәде, аккордеонны үкертә бирде.

Иделне чыгу күңелләрне җилкетте, туган як һавасы вагонның ачык тәрәзәсеннән җылы баллы җил булып керде. Паратск станциясенә килеп туктау белән халык кояшлы перронга коелды, солдатлар гимнастерка якаларын чишкән, яланбаш иде, барысы да насос киерткән мичкә янына җыелдылар, уен-көлке гөрләде. Асаф та, гимнастеркасын төймәләп, кояшлы вокзал мәйданына чыгып яланбаш басты. Сугыш әллә булган, әллә булмаган! Киоскаларда яшел суган белән тәеп пешерелгән кайнар бәрәңге, тозлы кыяр, пешкән ит, йомырка, лабазда ит саталар иде. Татарча сөйләшү колакка бәреп керде: гаҗәп, татарлар ысылдап сөйләшәләр икән:

— Исәнмесес!

— Ничек кайттыгыс?

— Исән торасысмы?

— Авырышмыйсысмы?

— Ярый, сау булыгыс!

Йөрәккә якын, сагынылган авазлар...Лабазда ит алырга чират торалар. Асаф алар янына килеп басты да рәхәтләнеп ике хатын-кызның тыныч кына сөйләшкәннәрен тыңлады.

— Әнә тегеннән генә ал. Нәрсә чират торасың? Менә мин ике кило алдым, — дип, чандыр хатын сумкасын ачып бер кисәбә ит күрсәтә.

Юантык хатын тегенең сумкасына күз сала да, тыныч кына җавап бирә:

— Минем этем юк шул, — ди. Ярты минутка тынлык. Ит алган хатык тын ала алмыйча буылып тора да, тынны җибәргәч, акрын гына җавап кайтара:

— Мин үземне эт дип уйламыйм.

— Ә үзем өчен мондый ит миңа бушка да кирәк түгел.

Тагын тынлык. Теге хатын тагын буылып тора да хәл кергәч телгә килә:

— Димәк, син ризык хәзерли белмисең.

Ах, шайтаннар! Сугыш булганын ни арада онытканнар... Асаф елмаеп перрон буйлап китте, паровоз өзеп-өзеп кычкыртып алды, тормозларын ычкындырды.

Поезд Казанга якынлашып килә иде.

Казанны узгач нибары ике сәгать — һәм Ташлытау. Ташлытау станциясенә төшкәндә Асафның йөрәге типте, тыны буылды, тамак төбе кипте. Исәнме, туган җир! Исәнме, агач вокзал, исәнме, мазут исе килеп торган шпаллар, исәнме, су башнясы... Җаныкайларым! Сез гел элеккечә икәнсез әле, ә менә мин җимерелгән су башняларын, макарондай бөгелгән рельсларны, үрә торган рельска асылып калган шпалларны, кара күмер өеменә әйләнгән вокзалларны күрдем... Сез нәкъ элеккечә икән...

Асаф паровозның су алганын, пошылдаганын тыңлый-тыңлый Ташлытау станциясендә йөрде. Поезд Симетбаштан ун чакрым ераклыктагы разъезд аркылы уза иде, авыр чемодан белән Ташлытау аркылы йөргәнче шул разъездда — «Алтмыш сигезенче» дип йөртелгән платформада төшмәкче булды ул. Әмма пассажирскийлар анда туктамый

иде. Асаф машинист янына китте. Тешләре генә күренеп калган, майга баткан кап-кара адәм, чүпрәк белән паровозның поршеньнарын сөртеп йөри иде, күрәсең — ярдәмче. Асаф егетлек күрсәтте:

— Сэр, алтмыш сигездә тормозни, — дип сүз башлады ул. — Союзниклар күчтәнәчен авыз иткәнең бармы? Шеф кайда?

Өстә тимер тоткага тотынган кара майлы гәүдә күренде.

— Сәлам, шеф! — Асаф кесәсеннән целлофанга төрелгән бер пачка чыгарды. — Алтмыш сигездә дим, акрынайтыгыз, мөмкин булса. Ә монысы — күчтәнәч. Дрезденның үзеннән. «Вени, види, вици». Килдем, күрдем, җиңдем, дигән сүз. Америка сигаретлары.

Целлофанлы пачка өскә очты. Кара кешенең ап-ак авызы көләч елмайды:

— Платформага житкәнче... Стрелка алдыннан! Аңладыңмы? Барысы да тәртиптә булыр, лейтенант! Кәләш янына?

Ах, йөрәкне телгәләмәсә иде бу актеш.

Кәләш... Юк инде, табигатьнең гүзәл баласы затлы Сылу, кайнар сулышлы, дәрт тулы яшь кәләш юк инде. Асафның үлгән хәбәре килгәч, ул инде каядыр китеп барган, югалган... Йөрәкне телгәләмәгез. Асаф әнисеннән килгән бер хатның утлы сүзләрен күңелдән белә. Әнисе ип белән, жай белән язган иде. «Кадерле угълым, сине күрер күк түгел, күрмичә үләрмен дип куркам. Бигрәк үлеп беткәчләр яңадан табылдың бит. Сылу балакаем белән эшләрегез бик тирәнгә киткән булган икән. Габделнур кайтты, ул кайтканчы әле өметем бар иде. Шуннан Сылу килде. Габделнур әйтте: Асаф, диде, бетте, диде. Сылу үксн-үкси бер елады, балакай. Үзенә дә бик ошаган иде. Насыйп булмагандыр инде. Әле Бибиҗамалга хаты килгән, госпитальдә яткан бер командирга кияүгә чыктым, дип әйтеп әйткән, үзе госпитальдә эшли икән».

Машинист вәгъдәле кеше булып чыкты, «Алтмыш сигез»нең стрелкасы алдыннан тормозларны кысты, Асаф чәчәкләре рельска ук тирәләп үскән бер сукмакка сикереп төште, проводник аңа авыр чемоданын бирде, яшел капчыгын ыргытты. Туктар-туктамас шуышкан поезд буферларын ыңгыраштырып хут алды, китеп тә барды. Асаф урман эчендә ялгызы калды, разъездның вокзалына таба барып торуның хаҗәте юк иде, әгәр сугыш вакытында үзгәртеп бетермәгән булсалар, бу турыдан гына бер сукмак урман эчендәге юлга, аннан — басуга кадәр алып чыгарга тиеш. Урман эченә керде, биткә җылы парлы бал, имән мичкә, корыган яфрак, кырмыска түмгәге исләре бәрелде. Чемодан белән капчыгын куйды да беравык туктап торды. Урманда май ахырында гына була торган концерт иде. Кошлар барысы берьюлы сайрый, барысы берьюлы кычкыра, урманда булган барлык бөҗәк барысы да берьюлы гөжли иде. Моннан аерылып китү мөмкин түгел иде, Асаф чирәмгә тәгәрәде.

Сугышның беткәнен ул хәзер генә аңлады. Менә үлән арасында йөк күтәргән кырмыскалар йөгерешәләр, менә сандугач тәпие дигән чәчәккә төклетура килеп кунды, аның авырлыгыннан чәчәк сыгылып китте дә, төклетура үлән арасына егылып төште, бызылдап үрмәләп чыкты, тагын кунды, тагын егылып төште. Якында гына ачып утырган бал мичкәсе кебек нәрсәдер тоныкчымырдый — Асаф яткан җирдән әйләнеп артына карады — чүмәлә кадәр кырмыска оясы икән. Кырмыскалар, төш вакытының эссе кояшында мыжгып, миллиард кызыл ылыстан корылган йортларын селкетәләр иде. Агач башында — иң биек агач башында булырга тиеш — күке гомер саный. Сана, күке, сана, эш җиңеләйде хәзер. Асафлар чорының егетләре — егерме икенче, егерме өченче елгылардан ун егеткә берәү исән калды. Ун егеткә берәү!

Куе шомыртлык ягында, кояшлы алан түрендә урман тавыгы корылдый.

Кыру-кыру-кыру...

Урман язгы дымнан, көндезге кояшның кайнар нурыннан бүртенгән, парланган, куе балга чумган иде. Асаф ашыкмыйчы гына торды, акрын гына алга атлады. Сугышның бетүе шушы икән. Тынычлык менә шундый була икән... Сугыш кичмәгән булсаң, шушы матурлыкны күрә белер идең микән?

Урман авызына җиткәндә генә борынга сазлык үләне, урман бөтнеге исе бәрелде. Әйе, бу урында җәй буе су җыелып тора, монда арба тәгәрмәче кучәренә кадәр бата иде, әле дә шулай икән. Сазлык өсте шәмәхә-миләүшә төстәге чикләвек зурлыгындагы чәчәкләр белән капланган, чебен-черки мыжгып тора. Агачлар арасыннан бит-кулларын чыбык-чабыкка сыдырып, сазлыкны әйләнеп узганда, Асафның күзләренә кинәт кенә сап-сары бер ашъяулык күренде. Нигәдер йөрәге дөпелдәп куйды, тыны кысылды. Сазлык кырыенда, карт имән тирәсендәге сулыкны ут чәчәге каплап алган иде. Бу матурлык аңа кырык беренче елның июнь көнен исенә төшерде: бәхетле дә, әллә нинчек шомлы да, саташулы да бер көн иде ул.

Урманны чыгуга уҗым басуыннан коры йомшак җил бәрелде, юл читеннән, ук булып атылып, анда-санда тургайлар күтәрелде. Һәр кошның атылып чыгуы йөрәкне сискәндерә, миналы сугыш кырын хәтерләтә иде, юк, сугыш урман эчендә ятып торганда гына онытылып торган икән...

Ындыр артында тачкасына ярты кочак ат кузгалагы салган сипкелле, борыны кубыклаган бер малай, күзләрен челт-челт йомып, сәерсенеп Асафка карап торды да, тачкасын ташлап авылга йөгерде.

— Сөенче алырга йөгерде, — дип, шатланып уйлап куйды Асаф. — танылымы икән? Әллә кем белән бутап бөтенләй икенче кешеләрнең йөрәген җәрәхәтләмәсме икән?

Әмма малай туп-туры болар чатына таба элдертте, аның төссез кыска ыштаны арттан ертылган, шуңа күрә йөгергәндә малайның бөтен байлыгы ялтырап күренә, өстәвенә — Асаф юри санады — һәр биш адым саен сул кулын артка чыгарып, малай җәһәт кенә төссез сәләмә ыштанын күтәреп куя иде.

Кызык. Дрезденның мәшһүр галереясын фашист миналарыннан чистарып йөргәнгә, андагы мәшһүр картиналарны һәлакәттән коткарганга әле кайчан гына, ә монда ат кузгалагы җыеп йөргән кубык борынлы малай йөгерә.

Капка төбенә ни арада өч-дүрт хатын-кыз җыелып өлгергән, барысы да яшь катыш елмаю белән тыкрыктан чыгып килгән Асафны карап торалар иде. Фатыйма апа, алардан аерылып, җәһәт-җәһәт атлап юл уртасына чыкты. Асаф урамның урта бер җиренә чемоданын куйды да, иңендәге капчыгын җайлап ике кулын җәйде, ябык, кечкенә гәүдәле әнисен кочагына алды.

— Исән-сау кайттыңмы, балам? — диде Фатыйма апа, арык җилкәләрен дерелдәтеп. — Бөтен җирең дә исәнме?

Капка төбендәге хатыннар янына Асаф әнисенең җилкәсенә кулын салган хәлдә килде. Барысы да танышлар, үзләр, якыннар иде.

— Я, күршеләр, исән-имин торасызмы? — дип ул аларның һәрберсе белән ике куллап күреште.

— Бәрәч, син үзебезнең телне онытмаган икәнсең әле, — диде Бибиҗамал җиңги. — Анда синең иптәш-тауарищлар телләрен калдырып та кайттылар.

Кубык борынлы малай күлмәк итәген күтәргән, итәктә ниндидер тәмле әйбер булса кирәк, авыз тулы, күзләр әсәрүле иде.

Асафның гомеренә хәтерләп калганы нигәдер шул булды: малайның тузанлы, керле корсагы һәм урман чикләвеге кадәр калкып чыккан кендеге. Фатыйма апасы аңа ниндидер тәмле әйбер биргән булса кирәк, малайның авыз аппараты бөрөзлексез эштә иде.

## XVI

Асаф утыз бишенче елны ук этисез калды. Этисе Фәисхан агай укымышлы, тормыш итүнең ибен-җаен белә торган кеше иде. Гомере буе руслар белән аралашып яшәде, Ташлытау руслары белән умарта, калай, буяу мәсьәләләрендә әвәрә килеп аралаша иде. Өендә сирәк торды, чөнки Симетбаш-Ташкичү өсте урманнарында баштарак өстерилек, утызынчы елдан соң лесничий булып эшләде. Йортта көндез булмады да диярлек. Кайтканда да бакчага чыгып китеп, умарталары арасында кайнаша иде.

Асафны кечкенәдән умарта кортыннан курыкмаска өйрәтте. Этисенең умарта тирәсендәге кагыйдәләре бик гади иде: тирләгән көе умарта янына килмәскә. Аракы эчкән, одеколон сөрткән, тәмәке тарткан кешене кортлар яратмый. Кирәккә-кирәкмәскә кортларны төтен белән котыртмаска, корт бәйләнә башласа — чәбәләнмәскә. Битеңне саклыйсың килсә, иң яхшысы —капланырга да, ятарга. Иң күңелле көннәр — бал суырткан вакытлар була, бу көннәрдә Фатыйма апа күрше-күләнгә күчтәнәч итеп ахак төсле сыек бал өләшә иде... Фәисхан агайның корт өе — урталай ярма нарат бүрәнәдән. Сап-сары бу йорт бакча түрендә, ул йортның артыннан челтерәп инеш ага, йортның эчендә җәй көне, умарталарны чыгаргач аеруча күңелле була иде. Монда нарат тактадан эшләнгән хуш исле рамнар саклый торган озын сандык, тәрәзә төпләрендә китаплар, сары стеналарда курилка, корт туболлары, битлекләр.

Аларга еш кына урман эше, печән-бүрәнә мәсьәләләрен хәл итеп йөрүче район житәкчеләре туктала һәм кайберләре шул умарта йортына кереп йоклап та ала иде.

Рәхәт, бәхетле бала чакны Казиле каракларының балтасы кара канга батырды.

Утыз бишенче ел маенның кояшлы бер иртәсендә кайгысына баткан әнисе Асафны йокыдан уятты.

— Улым, тор, йортыбызга бәла инде,— диде.

Фәисхан агайны йортның уртасындагы зур өстәлгә сузып салганнар, башында чалма кадәр канлы марля, йөзе зәңгәр, күзләре тоныкпыяла, ияге гадәттән тыш калкып алга чыккан иде. Ике милиционер, тагын әллә кемнәр нидер язалар, сорашалар...

Асаф ни икәнен аңышып бетмәстән урамга чыкты, күзенә җете кояш бәрелде. Хәер, ни икәне аңлашыла — этисе үлгән иде. Урам тулы халык... Урам уртасына алды арбасыз гына бер озын арбаны сузып куйганнар. Халык шул арба тирәсендә кайнаша, шаулыйлар, берсенберсе бүлдерәләр.

— Безнең колхозныкы түгелме?

— Юк, юк, аларның арбаларында мондый ызнакның булганы да юк.

Асаф арба янына килде. Өлкән ирләр малайга юл бирделәр Арбаның урта бер җирен бау белән мичәләгәннәр — утыра торган урын ясаганнар. Бүрәнә ташу өчен җайланган арба. Бөтен кеше бөкрәя-бөкрәя агач күчәрнең арткы ягына яшел буяу белән язылган хәрефләрен укый. Алама гына итеп, күрәсең, бармак белән генә, өч хәреф төшергәннәр: «У. К. А.» Нәрсә булыр бу? Агайлар шулай баш ваттылар.

Сәрдәләр түгелме? Күршедә Сәрдәдән килгән бер килен бар иде, җилтерәтеп аны алып килделәр.

— Танымыйсыңмы, сезнең авылныкы түгелме? — дип ирләр шаулашып сораштылар.

— Юк, — диде яшь килен, — юк. Бездә, тучны гына беләм, колхоз арбаларына кызыл буяу белән язалар.

— Казиләләр эше түгелме?

Халык тагын шаулашты. Авылда Казиледән килгән килен дә бар икән, аңа торып йөгерделәр. Казиле килене озак көттермәде, канатлы ак алъяпкычын җәйге җилдә уйнатып, килеп тә житте.

— Бәрәч, безнең колхозныкы бу, — диде ул, әлегә үзенең нәрсә әйткәнен белмичә.

— Сезнекеме? Сезнекеме? — Ирләр шар ярдылар — кычкырдылар, ыгы-зыгы килделәр.

— Ие инде, ие. Әнә ич: хәрефләре безнеке.

— Нәрсә ул? Ни дигән сүз? Аңлатып сөйлә. Монда кәтер китәрлек эш.

— Нәрсә булсын? — Килен канатлы алъяпкычы астына кулларын тыгып, тураеп басты. Ирләргә борылды:

— «Ударник» колхозы арбасы дигән сүз. Шуны да белмәскә сез. Ир башыгыз белән.

Киленне йортка алып кереп киттеләр.

Авыл кайнады, ике көннән соң Фәисхан агайны зурлап күмделәр. Ташлытаудан әллә никадәр руслар килгән иде. Казиле караклары телдән төшмәде. Ахырдан сөйләделәр: урман эчендә туры озын имәнне кисеп ятканда күрәчәгенә каршы караклар янына Фәисхан агай килеп чыккан икән. Тегеләр кызмача булганнар, бирешергә теләмәгәннәр. Протокол язарга кордонга алып чыгарга әйдәкли башлагач, башына балта белән бәргәннәр дә, торып чапканнар. Әмма озын арбаның артын калдырып качканнар. Яктырып килә икән... Фәисхан агайның канлы гәүдәсен өстерилек үзенең эте өргән тавышка барып тапкан.

Казиле каракларына зур суд булды, авылдан ул судка күп кешене чакыртканнар иде.

Шулай, Фәисхан агай бетте, аннан аның умарталары. Аннан алмагачлары корды...

Фәисхан агайны ике төрле итеп күмделәр ул вакытта: районнан китерешли үк клуб каршында митинг булды, анда халык дошманнары кулыннан һәлак булган лесничий турында матур сүзләр әйтелде дә, митинг тәмамланды. Аннан агач ящиктагы гәүдәне йортка алып кайттылар да, мөселманча йола үтәделәр.

Асаф сугышта күпме үлем күрде, әмма шул заманнан ике җөмлә гомеренә хәтерендә калды. Ике йоладан — яңасыннан һәм искесеннән. Беренчесеннән:

— Черек либерализмга каршы юнәлтелгән...

Икенчесеннән:

— Инния лиляйһи вә инния лиляйһи ражигу-у-н!

...Самавар инде өченче тапкыр яңартыла, ана белән ул үткәндәгеләрне хәтерләп сөйлиләр дә сөйлиләр иде. Бу — кырык беренче елның июнендә эчеп бетерми калган чәйне эчү, күп көтелгән, еллар буе хыялланган сөтле чәй, тыныч сөйләшү иде. Барысы турында да сөйләшкәндә, тик бер генә мәсьәләгә кагылмадылар: Сылу кайчан, ничек авылдан киткән, хәзер кайда...

Асаф карап, сизеп утырды. Әнисе юри бу темага керми, бөтенләй әйләнеп уза.

— Аннан килепе... аннан килепе... — дигән булып, бөтенләй читят мәсьәләләр турында сөйли, сөйләр өчен әллә нәрсәләр хәтерли.

— Габделнурлар кайда соң хәзер? — дип сорады Асаф, нигәдер авыр сулап.

Габделнурдан алып Сылуга кадәр — бер адым.

— Бер авыз сүз татарча сөйләшмәде, җавыз. Хатыны елый-елый әйткән: син, диган Гриша — сугыштан ул Гришага әйләнеп кайткан — син, дигән, үзегезчә сөйләш. Нигә алай кыланасың? Минем белән сөйләшеп аңлашкач, шул җитмимени? Менә шундый акыллы марҗа алып кайтканые тозкүз. Кыз бала бит, бу юньсезнең кем икәнен белмәгән инде.

— Нигә юньсез дисең Габделнурны? Ул кан коеп кайткан бит?

— Койган пычагым! Уч төбен күрсәткән була. Ниндидер бер җөй бар шунда. Андый гына инде ул утын ярганда да була. Юньсез дими... Елый-елый сорадым: бер атнада чыгып киттегез дидем, кая калдырып кайттың? Уайна, бабешка, уайна дигән була, әҗәткана. Кайда аерылыштыгыз соң сез аның белән?

Асаф тагын авыр сулады. Кырык өченче елның октябрь ае, алабута баскан кысыр басу һәм бөтен авылның йортлары, мунчалары хәрәкәткә килгән сыман кузгалган немец танклары күз алдына килде. Һәм үзенең актык мәртәбә кычкырганын хәтерләде:

— ПТР кайда? ПТР кайда? Сволочь, прикрой меня! Беренче танкны туктат! Туктат, гад!

Хәер, моны төгәл хәтерләп булмый иде, сугыш беткән көннән соң болар барысы да төш сыман гына, берсе дә булмаган сыман тоела. Иң яхшысы — әлегә бу төшне хәтерләмәскә. Еллар рәткә салыр әле дүрт ел эчендә күргәннәрне...

Кайда аерылышканны Асаф сөйләп тормады.

— Минҗан абзый кем белән калды соң инде?

— Һи-и-и... Әле сөйләсәм шаккатырсың. Шуннан килепе... Гаделия килде бер көн. Хәл-әхвәл сорашты, ике кила чамасы бодай оны күтәреп килгән. Сиңа коръән укытырга йөрим. Бичара кыз, күңелендә гел син булгансың икән. Дөньяларның, Фатыйма апай җаным, диде, бер яме дә калмады, диде. Шушы йортларга килен булып төшеп, бер рәхәтләнеп яшәрбез дип кенә уйлап яшидерием, диде. Юк инде, булмагач-булмый инде дип, елап йөгерде. Бичара. Эше нинди әйбәтие — җазылды да китте. Казанда, заводта эшли хәзер.

Асаф дәшмәде. Күңелендә Гаделияне кызгану хисе туды. Шуннан башка хис юк иде. Әнисе сүзнең төп ниргәсенә кергән иде, җай белән генә алга таба үрләде.

— Аннан килепе... Миңа әйтмәгән бер эшегез булган икән, малай. И бала, бала... Шул кызны өйгә китереп, минем янда калдырып китә белмәгәнсең. Үзем белгән булсам...

Бернинди исем аталмады, әмма сүзнең кем турында барганлыгы аңлашыла иде.

— Үзем белгән булсам. Бер көн тотмыйча монда җитәкләп алып киләсе идем.

— Аның өе тулы ятимнәр иде шул.

— Ятимнәр юк. Балаларының икесе дә приютта. Әмма тегесе әрәмнәр генә булды. Синең югалган хәбәрең килгәч керде безгә. Ярабби... Килепләр басты менә шушында, стенадагы карточкаларны карый. Ул гәүдәләр, ул чәч толымнары, ул кашлар-күзләр. Андагы мәхәббәтлелек, сылулык. Хурлыгына чыдый алмыйча гына китте инде. Җәйгә хәтле торасы иде әле.

Асаф тетрәнеп китте. Нәрсә, тагын Габделнурмы әллә?

— Нинди хурлык? Нәрсә булды?

— Хурлык дипе... Кызның бер гаебе дә юк. Бер катнашы да юк. Габделнурлар өйне ташлап чыгып киткәч, Минҗан карт җалгыз кал-

ды. Шул. Йөргән, йөргән дә, бер көнне, билләрем сызлый, банке салмассыңмы дип, Симетбашка — теге балакай янына килгән. Балакай караган, тыңлаган, язулар биргән даруга. Китми дә китми ди. Шуннан соң әйтә ди бу.

Фатыйма апа авыр сулап куйды.

— Ни дип әйтә ди... Шулай-шулай, дип әйтә ди, син дә җаңгыз, мин дә җаңгыз, дип әйтә ди. Утыны, ашау-эчүе бар, дип әйтә ди. Минем дип әйтә, ди, тулы тәнле хатын янында арка җылытып ятасым килеп гомерем үтте, дип әйтә ди. Бергә-бергә кушылып яшик мәллә ди икән бу...

Асаф тагын урыныннан торды. Әнисенең күзләре яшькә тыгылган иде.

— Миңа, ди икән бу, нибары алтмыш яшь. Егетләр кырылып бетте, хәзер ир табуы алай җиңел эш түгел, ди икән бу... Шул көнне үк балакай безгә килеп, үксеп-үксеп елады да, хушлашып чыгып китте. Стенадан синең картечкәңне генә сорап алды. Миндә ди, берәү бар, монысын да бир дигәч, түзмәдем. Яшь җан бит, мөлдерәтеп карап сорады. Менә быел язлыкта гына Бибиҗамалга хаты килгән. Бер әфисәргә кияүгә чыктым дигән, Урал ягында ди.

Асаф ишекле-түрле йөренде, дәшмәде. Көтү кайтыр вакыт җитә иде, әнисе сәгатькә карады, торып учак янына килде.

— И-и, аллам, аш салырга соңга калганмын бит...

— Габделнур нинди эштә икән соң? — дип сорады Асаф калтыравыклы тавыш белән.

— Минҗан карт сөйләп торды. Кыш башында авыл Сәвитенә килгән иде. Малайны илиминткә бирергә дип әйткәннәр иде. киленнең хаты килеп төшкәч авыл Советына килеп укыттым ди. Килене әйткән: ай саен үзем акча салып торырмын, хәзер мин дә эшкә урнаштым, күңелсезләнмик дигән. Пучтыга эшкә урнаштым, бала исәюгә дигән.

— Габделнур нинди эштә икән соң?

— Анысы милитсәдә ди. Анда да әллә ниләр кыландырып бетергән. Машиналарны туктатып шуфирларны бик каһәрли икән. Акча җыйган шулардан бик күп. Бервакыт куркытып та караганнар: болай бик азынсаң, җыештырабыз, дип әйткәннәр. Әле менә күптән түгел генә киленнәреннән хат килгән. Минҗан карт хатны мәктәпкә алып килеп русча укытучыдан укыткан. Теге шуфирлар тәки үчләрен алганнар икән. Бер көнне кич саклап торып, тотып кыйнаганнар, ди, артына утыртканнар, ди. Минҗан карт әйтә ди: ике тапкыр утыртсаң — кеше бетте инде, үпкә-бавырлары кузгала да, саргаеп акрынлап кибә, дип әйтә ди. Әлегә бульниста ята икән, чын булса...

Икәүләп ишегалдына чыктылар. Капкада аксыл-алсу күн танавыннан селәгәй агызып Акбаш тора иде, соңга калып чыкканга рәнҗеп, хуҗа хатынга карап мөгрәп алды.

Берничә минуттан ишегалдына сөт кебек җылы моң таралды:

— Тез-з-з... Тез-з-з... Тез-з-з...

И тыныч тормыш! И бу тыныч тормышның җанга якын авазлары! Юк, адәм баласы беркайчан да мылтык, снаряд, бомба тавышларын сагынмас. Беркайчан да...

*Ахыры бар.*

## Роберт Әхмәтҗанов

### Соңгы монолог

*Тукай турында шигырьдән*

Яна шәме, калгып, сулыгып яна,
Әрнеп яна шагыйрь каршында!
«Коткар мине! — диеп, сыгылып яна, —
Күңел утың калдыр барысын да!..»

Апрель төне. Дымсу яз җилләре
Пыялага өрә сулышын...
Китәргә дә вакыт җиттемени,
Синең белән, дөнья, сугышып?!

Китәргә дә вакыт җиттемени?
Килдем юкса сиңа өр-яңа...
Калырга да мөмкин булыр микән
«Китмибез без!» дисәң дөньяга?..

Килдем сиңа бер кәрзинем белән
(Юк, бирелгән димә аһ-зарга),
Син күпсенмә, тормыш, бу төенне,
Мин вокзалда, соңгы вокзалда...

И шакыдым синең ишекләрне!
Ачылдылар алар кайчакны...
Назлы куллар яклап яшерделәр
Тик каракны түгел, качакны...

И ничаклы ишек тоткалары,
Сыйпамады баштан кем генә!
Тапшыргансың кеше кулларына, —
Рәхмәт инде, әнием Мәмдүдә!..

Сиңа килдем, Тормыш! Буем җитми
Тордым синең ишек артында.
Бер мәҗнүнең идем... Тәпиләрнең
Тиресе кубып калды салкында...

Җылы җыйдым бөтен күңелләрдән,
Менә җылы инде... Җитте яз!..
И мөкатдәс моңлы сазым минем,
Уйнадың соң әле ник бик аз?!.

## Гамил Афзал

### Чулман ярында уйланулар

●

Чулман суы иртән көрән кебек,
Тимгел-тимгел, үзе тирән кебек,
Чулман суы көндез юаш кебек,
Дулкыннары тугры юлдаш кебек.
Чулман суы кичен кургаш кебек,
Шадралатып кичке җилләр өрә,
Чулман өсте йөз төрлегә керә,
Уйларым йөз төрле шуңа күрә.

●

Тау артына китеп кояш сүнде,
Кызыл нурын яшел эңгер җиңде,
Яр буена ямансулык иңде,
Сау булыгыз инде!

Куакларга кичке җилләр килде,
Түтәл чәчәкләре аллы-гөлле,
Һәр чәчәге уйчан башын иде,
Сау булыгыз инде!

●

Чулманга чыга кораблар,
Дулкын ярып юл үтәләр.
— Хәерле иртә, наратлар,
— Хәерле иртә, юкәләр!

Чирәмдә җемелди чыклар.
Сәлам әйтә аяз күкләр:
— Хәерле иртә, чыпчыклар!
— Хәерле иртә, кәккүкләр!

•

Таң җилләре белән чәчең тарап,
Йөзеп барган болытларга карап,
Күк-күгелҗем офыкларга карап,
Нинди уйлар уйлыйсың син, нарат?

Юктыр синең дусың-дошманың да,
Юктыр синең эчең пошканы да.
Кояш бата, йолдыз калка гына,
Ерак йөрсен иде балта гына...

•

Шигырь уйлап тар сукмактан барам,
Бер кырмыска килә миңа каршы.
— Хәерле юл сиңа, оптимист җан,
Теләкләрең гел гамәлгә ашсын!

•

Куаклар артында көлә кемдер,
Якын дусы белән бергәдер.
Сәрви төпләрендә серле эңгер,
Бер кәккүк моңая нигәдер.

•

Таланып беткән куакка
Сандугач кунамыни.
Дөньялар шаулый колакта,
Җан тыныч буламыни,
Җан тыныч буламыни!

•

Сүрелде күзләр, сүрелде
Сентябрь күге сыман.
Тугайлар — зәңгәр томан.
Үткәнем яшел урмандай,
Киләчәк — кара урман,
Урманга карап торам.

•

Фән-техника чоры алга чаба,
Бар, син аны куып җитеп кара.
Күңел тала, кул-аяклар тала,
«Их, булмады» — диеп йөрәк яна,
Ак кәгазьдә моңлы шигырь кала.

●

Айлы төнем зәңгәр, көнем якты,
Сулышларым иркен, суым татлы.
Кемнәрдер моңайган миңа чаклы,
Кемнәрдер елаган миңа чаклы.

Таңым — сары алтын, көнем — көмеш,
Кайдан килгән миңа мондый өлеш, —
Кемнәрдер өләшкән миңа чаклы,
Кемнәрдер көрәшкән миңа чаклы.

●

*Бер артистка*

Сәхнәгә чык, йөрәкләрне тетрәт,
Акыл көлсен, намус дуласын,
Хисләр ташып, ут суласын күкрәк,
Җан сөенсен, күзләр еласын!
Якты юллар ачып алга таба,
Үз кыйбласын күрсен хыялчы, —
Ике сәгать даһи булып кара,
Гомер буе кәмит булганчы...

●

Күлләрдә аккошлар кагынсын,
Иң гүзәл җирләрдә торам дип,
Гөлләргә саф җилләр кагылсын,
Тирә-як озонлы урман дип...
Ә безне оныклар сагынсын,
Бабайлар акыллы булган дип.

●

Ярларыңда ылыс исле урман,
Су өсләрең томан,
Тарихыңа күпме серләр тулган,
Сау бул инде, Чулман!




## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**Нигъмәт Ихсанов,**
**Михаил Скороходов**

# ЙӨЗГӘ-ЙӨЗ

ПОВЕСТЬ



Локман Исхаков Колчак гаскәрләре тылында каһарманнарча көрәшүче партизан берләшмәләренең берсендә комиссар иде. Бервакыт төнге сугышта ул контузия алды һәм берничә иптәше белән әсир төште. Аклар аларны тачанкада бронепоездга кадәр китерделәр һәм көнчыгышка озаттылар.

Николаевскида хөкем сөргән ак террор шәһәргә японнар кергәч тагын да көчәйде. Юк кына гаеп өчен дә халыкны рәхимсез җәбер көтә иде. Локман төрмәдәге якташларыннан шәһәрдә большевиклар подпольесы эшләвен, ә якын-тирәдәге тайгада Максим Носорогов партизан отряды хәрәкәт итүен белде. Подполье комитеты партизаннар һәм сәяси тоткыннар белән элемтә тота, халыкның интервентлар һәм акгвардиячеләргә каршы көрәшенә җитәкчелек итә иде.

Партизаннарның күптән түгел күрсәткән бер батырлыгын тоткыннар үзләре, әле генә Носорогов отрядыннан килгәндәй, бигрәк тә дәртләнеп һәм тәфсилләп сөйлиләр иде. Бу хикәяләрнең аерым урыннары берсе икенчесенә бик үк туры килеп бетмәсә дә, нигезе бер иде. Партизаннар чыннан да баштанаяк коралланган ике йөз кешелек япон җәзалау отрядын тулысынча диярлек юк иткән иде.

Төрмәгә көн саен тоткыннарның яңалары өстәлеп торганлыктан, тиздән инде Локман үзе дә Носорогов отрядының диңгез артыннан килгән чакырылмаган кунакларга ничек итеп сабак бирүе турында илһамланып сөйли башлады.

«Япон гарнизоны башлыгы Нарусакага ерактагы постны тагын партизаннар туздыруын әйтәләр. Җене чыккан полковник тайгага җәза отряды җибәрә. Беренче көнне кичкә таба японнар калкулык артыннан атлар кешнәвен ишетәләр. Бик җиңел генә партизаннарны эләктерергә ниятләп, хәрби сәнгатьнең бөтен шартын китереп тозак кора болар. Тозак коралар да, күптән түгел генә булып узган бәрелештә партизаннар теткән акгвардиячеләр өере калдыгын кызулык белән юк итеп ташлыйлар. Чөй өстенә тукмак! Шайтан саташтыра тегеләрне.

Кичен зур гына бер аланда японнар лагерь кора. Барлык пулеметлардан тайгага ут сиптерәләр — каршы ник бер җавап булсын. Тавыштын юк. Төн тыныч уза.

Иртә белән отряд тайга эченә, Амур буена урнашкан авылга ыргыла. Исәпләре гап-гади: беренчедән, авыл кешеләреннән партизаннар турында мәгълүмат алу; икенчедән, аларны куркыту, талау; өченчедән, егетләнеп, җиңүче булып кайту. Әмма моннан соң самурайлар өчен тынычлык бетә. Сирәк булса да, әле уңда, әле сулда ату тавышлары ишетелә башлый.

Иңбашында погоннары булмаса да, беренче булып отряд командиры ава. Бер колагыннан кереп, икенчесеннән диярлек чыккан пуля аның башын тишә. Аңардан соң тагын берничә офицер теге дөньяга озатыла. Менә шунда гына җәзачылар партизаннарның баштан ук ияреп килүенә, снайперларча эзәрлекләвенә төшенәләр.

Партизаннар исә аз, әмма төз атып, дошманны чүпли бирәләр.

Алда тар үзәнлек. Аны урап алган үрләр чыршы белән капланган. Кара урман, кыскасы, тозак кору өчен менә дигән җир. Туктыйлар. Чая халык дип алга разведчикларын җибәрәләр. Ты-ты-ты! — Сулдан. Ты-ты-ты! — Уңнан... Разведчиклары җан тәслим кыла. Снайперлар исә һаман үз эшләрендә, тын алырга ирек бирмиләр. Шуннан отряд та кире борыла. Чигенү качуга әйләнә, японнар партизаннарның төп көчләре инде артта дип ышаналар, аякларына дәрман гына бир хода. Әмма тайгада япон алласы түгел, Максим Носорог хуҗа, менә ул күрсәтә боларга нужа. Җәзачыларга як-яктан пулемет уты яудыра башлый. Кыскасы шул: дошманның бик әзе генә Николаевскига кайтып егыла. Шуннан бирле аксаган эт Нарусака тайгага ник сыңар аягын атласын».

Локман хикәясен тәмамларга да өлгерми, ветераннарның берәрсе аңа төзәтмә кертә.

— Японнарның барысын да дөмектерәләр, берәмтекләп барысын да. Әгәр кайсы да булса шуышып китә башласа, тайга йотар иде үзен. Японнарга аннан котылып чыгу юк. Фудзиямадан — теге дөньяга! Менә шулай, туган.

*
* *

Партизаннар лагерьны кечерәк бер күл буена корып, иң беренче чиратта яралыларны чатырларга кертеп салдылар. Максим Носорогов үзе дә ашык-пошык ясалган шундый ук куышка урнашты. Керосин лампасы яктысында картага иелеп, дошманны янадан кайда һәм кайчан дөмбәслисен уйлый-уйлый отряд һәм аерым төркемнәрнең алдагы сәфәрләрен билгеләде. Төнге тынлыкны атлар пошкыруы, котелоклар шалтыравы гына бүлә иде.

Чатырга командир ярдәмчесе Мәхмүт Зөбәйдуллин килеп керде. Картага карап, бармагы белән төртеп күрсәтте дә:

— Юлга якынрак булды, — диде. — Кунаклар рәхим итмәсен та-

гын. Постлар куйгач бераз черем итеп алмакчы идем дә күз алдыма шушы юл килде. Нарусака кул кушырып утырмаячак инде ул. Колакка тояклар тупылдаганы ишетелгән кебек булды.

Носорогов башын күтәрми генә бөдрә сакалына бармакларын батырып мыгырданды:

— Татарларда, сакланганны ходай саклар, дигән мәкаль бармы әле?

Мәхмүт көлеп җибәрде, командир бу мәкальне аңардан ишеткән иде. Чатырдан чыккач та ул йокларга уйламады. Таңны иң ерак пост-та — чыршылык битендәге юлда каршылады. Күлдәге камышлар арасында үрдәкләр бакылдый, томан пәрдәсе ялкау гына куак башларына таба күтәрелеп эри бара иде. Мәхмүт лагерь ягына борылганда сакчының кинәт:

— Тукта! — дип кычкыруы ишетелде.

Боерык аңа кагылмавы ачык иде. Шулай да ул кире борылды. Урман битендә кулына кәрзин тоткан бер яшь кенә кыз басып тора иде.

— Каян киләсең, чибәркәй? — диде ул. — Кая юл тотасың?

— Николаевскидан мин. Җиләк җыям.

— Әйдә әле минем белән.

— Ә сез кем соң, аклармы, әллә кызыллармы?

— Нинди чая, кара аны. Атла, әйдә.

Кәефе килгән сакчы:

— Әләктеңме, таң чыпчыгы! — дип кычкырып калды.

Чатыр алдында аякларын җәеп яшь имән төсле базык гәүдәле, киң җилкәле, биленә маузер аскан Носорогов басып тора иде. Янәгында җөй — акгвардеец кылычы кисеп үткән эз. Кыз аның алдында туктап елмайды:

— Сез Максим Носорогмы?

Командир гаҗәпләнеп кашларын күтәрде, сумаладай ялтыраган толымлы кара тут татар кызын аның беренче тапкыр күрүе иде.

—Кем бу? — диде ул, Мәхмүткә эндәшеп.

— Николаевскидан ди. Аклармы сез, әллә кызыллармы дип кызыксына.

— Кызыллар икәнегезне үзем дә күрәм хәзер. Янак җөе буенча атаклы партизаннар командирын таныдым инде. — Кыз бераз гына тынып торды да сүзләренә басым ясый-ясый мәгънәле итеп тәгаллләде: — Михаил иптәштән сәлам сезгә.

Николаевск подпольесының пароле иде бу дүрт сүз. Носорогов бөтен йөзе белән елмаеп:

— Рәхмәт, күгәрченкәем, — диде. — Яңа элемтәче, алайса? Рәхим ит партизаннар чатырына. Ни атлы буласың?

— Мәдинә Урмангалиева.

— Япон постлары яныннан узып китү кыен булмадымы?

— Куркыныч, әмма түзәрлек. Мин күзгә ташлана торган кеше түгел үзе. Менә сезгә хат,— диде ул, кәрзинен җиргә куеп.— Кура җиләгеннән дә авыз итегез.

Носорогов үзенә сузылган, бөрешеп беткән кәгазь кисәген алды да тезенә куеп җәйде һәм укый башлады. Укыган саен йөзе кырыслана барды, яңак калкымнары ирексездән уйнарга тотынды.

— Политик тоткыннардан... Отрядны сафка тез, Мәхмүт. Барысы да тыңласын әле бу хатны. Бик күп рәхмәт сиңа, Мәдинә. Ничек соң анда шәһәрдә?

— Әле һаман җәзачыларны ничек тукмавыгыз хакында гөр киләләр. Телләрендә сез генә.

— Монысы әле баласы гына.

— Михаил иптәш үзегезгә генә телдән әйтергә кушты, — диде Мә-

динә, куыштан Мәхмүт чыгып киткәч, — подпольечылар тоткыннарны төрмәдән качыру планын әзерли, сезнең ярдәмгә өметләнәләр.

— Тагын?

— Шул гына әлегә.

— Кайтып әйт: эш безгә терәлеп калмас...

Отряд сафка тезелгәч, Носорогов һәр сүзен ачык ишетелерлек итеп кычкырып тоткыннарның хатын укый башлады.

— «Кызыл партизаннар, кадерле дусларыбыз һәм туганнарыбыз! Без, политик тоткыннар һәм партизан отрядларының элекке сугышчылары, сезнең кансыз интервентларны һәм акгвардияче хәшәрәтләрне ярсулы, рәхимсез рәвештә тукмавыгызга шатланабыз. Бу рухыбызны күтәрә, мыскыл итү, газаплауларга, ачлыкка чыдарга ярдәм итә. Сафларыбыз көн саен, сәгать саен сирәгәя бара. Күпләр ябыгу, ерткычларча кыйнаулар аркасында үлемгә дучар булды. Әмма җәлладлар күбрәк котырынган саен йөрәкләребездә аларга булган нәфрәтебез тагын да көчлерәк дөрли. Чөнки без сезнең янәшәдә икәнлекне тоябыз, тиздән җиңү киләсенә ышанабыз. Дошманнарны аяусыз дөмбәсләгез, Себер җирен дошманнардан чистартыйк!»

Тирән тынлык урнашты, бары тик тайга шаулавы гына ишетелә иде. Носорогов хат тоткан кулын күтәреп селти-селти, сугышчыларына мөрәҗәгать итте:

— Иптәшләребезнең үлеме һәм газаплары өчен үч алыйк, коралдашлар. Николаевск төрмәсе тоткыннары белеп торсын: аларны азат итәр өчен тормышыбызны да кызганмабыз! Кызыл партизаннар Себер җиреннән акгвардияче, самурай һәм башка кабәхәтләрне себереп түкмичә коралны ташламаячак!

Сафлар:

— Самурайларга үлем!

— Сыпыртыгыз Николаевскидан!

— Чыда гына, микадо! [1] — дип шаулашып җавап бирде.

Митингтан соң Носорогов Мәдинәгә подпольечылар белән партизаннар арасындагы элемтәчеләрнең чираттагы очрашуы хакында теләген әйтте һәм отрядның тоткыннарны азат итәргә бүген үк әзер икәнлеген белдерергә кушты.

*

* *

Мәдинә Урмангалиева үзе дә әле күптән түгел зинданнан азат ителгән иде. Кулга алынганчы ул Благовещенскида яшәде, сәүдәгәр Кириев тегермәнендә эшләде. Амур буендагы халыкның күпчелеге шикелле аларның зур гаиләсе дә бер сынык икмәккә тилмерә иде. Ужымнарны корылык көйдерде, ашлыкны бөртекләп диярлек тарталар иде, тегермән хуҗасы эшчеләренә онта себереп алуны да тыйды. Бервакыт тегермәнче, Мәдинәне кызганып, кулына калдык-постык салынган янчык тоттырган иде, тик кыз капкадан чыкканда гына Кириевкә тап булды...

Благовещенскидагы төрмә шыгрым тулы булганлыктан, Мәдинәне гаебе чамалы бүтәннәр белән бергә Николаевскига җибәрделәр. Портта йөк бушату кебек авыр хезмәт, төрмәдә җан сакларлык кына ашату, болай да ябык кызның сәламәтлеген бик тиз какшатты. Көннәрнең берендә ул тәмам хәлдән таеп, траптан бозлы суга егылып төште һәм төрмә шифаханәсендә генә һушына килде. Бәхет кошы үзен күтмәгән кешенең башына куна, диләр. Хаксыз җәберләргә дучар булган кыз тормышында да уйламаганда якты үзгәреш барлыкка килде. Аны по-

[1] Микадо — япон императорының дәрәҗәле исеме.

литик тоткыннар белән бер палатага салганнар иде. Монда ул революционер хатын-кызларның Ленин турындагы, Рәсәйдәге тиңдәшсез вакыйгалар, бөтендөнья хезмәт ияләренең киләчәктәге рәхәт тормышы турындагы сүзләрен йотылып тыңлады. Әз сүзле, йомыкый холыклы кыз яңа дусларына ачылып китеп, үзе күргән газапларны сөйләп күңелен бушатты.

Мондый эчкерсез әңгәмәләр Мәдинәдә ихтыярсыз курку уята торган, һәрбиләрчә төз буйлы, кырыс чырайлы төрмә докторы Сигизмунд Сигизмундович палатага кергәч кенә өзелә торган иде.

Чираттагы карау вакытында ул кыюсыз гына:

— Доктор, бүген мин төрмәдә соңгы көнемне уздырам, — диде.

— Бик әйбәт, кызым. Әмма сиңа иртәгә дә дәваланырга кирәк әле...

Мәдинә, ирекқә чыккач, күрше урамдагы ялгыз карчыкка фатирга урнашты. Яшерен комитет әгъзасы булган хуҗа хатын аңа эш эзләп табарга вәгъдә итте. Һәм тапты да: озакламый төрмә шифаханәсендә авырулар багучы урыны бушады.

— Анда кермим, куркам, докторлары әллә нинди, усал. Сигмунда генерал шикелле. Анда эшләгәнче, байларга кер юып йөрүең мең артык.

— Шундый генераллар күбрәк булсын иде әле, — дип көлде карчык. — Әллә син Николаевскида элекке тоткынга эшкә керү, бигрәк тә төрмә шифаханәсенә урнашу бик җиңел дип беләсеңме? Сер итеп кенә әйтәм: синең турыда Сигизмунд Сигизмундович үзе кайгыртты, вице-губернатордан үзе рөхсәт алды. Доктор әйбәт кеше, төрмәдә аннан башка берәүгә дә ышанма, сәяси тоткыннарга да бик ачылып китмә.

Берничә көн узгач, Сигизмунд Сигизмундовичтан куркып йөрүенә Мәдинә үзе дә гаҗәпләнеп бетә алмады.

— Сез большевикмы? — диде ул, кызыксынып.

Доктор кулларын чалыштырып күкрәгенә куйды да, кашларын җыерып, тәкәббер генә белдерде:

— Мин куркыныч япон генералы Сигмунда!

Икесе дә көлеп җибәрделәр. Аннары доктор җитди төскә кереп әйтте:

— Бүген мин сине бер кеше белән таныштырырмын. Исеңдә калдыр, Локман Исхаков булыр ул. Әгәр мине... Кыскасы, мин юкта ул кушканнарны үтәрсең. Багучы булып озак эшләмәссең, шәфкать туташы итеп әзерләрмен мин сине. Килештекме?

— Әйе.

— Бер юлга ярар инде. Югыйсә, калыбына кертеп: «Баш өсте, галиҗәнаб!» дияргә кирәк.

Бу көнне Николаевск төрмәсенә подпольечылар эшкә урнаштырган өлкән надзиратель Бугров ярдәме белән Локман докторга күренергә керде һәм шунда комитет тарафыннан үзенә тоткыннарның күпләп качуын оештыру йөкләнүен белде. Өч атна вакыт бирелгән иде аңа. Шул вакыт арасында партизаннарның бер өлеше шәһәргә үтеп керәчәк. Бугров һәм тагын бер күзәтче төн уртасында камераларны ачарга тиеш. Кайбер сәяси тоткыннарга пистолет, граната, хәнҗәрләр бирелер. Каравылда да үз кешеләр бар, алар капкада торачак. Шәһәр читендә качкыннарны иярле атлар, тачанкалар көтеп торачак. Авыруларны үз арбасында төрмә олаучысы алып чыгарга тиеш.

— Сатмасмы икән? — диде Локман Бугров турында. — Эчкече диләр аны.

— Ул гадәттә минем кабинетта баш төзәтә. Сатмас, сыналган адәм. Аны тентеп кертмиләр, инде кайчаннан бирле шул кеше ташый ич безгә хатларны.

Локман тиз генә берничә юл язу язды, доктор ул биргән кәгазь кисәген бөкләп кесәсенә салып куйды.

— Әйтегез әле, Сигизмунд Сигизмундович, Носорогов отрядына сәяси тоткыннарның кумәкләшеп язган хатын тапшыру мөмкинлеге бармы?

— Тапшырырбыз. Шимбәгә кадәр хат минем кулга керергә тиеш. Имзасыз, билгеле.

— Шулай да почтальоныгыз һаман икеләндерә әле мине, бик хәтәр эш ич бу.

— Хатны үзем алып чыгармын. Һәр шимбәдә вице-губернатор мине алмага фаэтонын җибәрә, без аның белән карта уены дигәндә үтә хирыс җан дуслар.

— Ышандырдыгыз. Кадерле доктор, бөтен сырхауларым бетте хәзер, бернинди дару да кирәкми.

— Бер кулыма эләккәч, болай гына котыла алмассыз шул. Хәзер процедура кабинетына керәбез, яңа багучыбыз белән таныштырыйм әле үзегезне. Аңа таянырга мөмкин, уңайсыз хәлдә калдырмас. Үзегез сак булыгыз, бигрәк тә яңалар янында...

Төнгә таба палатага кергәч, Мәдинә сискәнеп китте: караватларның берсендә ятучы авыру аның элекке хуҗасы Кириевкә бик тә охшаган иде. Авыру йоклый иде. Мәдинә якынрак килеп төбәлде дә җиңел сулап куйды: Кириев — карт иде, ә бу авыру сары сакалы аркасында олырак яшьтә күренсә дә, егерме бишләрдә генә булыр. Әмма Кириевкә охшаса да охшар икән. Тутык кунган төсле тупас чәчләр, сөзәк маңгай, төймә борын, хәтта кулындагы бармаклары да шундый ук шешенке, сирәк сары төкле. Кириев бармаклары гомергә исендә калды аның. Хуҗасының улы бар идеме икәнен Мәдинә белми иде.

Теркәү кенәгәсендә Кириев фамилиясе юк иде. Авыру бүген көндез кергән икән. Дрожжин Сергей Алексеевич, егерме дүрт яшьтә, Мәскәүдә туган. Сул иңбашы пуля тиеп яраланган.

Дрожжин иртә уянды, Мәдинәне күргәч, аңа ягымлы елмайды. Авыру Благовещенск төрмәсеннән килүен, юлда ярасы ачылуын, туптуры шифаханәгә эләгүен белдерде.

— Уңдым әле мин: шәпләп йоклап туйдырдым. Күземне ачсам, тынлык, тәрәзәдән таң атып килүе шәйләнә, янәшәмдә — фәрештәдәй чибәркәй. Кайда икәнлегемне дә белештермәдем башта... Син монда күптән эшлисеңме?

— Беренче атна.

— Спирт алып кил әле миңа!

Мәдинә тагын икеләнеп калды, авыру көлгәндә караңгы чырайлы Кириевкә бөтенләй охшамый иде. Мөгаен, очраклы охшашлыктыр, дөньяда сары чәчлеләр әзмени.

Шулай да үзенең шикләрен Сигизмунд Сигизмундовичка әйтми кала алмады. Доктор аны зур игътибар белән тыңлады һәм моннан соң Дрожжин белән нииндирәк мөнәсәбәттә булырга кирәклеген өйрәтте. Иртәгесен ачыклый алган мәгълүматларны да хәбәр итте. Дрожжин эшче гаиләсеннән, имеш. Гади кызылармеец, Байкал артында сугышкан, партизаннарга кушылган, яраланган, әсир төшкән — кыскасы, гадәти язмыш. Партизан отрядында чынлап та булган икән. Ә менә Кызыл Армиядә хезмәт итүен тикшерү читен иде хәзер. Кириевнең улы чыннан да бар икән, чама белән шул яшьләрдә, сигез еллар элек Мәскәүдәге туганнарына киткән булган. Хәзер аны танырлык кеше юк иде шәһәрдә.

Шат күңелле, тиз аралашучан Дрожжин тиз арада шифаханә хезмәткәрләре, палатадагы күршеләре белән танышып алды. Мәдинә белән сөйләшкәндә тәмле-татлы сүзләргә бер дә саранланмады.

— Син чынлап та төрмәдә утырдыңмы? — диде ул бервакыт.

— Әйе.

— Үзегезнекеләрне — Благовещенск кешеләрен очраткалыйсыңмы?

— Танышларым юк, бар да китеп бетте.
— Ә син нигә калдың?
— Бераз акча эшләгәч кайтырмын әле.
— Ә мин качачакмын, Мәдинә.— Дрожжин пышылдауга күчте.— Һичшиксез сыпыртачакмын моннан. Партизаннарга. Носорогов отрядына.
— Тотарлар да үтерерләр үзегезне.
— Мине тота алмаслар. Беренче көннәрне шәһәрдә посып, ыгы-зыгы басылганчы гына көтеп торырга кирәк. Кара әле, сиңа бик зур бер үтенечем бар минем. Тик безнең бу сөйләшү турында берәүгә дә ычкындырма!
— Юк, юк, серегезне тыңлыйсым килми, куркам.— Мәдинә китәргә кузгалган иде, ләкин Дрожжин аны җибәрмәде.
— Курыкма, өркерлек берние юк аның. Минем бер танышым әле дә шәһәрдә яши микән, шуны гына белешсәң икән, адресын бирим ме?
— Ярамый, доктор кушмый.
— Ул берни белмәс.
— Беләчәк.
— Тинтәк кыз син. Шул йортка язу гына илтә аласың ич инде. Ишек асларына кыстырасың да бетте-китте.
— Булдыра алмыйм. Сине үтерерләр, ә мине тагын төрмәгә утыртырлар.
— Бигрәк шүрлисең икән инде.
— Әйе шул. Куркам.
— Я, ярар. Батыррак бул, язу илтерлек кыюрак кем бар соң монда?
— Һичкемне белмим мин.
— Ә белсәң әйтерсеңме?
— Белешмим дә, әйтмим дә. Кычытмаганны кашып йөрсәм, эштән куарлар да чыгарырлар.
— Ярар, белешмә, алайса. Ярдәм итәргә теләмисең икән, кирәкми. Төрмәдә черермен. Мине инде синең кебек азат итмәячәкләр. Кулым төзәлгәч, бәхетне сынап карармын әле, барыбер баш бетәчәк бер... Шәһәрдә партизаннар хакында ни дә булса ишетеләме соң?
— Хуҗа хатыным, кышын катып бетәчәкләр, ди.
Мәдинә шушы сөйләшүне докторга сүзгә-сүз җиткергәч, Сигизмунд Сигизмундович көтелмәгән нәтиҗә чыгарды:
— Провокатор, күрәсең.
Дрожжинны өлкән надзиратель Бугров фаш итте. Яңа кошның качу турындагы сөйләнүләре үзенә килеп ишетелгәч, ул аңа «күңелле тормыш» вәгъдә итте һәм шуның бисмилласы итеп җилкәсенә авыр ачкычлар бәйләмен тондырды.

*
* *

1918 елның җәендә Себердә һәм Ерак Көнчыгышта акгвардиячe отрядлар, баш күтәргән чехословак корпусы, япон, инглиз, америка интервентлары Совет властена каршы берләшеп чыгыш ясагач, Кызыл Армия вакытлыча фронт сугышын туктатырга, партизаннарча көрәш алымына күчәргә мәҗбүр булды.
Николаевск төрмәсе сәяси тоткыннар, элекке партизаннар һәм әзгенә гаебе булса да, большевикларга теләктәшлек күрсәткән өчен дип кулга алынган кешеләр белән шыгрым тулы иде. Локман һәм аның иптәшләре подпольечылар, партизаннар, яңа кулга эләгүчеләр аркылы иректәге хәлләр, хәрби террор, җәзачыларның коточкыч шәфкатьсезлеге, халыкның нәфрәте арту турында белеп торалар, бу мәгълумат-

ларны өметсезлеккә төшкән кешеләрнең рухын күтәрү өчен көндәлек күрәштә файдаланалар иде.

Тыштан караганда һәрчак тыныч Локман тоткыннар белән бик тиз уртак тел таба иде. Тоткыннарның төп массасы асылда инде хәлиткеч хәрәкәтләргә әзер иде, әмма качуның конкрет планын әле бик азлар гына белә иде.

Төрмә башлыгы белән сөйләшкәннән соң Бугров Дрожжинга кычкыргаласа һәм кай арада йодрыгын татыткаласа да, ачкычлар бәйләмен бүтән болгамады. Локман исә провокатор белән катлаулырак уен алып бара иде.

Алар бер камерага эләктеләр. Дрожжин тоткыннар арасында Локманның абруе зур булуын күреп алгач ук, аңа якынаерга тырышты. Локман да егетне ошаткандай кыланды һәм алар тиздән янәшә сәндерәләргә урнашып, «чын күңелдән» серләшеп алдылар.

— Әллә үзеңнең генә иреккә чыгасың килә дип уйлыйсыңмы? — Локман авыр сулыш алып, дәшми торды.— Теләк кенә әз әле, туганкай. «Канкойгыч» надзирательләрнең дә нәкъ үзе кебекләрен җыйнаган. Каравыл турында инде әйтәсе дә юк — һәммәсе башкисәр. Доктор исә вице-губернатор әшнәсе, шифаханә аппаратын учында чәнечкеле биләй белән эләктергәндәй тота. Утка керергәме? Шуны гына көтәләр дә инде, хәзер туздырып ташларлар иде. Менә ни өчен тыштан юл ачуларын көтәбез без. Шәһәрдә подполье хәрәкәт итә икән дигән булалар да, шушы көнгә кадәр безнең белән элемтә урнаштыра алмаган, көчләре ташка үлчим генәдер инде аларның. Партизаннарга өметләнгән идек тә, бер отряд нишли алсын соң? Носорогов үзе дә яраланган диләр, иштекәнсеңдер.

— Әйе. Үлем чигендә, имеш.

— Бик мөмкин. Отрядын камап алганнар, күрәсең. Ярдәм көтәргә җир юк та юк. Партизаннарның азык-төлек ягы да такы-токы, патроннары да исәпле. Хакыйкатьнең күзенә карарга кирәк, кыш керүгә харап итәрләр, ахры, аларны.

— Димәк, бар өмет бөтендөнья революциясендә?

Дрожжин пышылдавында мыскыллау тоеп алгач, Локман үзе дә караңгыда көлемсерәде һәм тыныч кына дәвам итте:

— Һи-ии, бөтендөнья революциясе кайчан булыр әле ул, берәү дә белми. Ә менә бөтендөнья контрреволюциясе — рәхим ит, япон эсминецлары сары кырпулы фуражка кигән солдатлар рәвешендә янәшәбездә генә. Хәзер бар өметебез Совет Рәсәендә, Кызыл Армиядә инде.

— Әйе, тот капчыгың, кызыллар килер, камераларны ачар — чыгыгыз, кадерле иптәшләрме?.. Ә ул вакытта чыгарлык кем дә калмас, барыбыз да кырылып беткән булыр.

— Дистә еллар буе төрмәдә ятып та үлмәгән затлар бар. Ә синеңчә нишләргә соң?

— Җир астыннан тышка юл казырга иде һич югы. Тычкан кебек утырабыз... Беләсеңме, монда шәһәрдә бер туганым яши минем. Тол хатын, үз бала-чагасы булмагач, кайчандыр мине баккан. Ире үлгәч, шактый алтыны калды аның. Мин дигәндә җанын бирергә әзер ул. Элемтәгә керсәк, бөтен каравылны сатып алырлык алтынлы булабыз инде.

— Барысын да кирәкми. Ул синең монда икәнлегеңне беләме соң?

— Бөтен эш тә шунда шул, белми. Аңа кеше җибәрергә кирәк иде. Мин үзем кайберәүләрне капшап караган идем дә, барып чыкмады.

— Алтын турында әйттеңме соң?

— Юк, сиңа беренче чишүем серне. Сөйләшеп кара әле син. Шифаханәдәге яңа багучы кыз Мәдинәне беләсеңме? Аның белән син уртак тел таба алыр идең инде, татар ич ул.

— Бармый, үләр дәрәҗәдә коты алынган, кемне дә булса бүтән

бирәүне табарга кирәк. Эзләрбез. Ә син надзирательләрнең кылын тартып кара. Алтын кармакка чиртүләре ихтимал...

Носороговның каты яралануы турында имеш-мимешне шәһәрдә подпольечылар таратты — чынлыкта аның аягы гына җиңелчә зарарланган иде. Отрядның хәле исә чынлап та авыр иде. Көньяктан һәм көнбатыштан партизаннарны ак бандалар кысрыклап килә. Соңгы вакытта япон постларына һөҗүмнәр дә туктатылды. Яшерен комитет фикеренчә, бу тоткыннарны азат итү операциясенең уңышлы тәмамлануына ярдәм итәргә тиеш иде. Японнар теләсәләр шәһәрдән чыгу юлларын бөтенләй яба алалар, шуңа күрә аларның уяулыгын йомшартырга кирәк иде. Җәзачыларның яңа чыгышыннан исә партизаннар курыкмый иде.

Әлеге сөйләшүдән соң Локман Дрожжин миңа ышанды булса кирәк дип уйлады. «Аның төп максаты безнең аша подпольега юл сабу, — дип фикер йөртте. — Әгәр өркетмәсәк, бу бәндә әлегә качуның исе дә чыкмый дип хәбәр итәчәк. Безгә шул гына кирәк тә. Тагын унлап көн калды. Башын әйләндерим әле, бай апасына үзе сукмак сузсын».

Әмма вакыйгалар бөтенләй Локман һәм аның дуслары көтмәгәнчә ага башлады.

Иртә белән тоткыннарның бер өлешен төрле камераларга күчереп, яңача урнаштырдылар. Локман бер кешелек казаматка ябылды. Өлкән надзиратель аңа:

— Ниндидер яңа подпоручик килде. Барысына да боерык бирә, көр күңелле шайтан, — дип пышылдарга өлгерде.

Төштән соң тоткыннарны берәмләп төрмә башлыгы кабинетына сорау алырга алып китә башладылар. Чират Дрожжинга да җитте.

Яшь кенә көяз подпоручик бер өем папкалар яткан төрмә башлыгы өстәле артына утырган, «Канкойгыч», трубкасын төтәтеп, тәрәзә буенда басып тора иде.

— Сәлам, дускай, — дип елмаеп подпоручик бүлмәгә кергән Дрожжинның кулын кысты да урындыкка утырды. — Атагыз исән-сау, сәлам әйтте, кайбер нәрсәләр дә җибәрде, ләкин башта эшне хәл итеп бетерик әле. Барын да тәртибе белән һәм җентекләп сөйләгез...

Ул бик кызыксынып Дрожжинның хикәятен тыңлады, кайбер детальләрне ачыклады, аннары тагын аның матур, хәрәкәтчән йөзендә елмаю уйный башлады. Алтын портсигарын шартлатып ачты да:

— Рәхим ит, американнарныкы, — диде.

Үзе дә кабызып, төтен алкаларын түшәмгә өрә-өрә уйга калды. Аннары сигаретын таш көллек кырыена куйды, өстәл өстендәге папкаларны читкәрәк этте.

— Төрмә... Подполье... — дип, ул бер-бер артлы папкаларның икесенә дә йодрыгы белән суккалап куйды. Башын бормыйча гына бармагын төрмә башлыгына таба сузып: — Партизан отряды, — диде. Тегесе көлгән булып, трубкасы белән мәченекедәй сары мыекларын сыйпап куйды. — Сез инде аларның бернинди элемтәләре дә юклыкка ышандыгызмы? Әгәр Марста партизаннар булса, большевиклар инде күптән алар белән дә бәйләнешкә кергән булырлар иде. Ярый әле, бәхетегезгә каршы, мин вакытында килеп җиттем. Исхаков сезне бик рәхәтләнеп кәкре каенга тертәтеп калдырыр иде. Туганыгызның алтыны партизаннарга күчәр, үзе ул иптәшләре белән тайгага сызар, ә сез партизаннар суды карары белән атылыр идегез. Әгәр инде шуңа кадәр үк камерада буып ташламасалр.

— Мин үзем аларны атарга күнеккән! — дип кычкырды Дрожжин, башын күтәреп. — Судсыз-нисез. Аттым да, астым да.

— Шул күңелле эш белән тагын шөгыльләнәсегез килмиме? Мин менә нәкъ шундый мөмкинлекне бирергә телим сезгә. Уйлагыз әле.—

Подпоручик өстәл тартмасыннан кәгазьләр чыгарды.— Дөресен әйткәндә, тиз көндә генә нәрсәгә дә булса ирешерсез дип өметләнмәгән дә идем... Кыскасы, бүген кичен сезне качыру оештырылыр... Хәзер камерага кайтырсыз. Аннан тоткыннар төркеме белән эшкә... Мондарак килегез әле, сызымга күз салыгыз. Сезгә менә шушы юлдагы чокырларны күмәргә кушарлар. Конвоирларның берсе:«Син монда йокларга килдеңме, эшләргәме?» дип кычкырыр. Ярам ачылган, хәлем юк диярсез. Ул сезне кире төрмәгә алып китәр. Унлап адым атлауга, туп-туры японнар постына таба йөгерегез. Конвоир ата башлар, аңа игътибар итмәгез. Японнар сезне яшерер. Кичке уннарда шәһәргә китәрсез. Ерак барасы түгел, менә шушы урам, шушы йортка. Чаттан икенче. Анда әлеге багучы Урмангалиева туташ тора, тик ул бу вакытта эштә булыр. Хуҗа хатынга: «Лиза апа, сезгә иптәш Исхаковтан сәлам», диярсез. Ул үзен ничек кенә тотса да кием-салым, яшеренергә адрес сорагыз. Төрмәгә күптән түгел генә эләгүегезне, Исхаков белән качу турында сүз берләшүегезне әйтегез. Үзегезне ышанычлы тотыгыз. Бүген иртән таныш түгел офицер килде, сәяси тоткыннардан сорау ала, Исхаковны ялгызлар камерасына күчерделәр диярсез. Өйдән үзен генә чыгармагыз, янәсе, төрмә якын, патрульләр йөри. Өйдә калдырып китәргә теләсә, риза булмагыз. Исхаков адрес биргәндә сезне куркыныч астына куймаска кушты, фәлән дә төгән дип күңелен күрегез... Ашыктырыгыз, ушына килгәнче өлгерергә кирәк. Сезнең белән бармакчы булса, үгетләп маташмагыз. Әгәр икәү чыксагыз, зыян юк, артыгыздан күзәтеп барырлар. Сез, уңаен туры китереп, үзегез генә качыгыз. Адресны алгач...— Подпоручик көлеп торган күзләрен маңгай астыннан Дрожжинга төбәде.— Хәер, аның сезне очырып чыгаруы да ихтимал, әмма яхшыга өметләник әле. Нишләсә дә, соңгы чиктә урам аркылы чыгарсыз да, менә бу йорт артында сезне каршы алырлар. Шуның белән миссиягез дә тәгалләнер. Аллага тапшырдык...

Дрожжинны озаткач, подпоручик үзалдына елмаеп, кабинетта арлы-бирле йөрде, аннары яңадан урынына утырды.

— Өлкән надзиратель белән сөйләшәм дә Исхаковка тотынам. Без аның белән иске дуслар.

— Тәгаллагач миңа кагылырсыз,— төрмә башлыгы иснәде, кызарынган, тирләгән битен сөртте һәм кабинеттан чыгып китте.

Аның артыннан ишек ябылгач, подпоручик теш арасыннан:

— Бүкән... Миңгерәү...— дигән сүзләрне сытып чыгарды.

*

* *

— Кадер-хөрмәт күрсәтим әле, түргә узыгыз, Исхаков,— диде подпоручик,— сезне күрүемә шатмын. Әллә танымыйсызмы?

Ачык соры күзләрне, туры нәфис борынны, юка иреннәрне, бер генә сыр да салынмаган шома маңгайны Локман кайдадыр күргән төсле иде. Төштәгедәй әйле-шәйле охшаш сурәт хәтерендә җем-җем килсә дә, аны туктатып, чагыштырып карарлык дәрман юк иде.

— Бер котелоктан ботка ашадык дияргә мөмкин, Совет власте өчен бергә сугыштык,— подпоручик көлемсерәп бармаклары белән өстәлне шакылдатты.

Хәтерләде Локман. Әлбәттә, шул. Сакалын кырган, мыекларын китәргән, шуңа яшәреп киткән.

— Кыяфәтегез шәптән үк булмаса да, мин сезне бер карауда ук таныдым. Ябыккансыз, тире дә сөяккә генә калгансыз. Чигәләр дә агарган. Кабызып җибәрегез,— дип, ул Локманга ачык портсигарын сузды.— Американнарныкы.

Партизан дивизиясенең элекке сугышчысы Салтыков власть иясе булуына масаеп, аның алдында борын күтәреп маташа иде.

— Акгвардияче әләм-этрәк, — Локман портсигарны читкә кагып җибәрде. — Кызганыч, мин теге вакытта тидерә алмаганмын.

— Танылыгыз, ахры... Бөтенләй тимәде түгел, пулягыз ярты колагымны өзеп китте. — Салтыков башын борып, шыксызланган колагына бармагын орындырды да гәүдәсен урындык аркасына ташлады. — Шулай, шулай. Димәк, диңгез ярына утырып, Кызыл Армияне көтәсез. Килер бер тансык көн, ачылыр ишекләр — сез азат, кадерле иптәшләр! Әмма Дрожжин иреккә чыга алмас, сабыры җитмәде мескенен, бүген качарга маташканда үтерелде...

Локман бу хакта белә иде инде. Дрожжин, ихтимал, провокатор да булмагандыр әле дип баш ваткан иде. Менә хәзер бар да үз урынына утырды: төнге әңгәмәләре Салтыковка мәгълүм икән.

— Йөрәге сизгәнмени, алтынын камерадагы күршесе Дәүләтшин-Исхаковка васыять иткән...

Локман һәлакәт якынлашуына төшенде. Юкка чыккан өметләр бөтен җанын тетрәтте. Сау бул, тайга!

Газаплы, коточкыч уйлардан арынасы килеп, ул ихтыяр көчен җыйды һәм үзен подпоручик тавышына колак салырга мәҗбүр итте. Бу оятсыз, үз-үзенә ышанган бәндәнең сүзләрен аңга сеңдерергә, фикер йөртергә һәм җавап бирергә, бәхәсләшергә кирәк иде.

— Әмма Дәүләтшин-Исхаков та чыкмаячак, ул да азат итүне көтеп җиткерә алмады, хәрби кыр суды карары белән аны астылар...

— Васыятьтә кем имзасы иде соң? Дрожжин-Кириевнекеме?

Подпоручик йөзенә күләгә төшкәндәй булды. Ул бер мәлгә нидер уйлап тынып калды да яңадан елмайды, телгә килде, әмма тавышында элекке кинәнү, тантана юк иде инде.

— Юк белән вакыт уздырмыйк, Исхаков. Әйдә турысын гына чәпик әле. Тоткыннар исемлегендә фамилияңне күргәч үк, миңа синең монда кул кушырып ятмавың ачык иде инде. Куплэп качу, баш күтәрү яки шуныңише бүтән берәр нәрсә әзерлисеңдер әле. Син Лена фетнәсендә катнаштың, Якут җирендә сугыштың, Радзинский отрядында булдың. Бодайбода, аннары Өркет төрмәсендә утырдың. Анда сине Хәсән Дәүләтшин буларак беләләр иде. Байкал артындагы каһарманлыгыңа мин үзем шаһит булдым. Сине төрмәдә тоту акылсызлык дип саныйм. Асып куйгач, аякларың тиберченүен рәхәтләнеп бер карап торасым килә. Ә бусы өчен, — ул кулы белән шөкәтсез колагын капшады, — син шушы кабинетта бүген үк түләрсең, җәзаның бер өлешен ала торырсың. Синең аркада атаман Семенов боерыгын үти алмавым өчен үч булыр ул. Әлбәттә, син мондагы подполье белән бәйләнештәдер. Әгәр пароль, исемнәр, яшерен очрашу урынын әйтсәң, гөнаһларың кичерелер, тулысынча кичерелер. «Мирас»ны да хет бүген үк тәлинкәгә салып китерерләр. Шуны да искә ал, синең батырларча дәшми калуың гына аларны коткармаячак. Мин подпольены юк итәргә өстемә алдым һәм юк итәчәкмен дә. Бөтен шәһәрнең астын өскә китерәчәкмен. Уйларга биш минут бирәм, вакытым аз минем.

Хәтергә Байкал арты тайгасындагы бөркү төн килде. Командир чатырында Бурлов отряды алдында торган бурычларны Локманга аңлатып тора иде, кинәт ул ярты сүздә тукталып, колакларын торгызды, кисәк башын борып, чатыр почмагына күз ташлады. Үзләрен кемдер тыңлап торуын секунды белән төшенеп алган Локман кулына пистолетын тотып тышка ыргылды, куаклар арасына сикергән күләгәне күргә, бар пулясын шул якка сиптерде. Иртә белән рядовой Салтыковның юкка чыгуы беленде. Отрядларга аның качуын һәм шуның өчен үлем җәзасына хөкем ителүен игълан иттеләр.

«Көллекне тондырыргамы әллә? — дигән уй килде Локманга.— Кулын кесәсендә, коралда тота. Өлгерә алмам».

Аның уйларын чамалагандай, Салтыков фәрештә елмаюы белән кесәсеннән пистолетын чыгарды һәм өстәл кырыена түтәсен терәп, көпшәсен Локман башына төзәде.

Келт-келт, келт-келт...

— Әй, син, япон ялчысы, Семенов кабәхәте, ташла кыдрачлануыңны, туйдырды!

— Син үзеңә-үзең үлем хөкеме чыгарырсың, дип уйлаган идем аны. Болай ошыйсың үзе миңа, Исхаков, әмма Россия алдындагы изге бурычым...

— Бушбугаз! Кан коючылар, сатлыклар — сез ул, үзегезне үлемгә дучар иттегез. Ә большевиклар яшәячәк әле. Рәсәйне нинди коткаручы инде сез, хәсрәт капчыклары... Аның иң явыз дошманнарын үзегезгә ярдәмгә чакырдыгЫз. Теләсә кайсы япон солдаты яңагыгызга чабып җибәрә ала, сез шуңа «сөбханалла» дип кенә торасыз. Сезнең шикелле мөртәтләрдән чынлыкта японнар җирәнәләр, әгәр алар монда төпләнеп калсалар, синдәйләрне беренче чиратта таптап изәрләр, чөнки аларның үз офицерлары да буа буарлык. Озакламый алар алдында мүкәләп йөриячәксез әле, исән калганнарыгыз кояш чыгышы иленә үзләре белән алып китсен өчен, японнарның табаннарын үбәчәксез. Үңганракларыгыз аннары үлгәнче самурайлар артын ялаячак.

— Беттеме? — дип подпоручик пистолетын күтәрде һәм Локманга төзәде.

— Юк, бетмәде әле, — диде Локман, тавышын күтәреп. — Партизаннар суды сине атып үтерергә хөкем итте. Менә хәзер тәмам.

Исхаков үз сүзләре подпоручикка болай ук көчле тәэсир ясар дип уйламаган иде: агарынды теге, акай күзләрендә нидер калтыранды, пистолет тоткан кулы салынып төште. Бераз вакыт алар бер-берсенә дәшми-тынмый карап тордылар. Локман җаны-тәне белән куралмаган йөздә шат елмаюның сүнүенә кәефе килеп, балкып китте.

— Авыз ерасыңмы, хәшәрәт? — дип ысылдады подпоручик.—Ярар, әйдә, елмай, елмай...

Ул тагын пистолетын күтәрде. Локман, көпшәнең үз колагына төзәлгәнен күреп, елмайган көе демонстратив төстә подпоручикка яны белән борылды. Кораблев ике мәртәбә түшәмгә аткач, ишекләр ачылып китте һәм шул минутта кабинетка атылып кергән ике сакчы Локманга ташланды.

*
* *

Икенче көнне подпоручик Кораблев Сигизмунд Сигизмундович белән бергә төрмә шифаханәсен карап йөрде.

— Бу нинди мумия тагын? — диде ул, башы, куллары, күкрәге саргайган бинтлар белән уралган кешегә ишарәләп.

— Локман Исхаков.

— Аны адәм рәтле хәлгә китерү өчен күпме вакыт кирәк дип уйлыйсыз?

— Савыгуына бик үк ышанып бетмим әле мин аның.

Кораблев гаҗәпләнеп докторга карап көлемсерәде.

— Шикләнмәгез, савыгачак. Чыдам халык ул. Бәхәсләшәбезме? Сез аны тайгада күрсәгез икән әле!

— Сез хәзергесен искә алып бетермисез...

— Мин барын да исәпкә алам. Берсекөнгә кичен ул бер кешелек камерага күчереләчәк. Аягында басып торуы хәерлерәк.
— Кызганычка каршы, медицинаның кодрәте чиксез түгел.
— Тора алмаса, Исхаковның үз башына инде.
— Аның мие тетрәгән, яңак сөяге чатнаган. Сорау аласыгыз киләме? Сабыр итү үз файдагызга ич. Ул телгә килсә дә...
— Әһәмияте юк.
— Бары ун көннән соң гына.
— Ә ул миңа берсекөнгә кирәк.
— Врач буларак, мин протест белдерәм.
— Авыруны кайгырту сезнең эш, ә мин Россияне кайгыртырга тиешмен...
Бу көнне тагын дүрт сәяси тоткынны шифаханәгә күтәреп китерделәр.
Мәдинә фатир хуҗасына Локманны юк итәргә әзерләнүләрен әйтте. Тоткыннарның баш күтәрүеннән, халык нәфрәтеннән куркып булса кирәк, аклар суд бинасында ике көннән соң спектакль куярга җыеналар иде. Сигизмунд Сигизмундович тоткыннар качуын берсекөнгә төнлә оештырырга тәкъдим итте. Локманның хәле хәзергә әле бик үк начар түгел иде.
Подполье комитеты тоткыннарны качыруны алдан билгеләнгән вакытта хәл итәргә карар бирде. Исхаковны исә суд бинасына алып барганда азат итәргә җыендылар.
Өсте ябулы арба төрмә капкасыннан иртәнге биштә, урамда бер җан иясе дә күренмәгән вакытта чыкты. Аны япон карабиннары белән коралланган дүрт атлы сакчы озата бара иде. Бишенчесе Локман белән янәшә утырды.
Суд бинасына таба ярты юлны узгач, җайдакларның берсе атын тыеп туктатты да үкчәсенә басып килүче юлдашын мылтык түтәсе белән сугып, атыннан егып төшерде. Арбадан берьюлы диярлек ике ату тавышы яңгырады — икенче яктан килүче сакчылар да иярдән егылды. Арба тыкрыкка борылды, олаучы кырыйга алып ташланды.
Өч җайдак буш урамнар буйлап урманга таба чабып уздылар.
Вице-губернатор фон Бунге сәяси тоткын Исхаковның качуы һәм япон постларына партизаннар һөҗүм итүе турындагы хәбәрне телефоннан ишеткәч, яңалыкны үзендә куна калган, әле йокысы да ачылып җитмәгән подпоручикка белдерде.
— Партизаннар шәһәр капкасы төбендә, тик, улым, алар белән турылыклы союздашларыбыз шөгыльләнсен, ә безгә тамак ялгарга вакыт.
Подпоручик хәбәрдән исәнгерәп калды, шунда ук аштан баш тартып, кайнар эзләр буенча фетнәчеләрне барларга һәм арт сабакларын укытырга төрмәгә ашыгуын әйтте.
— Бер чәркә аракы да, мин йөгерәм.— Подпоручикның куллары калтырый иде.
— Төсегез-битегез киткән. Иртәнгене ашатмый җибәрмим. Йөрәккә бик үк якын алмагыз моны. Бер тоткын артык ни, ким ни... Ашханәдә көтәм үзегезне...
Өстәл янында сүз төрмә докторына кагылды.
— Шикле шәхес, — диде Кораблев. — Мин аны...
— Сигизмунд Сигизмундовичмы? Һа! Преферанс патшасы. Ул сәясәттән өстен, аның идеалы — сәламәт кешелек дөньясы. Борчымагыз аны.
— Ләкин...
— Һичбер «ләкин»не ишетәсем килми. — Фон Бунге ачулана башлады. — Нинди дә булса дәлилләрегез бармы?

— Юк, әмма булыр. Исхаковның качуында шул преферанс патшасының катнашы барлыгына иманым камил.
— Сафсата, сафсата. Сез ялгыш юлда, подпоручик. Эшегезгә тыкшынырга теләмим, әмма Сигизмунд Сигизмундовичка килгәндә... Әдәпле генә сорау алырга мөмкин, әгәр аңа чәнчә бармагыгыз гына кагылса да, үзегезгә йодрык белән китереп сугачакмын, — вице-губернаторның симез йодрыгы күтәрелде дә өстәлгә чүкеч кебек саллы килеп төште. — Сүз уңаенда әйтүем, ул сезне авыру дип саный. Диагнозын беләсегез киләме?
— Кызык.
— Хроник садизм. Ха-ха-ха!! Тагын бер чәркәнеме?
Җене чыккан подпоручик сикереп өстәл артыннан кузгалды.
Бу иртәнге сәгатьтә дә, көндәгечә, вице-губернатор өе янәшәсендәге японнар казармасына яңа тотылган балык салынган кәрзиннәрен төяп бер атлы якынлашты. Килбәтсез аты белән янәшә, трубкасын теш арасына кыстырып, бөтен шәһәргә билгеле карт якут Байбал Мыкчыканов атлый, ә аның хатыны Дарья кулы белән кәрзиннәрен тотып, арбада утырып килә иде.
Карт нарат кәүсәсенә арба күчәрен ордырып ат туктады. Байбал дилбегәне хатынына ыргытты һәм арбаны әйләнеп узганда сөртенеп егылды. Дарья борылып тормыйча гына аягы белән арбадагы мылтыкны агач төбенә этеп төшерде.
Бу вакытта болдырга чыккан подпоручик кулы белән кояшны каплап, ашыгып баскычтан төшеп килә иде. Байбал тәтегә басуга, ату тавышы яңгырады. Дарья иелеп мылтыкны эләктереп алды да әлеге агач куышына ташлады.
Мылтык гөрселдәве һәм подпоручикның әче авазы бөтен казарманы аякка бастырды. Чаттан йөгереп килгән часовойлар атын йөгәненнән сөйрәгән Байбалны һәм арбада бөкшәеп утырган хатынны гына күрделәр.
— Тегеннән аттылар! — диде хатын, куаклыкка күрсәтеп.
Куаклыкны минуты белән ут яңгырына коендырдылар. Байбал белән Дарья ашыкмыйча гына балык бушатуда булдылар. Әкренләп атыш тынды. Корсагына пуля тигән подпоручик госпитальгә җибәрелде һәм ул анда операция вакытында теге дөньяга китте. Вице-губернаторга, партизаннар казармага һөҗүм итеп маташты, әмма һөҗүмнәре кире кагылды, подпоручикка очраклы пуля тигән булса кирәк, дип доклад бирделәр.
Фон Бунге гореф-гадәт буенча мәрхүмне искә алу мәҗлесенә рус һәм япон офицерларын, төрмә башлыгы белән Сигизмунд Сигизмундовичны һәм башка дусларын чакырды.
Хәсрәтле тынлыкта эчтеләр. Кунаклар китәргә җыенгач, хуҗа кулын күтәрде. Утырдылар.
— Бәхетсез дускайны искә алдык менә. Себернең чәчкәсе иде ул.— Фон Бунге итләч бармаклары белән нечкә билле бәллүр рюмканы әйләндергәләп, Сигизмунд Сигизмундовичка күз салды. — Бер кадәр сәеррәк сыйфатлы чәчкә. Күңеле сизә иде үзенең. Әйе. Алтын портсигарын миңа бүләк итте. Ашыкты, үлеме ашкындырган икән. Аны өйалдына алып кергәч, янына килдем. Ыңгырашып кулымны эләктерде дә аңын югалтты. Шул мизгелдә солдатлар безгә сәнәк белән кадап тотылган җәен алып керделәр, аның саңаклары көчкә-көчкә генә кыймылдый иде... Символик язмыш!
Кунаклар рюмкаларын күтәрделәр дә саубуллаша башладылар.
— Шул җәен идемени бу? — диде Сигизмунд Сигизмундович, тәлинкәләргә ишарәләп.
— Әйе, әйе. Аш пешерүче үлчәгән иде — ярты пот! — фон Бунге ботларына шапылдатып сукты. — Амур!

* * *

Локманның партизаннар белән очрашуы шатлыклы, шау-шулы булды. Монда аның иске танышлары да әз түгел иде, әмма ул барыннан да бигрәк Бодайбо төрмәсендә бергә утырган, 1912 елдан бирле көрешмәгән якташы — отряд командирының урынбасары Мәхмүт Зөбәйдуллин белән көтелмәгән очрашуга сөенде.

— Мин бит сине Хәсән Дәүләтшин буларак кына белә идем, — диде Мәхмүт, дустыннан күзен алмыйча. — Мәдинәдән «Исхаков, Исхаков» дигәнне күп ишетсәм дә, аның син булу ихтималы бөтенләй башыма килмәде. Каты бизәгәннәр сине, кабәхәтләр... Менә Максим Михайлович та килә.

Култык таягына таянып, йөзе балкыган Носорогов аксый-аксый килде дә Локманны кысып кочаклап алды, аннары бер адым кире чигенеп, башын селкеде:

— Балданмы әллә син? Котлыйм!

— Рәхмәт!

— Сугышабызмы?

— Сугышабыз.

— Берәр чәркәне төшерәбезме?

— Була ул.

— Яле, башта җылын, — Носорогов бер партизан кулындагы кружканы алып, Локманга сузды. — Спирт, доктор бүләге. Менә шушы очрак өчен сакладым. Шулай, тәртип, димәк. Балык кап та мунчага йөгер, әнә теге чатырга. Санитарыбыз да шунда. Киемеңне алмаштыр, ул арада ашарга да өлгерер.

— Борыным сизә, балык шулпасы.

— Монда безгә бер якут пот ярымлы сазан китергән иде. Мәхмүт ага, аш алдыннан халыкны сафка тез.

Носорогов белән янәшә атлаганда Локман хәсрәтле тавыш белән:

— Без сугышырбыз ул, ә менә сез, Максим Михалыч... — диде.

— Син нәрсә? — Носорогов туктап калды. — Миннән башка сугышмакчы мәллә сез?

— Ярагыз...

Икесе дә шаркылдап көлеп җибәрде.

Локман «мунча»дан чыкканда партизаннар сафка тезелгән иде инде.

— Сугышчы һәм командир иптәшләр! — Носороговның көчле тавышы яңгырагач, тайга да тынып калгандай тоелды. — Дошманнар безне боҗрага кысып алып юк итмәкче була. Япон гарнизоны көчәйде, хәзер анда генерал Ямада командалык итә. Көньяктан һәм көнбатыштан безне баштанаяк коралланган акгвардияче отрядлары һәм атаман Семенов бандасы чолгап алды. Бу тирәләрдә кышлый алмаячакбыз, юкса безне сытып ташлаячаклар. Тайга ревкомы боерыгы белән безнең отряд төньякка күчеп урнашачак. Иртәгә юлга чыгабыз. Максатыбыз — көчләрне саклау һәм хәлиткеч сугышларга әзерләнү.

Үзегез белгәнчә, Николаевск төрмәсендә ике йөз большевик һәм аларга теләктәш тоткыннар газап чигә. Бүген безгә шул караңгы зинданнан беренче карлыгач очып килде. Дөресен әйткәндә, бөркет, баш имәс революционер — партизаннар берләшмәсенең элекке комиссары Локман Габдуллович Исхаков. Без аны үзебез белән алып китмибез, хәер, ул үзе дә моннан китәргә теләмәс. Махсус бурычны үтәр өчен аның янында үз иреге белән кырык кеше калачак. Нинди бурыч икәне хәрби сер...

Сафлар буйлап гөрләшеп алдылар.

— Чамаладылар, шайтаннар! — Носорогов гаҗәпләнгәндәй итте, —

Исхаков отряды яңа базага соңрак киләчәк. Иптәшебезнең төрмә газапларыннан котылуын исә мин, — оратор мыекларын сыпырып куйды, — безнең атаклы Амур балыгын, партизан шулпасын авыз итәр өчен сылтау итеп файдаланырга тәкъдим итәм. Мондый шулпадан соң, үзегез дә беләсез, үткерләнгән күз, ныгыган куллар микадоны шәбрәк тукмар!

Носороговның соңгы сүзләре партизаннарның хуплау авазларына күмелде.

Командирлар симез балык шулпасы пешкән казан тирәсенә утырдылар. Аннан авырлык белән олы сазан башын алдылар.

— Шуны ботарла әле, Локман,— дип кыстады Носорогов.— Син төрмәдә иртәнгене дә ашый алмадың ич. Соңгы вакытта безнең тамак яклары ярыйсы. Нигездә олаулар һәм келәтләргә һөҗүм иттек, безгә дә, синең булачак партизаннарыңа да кышкы киемнәр бик кирәк иде. Хәзер запасландык инде. Хуҗалык зур. Атлар биш йөз баш чамасы, боланнар йөзләп. Патроннар гына чамалы, әмма ун меңләп атылган гильзабыз бар, яңа базада шөгыльләнербез...

Ашаганнан соң Локманга отряд хуҗалыгын күрсәтте Мәхмүт, бөтен лагерьны бергәләп йөреп чыктылар. Бар җирдә кызу эш кайный, һәр яктан балталар тукылдавы, пычкы чыжылдавы ишетелә иде. Тимерчелектә кызарганчы утта тотылган дагалардан зәңгәр төтен күтәрелә.

Итәген Амурның саргылт бер тармагы урап алган сөзәк калкулыкка менделәр дә, карт имән төбенә утырдылар.

— Мин бүген яңадан туган кебек, — диде Локман шыпырт кына. «Без — өстебезгә аерым бурыч йөкләнгән кешеләр,—дип уйлады Локман. — Тарихны борабыз. Монда күпме гүзәл һәм фаҗигале язмышлар, омтылыш һәм өметләр. Боларның берсе дә кабатланмаячак. Бәлки әле шушы кешеләр арасында киләчәкнең елъязмачылары да бардыр...»

— Безне чакыралар, — дип, Зөбәйдуллин аның уйларын бүлде.

Лагерьга подпольечылардан элемтәче — Байбал Мыкчыканов килгән иде. Носорогов аны Локман белән таныштырды һәм канәгать елмаеп:

— Менә ул подпоручик кәмәшен бүген дөмектергән кеше, — диде. — Карт таза әле, егетләр кебек.

Байбал тагын бер яңалык хәбәр итте: яшерен комитет Сигизмунд Сигизмундович белән Мәдинәгә дә партизан отрядына китәргә рөхсәт биргән икән.

*

* *

...Учак янына җеп бөртеге калмый юешләнгән бер яшь партизан йөгереп килде дә, кулын чигәсенә куеп, Локманга рапорт бирде:

— Доктор сөйләшкән җиргә килде, шәфкать туташы Мәдинә Урмангалиева исә авыру тоткынга кайнар мәхәббәте аркасында үз ирке белән төрмәдә калган. Икесен бергә арбада алып чыгачаклар.

Локман кашларын җыерып:

— Учакны сүндерегез,— диде.— Киттек. Кайнар мәхәббәтне күрсәтермен мин аңа...

Төн уртасына кадәр шәһәрдә бер генә дә ату тавышы яңгырамады. «Бәлки бар да шулай тавыш-тынсыз, хәвеф-хәтерсез генә узар әле», дип уйлады Локман. Ул тачанкадагы пулемет артына ышыкланып, төн карасына күзен текәгән иде.

Ләкин шау-шусыз гына барып чыкмады. Менә куе караңгылыкта

винтовка тавышы яңгырады, аннан икенчесе, өченчесе. Берьюлы пулемет тырылдады, гранаталар шартлавы ишетелде — партизаннар шәһәр читендәге япон постларын чүплиләр иде.

Локман бер кырыйда хәрәкәтләнгән карамчыкларны шәйләп алды. Тачанка янына килгән партизаннарның берсе:

— Эш пеште, иптәш командир! — диде.

— Арба кайда?

— Артта сөйрәлә. Ыгы-зыгы да шуның аркасында чыкты. Патруль өстенә килеп чыктык...

Тоткыннар урманга агылалар иде, хәрәкәтләре бик үк елдам булмаса да, Локман аларны күздән кичергәч, бу колоннаны бернинди көч тә туктата алмасына ышанды.

Ниһаять, җайдаклар уртасында килгән арба да күренде. Атышлар тынды. Ун минуттан Локман янына дүрт партизан килеп житте, алар шинельгә салып каты ыңгырашкан яралыны күтәргәннәр иде.

— Бүтәннәр кайда? — диде Локман.

— Безне каплап чигенәләр... Петров яраланды, күкрәгенә дә, аягына да тигән.

Куа килүчеләр юк иде. Локманның яңаклары буйлап яңгыр тамчылары белән кушылган күз яшьләре тәгәрәде. Ниһаять, иптәшләре иректә!..

Бер атна узды. Локман отряды чытырманлы урман ешлыгында урын сайлады. Элекке тоткыннар хәл җыя, ерак походка әзерләнә иде. Хәзер отрядта ике йөзләп кеше санала иде. Тоткыннарның бер өлеше, партизаннарга кушылырга теләмәгәнлектән, тайгага кергәнче үк таралды. Докторның тырышлыкларына карамастан, дүртесе үлде. Отрядның сөеклесе, күңел юатучысы булган Петров та һәлак булды.

Кучер да партизаннарда бер генә тәүлек уздырды. Сигизмунд Сигизмундович спирт бик аз, дәвалау өчен генә тотарлык дигәч, картның чырае караңгыланды.

— Кире кайтам мин,— диде ул Локманга.— Күңелсез сездә.

— Атулары мөмкин, уйла әле, — дип үгетләп маташты командир.

— Минеме? Ә нәрсә өчен? Күбрәк салынган булган да, тайгада айныдым менә. Партизаннарны күрмәдем дә. Тарантас белән атны бирерсез ич?

— Ал.

— Димәк, казна малын коткаруым өчен «канкойгыч» бурычлы да булачак әле.— Кучер җанланып китте.— Бер чирек аракысын да даулаячакмын, бирми хәле юк. Үз өлешемне алмый калмыйм.

— Солдатлар сатмасмы соң?

— Гомердә дә! Ахирәтләр. Каравыл башлыгы минем туган да бит әле. Кайтуның тагын бер сәбәбе бар: төрмә ишегалдына хәзинә күмгән идем мин.

— Нинди хәзинә?

— Фляга. Теге канистрдан бераз чәлгән идем.

— Кара инде, алайса, — дип көлеп җибәрде Локман. — Рәхмәт сиңа.

Элекке тоткыннар кулларына корал эләккәч дәртләнеп киттеләр. Кайнарлак башлар, Носороговка буш кул белән күренмәс өчен, вице-губернатор яки генерал Ямаданы әсир төшерергә тәкъдим кертте.

— Утка керергә өлгерерсез әле,— диде Локман.— Аклар да, японнар да уяу хәзер. Вакыт кадерле, капчык авызын бәйләп куймагайлары.

* * *

1919 елның декабрь башында Носорогов отряды Җугҗур сырты буендагы базаларның берсенә килеп урнашты.

Киң иңкүлектә дистәләгән чум, чатыр, юнылмаган бүрәнәләрдән салынган ике зур барак, каралтылар тезелеп киткән иде. Кичен шактый соңга калып чираттагы разведкадан Байбал кайтты, гадәттәгечә, бу юлы да буш кул белән түгел, арыган болан тартып кайткан нартада тау сарыгының түшкәсе ята иде.

— Булдыргансың, — дип мактады Локман аучыны, иңеннән кочып. — Әйдә, командир янына чәйгә керик әле.

Байбал ике мөһим хәбәр алып кайтты. Беренчедән, күчмә тунгус аучыларыннан ул Зверев партизан отрядының Усть-Кут төбәген акгвардиячеләрдән арындыруын ишетте, икенчедән, Якутск ягыннан Аянга таба утызлап кеше, шул исәптән, япон солдатлары сагы астында зур гына олаулар төркеме хәрәкәт итүен белде. Алгы һәм арткы чаналарда пулеметлары да бар икән.

Носорогов картаны җәеп салды:

— Синеңчә, хәзер кай тирәдә ул олаулар? — диде.

— Нелканга җиткәндер.

— Кунарга туктасалар, эләктерәбез. Локман, Бугров отрядын чаңгыга бастыр, менә шушы урынга барып посып торсыннар.

— Үзем дә алар белән...

Нелкан поселогы инде күптәннән бирле Охот диңгезе ягыннан Якут өлкәсенә килүче йөкләрне күчереп төяү урыны булып хезмәт итә иде. Японнар Аян портын кулга төшергәч үк бу юлны төрле товарлар, сугыш кирәк-яраклары илтү, җирле халыктан акгвардиячеләр талап яки бай якут сәүдәгәрләре һәм кулаклары арзан бәядән сатып алган җәнлек тиреләрен, мамонт сөякләрен һәм башка кыйммәтле әйберләрне — кыскасы, төрле чималны алып китү өчен файдаланалар иде.

Тозакка килеп эләккән унбишләп атлы да Нелкандагы ак олаучыларга кушылды. Партизаннар ике яктан атакалады, сугыш рәхимсез булды. Отрядның биш кешесе үтерелде, уникесе, шул исәптән командир да, яраланды.

Трофейларны базага алып кайттылар. Партизаннарның әле беркайчан да мондый табышка юлыкканнары юк иде. Гомуми авырлыгы утыз поттан да ким булмаган унбиш әрҗә: кисәкле һәм бөртекле алтын, меңләгән тиен тиресе (аларны санап тормадылар, чама белән генә билгеләделәр), ике мең төлке, бер мең ас мехы!

Партизаннар бүрекләрен салып һәлак булган иптәшләренең каберләре янына бастылар. Баһадир наратлар ышыгындагы кайгылы тынлыкта Носорогов тавышы яңгырады:

— Бу сугышта биш кешебезне югалттык. Чын каһарманнар иде алар, кадерле иптәшләребез турындагы якты хатирәләрне партизан йөрәкләре мәңге саклар. Җиңүгә инде ерак түгел, аны батырлыклары белән менә шушы фидакарь сугышчылар якынайтты. Интервентлар Уралга барып җитәргә хыялланган иде, әмма аларның юлын халык нәфрәте бикләде. Тиздән ул нәфрәт барлык килмешәкләрне Себер җирләреннән җәһәннәм астына себереп түгәр. Һәлак булган иптәшләребез өчен без әле киләчәктә икеләтә үч алырбыз. Туган җиребездә аларның мәңгелек йокысы тыныч булсын.

Носорогов, Зөбәйдуллин һәм Исхаков кич белән учак янында, партизаннар кулына төшкән байлыкны нишләтергә дип киңәш корды. Отрядтагы кешеләрнең барысына да ышанып булмый иде, бу исә эшне тагын да катлауландырды.

Соңгы айларда шактый сирәкләнгән партизаннар сафы заманында көчләп мобилизацияләнгән Колчак армиясеннән качучылар һәм әсирләр белән тулыландырылган иде. Ул кешеләр башта сугышларда сынала һәм аннары гына партизаннар гаиләсенең тулы хокуклы әгъза-

сына әйләнә, тик алар арасында дошман шымчылары да булуы ихтимал иде.

— Әлегә кадәр җан тыныч иде... — диде Носорогов, трофейларга баш изәп.— Әллә яшереп куяргамы боларны? Нинди дә булса берәр мәгарәгә? Иртәгә шуны кайгырт әле, Мәхмүт ага.

— Бөтен кеше күз алдындамы? Ярамый, мин менә нәрсә уйлыйм. Японнар, мөгаен, алтыннан колак кагуларына риза булмаслар, кире кайтарырга омтылырлар. Ә без аларга әйбәт тозак кора алабыз.

— Шәп килеп чыгачак лабаса бу, — диде Носорогов җанланып.— Малны беренче базага алып китәрбез, анда борын тыгып маташсалар, «бәйрәм» ясарбыз үзләренә. Килү юлларында ук тарый башларбыз, чигенү юлын өзәрбез дә иңкүлектән чыгармабыз. Шулаймы, Локман?

— Ә нигә бөтен йөкне анда ташырга? Иртәгә беренче базага мехларны гына төяп җибәрергә кирәк. Кешеләрнең ышанычлыларын калдырырбыз да алтынны капчыкларга бушатып, боланнарга төяп, таулар арасына илтеп яшерербез, әрҗәләргә исә таш тутырырбыз. Хәвефхәтәр кимер.

— Дөрес, — дип килеште Носорогов. — Чигенә калсак, йөк белән азапланасы да булмас. Иске-москыны ташлап китсәң дә җәл түгел. Тиен тиреләренең бер өлешен менә отряд хаҗәтенә тотарга кирәк, хатын-кызлар мех оекбашлар тексен. Алтынның исә монда чакта поты бер тиен. Якутскига элемтәчеләр җибәрергә кирәк, нишләтергә икәнлеген сорарга...

Иртә белән алты юлчы үзләре теләп тайга аша ерак сәфәргә чыгып китте.

Алтынны якындагы кечерәк кенә бер мәгарәгә яшерделәр, куаклар һәм мүк үскән тар авызын ташлар белән каплап куйдылар. Ул урынны мондагы һәр таш, һәр агач, һәр чокырны яхшы белгән Байбал табып бирде.

*
* *

Шул ук иртәдә разведчиклар японнарның кечерәк төркемнәре яр буенда тыз-быз иснәнеп йөрүен, тайгага аяк басуларын хәбәр итте.

— Кыймылдый башлады хәшәрәтләр, — диде Носорогов канәгать төстә һәм, беренче базага кайчан әйләнеп кайтырга тиешлекләрен билгеләп, иң чос егерме мәргәнне «сунарга» җибәрде.

Беренче база Мая елгасының югарыгы агымында, ике ягыннан дага сыман Җугҗур тармаклары белән чорнап алынган тар иңкүлеккә урнашкан иде. Иңкүлекне урап алган тау тезмәләренең эчке һәм тышкы битләренә һичкем аяк баса алырлык түгел, бары аның куаклар һәм сирәк наратлык каплаган түбәсенә Җугҗурның көнбатыштагы сөзәк ягыннан гына үрмәләп менәргә мөмкин иде. Шуңа күрә Носорогов биш пулемет, мул гына гранаталар запасы белән коралланган партизаннар төркемен тарлавыкка, японнар капкынга кереп беткәнче яшеренеп торырга җибәрде. Аларның көнбатыштан басып керү ихтималы да искә алынды.

Ерак постлардагы күзәтче һәм разведчиклар базага алты качакны ияртеп алып кайттылар. Носорогов аларның һәркайсы белән аерымаерым әңгәмә ясагач, барысына да тиен тиреләреннән аяк һәм өс киемнәре тегәргә тәкъдим итте. Качакларның берсе ефәк төсле йомшак аксыл зәңгәр мехны учы белән сыйпады да:

— Берсеннән берсе шәбрәк, — дип сокланды. — Сәүдәгәр олауларын туңагансыз, ахры?

— Булды инде! — диде үткен генә бер партизан һәм көйләп җибәрде:

Японга мал илтә иде
Сәүдәгәр атлы дәҗҗал.
Партизан угы тиде дә
Тапты үзенә әҗәл!

Партизаннар яңа килүчеләр белән гәпләшергә иренмиләр, аларны кедр чикләвеге, тәмәке белән сыйлыйлар иде. Винтовка урынына аларга чакмалы мылтыклар тоттырдылар һәм яхшы коралны сугышта егетлек күрсәтеп кулга төшерергә кирәк булыр, бездә тәртип шундый дип аңлаттылар. Алтынны һичкем телгә алмады, әмма брезент белән аннан-моннан капланган әрҗәләр өеме күз алдында тора иде.

— Анда сезнең нәрсә ул? — дип сорады яңа килүчеләрнең берсе. Бу сорау көтелә иде.

— Хәзинә! — диде ветераннарның берсе, көлемсерәп. — Атылган гильзалар, җәйге чумнар һәм башка иске-москы.

— Аны нәүбәтче ни дип саклый инде?

— Носорог хикмәте, күзне дә йоммаска куша.

— Сунар яклары ничек соң? Чыгып йөрергә мөмкинме?

— Командир рөхсәте белән генә. Носорог яңашәсендәге адәмне күрәсеңме? Урынбасары Мәхмүт ага, шуңа мөрәҗәгать итегез.

Иртәгесен яңаларның дүртесе ауга чыгарга рөхсәт алды. Носорогов, аларның һич югы берсе базага әйләнеп кайтмас, дип көтә иде. Араларындагы шымчының — аның алты кеше арасында булуына командир шикләнми иде — кайтып сөйләве японнарны дәртләндерергә һәм ашыгырга мәҗбүр итәргә тиеш иде. Алтын һәм кыйммәтле мехлар базада. Отрядта ике йөздән кимрәк сугышчы, аларның да яртысы элеккеге аквардиячеләр һәм бандитлар, шуның өстенә яралылар күп. Килде-китте белән генә коралланганнар. Бары-югы алты пулемет, тик алар да ач паекта, һәр патроны исәпле. Партизаннар, күрәсең, базага һөҗүм итүне көтмиләр, ниндидер ерак сәфәргә җыеналар. Иңкүлеккә алып керә торган тарлавык шактый киң, анда бернинди ныгытма юк...

Әмма төшкә барлык аучылар да әйләнеп кайтты. Берсе иңенә куян аскан, икенчесе суер аткан иде, поши күргәннәр, тик ядрәле мылтык белән аңа якынлашып та маташмаганнар икән.

— Мылтыкмыни инде бу? — дип көенде суер очратканы. — Чыпчык атарга гына яраклы, карыйм кошкайны, миннән унбиш адымлап кына ераклыкта утыра бу матуркай, төзәдем дә шарт! Тидердем, ахры, дип сөенәм, ә аның исе дә китмәгән...

Кич белән Байбал командирларга кунакларның тайгада нишләп йөрүләрен сөйләп бирде. Әйтерсең лә артларыннан күз дә язмаган, чынлыкта исә ул аларның эзләрен генә өйрәнеп кайткан иде.

Аучыларның берсе кәкре борыны, зәңгәрсу дип әйтерлек чем-кара чәчләре өчен Суер кушаматы алырга өлгергән иде. Ул тайга буйлап арлы-бирле чапкан, әмма ау турында уйламаган да, партизаннар үзен күзәтмиләр микән, дигән уй күбрәк борчыган, ахры, аны. Күзәтмәүләренә ышангач, ун чакрымлап кырыйга элдергән дә үр төбәсенә менгән, кул астында коры-сары булуга карамастан, юеш утыннар җыеп учак яккан, каен тузына күмер белән тирә-юньнең картасын төшереп, ниндидер билгеләр белән чуарлап, берничә цифр язган. Тузны каен кәүсәсенә беркетеп куйган. Аннары «суер»га аткан да кайту юлына борылган. Байбал туздагы язуларның төгәл күчермәсен дә алып кайткан иде.

— Нинди тәре икән бу, аңлашылмый, — диде Носорогов, кешегә иштеттереп фикер йөрткәндәй. — Ярар, бу табышмакны калдырып торып, ары китик. Сызык белән «Җ» хәрефе — Җугҗур инде. Унда — Аян порты, Мая елгасы. Түгәрәге — база. Цифрлары, әлбәттә, кеше-

ләр, пулеметлар. Ә бу тәре алтынның базада икәнлеген белдерәдер. «Суер»га әлегә тимибез. Бәлки японнар сигналны күрмәгәннәрдер. Тикшерербез, нишләп Аянга сызмады, кире кайтты икән ул?

— Безне сагайтудан куркадыр, — дип фараз итте Зөбәйдуллин, — димәк, вакытыннан элек шик тудырасы килми.

— Мөгаен. Тагын сунарга чыгам дисә, җибәр...

Шуннан соңгы ике көндә «Суер» тырыша-тырыша тиен тиреләрен ялгап утырды, өченче көнне исә иртүк тагын тайгага ычкынды. Аның сигналын японнар күргән, тузын алганнар иде.

Разведчиклар таң белән ике тубы, олаулары белән биш йөз кешелек отрядның Аяннан чыгуын хәбәр иттеләр.

— Маскарадны туктатыгыз! — дип боерды Носорогов.

Партизаннар яшергән җирдән көлешә-көлешә винтовка, патрон, граната, пулемет тасмаларын чыгардылар.

*

* *

Японнарның алдан килүче төркеме тарлавыкны үтеп, тезмәгә сибелде. Берничәсе үргә күтәрелеп тирә-юньне күзәтә башлады. Күрше калкулык битендәге куе чыршылыкта партизаннар төркеме яшеренгән, Носорогов үзе дә шунда иде. Ерактагы үзәнлектә японнарның яңа тезмәсе күренгәч, беренче карлыгачлар күздән югалды.

— Әллә кая китә алмаслар, — диде Носорогов һәм биноклен үзәнлеккә төбәде. — Туплары кайда соң?

— Тегендә, үрләр арасына кара, — диде Байбал. — Әфисәрләре дә шунда, икәү. Араларында теге кыяфәтсез карачкы да бар. Бераз көтик, кәкрәйтермен мин аны.

— Сабыр ит. Киләләр төшсеннәр.

Японнар тезмәсе әкренлек белән якынлашты. Ачык яланда солдатлар менә дигән мишень иде. Носорогов тупларны, төлке якалы тун кигән ике японны һәм «Суер»ны эзләп тапты.

— Планны үзгәртмибез, — диде ул. — Килмешәкләргә үлем! Нинди тигез килә, хәшәрәтләр. Алгы тезмәгә — ут!

Залп яңгырады, унлап япон карга ауды, тезмә җиргә ятты. Шул минутта ук партизаннар артыннан мылтык, пулемет тавышлары ишетелде. Носорогов иптәшләре белән чаңгыда шуып үрдән төшеп китте һәм базага таба юнәлде. Чыршылыкта беренче снаряд шартлады. Әйтерсең бәрелеш башлануын гына көткән, диңгез ягыннан томан исе килгән дымлы җил исә башлады, тайга хәрәкәткә килде, үр өсләрендә, Җугҗур түбәләрендә кар өермәләре бөтерелергә тотынды.

Куак артыннан Носороговка таба көтмәгәндә япон солдаты атылып чыгып, винтовкасын төзи башлады, әмма Байбал аңардан өлгеррәк булып чыкты, төзәми диярлек атты һәм үтерелгән солдат кулыннан төшкән коралны эләктереп өлгерде.

Тупларының утка тотуына аркаланып, дошман солдатлары сак кына базага якынлаштылар, партизаннар атыша-атыша чигенә башлады. Кар өермәсе бөтерелгәнгә күрә төзәп ату кыенлашты, базага килеп җитәрәк кул сугышлары башланды.

Тупларның берсе көньяк тау битенә ата башлады. Носорогов Бугров отрядына аны юк итәргә боерды. Японнар соңгы көчкә кадәр үҗәтләнеп сугыша, бер адым да чигенмиләр иде. Төн уртасында японнарның төп көчләре тарлавык аша инкүлеккә ташланды. Һаман көчәя барган җил ыжгыруы дәһшәт белән тәгәрәгән ташлар дөбердәвенә кушылып, снаряд һәм гранаталар шартлавын, пулялар сызгыруын, яралылар ыңгырашуын күмеп киткәндәй булды.

Сугыш төне буе дәвам итте. Иртә белән буран басылды, сәер тынлыкны ярып сирәк-мирәк ату тавышлары яңгырый — япон отрядының калдыгы чолганышны өзеп чыгарга маташа иде.

Җиңү партизаннарга кыйммәткә төште — отрядның чиреге һәлак булды, күпләр, шул исәптән Бугров белән Носорогов та, яраланган иде.

Носороговның аягы һәм күкрәге яраланган, каны күп аккан иде. Сигизмунд Сигизмундович Локманга берни эшләп булмый диде.

— Сау булыгыз, бөркетләр... Алтынны... халыкка, балаларыбызга. Дошманга граммын да... — диде командир, соңгы сулышын алып.

Куркусыз командир Бугров та һәлак булды. Партизаннар иптәшләрен баһадир агачлар ышыгына, туганнар каберенә күмделәр. Көяшлы кичке тынлыкта залп яңгырады. Локман бөтаклардан яңа кабергә коелган кар бөртекләрендә күз яше аша кинәт бер мизгелгә балкып киткән салават күперен күрде.

*
* *

Январь инде бетеп килә, Якутскига җибәрелгән элемтәчеләр әле һаман кайтып җитмәгән. Локман Байбал белән һәр иртәне килешенгән җиргә барып килә, юл уңаенда куян аулыйлар иде. Бервакыт учак янында элемтәченең ире—карап торырга кырыс кыяфәтле утыз яшьләрдәге партизан янына килеп Локман кулын утка таба сузды:

— Тоткарланды әле Мәрьямең.

— Кайтыр. Барысыннан да алда ул булыр, я бүген, я иртәгә. Вакыты җитеп килә.

— Нинди вакыты?

— Бала табасы бар.

— Бала?!

— Әйе, иптәш комиссар, тиздән...

— Син аны авырлы икәнен белгән хәлдә җибәрдеңме?

— Аны тотып калып булмый иде. Син курыкма, кайтыр. Сигизмундтан бер кая да качмас. Докторны андый эшләргә оста диләр...

— Менә сиңа хәлләр! Нәрсә, бездә башка хатын-кызлар юк идеме әллә?

— Бар иде, хәзер калмады!

— Сез бала тапмыйсыз, сезгә нәрсә, — диде партизаннарга һаман тынычлана алмаган Локман, — шуңа күрә хихылдашасыз. Ә аңа мондый сәяхәт...

— Малае чаярак булыр... — диделәр тагын аны бүлеп.

Уен-көлке тавышлары астында Локман Зөбәйдуллинны эзләп китте.

— Хет көл, хет ела, — диде отрядның яңа командиры, Локманның хәбәрен ишеткәч. — Алты кешедән берсе дә барып җитә алмас микәнни? Мин, дөресен әйткәндә, Мәрьямгә бик ышанган идем.

Гаҗәеп катлаулы, кыен язмышлы Мәрьям Камалетдинова отрядның горурлыгы иде. Ул Благовещенскида туа, бөтендөнья сугышы башланганчы ук кияүгә чыга. 1914 елда, ирләре армиядә булган башка солдат хатыннары кебек, Владивостокта казармада яши. Ире өчен ай саен ярдәм, «җан асрарлык» дип телгә кергән туксан тиенне ала. Ул акча ачлы-туклы яшәргә дә җитми, кер уып азык юнәтергә туры килә. Революциядән соң күп кенә солдат хатыннары Ерак Көнчыгыш революцион партизан отрядына китә. Аларны Амур буендагы Николаевскига, аннары шундагы идарәчеләрне бәреп төшерү һәм каторгадагыларны азат итү максаты белән Сахалинга җибәрәләр. Отряд бер тапкыр да атмыйча җиңә — төрмә каравылы тулысы белән алар ягына күчә. Поз егермедән артык сәяси тоткын иреккә чыга. Хатын-кызлар

берничә көн рәттән аларның богауларын кисеп азапланалар. Тоткыннарның бер өлеше Владивостокка кайтырга боерык алган отрядка кушыла. Анда араларында Мәрьямнең ире дә булган элекке патша армиясе солдатлары отрядны тулыландыралар. Отряд командиры Иван Кудрецов партизаннарны Охотскига алып китә, тик шәһәргә диңгездән акгвардиячеләр килеп тулганлыктан, сугыша-сугыша тайгага чигенәләр. Охотск гарнизонының бер өлеше партизаннарга кушыла. Составында балалар күп булган отрядын Кудрецов Өркеткә юнәлтә, тик Мәрьям белән ире, бу якларда калырга теләп, Носороговка күчәләр. Яшь партизанка әйбәт разведчик буларак танылып китә. Тик менә хәзер... болай озаклагач, Локман аның әйләнеп кайтырына ышанырга да, ышанмаска да белми иде.

— Бәлки тагын берничә кеше җибәрербез, — диде ул.

— Берәр атна көтик инде.

Берничә көн узгач, Локман белән Байбал, гадәттәгечә, лагерьдан чыгып киттеләр. Мамык кар кунган яфраклы сирәк урманда таң яктысы ялкау гына беленә башлаган иде. Байбал барган көйгә:

— Якутскидан кемдер килгән, — диде.

Элемтәчеләр белән очрашасы җиргә җитәргә әле ерак иде, ләкин тәҗрибәле эзтабарга ышанганга күрә Локманның күңеле шунда ук күтәрелде.

— Син аны каян беләсең, һич акылым җитми.

— Анда учак яна. Төтен исе килә.

Озакламый алар чаңгы эзен кисеп үттеләр, тик Локман аңа игътибар итмәде.

— Мәрьям икән, — диде Байбал. — Төнлә кайткан, утын җыеп йөргән.

Учак янында мех сәләмәләргә төренгән бер кечкенә хатын бөкрәеп утыра иде. Каралган, суырылган Мәрьямне Локман көчкә таныды. Аның күзләре генә элеккечә иде. Ирләрне күргәч, Мәрьям кыенлык белән тураеп басты. Локман аның җил ашаган, җыерчыклар яргалаган йөзенә ягымлы карап:

— Арыдыңмы? — дип эндәште.

— Коры сөяккә калдым. Боланны күптән ашап бетердем, тик ау белән маташырга вакытым булмады, бик ашыктым. Якындагы базага китмәкче идем әле. Барып җитә алмас идем, мөгаен. Хәлем бетте. Ирем саумы соң?

— Исән, көтә-көтә көтек булды.

— Ә доктор?

— Сау-сәламәт. Ул да сине көтә. Кузгалыйк акренләп.

Лагерьга кайтканда Мәрьям шатлыклы хәбәрләр сөйләде. Якутскида декабрьда ук Колчак диктатурасы бәреп төшерелгән икән. Кызыл Армия һөҗүм итә, күптән түгел Красноярскины алганнар, Өркеттә власть баш күтәргән эшчеләр кулына күчкән. Отряд Якутскига юнәлергә, алтынны шунда тапшырырга тиеш. Дошманны мөмкин кадәр читләтеп үтәргә тырышырга кирәк.

— Ә теге биш җан кайда? Син аларны күрдеңме? — диде Локман.

Мәрьям сөртенеп китте, ирләр аны култыклап алды. Хатын көчкә ишетелерлек итеп:

— Кире кайтканда аларга килеп төртелдем, — диде. — Газаплап үтергәннәр... Якутскига җитәргә әз генә калганда...

*

* *

Отрядка тайга буйлап мең чакрымнан артык юл узарга кирәк иде. Зөбәйдуллин, походның төрле вариантларын тикшерү өчен, командир-

ларны киңәшмәгә җыйды. Көчләрне таркатмаска карар иттеләр. Отрядта хатын-кызлар һәм балалар белән барлыгы өч йөзләп кеше бар иде. Йөкләрне чаналарга һәм нарталарга урнаштырдылар. Японнардан эләктергән тупны, снарядлары сигезәү генә булса да, үзләре белән алырга карар иттеләр. Аны чанага салып, «батарея» командиры итеп соңгы сугышта егетлек күрсәткән Гыйльметдинне — Мәдинәнең ирен билгеләделәр.

Поход башланырга берничә көн калганда отрядка ике бәби өстәлде: Мәрьямнән соң Мәдинә дә ир бала тапты. Малайларның икесенә дә сөекле командирлары хөрмәтенә Мәхмүт исемен куштылар.

Җугҗурның көнбатыш битеннән төшү белән партизаннар разведкасы бандитлар белән бәрелеште һәм берсен әсир төшерделәр. Әсир бу якларда соңгы вакытта «алтын олаулары»ның хуҗасы, бай алыпсатар Баешовның зур бандасы төпләнүен сөйләп бирде. Җирле халык аларны күралмый, чынлыкта бандитлар белән сугыш алып бара икән. Баешов байлыгын кире кайтарырга тели, күп санлы вак кулак һәм акгвардияче бандаларны, юмарт бүләкләр вәгъдә итеп, бергә берләштергән. Партизаннар байлыкны Мәскәүгә Якутск яки Бодайбо аша озатырга тырышыр дип уйлап, бандитлар юлда тозак әзерлиләр икән. Әсирлеккә төшкән якут кулакта батрак булган, озак еллар кадәри хәл шуңа тир түккән, әмма талауларда катнашасы килми, партизаннарга бандитлар лагерен күрсәтергә әзер иде.

— Бу банда белән бәрелештән барыбер качып котылып булмый,— диде Зөбәйдуллин. — Шуңа күрә башлап үзебез һөҗүм итик. Тылда мондый адәм актыкларын калдырырга ярамый...

Баешов бандасын тар-мар иткәннән соң отряд юлга чыкты һәм Якутскига барып җиткәнче бүтән җитди сугышлар булмады. Юлда партизаннар Колчакның атылуын ишеттеләр.

Якутскига килеп җиткәч, отряд таратылды. Зөбәйдуллин белән Исхаковка асылташларны Өркеткә кадәр озата бару тапшырылды.

Гражданнар сугышы герое, Себердәге партизаннар хәрәкәтенең күренекле җитәкчесе Нестор Александрович Каландарашвили 1921 елның көзендә Ленин белән очрашканнан соң, Мәскәүдән Өркеткә килде. Бу вакытта Якут җирендә хәлләр тагын катлауланып киткән иде: тамыры корытылмаган барлык контрреволюционерлар кулларына корал алып, турыдан-туры совет властена каршы чыктылар.

Локман 1920 елның июненнән бирле Өркеттә яши иде. Юлда күп мәшәкать чыгарган теге кыйммәтле йөкне исән-имин тапшырганнан соң, Зөбәйдуллин кире Якутскига китте, Локманга монда калырга тәкъдим иттеләр. Ул кыска вакытлы сәяси курслар бетерде, губревкомда эшләп, Лена юлыннан Якут өлкәсенең халык хуҗалыгына кирәкле йөкләрнең үз вакытында җибәрелүе өчен җавап бирә иде.

Бүген кич Каландарашвили Локманны үзенә чакырып алды, аның Носорогов отряды хәрәкәте турындагы хикәясен игътибар белән тыңлады һәм стенада эленеп торган зур карта янында тукталып калды. Каландарашвили картага каравын дәвам итеп:

— Әйе, партизан отрядлары тайгада гомер онытылмаслык сукмаклар салды, — диде. — Максим Михайловичны белә идем мин... Иптәш Исхаков, Өркет губревкомы Якутскига сезне җибәрүне тиеш дип тапты. Анда шәһәрне сакларга әзерләнәләр, шуңа күрә кичекмәстән ирекле татар дружинасы тупларга кирәк. Сез моңа ничек карыйсыз?

— Үчүгәй![1] — диде Локман, күтәренке рухта.

— Мин дә сезнең урыныгыз анда дип хисаплыйм. Шәһәрдә татарлар күп, шуның өстенә сез якутча да беләсез. Әйдәгез, хәзер Якут өлкәсе һәм Приморьеда ниләр баруын карыйк әле, — Каландарашвили

[1] Үчүгәй — яхшы (якутча).

Локманны карта янына чакырды. — Бөтен Охот дингезе яр буе диярлек фетнәчеләр кулында. Күптән түгел монда Владивостоктан пароходларга төялеп есаул Бочкарев бандасы килгән. Охотск әлегә бирешми, ләкин көчләре бетеп киләдер инде, анда гарнизон зур түгел. Нелканда элекке колчакчы Коробейников егетләнә. Ак бандитлар Якут өлкәсенең эчкәре төбәкләренә үрмәли. Партия Үзәк Комитеты һәм Совет Россиясе хөкүмәте күрсәтмәсе буенча без монда, Өркеттә, Икенче махсус Төньяк берләшмәсе оештырабыз. Мин Якут өлкәсе һәм Төньяк крае хәрби көчләре командующие итеп билгеләндем. Өркеттән январьда чыгып китәчәкбез. Ә сез кайчан кузгала аласыз?

— Беренче мөмкинлек туу белән. Бүген егерме бишенче ноябрь... Берсекөнгә ямчылар почта алып китәчәк.

— Үчүгәй... Байбал Мыкчыканов кайда хәзер?

— Якутск тирәсендәге Табага авылында урман кисүче чыбык очы туганында яши. Юл уңаенда кереп, дружинага кушылырга өндәмәкче булам әле үзен.

— Дөрес. Мин һәрвакыт шундый картлар — якут һәм тунгусларга соклана идем, алар барында эш җиңеләя. Искиткеч эзтабарлар, сизгер, үткен күзлеләр, бер сырттан икенчесенә кадәр күрәләр, ә иң мөһиме, намуслы кешеләр. Ничек партизан булып киткән ул Байбал?

— Февральдән соң ул Неверск юлын кулга төшергәнниндидер бер эшкуарга батраклыкка ялланган. Бу паразит җирле халыктан терлек сатып яисә алмашып алып, аны алтын эзләүчеләргә котырынган бәядән генә бирә башлаган. Байбал бервакыт приискага терлек куып илткәндә, бүреләр дүрт үгезне ботарлап ташлаган. Хуҗа шуның өчен шашынып, аны Дарьясы белән бергә тирмәсеннән куып чыгарган, җеп бөртегенә кадәр талаган. Сәүдәгәр авылларга пар атта, ике җан сакчысы белән чыгып йөри икән. Олаучы якутка шулай ук бернинди игътибар юк, хайванга карагандай карыйлар. Байбал шул якут белән килешеп, бер көнне аның урынына үзе утырган һәм чаптырып килгән уңайга көймәле арбаны кинәт борып, пассажирларны Дарья белән теге олаучы аяк астына гына олактырган. Өчесен дә атып үтергәннәр дә тайгага кереп киткәннәр. Шунда Носорогов отрядын очратканнар...

— Булдырганнар! Якутскига бару юлында берләшмәне әнә шундыйлар белән тулыландырырга тырышачакмын. Иптәшләргә әйтегез, Владимир Ильич бөтен күңеле белән алар эшчәнлеген күзәтә, якут халкына булышыр өчен бөтен чараларны күрә. Бәхетебезгә каршы, Россия халыкларының менә шундый житәкчесе һәм юлбашчысы бар. Мартта мин үзем дә отрядым белән Якутскида булырмын. Ә хәзергә анда махсус отрядыбызның бер өлешен җибәрә торабыз, — Каландарашвили елмайды, хәзер ул яшәреп киткәндәй тоелды һәм берәү дә аны илленең теге ягындадыр, дип уйламас иде.

Локман хәтерендә ул менә шулай уелып калды. Тәкъдир аларга бүтән очрашуны язмаган иде.

Локман Мәхмүт Зөйбәйдуллиннан хатларны даими алып тора, яңалыкларны аерым дәфтәргә теркәп куя, картада билгеләр ясый — Якут җирендәге хәлләр аны инде күптән борчый иде. Китәр алдыннан төнлә белән ул шул язуларын тагын бер кат күздән кичерде, ак бандит отрядлары Якут җиренә ерак керә алырлармы икән, дип баш ватып, бик озак Себер картасын алдына җәеп карап утырды.

Өяз һәм олысларда Совет властеның ныгуы, халык хуҗалыгын торгызудагы беренче уңышлар, самодержавие богауларыннан һәм эксплуататорларның күп гасырлык изүеннән азат ителгән якут халкының культура яңарышы башлану, тетмәсе тетелеп бетмәгән акгвардияче офицерлар, поп, спекулянт, банда атаманнары, элекке тойоннарның [1],

---

[1] Тойон — солтан, морза (якутча).

буржуаз милләтче һәм Советка каршы әләм-этрәкләрнең котырынган ачуын чыгара иде. 1920 елның икенче яртысында Якут өлкәсенең ЧК органнары тарафыннан, житәкчеләре яшерен рәвештә япон интервентлары белән бәйләнгән берничә контрреволюцион заговор ачылды. 1920 елның язынан башлап элекке колчакчылар бандасы Охотск тирәсендәге Булгин авылына урнашкан иде. Күптән түгел Носорогов отряды оя корган төбәктә — Аяннан Нелканга бару юлында да күп кенә акгвардияче калдыклары тупланды. Мая елгасында әле күптән түгел генә, шушы елның сентябрендә, ак бандитлар ике пароходны һәм азык-төлек, промтоварлар төягән дүрт баржаны басып алдылар. Соңгы хатында Зөбәйдуллин, Якут өлкәсендә төрле милләт кешеләреннән махсус бурыч үтәячәк рота оештырыла башлавын, ләкин шәһәрдә кызылармеецларның бик аз — йөздән дә кимрәк булуын хәбәр иткән иде...

Иртә белән Локманнар йорты алдына печән түшәлгән һәм аның өстенә болан тиреләре җәелгән чаналар килеп туктады. Локман почта олавы белән Лена юлы буйлап ерак сәфәргә кузгалды.

*

* *

Суык январь кичендә олаулар Табагага килеп житте. Локман урман кисүче Прокопий Данилов тирмәсен эзләп табып керде дә бусагада туктап калды. Озын өстәл артындагы сәкедә Байбал белән Дарья, хуҗалар һәм ике бала утыра иде. Уңъяк почмактагы балчыктан әмәлләнгән каминнан җылы бәреп тора, янәшәдә генә зур самавар гүелди иде. Якут гореф-гадәте буенча башта кунаклар түгел, хуҗалар исәнләшә иде.

— Капселин, тугу билин?[1] — диде хуҗа, өстәл артыннан торып.

— Сох, Эн тугу билин?[2]

Сәфәренең максатын әйтеп, Локман Байбал белән Дарьяга үзе белән китәргә тәкъдим итте. Карт белән хатын күзгә-күз карашып алды да кыска гына:

— Сеп! [3] — диде.

Локман капчыгыннан чәй, шикәр, тәмәке чыгарды.

— Каландарашвили иптәштән күчтәнәч...

Якутскига дүртенче январьда килеп җиттеләр. Берничә көннән клубта татарларның аерым җыелышы уздырылды. Аны Мәхмүт Зөбәйдуллин ачты. Шәһәрне саклар өчен мөселман дружинасы төзү турындагы карар хуплау авазлары, кул чабулар белән каршыланды.

— Дружиначылар казармада яшәүгә күчерелә һәм бөтен кирәк-ярак белән тәэмин ителәчәк, — диде председатель. — Хатын-кызларны алмыйбыз, ләкин шәһәрне саклауда аларга да катнашырга туры килер. Сакланыр өчен корылмалар төзергә, аяк һәм өс киемнәре тегәргә, сугыш кораллары әзерләргә кирәк булачак. Эш һәркемгә житәр.

Зөбәйдуллиннан соң Локман чыгыш ясады. Ул беренче татар гаиләләренең Лена буена моннан өч йөз еллар элек үк килеп төпләнүен искә алды.

— Күбегез өчен Якут җире инде ватанга әйләнде, — дип дәвам итте ул. — Безнең ата-бабаларыбыз байлардан һәм патша чиновникларыннан күп җәфа чиккән, соңгы чорда исә Колчак дәһшәтенә дучар булдык. Менә хәзер кара көчләр тагын безгә ябырылмакчы, яшь Совет властен буып ташламакчылар...— Локман тынып калган залга күз салып, Гыйльметдин белән Мәдинәне күреп алгач, елмайды. Ахырда дружинага язылырга теләүчеләрне өстәл янына чакырды.

---

[1] Сөйләп җибәр, дөньяда ниләр бар?

[2] Ә сездә ниләр бар?

[3] Сеп — хуп (якутча).

Дружинага кырыктан артык кеше, шул исәптән, татар дуслары белән бер сафта сугышырга теләгән берничә якут, рус, үзбәк һәм кыргыз да язылды.

Өйгә кайтканда Зөбәйдуллин Локманнан:

— Синең Алып турында ни дә булса ишеткәнең бармы? — диде.

— Юк, кем соң ул?

— Баһадир дружиначыбыз Рәхмәтуллинның энесе. Кулак бандасының атаманы. Якутлар аңа көчле һәм озын буйлы булган өчен Алып кушаматы биргәннәр. Абыйсыннан бер башка калкурак, диләр. Мондагы атларны култык астына гына кыстыра икән дә көчек күтәргән кебек кенә бара икән. Шәһәрдән ерак түгел Нам олысында хатыны, улы белән бергә гомер иткән гап-гади урта хәлле крестьян. Ярлылар аны чиктән тыш көче өчен хөрмәт иткән, абруе зур булган, тик үзе һәрчак тойоннарга тартылган икән. Болар өчен инде ул — табылдык! Төпсез чанага утыртканнар үзен. Йөзләп кешедән торган банда оештырганнар да байгышны атаман итеп сайлаганнар. Шайтан белсен, бәлки тойоннар аның турында юри имеш-мимеш тараталардыр. Әллә инде халык үзе табынган потның кабәхәт булып чыгуы белән килешергә теләми, һәр төрле уйдырмаларны колактан колакка сөйли. Иң таралганы менә шундый. Үз ихтыяры белән бандитлыкка чыкмаган икән ул. Бервакыт ауга киткән дә берничә көн югалып торган. Шул арада кемдер, ул ак бандага кушылган икән, дигән хәбәр тараткан. Кызылармеецлар өенә барганнар да хуҗалыгын пыран-заран китергәннәр, чибәр хатынын мыскыл иткәннәр, улының котын алганнар, терлекләрен алып чыкканнар, имеш. Алып аудан кайтып, тетрәткеч хәбәрне ишеткән, бөлдерелгән хуҗалыгын үз күзе белән күргән дә үч алырга карар биргән, дип сөйлиләр.

— Шушындый кыйссага ышанучы беркатлылар да табыла микәнни? Кызылармеецлар шулай...

— Ышанамы, юкмы, имеш-мимешләр тарала бирә.

— Бәлки алар кызылармеец киеме кигән бандитлар булгандыр, провокация?

— Бернинди туздыру-фәлән ясалмаган иде, тикшердек. Банда башлыгы булса да Алып үзе талау-җәберләүләрдә катнашмый. Моны исәпкә алырга туры килер.

— Димәк, үч алудан курка, хәйләкәрләнеп вөҗданлы юлбасар ролен уйнамакчыдыр. Ә абыйсы ничек? Шул әкиятләргә ышанамы?

— Юк та... Очраса үтерәм ди.

— Әйе, туган туганга каршы...

Локман өенә кайткач, дружиначылар исемлеген пөхтәләп күчереп язды да, күзләрен йомып уйга талды. Партизаннар сафы... Кичәге тоткыннарның йончыган йөзләре. Саргылт яшел тайга океаны. Җугҗурның караңгы үрләре, яфраклы агачлардан коелган көмеш кар тузаны...

Ул Носорогов отрядының исемлеген алып, татар дружинасына Байбал белән Гыйльметдиннең керүе турында билге ясады. Тайга аша узган мең чакрымлы походтан соң исән калган партизаннарны язмыш бөтен Себер буйлап чәчкән иде... Сигизмунд Сигизмундович моннан бер ел элек Хабаровскида туберкулездан вафат булды. Күп кенә көрәштәшләренең язмышын Локман әлегә фараз гына итә ала иде.

Икенче көнне дружина урнашкан казарма ишегалдына ак сакаллы карт — су ташучы Кечебай Биктагулов килеп керде һәм шәһәрне кулына корал тотып сакларга теләвен белдерде.

— Син, бабай, үз гомереңдә кулыңа бер дә мылтык тотканың юк лабаса! — дип кычкырды кемдер.

— Менәтерә, бер тапкыр тотып караганым бар ла,— дип каршы

төште карт. — Улым Дәүләт белән ауга барган идек. Шунда ул үрдәк атты. Дәүләт ермакка килеп төшкән кошны алырга киткәч, мылтыкны ныклап үзем тотып тордым! — Кечебай мылтыкны ничек тотып торуын күрсәтер өчен кысылган йодрыгын югары күтәрде.

— Бетте, бетте, җиңелдем болай булгач, — диделәр аңа, көлешүләр тынгач.— Үзебез сафка алабыз сине, тик, Кечебай ага, башта аргамагыңны китер әле, яшисен яшәгән инде ул, суеп казылык әзерли торыйк.

— Минем атның казылыгы тешеңне сындырыр, олан. Әнә теге аргамакны чалыйк! — диде карт, яшь алашаны күрсәтеп. — Кабыргалары йомшак, ите телеңне йотарлык тәмле, дошманны туздырырга барганда тез-буыннарың тимердәй ныгыр. Минем атта су ташырга гына, оланнар.

— Дөрес, Кечебай ага!—диде яңа гына килеп җиткән Зөбәйдуллин, картны яклап.—Сусыз яшәп булмый. Кичә нигә язылмадың соң син?

— Артта утыра идем шул, Мәхмүт энем. Сине күзем күрсә дә, колагым ни нәрсә сөйләвеңне ишетмәде.

Алар тагын бераз гәп корып, көлешеп алдылар. Зөбәйдуллин картны тынычландырып, аңа дружинада эш табылачагын белдерде.

Җил капка ягыннан нидер ымлаган Мәдинәне күреп, Зөбәйдуллин шунда атлады. Хатын аңа пышылдап, әле генә кибетче Әкембитевләрнең асраудагы яшь кызы Миңлекамәрнең үзен урамда туктатуы хакында сөйләп бирде. Аның хуҗасы җыелыштан соң ниндидер бер Юныс исемле кеше белән очрашкан. Сүз кибетче келәтендәге винтовка һәм патроннарны кемгәдер бирү турында барган.

— Яшерен корал хәзинәсе! Күптән эзли идек инде аны, — диде Зөбәйдуллин. — Рәхмәт, Мәдинә.

— Миңа түгел, — дип елмайды Мәдинә, — Миңлекамәргә әйтегез.

— Әйтербез, вакыты җиткәч, аңа да әйтербез.

Әкембитев йортын күзәтү астына алдылар һәм өч көннән соң аны төнлә, ике «кунагы» белән бергә утын келәтендәге яшерен урыннан корал әрҗәләрен кузгатып ятканда тоттылар.

Дружиначылар трофейларны санаганда, Мәхмүт белән Локман бандитлардан сорау алды. Алар икесе дә Алып отрядыннан булуларын, коралларны утрауларның берсенә илтеп, өч болан җигеме белән көтеп торган иптәшләренә тапшырырга тиешлекләрен танадылар.

Утрауда яшеренгән бандитларны бер атышсыз кулга алып, бөтен компанияләре белән ЧКга тапшырдылар. Юныс ярдәме белән Колчак чорында ук булдырылган тагын ике корал хәзинәсен таптылар. Үзе әйтүенчә, Юныс Алыпның ышанычын казанган кеше икән, әгәр атмасалар, киләчәктә чекистларга ярдәм итәргә, Алып бандасы һәм башка төркемнәрнең хәрәкәте турында хәбәр биреп торырга ышандырды.

— Алыптан соң отрядта иң көчле кеше мин, билләһи, — дип каргады Юныс. — Ул мине шуңа күрә хөрмәт итә дә. Дуслары күп күбен, ләкин берсе дә миңа тормый. Бер генә әчке мәҗлесе дә миннән башка узмый.

Күрсәтмәләр биреп, егетне кире җибәрделәр.

Якутск халкы дружиначыларга кулыннан килгәнчә ярдәм итте, шәһәрне саклау фондына атларын, боланнарын, азык-төлек, өс һәм аяк киемнәре тапшырды.

Тайга дәһшәтле шаулый, ак бандалар шәһәргә ыргыла иде.

*
* *

Алдан баручы отряд һәм Икенче Төньяк берләшмәсенең дүрт эшелоны Өркеттән январь уртасында юлга чыкты. Лена юлыннан барган-

да берләшмәгә үзе теләп күп кенә ир-егетләр кушылуы турында телеграф аркылы хәбәрләр алына иде. Тик бу вакытта Якутск өлкәсендә хәрби-сәяси хәл катлауланганнан-катлаулана. Февральдә аклар Лена-ның сул ягына күчеп, Нам олысын яулап алдылар һәм Якутскига килеп життеләр. 28 февральдә шәһәр камалыш хәлендә иде. Төньяк өязләр белән элемтә өзелде. Верхоянскида аклар терроры котырынды, күп кенә совет хезмәткәрләре, коммунистлар һәм комсомоллар газапларга дучар ителде һәм атылды, власть тагын тойоннар кулына күчеп, халыктан алдагы еллар өчен налог җыярга керешелде.

Локман беренче марттагы хәлне картага төшерде: кызыл карандаш белән Олекминск өязен, Якутск, Вилюйск, Нюрба, Амга тирәләрен кызыл сызык белән урады. Кызылармеецлар кулындагы Лена юлын исәпләмәгәндә, Якут җиренең калган бөтен мәйданы аклар тарафыннан басып алынган иде.

Кызылармеецлар һәм дружиначылар Якутскида 350 кеше иде. Акларның гомуми санын билгеләү кыен, алар, Локман фикеренчә, берничә меңнән артык булырга тиеш иде.

РКП(б)ның губерна бюросы чолганыштагы шәһәрнең оборона сәләтен көчәйтер өчен хәлиткеч чаралар күрде. Профсоюз әгъзаларына мобилизация игълан ителде — корал тота алырлык һәрберсе кызылармеец отрядларына һәм дружиналарга язылды. Коралларны төзәтү, сугыш кирәк-яракларын әзерләү остаханәләрендә көне-төне кызу эш кайнады. Җылы өс һәм аяк киемнәрен күмәкләп тегү оештырылды. Көнчыгыш өязләрдән чигенгән йөзләрчә качак шәһәр кырыенда ныгытмалар кора иде.

Бервакыт шәһәр Советы председателе Михаил Афанасьевич Литвинов Зөбәйдуллиннан татар дружинасы сугышчысы Гыйльметдин Камалетдиновны элекке эш урынына—тимерчелеккә аерым бурыч үтәр өчен җибәрүен үтенде. Тиздән аның электростанция мөдире Аппөлон Андреевич Гоголь белән яңа корал — гранатыргыткыч уйлап табулары ачыкланды. Гыйльметдин әйтүенчә, бронза белән казан тимереннән ясалган «якут тубы» гранаталарны кул белән тондыруга караганда ун тапкыр ераграк — өч йөз метрга атачак икән. Камалыш шартларында андый коралны әзерләү мөмкинлегенә шикләнсә дә, Зөбәйдуллин алдатмаска теләп:

— Уйлап табучыларга әйт, бер тупны — безгә, — диде.

Якут эшчеләре мөмкин булмаслык шикелле күренгән бурычны уңышлы үтәп чыкты: гранатыргыткычның берсен озакламый татар дружинасына китерделәр. Сугышчылар кыска көпшәле сәер корылманы урап алдылар, йөзе балкыган Гыйльметдин аны ничек файдаланырга кирәклеген өйрәтергә кереште.

Дружиначылар яңа коралны сугышта сынап карарга булдылар һәм шәһәрнең төньягыннан атыш башладылар.

Камалыштагы шәһәрне саклауның иң авыр көннәрендә сафка баскан берничә гранатыргыткыч кына көчләр чагыштырмасын үзгәртә алмый иде, билгеле, әмма ул ак бандалар рухына шактый җимергеч тәэсир итте.

1922 елның март башында аклар шәһәргә хәлиткеч штурм ясарга җыенганда, Якутскига Икенче Төньяк берләшмәсенең Иван Яковлевич Строд кул астындагы отряды килеп житте. Халыкның рухы күтәрелде, дружиначылар жиңел сулыш алды. Әмма берничә көннән ишетелгән кайгылы хәбәр шатлыкның тәмен җибәрде.

Алтынчы мартта Нестор Александрович Каландарашвилинең һәлак булуы турында хәбәр килде. Аның отряды Якутскидан утыз биш чакрым ераклыкта Тектүр белән Табага авыллары арасында дошман тозагына эләгә. Авыр сугышта Каландарашвилинең көрәштәшләре: штаб башлыгы Бухвалов, оператив отряд башлыгы Громов, Икенче Төньяк

берләшмәсе командиры Асатиани һәм башка командирлар, солдатлар һәлак була.

Губерна партия һәм совет органнары, хәрби командование хәлиткеч һөҗүмгә әзерләнә башлады. Төньяк край коралллы көчләренең яңа командующие итеп Байков, Икенче Төньяк берләшмәсе командиры итеп Строд билгеләнде.

Март аенда ук инде аклар шәһәр тирәсендәге төбәкләрдән тулаем чигендерелде. Апрель башында кызылармеецлар отряды Лена юлы буендагы ак бандаларны себереп түгеп, Якутскига соңгы эшелон булып баручы Себер ГПУ гаскәрләренең утыз өченче аерым ротасы һәм аның артыннан килүче дүрт йөзләп олаудан гыйбарәт гаять зур хәрби обозга юлны чистартты.

1922 елның апрелендә БҮБК президиумы Якут Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында карар кабул итте. Бу яңалык яшен тизлеге белән бөтен Себергә таралды һәм озакка сузылган гражданнар сугышыннан җәфаланып беткән халыкка, кызылармеец отрядлары һәм дружиналарга яңа көч өстәгәндәй булды. Ак бандаларның канлы йомгагы диңгезгә таба тәгәрәде.

* * *

Акларның төньяк төркеменә һөҗүм иткәндә Мәхмүт Зөбәйдуллин яраланган иде. Төп көче эшчеләрдән торган, сугышларда сафы сирәгәйгән данлы татар дружинасы үз миссиясен үтәгәннән соң таратылды.

Локман белән сөйләшеп, Строд аны үз отрядларының берсенә разведка командиры итеп билгеләде һәм тиз арада Алып бандасын юк итү операциясен әзерләргә боерды.

— Миндәге мәгълүматларга караганда, — диде ул, — тойоннар куштаны чамасыз кире беткән адәм икән. Бу хәлдә аны ничек авызлыкларга мөмкинлеген уйла әле. Тереләй кулга төшерәсе иде аны. Атарга өлгерербез...

Үзенең төп базасы өчен Алып сакланырга уңайлы урын сайлап урнашкан, чигенү юлларын да әзерләгән, банданы аннан алдалап чыгару бик җиңел түгел иде. Кызганыч, кул астында гына «алтын олаулары» юк дип фикер йөртте Локман. Тойоннар нәфесен сузар иде аңа. Алып өчен кораллар хәзер, мөгаен, алтыннан арзанрак түгелдер. Ул Якутскидан Строд отрядларына даими рәвештә зур партия хәрби йөкләр җибәрелүен белә, әгәр ышанычлы табышка юлыгасын сизсә, дошман оясыннан шуышып чыгар иде. Корал хәзинәсе өчен дип ялган урын эзләргә һәм Юныс ярдәмендә Алыпны кисәтеп куярга кирәк.

Байбал белән бергә алдавыч хәзинә һәм тозак өчен урыннар чамалап кайткач, Локман картасын алып Стродка керде. Анысы ниятен хуплап:

— Сынап карагыз, — диде. — Тик нигә буш әрҗәләр белән маташырга? Сизенүләре мөмкин. Трофей коралларны әйбәтрәк итеп әвештәвеш китерү өчен чын база оештырыйк. Бездә төрле җирдә күп җыйналды ул. Шунда ук үзебезнең яраксызга чыккан мөлкәтне дә китерерсез. Ышанычлырак булыр. Каравылның йомшаграк булуы да шик тудырмас, безнең өчен иске-москы гына ич бу.

Алып бандасы төнлә һәлакәтле бозрага килеп эләкте — бик әзләр генә аннан ычкына алды. Ул үзе, Юныс һәм тагын уннап бандит болан җигемнәрендә тайгага кереп яшеренде. Локманның атланган аты үтерелеп, ул үзе төп өстенә уңайсыз килеп төшкәнлектән, кабыргаларын сындырган иде.

Иртә белән разведчиклар бандитларның эзенә бастылар, ике арада кызу атыш башланды. Алып, бер-бер артлы коралдашларын югалтканнан соң, эзәрлекләүчеләрне саташтыру өчен, тайга эченә ташланды, әмма Байбал аңа күләгә кебек тагылган иде. Талчыккан разведчиклар артта калдылар.

Дүртенче тәүлектә, кичкә таба Алып белән Юныс актык боланны суйдылар, аның кайнар канын эчеп, йөрәген ашап, дүрт куллап җәһәт кенә тиресен салдырдылар. Байбал якынлашканда ике кулына ике маузер тоткан Алып тире өстенә сузылып йоклап ята, Юныс, винтовкасына таянып, учак янына чүгәләгән иде. Алар дәшми-тынмый икәүләшеп арыган атаманны ашыкмыйча гына, җиренә җиткереп кулларын бәйләделәр. Шунда гына Байбал үзенең дә тәмам арыганлыгын сизде, болан ите ашагач, учак янында йокымсырап ук китте.

Ату тавышына ул сискәнеп уянды.

— Юныс кайда? — дип, хырылдады Алып. Күзләре дуамал ялтырый, кара төк басканлыктан, аның җил ашаган йөзе күмер төсенә кергән иде.

— Тегендә, — Байбал трубкасы белән тау битенә күрсәтте. — Үзен-үзе аткан.

— У-у-у! — Алып, бүре төсле улап, корсагына әйләнде, тешләрен тирегә батырды. Аннары башын күтәрде, авызына эләккән йонны төкерде һәм йөзе белән Байбалга борылды. Ялкынсынган, кан сауган күзләреннән яшь ага иде. — Ат мине, картлач. Алла хакы өчен ат!

Байбал көлеп, аны бер талпыну белән күтәреп утыртты.

— Ә син көчле икән әле, калын тамырлы, — Алыпның күзләрендә гаҗәпләнү уйнап алды. — Очла әйдә, башка бәр.

Байбал аның белән янәшә утырып, куеныннан яссы фляга чыгарды.

— Спиртмы?! — Алып муенын сузды.— Кая, бер йоттыр әле!

Байбал башта үзе берничә йотым эчте, аннары фляганы Алыпның иренәнә тидерде.

— Рәхмәт, картлач, — дип хырылдады Алып. — Хуш, хәзер инде чигәгә терәп гөрселдәт. Аннары ташлап китсәң дә була.

— Бергә кузгалабыз. Сине күптән атарга була иде дә, Строд, тере килеш кирәк, диде бит.

— Мин нәрсәгә аңа? Барыбер атачаклар. Яшисем килми минем, картлач, булдыра алмыйм, чирканыч. Сиңа аның өчен берни булмас, ат. Арыдым мин бу тормыштан, арыдым.

— Яз якынлаша, — Байбал күзләрен кысып якты болытларга карады. — Ит бар, ут бар... Яшә әле бераз.

Байбал госпитальдә яткан Мәхмүт белән Локман янына көн дә килеп йөрде. Палатадагы яралылар, караватларына кырын ятып, Алыпның ничек әсир ителүен төрлечә арттырып сөйлиләр иде. Андый чакларда Байбал үзе дә дәшми-нитми генә тыңлап тора да, хикәяче тынып калгач, Локманга күз кысып, пышылдап кына:

— Бераз шыттыра, — ди һәм калын трубкасына тәмәке төя башлый.

Локман елмая. Күптәнге дустының холкын ул яхшы белә: карт үз каһарманлыкларын тасвирлауны сөйми, моны лаеклы эшкә санамый иде.

Кичке шәфәкъ шәүләсе палата тәрәзәләренә төшкәч, Локманга тышта зур кызыл байрак җилфердәгән төсле тоелды. Ул аны гүя яңадан революция солдатлары сафына чакыра иде.

**Русчадан ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ тәрҗемәсе.**

# Гәрәй Рәхим

## Табылдыклар өстәле

Мин — табылдыклар өстәле.

Моңын югалтучылар,
Телен югалтучылар,
Илен югалтучылар,
　　Килмәгез дә!
Табалмассыз сез аларны
Минем табылдыклар өстәлендә.

Чөнки аларның сездә,
Сезнең рухыгызда, күңелегездә
Булганы юк!
Андый изге әйберләре булса,
Кеше аны саклый белә...
　　Килмәгез дә!

Мин — табылдыклар өстәле.
Өстәлемдә —
Төргәк-төргәк сагыш,
Бәйләм-бәйләм борчылулар,
Уйлар.

Кемнәр сагышка аптырый?
Кемнәргә борчылу кирәк?
Кемнең бер башына уй юк?—
Рәхим итегез!

Сугыш елларында,
Сугыш юлларында
Югалткан назыңны
Килеп ал, карт солдат,
　　Ул — миндә!
Имтиханда югалткан хәтереңне
Килеп ал, елак кыз,
　　Ул — миндә!
Иң кирәкле мәлдә
Югалткан пуляңны
Маңгаеңа ал, дезертир,
　　Ул — миндә!

Тагын кемнәр нәрсә югалттылар?
Хиросима, син күпме югалттың?
Моабит, син күпме югалттың?
Ватаным, син күпме югалттың?
Әнием, син күпме югалттың?
Йөрәгем, син күпме югалттың?

Мин — табылдыклар өстәле.
Өстәлемдә —
Кемнәрдер югалткан акча янчыклары,
Күзлекләр, перчаткалар,
Төрле фасондагы таяклар...
Шунда ук фашист чокыган күзләр,
Крематорийда янмый калган сөякләр,
Снаряд өзгән аяклар...
Зоопарктан качкан филләр бар монда,
Питоннар, маймыллар,
Югалган этләр, ташбакалар
Һәм башкалар, һәм башкалар...

Әй, сез, креслосын югалткан түрәләр,
Кабинетсыз президентлар,
Тәхетсез шаһлар,
Башсыз философлар,
Хөкүмәтсез илләр,
Актарыгыз килеп миндәге чүп-чарны,
Бәлки югалтканнарыгыз шундадыр.

Боларына без күнеккән инде.
Әле менә кичә генә
Югалган атом бомбасы,
Урланган атом көймәсе
Китерделәр өстәлемә...

Мин — табылдыклар өстәле.
Иманын югалтучылар,
Намусын югалтучылар килмәсен дә.
Алар берни табалмаслар минем өстәлемдә.
Ләкин минем
Парларын югалтканнарга парларым бар,
Ярларын югалтканнарга ярларым бар,
Мин киң күңелле —
Даннарын югалтканнарга даннарын бирәм,
Шаннарын югалтканнарга шаннарын бирәм.
Күзләрен югалтканнарга сары күзем бар,
Сүзләрен югалтканнарга җылы сүзем бар.
Киштәләрем сыгылып тора җылы сүздән.
Килегез, кешеләр, алыгыз,
Мин җыйдым ич аларны сездән.

Кешеләр киләләр,
Югалтканнарының барын да алып китәләр.
Рәхмәт әйтәләр,
Шатланалар, көләләр.
Шул мәлдә ник берсе:
«Иптәш, үзең ни югалттың?» — дисенче!

Мин — табылдыклар өстәле.
Ә шулай да Җирдә югалганның барын да
Китермиләр миңа.
Җирдә бар туганнар каберлекләре —
Шунда илтәләр югалган чын ирләрне.
Аннан соң базарлар бар әле —
Берәү анда яшерен генә намус сата,
Берәү сата изге һөнәрен,
Сатучы бар хәтта үз тәнен.
Әнә берәү рифма сата һәм югалта
Изге шигырь тәмен, сүз тәмен.
Тик барыбер миңа килегез, кешеләр.
Әгәр өстәлемдә ни дә булса табалмасагыз —
Сез алырсыз минем еллар буе
Җыйган шәхси бүләкләремне.
Югалтудан сүнгән күңлегезгә
Өмет чаткылары өсти торган
Иң-иң изге теләкләремне.

Килегез, рәхим итегез!

## Сакла

Сакла, күңел, сакла сагышларны,
Мөлдерәмә тулы сагышларны.
Тыңлама син, заман сагышлардан
Азат дигән ялган тавышларны.

Җиргә кара — анда күпме кабер,
Сугышлардан калган шешләр кебек.
Кемдер яный, әнә, кешелеккә —
Ракетлары азау тешләр кебек.

Тыныч яши алмый әле дөнья,
Һаман әле җирдә сугышлар бар.
Бушап калма, күңел, гел уяу бул,
Сугышлар бар җирдә сагышлар бар.

## Сызыклы уен

Тротуарда титак-титак килеп
Уйнап йөри кызлар сызыклы.
Шакмаклардан тышка басмый аяк,
Шуның белән уен кызыклы.

Бер уйласаң сәер дә соң: адәм,
Шушы яшьтән, көчләп үз-үзен,
Вак шакмаклар белән чикләп куя
Яшәешен, уенын һәм сүзен.

Ә кемгәдер бу бер гадәт булып
Сеңеп кала. Гомере — бер ызан.
Аякларым чыкмасын дип яши
Кемдер сызып куйган сызыктан.

Титак-титак атлап бара шулай,
Куркып карый уңга һәм сулга.
Көче җитми сызык-шакмакларны
Җимереп чыгар өчен зур юлга.

Шакмакларны, шартлы сызыкларны
Санламаучыларны күрсә ул,—
Яки тилергән дип карап кала,
Яки тып-тын гына өркә ул.

Кызлар уенын туктап карап тордым,
Бер елмаеп һәм бер көрсенеп.
Уйнасыннар кызлар. Бу уенга
Кушыла күрмәсен тик Кешелек.

## Кабарган болытлар

Кабарган болытлар кар алып килделәр,
Ак карлар кап-кара кырларны күмделәр.
Күрмәде димәгез, болытлар кырларда
Күпме моң-зар булса, барын да күрделәр.

Болытлар күрделәр — басулар бушаган.
Яланда, кырларда шау-шулар туктаган.
Борынгы җанварлар шикелле бөкрәеп
Кара җир өстендә эскертләр йоклаган.

Камылга тырналып комбайннар чапмый,
Кырда түгәрәк алтын көшелләр ятмый.
Су буендагы туплауга кырын төшеп
Җор телле көтүче тәмәкесен тартмый.

Кырлар һәм яланнар гүяки үлделәр.
Тик моны кабарган болытлар күрделәр.
Болытлар ашыгып кар алып килделәр,
Тирә-юньне ап-ак яктыга күмделәр.

Илдар Низамов

# УЛ КАБЫЗГАН МАЯКЛАР

КИТАПТАН ӨЗЕКЛӘР

Тыныч суда ерылып кала
Пароходның эзләре.
Безнең өчен маяк булыр
Ленин бабай сүзләре.

*Татар халык җыры*

## Пароход кузгалыр алдыннан



Владимир Ильич Ленинның Кремльдәге эш бүлмәсенә экскурсиягә килдек. Ленин эшләгән урын! Бөтен дөньяга мәгълүм әсәрләр язган, партиянең, хөкүмәтнең иң мөһим документларына кул куйган гап-гади каләм, менә-менә шалтырар кебек тоелган телефон, шүрлек-шүрлек китаплар, стенада берничә карта. Мин шуларның кергәч тә сул яктагысы янына ук туры килгән идем, карадым да шуңа текәлеп калдым. Менә кушылдыклары Кама, Ока, Вятка, Агыйдел белән мәһабәт имәндәй тармакланган Идел. Менә Казан. Күңел дигәнең шундый бит инде ул! Карта-фәләнгә күзең төшсә, район үзәгенә генә чыккан булсаң да, иң башта үз авылыңны эзлисең; ераккарак китсәң — Казанны, Татарстанны; ә чит илләрдә йөрсәң, әлбәттә, иң әүвәл «СССР» дигән сүзне табып аласың.

Владимир Ильич карта янына еш килә торган булган. Башка төбәкләрне карарга килгәндә дә ул Идел буйларына — туган-үскән якларына да бер күз салмый калмагандыр. Яраткан бит ул Иделне! Без дә Иделдән. Безгә дә Идел ана дигән эпитет өстәп әйтерлек изге, кадерле. Иделдән булуыбызга, Владимир Ильичның безнең иделдәш, якташ булуына без чиксез горурбыз. Шул хистән менә монда да күңел янә мөлдерәмә тулып бара. Әйе, яраткан Ильич Иделне! Бервакыт шулай, чит илдә яшәгәндә күңелендә җыелып торган бөтен ярату ул бер тын белән: «Ничек сагындым мин Иделне!» дип әйтеп салган. Болай дип ул соңыннан да, шушы карта янында да эченнән генә булса да әйткәләгәндер. Шундый мәлдә аның күз алдына тагын бер тапкыр 1900 елның җылы июне, әнисе һәм апасы белән Идел ярында басып торулары, пароходка утырып китүләре, аннан бер атна буе Идел, Кама, Агый-

дел буйлап сәяхәт итүләре килеп баскандыр. Бик истәлекле, сагынып сөйләрлек сәяхәт булган ул аларга, Владимир Ильич аны торып-торып исенә төшергән. Тагын шунысы да бар: бу — Ленинның Идел буйлап соңгы сәяхәте булган, бүтәнчә аңа Идел буйларына кайтырга туры килмәгән. Ә картага карап ул әле бу юлны күңеленнән тагын ничә тапкырлар үткәндер. Сагынган бит ул Иделне!

Бу картаны Владимир Ильич соңгы мәртәбә 1923 елның 18 октябрендә күрә. Шактый җылы, җилсез бер көн була ул. Авыруы бераз басылып, кәефе күтәрелеп киткән Ильич, ниһаять, түзә алмый, Горкидан Мәскәүгә барып кайтырга хәл кыла. Автомашинада башкала урамнары буйлап үтә, Кремльдә, квартирасында була, китапханәсеннән китаплар сайлап ала. Менә эш бүлмәсенә керә, андагы әйберләргә күз салып, берничә минут тын тора. Чыгып барышлый карашы картадан, Идел өсләреннән сирпелеп үтә.

Шул көннән соң да инде алтмыш ел чамасы гомер узып киткән. Искерде, бик нык искерде хәзер бу карта. Әлеге маршрутка — Идел, Кама, Агыйдел буйларына гына да күпме яңалык өстәргә кирәк: порт-пристаньнар, электр станцияләре, тимер һәм шоссе юллар, бөтен бер шәһәр, поселоклар. Елгаларның үзләрен дә нәзек җепләрдән киң тасмалар итеп үзгәртеп сызарга кирәк.

...Экскурсиягә бирелгән вакыт бетеп, мин Ленинның эш өстәлендә яткан тагын бер карта — Татарстан картасы турында сораша алмадым. Шулай итеп, бирегә тагын бер килеп чыгарга туры килде. Ильичның күңелендә якты истәлек булып уелып калган Нижний Новгород — Уфа сәяхәте эзеннән, ниһаять, юлга кузгалырга вакыт җиткән икән дигән тәвәккәллек алып чыктым.

## Очкынга таба

Ульяновлар Нижний Новгород пристаненнан да кузгалып киттеләр. Пароход дебаркадердан аерылып, аз гына үргә күтәрелде дә агым җаена борыла башлады. Каршыда чиксез киңлек ачыла барды. Бу яз, унтугызынчы гасырның соңгы язы, бик мул сулы. Иделнең нәкъ ташыган көннәре. Болын ягы — диңгез. Пристаньга төшкәндә биектән, тау башыннан караганда еракта-еракта шәмәхә урманнар төсмерләнә иде әле, төшә торгач акрынлап югалдылар, ә пароходтан инде эзләре дә калмады, анда су сахрасы, караш җитмәслек киңлек кенә.

Нинди олы син, Идел! Рәсәйнең үзе кебек үк колачлап бетерә алмаслык син, гайрәт-кодрәтең дә халыкныкы кебек үк төпсез, төкәнмәслек синең!

Алар икенче як палубага күчтеләр. Пристань инде шактый ерагайса да, озата калучыларны әле танырга була иде: әнә Софья Павловна белән Сергей Павлович Шестерниннар кул болгый, башкаларның да яулык, эшләпәләре чайкала. Ульяновлар да озак кына кул болгадылар. Аннары Владимир Ильич кулын җәһәт кенә пинжәк эченә батырды да, канәгать бер кыяфәттә әнисе белән апасына борылып:

— Әнкәйгә бик зур рәхмәт, — диде.

Ул әнисенә бер күз төшерүгә, аның бераз боегып-моңсуланып калганын абайлаган иде һәм моның нидән икәнлеген шунда ук аңлап та алды. Нижний — әнисенең кадерле шәһәре. Әтиләре белән алар гаилә тормышын шушында башлап җибәргән. Кокушкинода туй ясаганнар да Илья Николаевичның яңа эш урынына күчеп килгәннәр. Беренче балалары Анна белән Александр шушында туган. Биш ел буена бергә-бергә матур, тату яшәгән җирдә сагынып искә төшерерлек хатирәләр аз калмагандыр, инде хәзер, Илья Николаевич булмагач, алар аны юксынырга, моңсуланырга бер сәбәптер.

Мария Александровна Володяның карашын шунда ук тоеп алды. «Рәхмәт төшкере, бигрәк сизгер инде бу балакай. Ә нигә әле боегырга, бар да әйбәт ләбаса».

Ананың да йөзендә елмаю чагылып китте.

— Миңа түгел, үзегезгә рәхмәт, балалар. Ичмасам, бер ял итеп алырсыз, Идел һавасы сезгә һәрчак килешә иде. Наденька да сөенеп бетә алмас.

Владимир аңа рәхмәтне шушы минутта күңелен күрергә дип кенә әйтмәде, бу ничә көннән бирле тулып килгән зур хиснең ихластан чайкалып китүе иде. Хәзер

аның бөтен борчуы, чит илгә китеп, тизрәк газета чыгара башлау. «Искра!» Менә нәрсә хәзер аның маягы, менә нәрсә белән сулый аның бөтен күзәнәкләре. «Искра» — ул Россиядә марксизм реаль хәрәкәткә әверeләчәк дигән сүз. «Искра» — ул өр-яңадан барлыкка килеп, өр-яңача яши башлаячак партия дигән сүз. Газетаның беренче саны инде күз алдыннан да китми, хыялда күптән ясалган, аңа дигән сүзләр, җөмләләр күптән әзер. Партия оешып, мәһабәт корылмага әверелсен өчен аңа таянып-таянып үсәргә терәк-басма кирәк. «Искра» нәкъ шундый басма булачак!

Әнисе шушы сәяхәтне оештыра алды бит! Февраль башында Себер сөргененнән кайтышлый Надежда Константиновнаны Уфада калдырганнан бирле Владимир Ильич аның янына ничек тә барып кайтырга ният тотып йөрде. Рөхсәт юллап карады. Бирмәделәр. Шунда Мария Александровна Петербургка департаментка үзе китте. И-и-и ана күңеле, ана йөрәге! Синнән дә тәвәккәл, синнән дә кыю бу дөньяда тагын ни бар! Ульяновның үзенең үтенечен кире каккан һәм кайчан гына әле ананың үзенә дә: «Балаларыгыз белән горурлана аласыз, берсен асып үтердек, икенчесен дә бау зарыгып көтә», — дигән «ата жандарм» Зволянский янына тагын барырга синнән башка кемнең кодрәте җитсен! Мария Александровна Уфага улы белән бергә барачагын ышандыра, шулай итеп, рөхсәт алуга ирешә.

Россиядән «туендырып» торучы хәбәрчеләре төрле-төрле урыннардан, эшле булганда гына «Искра» колачын киң җәя алачак, сүзе тәэсирле булачак. Бу сәяхәт вакытында да яңадан-яңа агентлар табуга өмет ителә. Нижнийда ул өмет матур гына акланды да инде.

Владимир Ильич әнисен култыклап алды. Бу минутта ул бөтен рәхмәт хисен тик шулай гына белдерә ала иде.

— Сиңа каютага кереп, бераз ял итеп алырга иде, әни.

— Әйе шул. Сез дә озак юанмагыз, балалар, бәхәсләрегезне дә бу юлга калдырып торыгыз, кайчан әлегер тагын мондый ял.

Ананың үз борчуы. Атна-ун көн генә булса да балаларын тынычлап ял иттерәсе килә. Югыйсә, Володяның сөргеннән кайтканнан бирле ал-ял күргәне юк.

Мәскәүгә ул полициядән качып кына тукталган иде. Туганнары белән туйганчы сөйләшергә, ял итәргә чират тимәде — берничә көн вакыты бик кирәкле очрашу, сөйләшүләргә, китаплар табып укуга китте.

Сөргеннән соң аңа Петербургта, Мәскәү һәм, гомумән, эшче халык белән аралашырга мөмкин булган шәһәрләрнең барысында да диярлек яшәү тыелган иде. Хет кире Себергә кит! Петербургка якын берденбер шәһәр Псков калган иде. Владимир Ильич шунда урнашты. Биредә үткәргән берничә айда ул ялның нәрсә икәнен дә белмәде — баштанаяк «Искра» мәшәкатьләренә чумды, чит илгә чыгар өчен паспорт хәстәрләп йөрде.

Паспорт, ниһаять, кулда. Тик Владимир Ильич, «Искра»ның уңышлы чыга башлавына тәмам ышанмый торып, читкә кабаланмады. Менә ул яшерен генә Петербургка бара. Менә ул, «туганнары янына кунакка» дип, Подольскига килә. Һәркайда ышанычлы кешеләр белән газета өчен акча табу, аның белән аралашып тору, аны тарату турында җентекле сөйләшүләр.

Һәм менә Уфага, Надя янына бару да уңай хәл ителде. Маршрутны Владимир Ильич төпле уйлап төзи — ышанычлы кешеләр белән мөмкин кадәр күбрәк очрашып сөйләшергә. Ләкин үтә дә сак булырга, полиция козгыннарының күзе төшәрлек бер генә «гөнаһ» та кылмаска, читкә китүне, димәк, «Искра»ның язмышын кыл өстенә куймаска.

...Юлга алар Подольскидан кузгалдылар. Владимир Ильич, анда бер атна элек килеп, шул тирәдәге шәһәрләрдән дә дусларын чакыртып, байтак эш эшләп ала.

Анна Ильинична ул көннәрне үзенең истәлекләрендә телгә ала: «... Чакырылып килгән һәр кеше белән Владимир Ильич шифр мәсьәләсендә килеште, озакламый чыгачак гомумрус газетасына корреспонденцияләрне бик дөрес җибәрергә кирәклеген төшендерде. Газета хакында ул аеруча якын кешеләр белән генә сөйләште...».

...Алда — Нижний Новгород. Бирегә Владимир Ильич, сөргеннән кайткач, бер

килеп киткән иде. Ул чагында әле монда да, башка шәһәрләрдәге кебек, «экономизм» бизгәге тотучылар шактый була. Владимир Ильич шуларның берсе — Александр Иванович Пискунов белән очраша.

Әлбәттә ки, очрашкан минутларында әңгәмә майлаган кебек агып китми, чөнки Пискуновның «экономистларга» таба авышканлыгы беленә, бирєдәге башка социал-демократларның да әле һаман кустарьчылыктан котыла алмаулары, «экономистлар» җырына кушылганлыклары ачыклана.

Акыл сату, өстән торып үгет-нәсихәт бирү—Ленинга, гомумән, ят нәрсә. Аның кыйбласы — телдән булсын, язмача булсын — бәхәс, полемика. Пискуновны да ул, ничек итсә итә, бәхәскә тарта һәм шунда инде ышандырырлык дәлилләрен чын күңелдән кайнарланып, үтемле сүзләр белән хаталарын төшендерә башлый. «Сәгать ярымлап гәпләшкәннән соң мин элекке позицияләремнән нык кына авышкан идем инде», — дип исенә төшерәчәк соңыннан А. И. Пискунов.

Бу юлы Александр Иванович Нижнийда юк иде, хатыны белән Уфага киткән. Әмма аңардан башка да сөйләшер кешеләр табылды. Шестерниннарга рәхмәт, полиция шымчылыгы астында була торып та, Владимир Ильичның гозерен үтәп, Нижнийга берничә көнгә алдан киттеләр, марксистларны җыелышка әзерли тордылар.

Софья — Нижний кызы. Петербургта укыганда социал-демократлар сафына баса. Сеңлесе Зинаида да аңарга иярә. Невзоровалар Владимир Ильич белән бергәләп «Көрәш союзы»н оештыралар, аның җитәкче группасына керәләр.

«Союз»ның көтмәгәндә фаҗигагә дучар булуы, сөрген, эзәрлекләүләр дә кызларны каушатмады, алар, киресенчә, бөтен гомерләрен революция эшенә багышларга хәл кылалар. Икесе дә революционерларга тормышка чыга — Зинаида ерак Себердә Глеб Максимилианович Кржижановскийга, ә Софья — Шестернинга. Хәзер менә ике гаилә, илнең ике почмагында, Ленинга ничек тә ярдәм итәргә тырыша, аның кебек үк, «Искра» дип янып яши.

Җыелыш 8 июньдә Невзоровалар квартирасында булды. Кеше күп түгел иде, унлап кына. Әмма барысы да сыналган, ышанычлы марксистлар. Софья Павловна Владимир Ильичны, Анна Ильиничнаны моңарчы таныш булмаганнар белән таныштырды. А. Ф. Войткевич, В. А. Десницкий, О. П. Иванецкая... Эшчеләр дә килгән — Г. И. Гаринов, М. И. Самылин. Владимир Ильич Ванеевның кулын аеруча якын итеп, нык итеп кысты. Аның туганы — Анатолий Александрович «Көрәш союзы» буенча дусты, фикердәше иде. Ванеев Россиядә беренче марксистлардан. Белемле, нык ихтыярлы иде. Тик сөргеннән әйләнеп кайта алмады, Ермаков авылында вафат булып калды. Аның юлын менә туганы дәвам итә. Бик тә мөһим, бик тә яхшы эш бит бу! Юк инде, падишаһ, бернинди богаулар белән дә кул-аякны бәйли алмассың син безнең!

Ленин хис белән, кайнарлык белән Россиядә марксизмга ничек җан өрергә, аны хәрәкәткә китерергә икәнен сөйли башлады. Гомумроссия газетасын әлегә бары чит илдә генә чыгарырга мөмкин икәнен, ә моның өчен һәр марксисттан күп тырышлык, көч, тәвәккәллек таләп ителүен төшендерде. Җыелыштан соң ул Анна Ильинична белән һәр иптәшкә диярлек киңәш бирде: хәбәрләрне ничек язарга, нинди шифр белән яшерергә, кем аркылы, нинди адреска җибәрергә...

...Мария Александровнаны каютага озаткач, алар бер-берсенә елышты.

— Вәгъдәләшкән иптәшләрнең берничәсе генә чын агент булып китсә дә бик яхшы инде, Анюта! Шәһәр саен шулай булса, ә?! Нәкъ менә шуңа ирешергә тиешбез дә. Нижний инде артта калды, Анюта, бик армаган булсаң, алдагы пункт турында сөйләшик. Алда бит — Казан...

## Казанга тартылу

Казанга җитәрәк Идел өсте җанлана. Бу Вязовойдан ук башлана. Чуен юлдан төшкән пассажирларны, йөкләрне теге ярга парөм-баржалар, көймәләрдә чыгаралар.

Владимир Ильич китаптан карашын алмыйча гына уйлана: Идел аша күпер ки-

рәклеге ничә еллар инде сөйләнелә, тик патша хөкүмәте сүз боткасы пешерүдән ары китә алмый. Табигый хәл, яр буе җирләре дә, материал, заводлар да аерым хуҗалар кулында, килештереп кара аларны, күпер кемгә файдага, ә кемгә зыянга. Әлбәттә ки, капитализм Россиядә дә кара канатын җәя бара, аңа күперләр кирәк; озакламас, хуҗаларны ул килештерер, күпер салыныр. Әлбәттә ки, хезмәт иясе җилкәсендә, аның каны, тире белән салыныр. Ә халыкның үзенә власть бирсәң, нинди генә күперләр корып куймас иде ул.

Владимир Ильич дикъкатен янә китапка текәгән иде дә, тагын бүленде, апасының якынаюын тоеп алды. Ул китабын ябып куйды.

— Карале, Володя, ничек түзеп утырасың, Казанга җитәбез ич инде.

Алар палубаның борынына таба киттеләр. Анна Ильинична аны култыклап алды.

— Хәтерлисеңме, Казанга җитәрәк нинди ыгы-зыгы куптара идек. Барыбыз бергә, ничек күңелле була торган иде. Безнең базардан, балалар тавышыннан бөтен пароход ду килеп торыр иде. Әйдә әле, чыннан да, бер ду кубып алыйк әле!

Алар дөрестән дә күңелле итеп — әүвәлге җыенуларны, шуларга бәйле төрле хәлләрне искә төшерә-төшерә әле көлешеп, әле бер тынга моңсуланып, аннан янә җанланып китеп, ашыкмый гына җыендылар. Алар гаиләсенә Казан, Кокушкино кебек хатирәләргә аеруча бай тагын бер урын бармы икән? Мария Александровнаның яшьлек еллары шунда үткән, Илья Николаевичның — гимназия, университет еллары. Ел саен диярлек бөтен гаиләләре, туганнары белән шушында җыелганнар. Күпме кадерле истәлек монда!

— Гомер уза шул, — дип сузды Мария Александровна, — кайчан гына Казанга барыбыз бергә килеп төшә идек. Илья Николаевич та балалардан ким сөенмәс иде. Сашенька ничек ярата иде Кокушкино болыннарын, Оленьканы әйтәсе дә юк. Бер җыелып алырга килешсәк тә, өч кадерле кешебез җитмәс...

— Тагын кайберәүләр җитмәс иде, — дип көлде Владимир Ильич, — исәннәргә дә бик кочак җәеп тормыйлар анда.

Кинаясен аңладылар: Анна Ильинична, бармагын авызына куеп, шым булырга кушты. Баядан бирле инде ул тәрәзәдән өстәлгә төшкән эшләпә күләгәсенә игътибар итеп утыра иде. Владимир Ильич та шәйләгән булган икән:

— Чабаксардан тагылды шикелле, сизгәнне үзенә белгертмәскә кирәк, — дип пышылдады да элекке тавышы белән: — Ә бит көймәгә — рукоходка барыбер барыбыз да сыймас идек, ә барыбыз да утырмагач, ни кызыгы бар аның, — дип көлде.

Казанга әле шактый бар иде. Палубага чыктылар. Владимир Ильич янә шпикны уйлады. Анна Ильинична белән киңәшләшеп алдылар. Үзе генә йөри икән, Казанда ничек тә юлдан яздырырга, әгәр инде пристаньга өстәмә көч чакырткан булса, иткәне җыеп кына йөрергә, жандармерияне котыртмаска тырышырга карар иттеләр.

Казан ярларына карап, Владимир Ильич Федосеевны хәтеренә алды. Хәзер ул Казан дигәндә гел искә төшә. Язмышы фаҗигале булганга шулай микән? Ул Казанда Федосеев оештырган түгәрәкләрнең берсенә йөргән иде. Николай Евграфовичның абруе көчле булды, бөтен Идел буе аны ишетеп белә иде. Володя да аңа тартылды. Хат алыштылар. Владимир шәһәренә аны күрергә тәрмәгә дә барды, ләкин очраша алмадылар. Соңыннан аларны берүк вакытта диярлек сөргенгә сөрделәр. Ләкин төрле урыннарга. Федосеев шунда һәлак булды.

Әнә Казан — еракта, яр өстендә завод морҗалары, эреле-ваклы чиркәү, мәчет башлары, ә якында дебаркадерлар, пристань складлары күренә башлады.

## Кызыл күпер

...Иделнең тимер юл күперенә җиттек. «Волгарь-доброволец» моңсу да, тантаналы да итеп сузып кычкыртты. Гудок тавышы корыч челтәрләргә уралып көчәякөчәя яңгырый да, ярларга китеп, еракларда эри. Легендар кораб кызыл флотчыларның үлмәс батырлыклары сакланган истәлекле урыннарны гел шулай хөрмәтләп сәламләп уза.

Күпер дә шундый тарихи урын.

Ул 1913 елда салынып бетә. Романовлар нәселе патшалыгының 300 еллыгы хөрмәтенә диген булып, аңа Романов исеме бирәләр. Ачылу тантанасына патша Николайны да көтәләр. Килми. Халык нәфрәтеннән курыккандыр. Канлы Николай кушаматын йөрт тә ничек курыкмыйсың!

Владимир Ильич бу күперне күреп белмәгән.

Әмма Петроградтан, Мәскәүдән Казанга җаваплы бурычлар йөкләп дусларын озатканда яисә сугышчан операцияләр әзерләгәндә уенда ул бу юлдан, бу күпердән ничә мәртәбәләр үтмәгәндер.

1917 елның Февраль революциясеннән соң, социалистик революциягә курс билгеләгәч, Владимир Ильич Казанга үзенең иң якын көрәштәшләреннән берсе — Виктор Александрович Тихомирновны җибәрә. Тихомирнов Казанда большевикларны туплый, комитетның эшен җайга сала, «Рабочий» газетасын чыгара башлый. Урындагы Мулланур Вахитов кебек милли революционерларны дәртләндереп, аларга колач җәяргә булыша. Петроградта Бөек Октябрь революциясе җиңгәннең икенче көнендә үк, 26 октябрьда Казанда да коралды восстание җиңүле тәгәлләнә.

Идел күпереннән дә ике башлы сәмруг кош сурәте мәтәлеп төшә, халык аны Кызыл күпер дип атый башлый. Чөнки озак та үтми, күперне кызыл кан түгеп, я үлем, я җиңү дип якларга туры килә. Дәһшәтле унсигезенченең җәендә бөтен Идел буе аяусыз көрәш мәйданына әверелә. Антанта штыклары Казанга төбәлгән. Көнчыгыш фронт буенча гадәттән тыш комиссия булдырылды, аның председателе итеп карт большевик Мартын Иванович Лацисны Казанга озатканда аның белән Владимир Ильич үзе сөйләште. 14 июньдә үк әле хезмәт ияләре мөселманнарга Ленин һәм Вахитов кул куйган мөрәҗәгать игълан ителде. Андагы: Эшче һәм ярлы крестьян властен яклар өчен Россиянең барлык якларыннан җиңүле революцион мөселман солдатлары ут ташкыны булып күтәрелсен, һәм без ышанабыз, ихластан ышанабыз: үзенең бөек язмышына таба уянган мөселман пролетариаты революцион хәрәкәт тарихына данлы батыр сәхифәләр өстәр... дигән ялкынлы сүзләр меңнәрчә татар, башкорт егетләрен канатландырып җибәрде, көрәшчеләр сафына әйдәде.

Мөрәҗәгать «Правда» газетасында басылган көнне Мулланур Вахитов үзе дә Владимир Ильич кул куйган мандат белән Идел буйларына, ут сызыгына җыена. Үзе язган, үзе кул куйган чакыруына Мулланур бүтәнчә җавап бирә аламы соң!

Ленин инициативасы белән 24 июньдә хәрби моряк Николай Маркин Иделдә флотилия оештыру комиссары итеп билгеләнә.

Эсер Муравьевның сатылуы, троцкийчыларның адым саен көпчәккә таяк тыгулары, контрреволюцион офицерларның иң хәлиткеч минутларда шәһәр саклаучыларның аркасына атуы нәтиҗәсендә Казан бирелергә мәҗбүр була. Күзен кан баскан акларның нәфсесе үсеп китә, алар күпергә — Кызыл күпергә ыргыла. Аны кулга төшерү ул — тимер юл буйлап Мәскәүгә, елга буйлап Нижнийга туры юл дигән сүз.

Кызыл күперне бирмәскә! Ленин күрсәтмәсе! белән Свияжскига бер-бер артлы килеп төшкән яңа частьлар, эшче отрядлары, агитаторлар шулай дип ант итәләр. Көрәшчеләр сафына Владимир Ильич белән авыр елларда бергә чыныккан, бергә сыналган большевиклар баса. Иван Дмитриевич Чугурин. 1902 елдан большевик. 1917 елның апрелендә Иван Дмитриевич Ленинны чит илдән каршы алырга килә. Выборг район партия оешмасы исеменнән аны котлый һәм 600 нче номерлы партбилет тапшыра. Октябрь көннәрендә ул — Кышкы сарайны штурмлаучылар сафында.

5 нче армиянең оешып килгән чагы. Чугурин аның политбүлеге мөдире итеп, ярдәмчесе Каюров крестьян секциясе мөдирә итеп билгеләнә. Бөтен көч Казанны азат итүгә әзерлеккә юнәлтелә.

Аклар күперне саклаучыларга кабат-кабат ташланып карыйлар, ләкин безнекеләр Идел ярына тамырны тирән җибәреп өлгерә.

Тик шул көннәрнең берсендә коточкыч хәбәр барысын да тетрәтеп җибәрә: Ленинга атканнар!

Кыска-кыска митингларда яңгыраган кискен, кайнар антлар, мылтык түтәсенә, туп көпшәсенә куеп язылган ихлас хатлар: «Без синең өчен дошманнан үч алабыз. Ленин, тизрәк терел генә. Син безнең беләнl»

Чугурин белән Каюров та Владимир Ильичка телеграмма сугалар: «Сәламәтләнегез. Без 5 нче армиянең политик бүлегенә җитәкчелекне үз кулыбызга алдык. Мәгълүматларны Казаннан җибәрербез». Җавап та килә: «Рәхмәт. Сәламәтлегем бик тиз яхшыра. Ышанам: Казанда чехларны һәм акгвардиячеләрне, бер уңайдан аларга булышучы канэчкеч кулакларны бастыру үрнәк төстә, рәхимсез булыр. Кайнар сәламнәр. Ленин».

10 августта Владимир Ильич М. Д. Бонч-Бруевичка Көнчыгыш фронтны бөтен яклап көчәйтергә кирәк дип санавын, Югары Хәрби Советка Көнбатыш фронттан иң күп санда частьлар күчерү планын эшләргә тәкъдим итүен, бу планны иң кыска срокта үткәрергә кирәклеген, сугышка сәләтле барлык частьлар китәргә тиешлеген әйтеп, яшерен язу җибәрә.

Казан юнәлешендәге һәр яңалыкны Ленин белеп тора, бер генә батырлык үрнәге дә аның игътибарыннан читтә калмый.

12 августка каршы төндә дошман белән сугыш вакытында чехословак фронтында революцион гаскәрләрнең группа командующие иптәш Юдин батырларча һәлак булды. Аның данлы истәлеген мәңгеләштерү максатында Халык Комиссарлары Советы Красная Горка тимер юл станциясен «Юдино» станциясе дип үзгәртергә карар бирә, карарга Ленин үзе кул куя.

Ул арада В. И. Ленин, совнарком Иделдә чын хәрби флотилия булдыру чарасына керешәләр. Большевик Николай Маркин юлбашчының ышанычын аклап, көчле флот булдырыр өчен барысын да эшли — Нижний Новгородта революцион моряклар отряды туплана, коралландырырга мөмкин булган пароходлар табылып, аларны Нижний Новгород, Паратск завод-затоннарында ремонтлау, коралландыру оештырыла.

В. И. Ленин күрсәтмәсе белән Иделгә Кара диңгездән, Балтикадан эшелон-эшелон моряклар күчерелә. Шулай ук катерлар, хәтта миноносецлар да күчерергә хәл ителә. Тиешле судноларны тәгаенләү, аларны ремонтлап, корал һәм экипаж белән тулыландырып Иделгә озату Хәрби Диңгез Халык Комиссариаты коллегиясе члены С. Е. Сакска йөкләнә.

Ниһаять, миноносецлар да — «Ретивый», «Прыткий», «Прочный», «Порожающий» — ерак, моңарчы күрелмәгән походка әзер.

Иделгә Мариинск су системасы буйлап, ягъни Нева елгасыннан Онега, Ладога күлләрен, Вытегра, Свирь, Шексна елгаларын, Мариинск каналы шлюзларын, янә дә Ак күлне, тагын берничә елганы үтеп чыгарга тиеш булалар. 1100 километрга килеп баса.

«Хәрби суднолар Балтик флотыннан Иделгә һәм Каспийга чыгып киткәч, Ленин аларның хәрәкәте турында көн саен хәбәр бирүне таләп итте. Оператив бүлек аларның хәрәкәтен өзлексез күзәтеп торырга һәм килеп туган барлык кыенлыкларны аңа хәбәр итәргә бурычлы иде», — дип язды үзенең истәлекләрендә Хәрби Диңгез Халык Комиссариаты оператив бүлеге начальнигы С. И. Аралов.

Иделгә дивизион 22 августта чыга. Башта Рыбинскига туктый. Ләкин Владимир Ильич моряклары да, җирле властьларны да ашыктыра: «Туп, снаряд, күмер төяүне үтә тиз төгәлләп, һич тоткарлыксыз Нижнийга юнәлергә приказ бирәм. Бу эш иң кыска срокта үтәлергә тиеш», — диелә ул җибәргән телеграммада.

27 августта миноносецлар Казан янына Кызыл күпер төбенә төшеп җитә.

Дошманның көчен акрынлап сыгу, йомшарту максатында безнең флотилия көн саен аның флотилиясенә ташлана, батареяларының яшеренгән җирен ачыклап, аларны утка тота, коры җир гаскәрләре, авиация белән бергәләп, Казан тирәсендәге боҗраны кысканнан-кыса бара, аны хәлсезләндерә.

Аңа беренче булып көнчыгыштан һәм көньяктан 5 нче армия полклары белән Идел хәрби флотилиясе моряклары, ә төньяктан В. М. Азин отрядлары бәреп керде. 10 сентябрьдә, көндезге сәгать бердә Казан тәмам азат ителде...

Апасы, әнисе белән сөйләшеп утыру, Кама күренешләренә сокланып бару рәхәт булган кебек, Владимир Ильичка тынычлыкта җитди уйланулар, китап уку да ләззәт, канәгатьлек бирә. Кирәкле китапларны ул юлга да җитәрлек алган.

«...Ильич укып утырган китап битләренең бик тиз ачылып ябылуына ирексездән игътибар иттем: мин үз китабымдагы биш-алты юлны да укып чыгарга өлгермим, янәшәдә, Ильич китабында, ул арада яңа бит ачыла. Ильич кулындагы ачык китапка карыйм: чит телдә язылган.

— Владимир Ильич, сез укыйсызмы, әллә карап кына утырасызмы?

— Әлбәттә, укыйм. Өстәвенә, зур дикъкать белән.

— Ә шулай тиз укырга мөмкинме соң?

Ильич елмайды:

— Сез хаклы, мин тиз укыйм. Шунсыз ярамый: миңа бик күп укып чыгарга кирәк. Миңа акрын укырга һич ярамый...»

Менә шулай язган үзенең истәлекләрендә революционерка О. Б. Лепешинская, Енисей буйлап пароходта Владимир Ильич белән баруын хәтерләп.

Ә бу юлы ул яр буйларыннан карашын аера алмыйча бара. Нинди генә матурлыклар юк синдә, Россия! Кара инде бу кыя-тауларны! Җылыга кинәнеп изрәп яталар. Ә тегендә әнә таулар елгадан шактый еракка чигенгәннәр, ике арада тип-тигез болын җәелеп киткән. Аңа әле чалгы тимәгән. Төсле келәм кебек төрле чәчәкләрдән чеп-чуар булып утыра. Ә исе соң!

«Надюша чәчәкләр ярата. Чабып бетермәсәләр, Уфага җитәрәк берәр пристань тирәсендә җыеп менәсе иде», дип уйлый Владимир Ильич. Ул тагын Надясы янына оча, аның белән серләшә. «Тиздән, инде бик тиздән без очрашырбыз!» ди ул эчке бер сөенеч белән, һәм ерактагы җете чәчәкләрне берәм-берәм күз алдына китерергә тырыша.

Ул арада болын инде артта да калган. Таулар тагын елга янына ук килеп җиткәннәр. Болары шәрә түгел, ап-ак каеннар, бөдрә юкәләр белән купшыланган, ә алдарак наратлар башлана. Шәмдәй төз, сап-сары наратлар. Борынга коры ылыс, сагыз исе бәрелгәндәй булып китә.

— Аня, кара әле нәрсә күренә теге нарат төбендә?

— Нәрсә?

Анна Ильинична җитди кыяфәттә наратларга төбәлә, ә Владимир Ильич елмаеп:

— Шуны да күрмисең, майлы гөмбә ич, кара әле, кара, ничек тезелешеп киткәннәр.

Аның шаяртуыннан Анна Ильиничнага да, Мария Александровнага да рәхәт, Володя гөмбә җыярга, гомумән, урманда йөрергә бик ярата шул.

«Бу сәяхәтне мин бик яхшы хәтерләп калганмын, — дип язды азактан Анна Ильинична. — Июнь ае иде, елганың җәелгән чагы, шуңа күрә Идел буйлап, аннары — Кама һәм, ниһаять, Агыйдел буйлап пароходта бару гаҗәп әйбәт булды. Бөтен көннәрне палубада үткәрдек. Володяның кәефе бик күтәренке иде, ул елгадан һәм тирә-як урманнардан бөркелгән искиткеч һаваны ләззәтләнеп сулады. Кама һәм Агыйдел буйлап барган кечкенә пароходның өске буш палубасында төнгә кадәр сузылган озын әңгәмәләребезне хәтерлим, әни, арып, каютага төшеп китә. Сирәкмирәк пассажирлар аннан да элегрәк юк булалар. Палуба безнең икебезгә генә кала һәм тынган елга, йокыга талган ярлар арасында яшерен сөйләшүләр алып бару бик уңай иде. Владимир Ильич үзенең гомумрус газетасы планын миңа җентекләп, рухланып сөйләде. Газета партияне кору өчен төзелеш басмалары ролен уйнарга тиеш иде... Без аның белән «Кредо» һәм «Антикредо» турында да — ул чактагы барлык җитди мәсьәләләр турында сөйләштек. Володя көр кәефле, үзенә тартып торучан иде, һәм аның белән үткән бу сәяхәт минем иң әйбәт хатирәләремнән берсе булып калды».

Палубаны дөңгердәтеп матрос йөгерә иде, Владимир Ильич аның артыннан:

— Кайсы пристань була, милостивый? — дип калды.

— Әҗәкүл.

— Ә алдагысы, ялгышмасам, Груздевка.

— Я хәтер үзеңдә, расписаниегә бер генә тапкыр күз салган идең түгелме соң? — диде Анна Ильинична.

— Ә мин моннан ничәнче кабат узам инде, хәтерләрсең, шәт, — дип көлде Владимир Ильич.

— Әни дим, карале моны, Уфага якынайган саен җиңеләя инде әллә, Агыйдел буйлап та үткәне бар икән бу мактанчыкның...

— Хыялда дим бит мин. Сергендә чагында Надяны кая җибәрерләр икән дип, без карта буйлап Уфа губернасында бик еш «сәяхәт итә» торган идек. Миңа бу төрләрдә инде чыннан да булганмындыр кебек тоела.

Пароходка пристаньдә дүрт-биш мужик керде. Боцман аларга яман җикеренә башлады. Владимир Ильич түзмәде, аска төшеп, «тамашага» колак салды. Мужикларның чабаталары лычма пычрак, трапны да, палубаны да буяп бетергәннәр.

— Ярар инде, тышта чиләкләп койгач, нишләсеннәр,— диде теге матрос, — үзем ышкырмын.

Ул мужикларга күзе белән генә койрык якка ишарәләде дә швабра алырга ашыкты. Тегеләр буш биштәрләрен кулларына алып, аяк очларына гына баса-баса койрыкка элдерттеләр. Пароход кузгалып китте. Эше беткәч матрос алар янына килде. Авылдашлары, күрәсең, хәл-әхвәл сорашты.

— Груздев ике баржа икмәк озатасы ди, шуны төяргә кеше яллый ди, хет вэрак ипекәй бирмәсме дип кузгалу иде, бигрәк бер тәгам калмады, яңасы өлгергәнче әле...

— Сине, Исрафил, сырхаулаган дигәннәрие түгелме?

— Ипи исе чыкса, аякланырсың, шәт, биш авыз кәтеп утыра анда.

— Ә Груздевныкы бар, — дип сүз кыстыра машина бүлегеннән тын алырга чыккан кочегар карт.

— Бар, билгеле, бездән җыя да, менә хакы күтәрелгәч, озата башлый, Үзебезгә дә сатмый әле, ераккарак, тагын да кыйбатрак җирләргә җибәрә.

Ульяновлар кичә генә Алабуга өязен үттеләр, бүген менә Минзәлә өязе. Һәркайда шушындый хәл. Ә бит кешеләр бирердә иген игеп көн күрә, авызлары исә ипигә дә туймый. Ярлы-ябагай, кысыр басудагы алабута кебек, елдан-ел арта. Алар җилкәсендә алпавытлар, авыл буржуазиясе симерә бара. «Россиядә капитализмның үсеше» дигән китабында Ленин моңа мисалны — ялланып эшләүчеләр турындагы таблицаны шушы яклардан — Алабуга өязеннән китерде. Күпме хезмәт ясә монда үзе икмәк — байлык үстереп тә юньле тормыш күрми. Ә аларны чын-чыннан аңлы көрәшкә күтәрү өчен, эшчеләргә ярту өчен күпме эшлисе бар әле.

Аскы палубадан ул шактый дулкынланып менде. Анна Ильинична аның карашыннан ук сизенә: пароход аңа бик акрын бара кебек, алда күренгән сары комлыкларны, яшел болыннарны ул сулышы белән тартып якынайтыр иде. Шушы икеөч көн тыныч ял да аны ялыктыра башлады инде.

Шул ук вакытта Владимир Ильичка болай ашкынуы — тизрәк Уфага барып җитеп, тизрәк чит илгә чыгып китәргә кабалануы менә шушы мужиклар алдында уңайсыз да кебек. Бераз сүзсез баргач, ул, Анна Ильиничнага якыная төшеп, кызукызу сөйләп китте:

— «Искра»ның чит илдә чыгуы, партия съездының читтә чакырылуы Россия социал-демократларына, эшчеләргә, менә шушы гади халыкка ничек тәэсир итәр, Анюта?

Һәм шундук ул, апасының бүлдерүеннән курыккандай, тагын да ашыгыбрак сөйли башлады, бу адымның бердәнбер икәнен аңлатырга керешә:

— Өзлексез проваллар Россиядә съездлар җыю мөмкинлеген тәмам бетерәләр. Мисаллар бит баштан ашкан, үзең беләсең: Екатеринославта «Южный рабочий» ниш-

тәде, тамырын ук актарып ташлый яздылар. Гомумән, көньякта берничә оешма таркатылды инде. Болар бит съездга әзерлек алып барганда гына бирелгән корбаннар, ә съездның үзен җыя башласаң... Юк, юк, аны Россиядә җыю — акылсызлык! Ә «экономизм» кебек юнәлешләр белән көрәшер өчен, батенька, вакыт шактый күп кирәк булачак, бу эшне тик чит илдә чыга торган орган гына уңышлы башкара алачак, партияне үз тирәсенә туплау аның гына кулыннан киләчәк.

Ашыктыра, чыннан да ашыктыра иде бу кеше пароходны, бу ярларның артта калуын тели иде. Ачуланмагыз аңа, ярлар, үпкәләмәгез, хәерче мужиклар! Озак та үтмәс, «Искра» булып, партия һәм революция булып, бәхет булып кире кайтачак ул сезгә, мәңге китмәскә кайтачак.

## Икмәк юлы

«Мулланур Вахитов» безне Дербешкада, Агыйдел тамагында төшереп калдырды. Диспетчер безгә ике-өч сәгатьтән «Иван Кадомцев» дигән теплоход киләсен әйтте. Шуны көтеп рейдны күзәтәбез, яр буйларында йөреп киләбез. Кай тараф китсәң дә, иген басуларына барып чыгасың, хәтта су өстендә дә икмәк исе — ашлык төягән баржалар.

Икмәкле яклар! Икмәк белән бу як крестьяны үзен дә сыйлы, мул тормышлы итте, ил табынына да өлеш чыгарып, хөрмәтле булды. Кайчан күргән ул мондый дәрәҗәне.

Бередән китеп, нәкъ бер ел үткәч, 1901 елның октябрендә Владимир Ильич Уфа губернасында, Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендә икмәк мәсьәләсендә хәл шәптән түгеллеген анализлап, хөкүмәтнең ачлыктан интеккән крестьяннарны икмәк белән тәэмин итүдәге ялган «ярдәмен» ачынып язды.

Бөек Октябрь крестьянга гомерлек хыялы — җир, ирек, тынычлык бирде. Бу турыдагы документларга кул куйган Ленин исеме аның йөрәгенә җылы нур булып төшеп ятты. Шуңа күрә дә дәһшәтле елларда крестьян Ленин ягына, Совет власте ягына басты, унсигезенче, унтугызынчы елларны Петроградта, Мәскәүдә, башка үзәк шәһәрләрдә ачлык башланып, хөкүмәт икмәк дип мөрәҗәгать иткәч, булганын үз авызыннан бүлеп, булмаганда кулактан тартып алып, аларга озатырга тырышты.

1919 ел. Интервентлар, ак гвардия илнең иң икмәкле районнарын басып алган. Үзәк ач. Зәһәр ачлык көннән-көн миһырбансызлана. Азык-төлек халык комиссары Цюрупа, ачлыктан шешенеп, Совнарком утырышында һуштан яза. Хөкүмәт членнары, шул җөмләдән Владимир Ильич та, кыйпылчык кына паекларын да Мәскәү балаларына бирдертә. Менә Ленин алдына бәрәңге ведомостен китереп салалар. Совнарком хезмәткәрләренә айга бирәр поттан. Ленин исемлектә беренче. Аның турысында — 2 пот. Владимир Ильич аны 1 потка төзәтә. Ә «Н. Крупская — 1 пот» дигәнне бөтенләй сызып ата, «Совнаркомда эшләми» дип язып куя.

Шушындый хәлдә дә Кызыл Армиянең Колчак ялуларын җиңә алуы чын фидакарьлек, тиңдәшсез батырлык иде. Кама, Агыйдел буйларындагы икмәкле җирләр карыш арты карыш азат ителә. Кызылармиячеләр, ак бандаларга ташланып, алар алып китәргә әзерләгән икмәк эшелоннарын, баржаларны, обозларны йолып калалар, дөрләп янган амбар, складларны үзләре яна-көя булса да коткаралар.

В. И. Ленин белән А. Д. Цюрупа 5 нче армия реввоенсоветына ашыгыч телеграмма суга: «Мәгълүматларга караганда, Агыйдел елгасы пристаньнарында колчакчылар тарафыннан файдаланылмаган һәм чигенгәндә калдырылган 2 миллион пот чамасы әзерләнгән икмәк бар... Аның күләмен телеграф аша азык-төлек халык комиссары Цюрупага хәбәр итәргә... Азык-төлек Халык Комиссариаты рөхсәтеннән башка икмәк тоту тыела. 1919 ел, 13 июнь.

Оборона Советы председателе Ленин

Наркомпрод Цюрупа».

Бу телеграмма нигезендә ашлыкны төгәл исәпкә алу, аны саклау, бик ашыгыч рәвештә елга юлларына, пристаньнарга ташыту чаралары күрелә. Озак та үтми, Ленин исеменә реввоенсовет җитәкчеләре Тухачевский белән Смирнов кул куйган телеграмма озатыла: Уфа губернасының Кама һәм Агыйдел буйлары территориясен азат иткәндә 5 нче армия... барлыгы 818153 пот икмәк тартып алды...

Су транспорты кыен хәлдә була. Аклар Кама флотын тәмам эштән чыгарганнар — пароход, баржалар ватылган-шартлатылган, батырылган. Исән-савына да, чигенгәндә Чусовойга кертеп тутырып, өсләренә керосин, мазут сибәләр дә ут төртәләр. Ярый әле, беразын безнең матрослар коткарып кала ала.

Агыйдел флоты да шул ук хәлдә. Колчак бандалары пароходларның машина-казан частьларын сүтеп, вагоннарга төяп алып киткәннәр, өлгермәгәннәрен ватканнар, җимергәннәр.

Менә шушындый хәлдә калган флотны аякка бастырып җибәрү үзе генә дә батырлык саналырга хаклы. Совнарком вәкил итеп җибәргән С. Ф. Авдеев, И. Т. Гаврилов, В. М. Зайцев һәм башка большевик елгачылар флотны тәртипкә китерү, аны икмәк ташуга җигү өчен көчләрен кызганмый эшлиләр.

Икмәкнең юлы авыр, ай бик авыр...

Күптән түгел Совет Армиясе Үзәк Дәүләт архивында 5 нче армия политбүлеге инспекторы Федор Павловка кагылган документларга юлыктым. Алар шул икмәк юлының нинди-нинди кыен булганлыгын тәфсилләп сөйләп бирделәр.

8 июньдә Федор Павловны бернечә кызылармеец һәм матрос белән Әҗәкүлгә ашыгыч командировкага җибәрәләр. Анда төяүле баржа булырга тиеш, шуның икмәген Петроградка илтеп җиткерергә!

Бөгелмәдән озак чакрымнар үтеп килеп җитсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, Колчак вәхшиләре онны, ярманы яндырып киткәннәр. Нәфрәттән, ачуыннан җаннары әрнегән кызылармеецлар, әлбәттә, тәртәне кире борырга уйламыйлар да. Җыелган икмәк тагын Дүртөйледә булырга тиешлеген белгәч, Федор, иптәшләре белән киңәшләшә дә, тиз генә шунда юл тоталар.

Чыннан да, Дүртөйледә 40 мең пот чамасы он һәм борчак туплый алалар. 27 нче дивизия җитәкчеләре булышлыгында баржа табыла, ашлык төялә. Менә көтелгән минут та җитә — «Токарь» пароходы аны буксирга алып, Агыйдел буйлап төшеп тә китәләр.

Ләкин шатлык кыска гомерле була — «Токарь» Идел хәрби флотилиясенең 3 нче дивизионы карамагында икән, аларны Агыйдел тамагында калдырып, хәрби флот штабына, Сарапулга китеп бара.

Егетләре белән Павлов алай сугылып карый, болай бәрелеп бага, тик юньлебашлы буксир таба алмыйлар. Шуннан ул, егетләренә баржаны күз карасы кебек сакларга кушып, Сарапулга юл тота. Ләкин флотилия штабында сыңар гына да буксир табылмый.

...Йөреп-йөреп тә эш чыкмагач, хәлне аңлатып, ул берьюлы ике адреска: 5 нче армиянең реввоенсоветына һәм Нижний Новгородка, су транспортының өлкә идарәсенә телеграмма язды. Үтенече бер генә: буксир! Шунда аның бу көннәрдә үзен тетрәтеп йөргән бөтен уйлары, борчулары, өметләре бер ноктага укмашты да өченче телеграмма булып дөрләп кабынды — ул кабалана-кабалана тагын бер адресны язарга тотынды: Мәскәү, Эшче һәм крестьян оборонасы советына, Ленинга...

... Тагын көтү. Атна үтә, ун көн. Баржага көн саен әле власть вәкилләре, әле ярлы-ябагай, әле бандитлар килеп чыга. Берәүләренә яхшылап аңлаталар, икенчеләрен, икмәкне ач балалар көтә, менә карагыз, үзебез дә как сөяккә калдык, бер кадагына тимибез дип үгетлиләр, өченчеләренә мылтык терәп каршы торырга, өркетергә туры килә.

Ниһаять, аларга таба да бер буксир борылыр икән! Казаннан җибәргәннәр. Капитанны кочаклап алалар. Шулай да Федорның каткан бәгыре тиз генә эреп китә алмый. Әйтә:

— Рыбинскига чаклы бер кайда туктамаска, беркемне тыңламаска,— ди. Үзе болай гына кебек итеп наган кобурасын рәтләп куйгандай итә. Карт капитан үзеннән күп яшь Федорның ишарәсеннән мыек астыннан гына елмаеп куя:

— Сайга утырудан гына алла сакласын диегез инде, бер нинди түрәгә баш июю юк, беане монда иң зур начальство җибәрткән бугай.

«Ленин» дип уйлады Федор. Күзләре очкынланып китте, хәтта тамагына төер бөялде. «Менә, ичмасам, кеше!»

Кәрван чыннан да бер җирдә дә тоткарланмады, хәтта Казан белән Нижнийга да ягулык алырга гына кереп чыктылар. 1 июльдә Рыбинскига килеп җиттеләр.

Кызу җан Павлов бу юлы инде станцияны аякка бастырды. Эшчеләр, матрослар ярдәмгә чакырылды. Федор белән бергә делегат-кызылармеецлар үзләре арка тиреләре чиләнеп купканчы тиргә батып капчык ташыдылар. Баржадагы икмәк бер тәүлек дигәндә вагоннарга күчеп беткән иде.

Тик вагоннар бик шома гына тәгәрәп барып җитә алмадылар. Тимер юлларда да вагон, паровозлар һәм... тәртип тәмам какшаган көннәр иде. Паровоз 42 вагоннан артыгын тарта алмый, башка состав белән озатырбыз дип, башта җиде вагонны аерып калдырдылар, аннары Бологое станциясенә җиткәнче, буксалары янып, ярты җаннарын өзеп алган кебек, тагын дүртне калдырырга туры килде. Шулай да Павлов Медведевка станциясенә җиткәч, болай да санаулы егетләренең икесен кире борды: калган барлык вагоннарны җыеп, ничек тә Петроградка китереп җиткерергә!

Юлдан ук Павлов үзләренең якынаюын Петроград оборона советына хәбәр итә. Совет икмәкнең бераз өлешен Петроград тирәсе пунктларында ук калдырырга куша. Ә утыз вагон икмәк, Петроградның үзенә китереп җиткерелеп, делегация аны Совет власте вәкилләре кулына тапшыра.

Шәһәрдә шатлыкның чиге булмый. Икмәкнең соңгы запаслары да бетеп, халыкка бишенче көн инде бер грамм бирелмәгән була. Меньшевик, эсер кебек кара көчләр, үлем көткән козгын кебек, туктаусыз каркылдап, кешеләрдә ризасызлыклар, гауғалар чыгарырга маташканнар.

Предприятиеләрдә митинглар оештырыла, эшчеләр Павловка һәм аның егетләренә һәркайда ихластан рәхмәт укыйлар, күтәреп кенә йөртмиләр. Делегатлар исә фронт хәлләрен сөйлиләр, транспорттагы кыенлыкларга зарланалар, петроградлыларның да түземлек-батырлыкларына соклануларын яшермиләр. Фронтка әйләнеп кайткач дошманны тизрәк, аяусызрак кырырга вәгъдә бирәләр. Болар да эшчеләрне икмәк белән бер үк дәрәҗәдә канатландырып, дәртләндереп җибәрә. Предприятиеләрдә Кызыл Армиягә биреп җибәрергә тиз арада китап-матбугат җыйдылар. Тәмәке җыю башланды. Петроград оборона советы, 5 нче армия штабы җитәкчеләренең үтенечен канәгатьләндереп, делегациягә күп кенә пулемет детальләре, хәрби карталар, бүтән кирәк-ярак хәстәрләп тапшырдылар.

25 июльдә делегация исән-сау Уфага кайтып җитеп, шул көнне үк Павлов политбүлектә заданиенең ничек үтәлүе турында рапорт язарга утырды.

Ленин телеграммасын үтәү өчен оештырылган икмәк командировкаларының берсе менә шулай тәгәлләнде.

## Караңгыда җемелдәгән нурлар

Владимир Ильич каюта стенасына, палубага бәреп яуган яңгырдан уянып китте. Каютада дөм-караңгы. Юлга чыккач, бернич͏ә көн рәттән мондый гына тавышларга һич исе китмичә рәхәтләнеп йоклаган иде. Уфага якынайган саен, йокы кача бара. Аның каравы, хәзер Надя күз алдыннан бөтенләй китми диярлек. Очрашасы башка кешеләр дә берәм-берәм килеп баса.

Тәрәзә пәрдәсен аз гына күтәреп, Владимир Ильич тышка карады. Баз эчедәй караңгы. Пароход туктаган бугай, чайкалуы җилдән, дулкыннан шикелле. Бөтен дөньясы үлем тынлыгында. Ник бер сукыр ут чырае булсын. Бу тирәләр Бөре өязе булырга тиеш. Үзенә каршы кешеләрне патша менә шушындый алла каргаган базларга дөмектерә дә инде. Ләкин барыбер рухларын сындыра алмый. Теге юлы, февральдә, биредән аның белән очрашырга Ольга Афанасьевна Варенцова килгән иде. Аптекман квартирасында оештырылган җыелышта булды. Ленин белән теләктәш иде. Моннан Воронежга күчкәндә ул Надежда Константиновнаның адресын алып китеп, аның белән бәйләнешен тегеннән дә яңартып җибәргән. Надежда Константиновнаны ул Бөредәге башка иптәшләр белән дә таныштырып калдырырга тиеш иде. Өлгердеме икән? Очрашуга килә алырлармы? Казаннан исә Минзәләгә хәбәр салырга өлгерделәрме икән? Мишеневны ничек тә күрергә иде.

Моңсу гына елмаеп, янә Надя килеп баса. Владимир Ильичның зарыгып сагынган йөрәге кысылып-кысылып куя. Күрешмәгәнгә дүрт айдан артты. Февральдә нишләп шулкадәр кабаланып китеп баргандыр. Уфа — Петербург түгел, күпме яшәсәң

дә, бәйләнүче булмас иде. Хәер, һәр көн, һәр сәгать санаулы иде шул. Бу юлы да, ничек кенә сагынган булма, барыбер озак юанып булмаячак. Тагын аерылышу, тагын зарыгу. Надяның сәламәтлеге болай да мактанырлык түгел, өстәвенә аларның килүе күпме эш, мәшәкать, ә киткәч әле тагын күпме өстәләчәк. Бу көннәрне бергәбергә, күңелле итеп үткәрәсе иде; иң мөһиме, Надяның үзендә дә, аның танышиптәшләрендә дә киләчәккә ышанычны ныгытып, озак вакытларга сүрелмәслек итеп беректереп калдырасы иде...

Февральдә очрашканда ук әле Уфадагы иптәшләр яхшы тәэсир калдырганнар иде. Хәзер менә һәркайсы берәм-берәм тагын күз алдыннан үтәләр. Цюрупа, Гезенбуш, Петренко, Крохмаль... Пискуновлар да анда булачак: тагын бәхәсләшергә туры килерме? Надя бит яңа танышлары Кадомцевлар гаиләсе, эшче Якутов турында да язган иде. Шәп, шәп! Надяга ошагач, кызык кешеләр булырга тиеш. Тизрәк күрәсе, сөйләшәсе иде үзләре белән!

...Иртән дә күк йөзе авыр болытлардан арынып бетмәгән иде әле. Торып-торып пароходны яңгыр юып ала. Ләкин шундый көнне дә табигать ягымлы, тирә-як матур күренә, һава аеруча сафланган иде. Болытлар арасыннан кояш чыгып торганда яр буйларыннан сыек кына, нәфис кенә пар күтәрелә.

Ульяновларның кәеф әйбәт иде — ниһаять, Уфага якынаеп киләләр. Әйберләрне төйнәп, палубага ук чыгарып куйдылар. Ул арада сул якта яшеллеккә төренгән таулар башланды. Вакыты-вакыты белән күккә үрелгән шәрә кыялар, горур сакчылар кебек, елга өстенә үк чыга. Пароход чарыкларының тырышып-тырышып шапылдау тавышы аларга бәрелеп, кире су өстенә, пароходка кайта.

Әнә яшеллек арасыннан каралты-куралар, ә су өстендә ярга сыенган көймә, саллар күбрәк күренә башлады. Кайдадыр якында гына, кыялар артында гына, паровоз кычкырткан ишетелде.

Анна Ильинична сораулы карашына юлыгып, Владимир Ильич:

— Чуен юл бередә ярга сыенып үтә. Шәһәр читеннән. Ә Уфа үзе тау башында, моннан бөтенләй күренми, — дип төшендерде, ә үзе тагын да бирелебрәк алга текәлде. Анда инде яңгыр пәрдәсе эченнән тонык кына булып Сафронов пристаненың агач амбарлары, күкшегән баржалар арасыннан шактый купшы дебаркадер аерылып күренде. Анда төрле-төрле зонтлы, төрле киемнән кешеләр төсмерләнде. Владимир Ильич бик текәлеп карап торгач, шулар арасыннан Надежда Константиновнаны һәм әбисе Елизавета Васильевнаны күргән кебек булды, «Исәнмесез, кадерлеләрем!» — диде ул эченнән.

...Хәл-әхвәл сораша-сораша ашап-эчеп алгач, тәбәнәк кечкенә бүлмәнең бик кысан икәнен тойдылар, өстәвенә ифрат та бөркү иде. Яшьләрнең тизрәк урамга чыгасы, Уфа карыйсы килде.

Тик әбиләр урамда озак юанмадылар, яшьләрне калдырып, ял итәргә янә өйгә кайттылар. Елизавета Васильевнаның кунакларны сыйларга хәстәрләнәсе бар иде. Мария Александровна да көпә-көндез ятып торуны яхшысынмады, килененең өстәлендә каләм, кәгазь күреп, шунда килеп утырды. Уфаларны сәламәт-имин күреп, ул инде бераз тынычланган иде. Володяны исән-сау китереп җиткерүенә бик тә шат иде. Тик күңел дигәнең инде яңа уй, яңа борчу эзләп тапкан: Подольскида калган балаларның ни хәле бар икән? Безнең өчен борчылып торалардыр инде, җәһәт кенә хат язып салырга кирәк.

«1900 ел, 15 июнь. Уфа шәһәре.

Ниһаять, сәгать 12 дә килеп җиттек. Монда да шулай ук яңгырлар коя, шулай итеп, шәһәргә дә — 4 чакрым тауга — бераз яңгыр астында менәргә туры килде, коточкыч пычрак. Н. (Надежда) һәм Е. В. (Елизавета Васильевна) сау-сәламәт. Сезгә сәлам әйтәләр. М. Грачевскаяга кергән идек, тик, кызганычка каршы, өйдә булмадылар, 50 чакрым тирәсендәге хуторга киткәннәр. Безнекеләрнең квартирасы безгә бер дә ошамый. Тәбәнәк бүлмәләр, котчыккыч бөркү һәм өстәвенә биек текә баскыч, аннан бик еш менеп йөрергә туры килә. Сездән хат көтәм, кирәк булса, телеграмма сугыгыз. Икегезне дә, кадерлеләрем минем, каты үбәм. Әниегез».

Бу вакытта Владимир Ильич, Анна Ильинична Надежда Константиновна «җитәкчелегендә», бирелеп сөйләшә-сөйләшә, Уфа белән таныша-таныша, яңа дуслар белән очрашырга ашыгалар иде.

# ЛЕНИН ШОФЕРЫ

## 459 нчы таныклык

«1918 елның 29 июне, Петроград. Бу таныклык гражданин Борнашевның чыннан да эшче һәм солдат депутатлары Советы Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы 2 нче гаражда шофер сыйфатында хезмәт иткәнен белдерә һәм бу таныклык шулай ук Петроград шәһәрендә тоткарлыксыз хәрәкәт итү хокукы бирә. Моның шулай икәнлеге имза һәм печать белән раслана. 2 нче гараж комитеты председателе В. Жамойдо. Секретарь В. Каныш». Әлеге документ Мөхәммәтвәли Сәйфуллович Борнашевның шәхси архивында саклана һәм аның яшь Советлар республикасы гаражында эшләве турында сөйли.

Яшь революционер Борнашевның пролетариат юлбашчысы В. И. Ленин һәм аның якын көрәштәшләре Я. М. Свердлов, М. И. Калинин, Ф. Э. Дзержинский, Н. К. Крупская М. И. Ульянова, Г. К. Орджоникидзе, С. М. Киров, В. Д. Бонч-Бруевич, А. М. Коллонтай, Е. Д. Стасова һәм башкалар белән ничәмә тапкыр очрашуларының һәм аларны машина белән озатып йөрүләренең исәбенә чыгарлык түгел. Ләкин Бөек Октябрь революциясе ветераны аларның берсен дә онытмаган...

Мөхәммәтвәли Сәйфуллович Борнашев 1891 елның 8 мартында (иске стиль белән) Петербургта туа. Яшь чагында исеменең «Мөхәммәт» өлешен төшереп калдырып, үзен Вәли дип кенә атый, шуңа күрә сакланган күп документларда ул Вәли Борнашев дип языла. Аның әтисе Сәйфулла патша Россиясе башкаласына эш эзләп Тамбов губернасының Ялатмән өязендәге Азиево авылыннан килә һәм шунда төпләнеп кала.

Мөхәммәтвәлине унбер яшьтә чакта Нева проспектындагы француз Альберт фабрикасына «малайлыкка» бирәләр. Ул анда өч елдан артык эшли. Революцион «фетнә»дә катнашкан өчен Мөхәммәтвәлине фабрикант бик каты кыйный һәм киемен йолкып ала да урамга куып чыгара.

— Мин бу хәлдән соң ун ел буена теләсә кайда эшләп тамак туйдырдым, — дип искә ала Вәли Борнашев.

Вәли кечкенәдән үк техника ярата һәм ул заманда сирәк очрый торган шофер һөнәрен үзләштерергә карар кыла. Революциягә кадәр Петербургта автомобильләр бармак белән генә санарлык санда була әле. Вәли Гатчинога күчә, «Сикорский һәм Илья Муромец» автоавиаучилищесына укырга керә. Анда бер ел да өч ай укыгач, Петербургка әйләнеп кайта, «Бенс» фирмасы гаражына (Лиговка, 42) өйрәнчек шофер булып урнаша.

— 1912 елда,—ди ул,—мине, бер автомобильгә ияртеп, чыгышы белән кавказлы князь Белотуковка саттылар. Князь Борнашевка аена 35 сум эш хакы билгели. Банкир Белотуков бозык кызлар белән «шаярырга» ярата торган кеше булып чыга. Озакламый Борнашев аны ташлап китә һәм Царское селодагы дәүләт гаражына эшкә барып керә. Чынбарлыкта бу гараж «Галиҗәнаб»ныкы була һәм патша генералы Осипов карамагында тора.

Тиздән яшь шофер революцион рухтагы эшчеләр белән аралаша башлый. Борнашев аларның җыеннарында катнаша, күп кенә эшче-революционерлар белән

таныша. Озакламый аны ышанычсыз булганы һәм «сүз» тыңламавы» өчен «Галиҗәнаб» гаражындагы эштән чыгаралар. Соңыннан мәгълүм булганча, генерал Осипов Бөек князь исеменә В. Борнашевның ышанычсыз һәм фетнәчел революционерлар белән фикердәш булуы турында рапорт язган булып чыга. Рапортта: «Аеруча куркыныч шофер», — дип яза Осипов аның хакында. Борнашевка автомобильне тапшырырга кушыла, аннары аны өч солдат сагында Петроград вокзалына кадәр озатып куялар да, ышанычсызлар белән бер вагонга утыртып, штрафниклар белән бергә хәрәкәттәге армиягә—Витебскига җибәрәләр. Юлда барганда ул патша солдатларының поездда революцион караштагы студентлар һәм эшчеләрдән торган биш вагон озата баруларын белә. Аннары Вәлиләрне Витебскидан Минскига җибәрәләр һәм батальоннарга бүлеп куялар. Икенче көнне штрафникларга кәйлә белән көрәк тоттыралар да Молодечно янына окоп һәм блиндажлар казырга җибәрәләр. Бу 1916 елда көз ахырында була. Борнашевның каты салкын тидерүдән үпкәсе кабарып чыга. Аны фронт тирәсендәге бер лазаретка салалар.

Хәрби җитәкчелек Борнашевның шофер икәнлеген белеп ала. 10 нчы армия командующие генерал Эверт Вәлинең савыгып чыгуын көтеп тора да трофей автомобиль шоферы итеп билгеләп куя. Борнашев атна буе машина төзәтеп ята. Аннары Эверт бу автомобильне шоферы-ние белән армиянең санитария бүлеге башлыгы хатын-кыз полковник Коковцевага тапшырырга дигән боерык чыгара. Бу хатын шушыңа кадәр күптән түгел генә хөкемсез-нисез үз кучерын атып үтергән була.

— Минем шоферым һәм денщигым булырсың,—ди ул Борнашевка. Һәм, сүзен тыңламый-нитә калса, Вәлине дә шул кучер язмышы көткәнен искәртеп куярга онытмый. Вәли, өч көн үтүгә үк, бу җәллад хатын-кыз полковниктан качып китә, тик патрульләргә барып эләгә. Аны 10 нчы авиация дивизионы командиры полковник Горшков янына алып киләләр. «Дезертир» яшерми-нитми полковникка качып китүенең сәбәбе турында сөйләп бирә һәм аннан үзенең частенда калдыруын үтенә. Шулай итеп, Вәли Борнашев полковник Горшковның шәхси шоферы итеп билгеләнә.

Борнашевка командиры белән бергә немецларга каршы күп кенә сугышларда катнашырга туры килә, ул 1 нче, 2 нче дәрәҗә «Иҗтиһатлык өчен» Георгий медальләре белән бүләкләнә. Ул Николай патшаның тәхеттән ваз кичүе турындагы хәбәрне дә фронтта ишетә. Хәрәкәттәге армиядә революцион комитетлар төзелә башлый. Вәли дә шуңа катнашып китә.

Ул революцион карашлы солдатларның бер төркеме белән Питер эшчеләренә ярдәмгә Петроградка кайтып төшә. Власть башында—Вакытлы хөкүмәт. Вәли үз иптәшләре белән Питерда яшәүче әтисендә туктала. Бераздан алар большевикларның графиня Кшесинская сараенда урнашкан революцион комитеты клубына килеп кушылалар. Тиздән Вәлине большевиклар партиясенә алалар. Һәм шул чакта ул сугышчан дуслары белән бергә Россия пролетариаты юлбашчысы В. И. Ленинның Кшесинская сарае балконына чыгып сөйләгән тарихи речен тыңлый.

## «Ышанычыгызны аклармын!»

Петроградта большевиклар В. И. Ленинның фин подпольесыннан кайтып җитүен түземсезлек белән көтеп торалар. Аны башкаланың Финляндия вокзалында каршылаучылар арасында Вәли Борнашев та була. Питер пролетариаты зур шатлык кичерә. Владимир Ильич Ленинның броневикка басып сөйләгән речен Вәли үз хәтерендә гомергә калдыра: Ленин эшчеләрне, солдат һәм матросларны социалистик революция ясарга өнди.

— Миңа һәм барлык эшче, солдат һәм матросларга Ленин сүзләре гаҗәеп көчле тәэсир итте. Безне властьның большевиклар кулына күчәчәге, хыянәтчел Вакытлы хөкүмәтнең, эсерлар һәм меньшевиклар властеның котылгысыз һәлакәткә дучар ителгән булуы аеруча шатландырды, — дип искә ала Борнашев ул көннәрне.

Петербургта һәр урында революцион комитетлар һәм отрядлар оеша башлый. Вәли Борнашев шофер булып эшләгән «Рено» заводында да революцион комитет төзелә. Бөек Октябрьга кадәр В. И. Ленинның турыдан-туры җитәкчелеге белән



*Мөхәммәтвәли Борнашев.*

Октябрь революциясен әзерләүдә гаять зур эш җәелеп китә. Вәли Борнашев та «Рено» заводында үзенең иптәшләре белән яшерен агитация эше алып бара. Ул зур дәрт белән эшче һәм солдатларның сугышчан дружиналарын оештыруга катнашып йөри.

Бөек Октябрь социалистик революциясе тарихи җиңү белән тәмамлана — планета кешелеге өчен яңа чор башланып китә. Кышкы Сарайны яулап алучылар арасында Вәли Борнашев та була.

Совет власте урнашуга, аны Халык Комиссарлары Советының автобүлек начальнигы Седовский янына чакырып алалар. Седовский Борнашевны Халык Комиссарлары Советының эшләр идарәсе управляющие В. Д. Бонч-Бруевич белән таныштыра. Ул Вәли белән бик озак сөйләшеп утыра. Аннары ул аны Владимир Ильич янына алып керә. Ленин Вәлинең кайда укуы һәм шоферлыкка ничек өйрәнгәнлеге, гаиләсе, большевиклар партиясенә кайчан керүе белән кызыксына, фронттагы хәлләрне сораша.

— Сез, Мөхәммәтвәли Сәйфуллович, бездә шофер булып эшләргә телисез икән, — ди ахырдан Владимир Ильич. Бераз уйланып торгач: — Яхшы, бик яхшы, иптәш Борнашев. Шуны онытмагыз, Сезгә революцион хөкүмәтнең автобүлегендә эшләргә туры киләчәк. Әйе, әйе, бу зур бурычлар йөкли.

— Зур рәхмәт, Владимир Ильич, ышанычыгызны аклармын.

— Аннары, — дип искә төшерә бүген карт большевик, — Владимир Ильич елмаеп куйды, күзләрен җемелдәтеп алды һәм кулын минем җилкәмә дустанә салды да: «Кадерле Мөхәммәтвәли, бергә эшләячәкбез. Белеп торыгыз: күп, бик күп эшләргә туры киләчәк. Авыр заман. Көрәш әле озак барачак һәм без һичшиксез җиңәчәкбез. Әйе, әйе, җиңәрбез. Моны бер минутка да хәтерегездән чыгармаска кирәк. Сез шофер гына түгел, революционер да булырга тиеш. Сез Совет властен кулыгызга руль һәм корал тотып та сакларга һәрвакыт әзер булырга тиеш. Әйе, кулга корал тотып», диде. Ленин минем кулны кысып саубуллашты да, шул ук вакытта борылып, Бонч-Бруевичка: «Владимир Дмитриевич, иптәш Борнашевка мандат һәм револьвер бирергә боерыгыз», диде. Мин Ленин кабинетыннан шатлыгымнан нишләргә дә белмичә, гаҗәеп яхшы кәеф белән чыгып киттем. Шул ук көнне миңа Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының 2 нче гаражы шоферы булып эшләвем һәм корал йөртүгә хокуклы булуым турында мандатлар һәм реквизит язуы бирелде.

— Сезгә җаваплы бурыч — буржуйларның автомобильләрен тартып алу һәм ВЦИКның икенче гаражын оештыру бурычы йөкләнелә, — ди аңа В. Бонч-Бруевич.

Борнашев әйтүенчә, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының беренче гаражы хәрби гараж булган. Аны оештыру эшенә Вәли Борнашев актив керешә. Беренче адымнарында ук гаять зур авырлыкларга тап була. Совет строеның 'кан дошманнары җимерү эше белән өзлексез шөгыльләнә, саботажлар оештырыла. Буржуазия революция законнарына буйсынырга теләми, үзендәге автомобильләрне сүттереп юкка чыгара башлый. Әйтик, «Нобель» компаниясе акционеры капиталист Монтащов үз лимузинын сүтеп һәм яшереп куярга тели. Бу хәбәрне Борнашевка җиткерәләр. Ул, ике кызыл гвардияче алып, буржуй гаражына ашыга, килеп кергәч, сүтелеп ташланган һәм детальләре теләсә кая таратылган «Ройлли-Ройс» автомобилен күреп ала. Акционер шоферы Никандров алдан ук ике айлык эш хакы биреп, большевикларга эләкмәсен өчен машинаны сүтәргә мәҗбүр итүләре турында сөйләп бирә. Аңа революция исеменнән автомобильне кабат җыярга, бензин салырга һәм гаражга китереп куярга боерык бирелә. Ул әйтелгәнчә эшли һәм соңыннан

үзен революцион гаражда эшкә калдыруларын сорый. Һәм бу үтенеч канәгатьләндерелә. Большевиклар эшкә алганга ул сөенеп бетә алмый һәм эшенә һәрвакыт намус белән карый торган кеше булып таныла.

Вәли Борнашев италияле банкир Кафтель гаражындагы «Вакс-Холл» автомобиленең дә шул хәлгә дучар булганын белә. Аны да машинаны җыярга һәм революцион властька тапшырырга мәҗбүр итәләр.

Борнашев һәм аның иптәшләре шактый авырлык белән 5 автомобильдән торган гараж туплауга ирешәләр. Ул манеж бинасында җиһазландырыла. Шоферлар штаты да билгеләнә. Вәли Борнашев өлкән шофер һәм гараж механигы була. Башка шоферлар итеп Никандров, Лабезов, Кнопка куела. Алар барысы да элеккеге капиталистлардан алынган машиналарда эшли. Шушы беренче гаражның шоферлар штатына Кузьмич, Гилль, Космачев та керә.

— Автомобильләр хөкүмәтнең аерым бер башлыгына беркетелмичә, чакыруга карап, дежур тәртибендә файдаланыла иде. Мин дә, башка шоферлар да күп тапкыр Владимир Ильич Ленин, Я. М. Свердлов, М. И. Калинин, Ф. Э. Дзержинский, А. В. Луначарский, В. Д. Бонч-Бруевич, Н. К. Крупская, М. С. Урицкий, А. М. Коллонтай, партия һәм хөкүмәтебезнең башка җитәкчеләрен йөрттек, — дип сөйли Вәли Борнашев.—Владимир Ильич һәрвакыт кичкә кадәр эшли һәм автомобильне еш кына соң чакырта иде. Миңа аны Путилов һәм Обухов заводларына, башка предприятиеләргә эшчеләрнең кичке сменасы алышынган вакытка алып барырга туры килде. Кагыйдә буларак, Ленин эшчеләр белән озаклап сөйләшеп, алар алдында чыгышлар ясый торган иде. Алар Владимир Ильичны һәрвакыт машина янына кадәр озата киләләр. Ул эшчеләр белән һәрчак кул биреп саубуллашыр иде. Әңгәмә вакытында кесәсеннән еш кына куен дәфтәрен чыгара да тиз-тиз генә нидәрдер язып куя. Ничектер мин аннан: «Владимир Ильич, Сез бик күп язасыз, кулыгыз армыймы?» — дип сорадым. «Юк, кадерле Мөхәммәтвәли, армый, ялкауларның гына кулы ара», — диде ул һәм мөлаем күзләрен нурландырып: «Күрәм ич, Сезнең дә кулыгыз руль тотып армый бит, чөнки эшне яратасыз, дөрес түгелме?» — дип өстәде.

Владимир Ильичтан аны акрынмы яисә кызу йөртергәме дип сораганда, ул: «Сезгә ничек уңайлырак, шулай йөртегез», — дия торган иде. Мин машинаны һәрвакыт акрынрак—димәк, саграк!—йөртергә тырыштым. Чөнки Ленин кайвакыт куен дәфтәренә машинада барганда да язгалый иде.

— Бервакыт, — ди Вәли Борнашев, — Владимир Ильичны Смольныйга илткәч (ул шунда яши иде), ул машина ишеген ачты да, сау булыгыз, кадерле Мөхәммәтвәли дип, миңа кулын сузды. Мин бераз югалып калдым һәм: «Владимир Ильич, минем кул майлы, Сезнекен дә пычратуым ихтимал», — дидем. Ул миңа кырыс итеп карап куйды: «Ялгышасыз, кадерлем, эшчеләрнең кулы пычрак булмый. Буржуйларның куллары пычрак. Әйе, әйе, буржуйларныкы. Моны хәтерегездә калдырыгыз», — диде дә кулымны тагын да ныграк кысып саубуллашты. «Нинди киң күңелле һәм миһербанлы кеше» дип уйлый идем мин Ильич турында. Аның мәрхәмәтлелеге, гади кешеләрне чын күңелдән яратуы, бөек һәм даһи образы һәрвакыт сокландыра. Бервакыт мин аны Питер фабрикаларының берсенә алып бара идем. Коеп яңгыр ява. Нева проспекты белән Пушкин урамы чатында ике егетнең бер өлкән кешене култыклап баруын күреп алдым. Алар, кул күтәреп, минем машинаны туктатуны үтенделәр. Ләкин мин, тизлекне киметмичә, юлны дәвам иттердем, чөнки Бонч-Бруевичның «иминлек максатларында хөкүмәт машинасына чит кешеләрне утыртмаска» дигән боерыгы бар иде. Владимир Ильич (ул урамдагы хәлгә шундук игътибар иткән булса кирәк) борчулы тавыш белән машинаны туктатырга, егетләргә ярдәм итәргә кушты. Җәяүлеләрнең берсе — өлкән агай — авыру кеше булып чыкты, егетләр аны Знаменский мәйданындагы бер аптекага утыртып алып баруымны үтенделәр. Владимир Ильич алар белән иске танышларыдай сөйләшеп барды. Ул яшьләрдән гади кешеләрнең Совет властена, большевикларга ничек караганнарын сорашты. Без эшчеләр хөкүмәтенә рәхмәт белдерәбез, тиздән тормыш рәтләнер дип өметләнәбез диде егетләр. Авыру абзый: «Ул көннәргә кадәр яши алмам инде», дигәч, «Һичшиксез яшәрсең», — диде аңа Ленин. Аптекага барып җиткәч, авыру абзый аңа рәхмәт әйтте һәм, миңа борылып: «Хуҗаң яхшы кеше күренә, кадерен бел», — диде. Мин көлеп куйдым да машинаны үз юлыбызга бордым. «Менә бит,

Мөхәммәтвәли, без берни дә югалтмадык, ә күпме рәхмәт ишеттек», — диде Ленин елмаеп... 1917 елның ахырында һәм 1918 елның башында хәл чиктән тыш авыр иде,— дип дәвам итте сүзен Вәли Борнашев. — Тәүлегенә 150 грамм икмәк бирелгән заман. Шундый көннәрнең берсендә Ростов-Доннан Петроградка, революцион штаб карамагына, ике вагон азык-төлек килеп җитте. Ленин аларны больницалар һәм балалар йортларына бүлеп бирергә кушты. Вагоннарны озата килгән карт крестьяннарның берсе Владимир Ильичка бүләк итеп Ростов икмәген алып килгән. Ленин аның кыерчыгын гына кисеп алды да: «Шофер белән безгә бу бик җитә, калганын балаларга бирегез»,—дип, икмәкне крестьянга кире кайтарды.

## Соңгы очрашу...

Октябрь революциясеннән соң В. Борнашев башта атасы һәм ир туганы белән Петроградта яши. Барысы да совет учреждениеләрендә эшли. Совет хөкүмәте Мәскәүгә күчәр алдыннан аларның аталары каты авырып китә. Владимир Ильич Вәли Борнашевка аны туган авылына — Тамбов губернасына җибәрергә киңәш бирә. Ә 1918 елның җәендә Мөхәммәтвәлине Мәскәүгә чакырып алалар һәм Тамбовка — контрреволюцион фетнәне бастыруга катнашырга тәкъдим итәләр. Ул Тамбов революцион комитеты карамагына килә. Аны Нагель җитәкчелегендәге революцион отрядка билгелиләр.

Вәли Борнашев фетнәчеләр бандасы белән бер бәрелештә авыр яраланып лазаретка эләгә. Сәламәтләнгәч, партия һәм совет эшен җайга салу өчен, аны туган авылы Азиевога җибәрәләр.

1919 елның язында Борнашевны (бу вакытта ул чекист була) яңадан Мәскәүгә чакыртып алалар. Аңа Казанга юл алырга һәм Татарстанда автотранспорт эшен җайга салырга дигән җаваплы партия бурычы йөкләнә. «Иптәш Борнашев Вәли Сәйфуллович Тамбов шәһәреннән Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының Революцион комитет автобазасын оештыру өчен чакырыла», — диелә Татарстан Халык Комиссарлары Советы документларының берсендә.

Казан вокзалында Вәли Борнашевны Революцион совет председателе С. Сәетгалиев каршы ала. Аңа бернинди ресурс булмаган җирдә Татарстан автохуҗалыгын төзү бурычы йөкләнә. Юктан бар ясарга туры килүен яхшы аңлаган хәлдә, Вәли үзенә хас дәрт белән шушы эшкә керешә. Мәскәүгә командировкага барып, ул гамәлдән чыгарылган автомобильләр арасыннан төзәтеп булырдайларын сайлап ала һәм Казанга кайтартырга уйлый. ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1920 ел, 24 ноябрендә бирелгән 6143 нче мандатында хөкүмәт автобазасын оештыручы һәм аның мөдире Вәли Борнашевның Мәскәүгә машиналар һәм автоматериаллар алу өчен җибәрелүе турында, барлык совет учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмаларыннан, шул исәптән хәрбиләрдән дә, әлеге бурычны үтәүдә Борнашевка һәрьяклап булышлык күрсәтү сорала. Бу мандат аңа поездларга чиратсыз утыру һәм чиратсыз телеграммалар сугу хокукы да бирә.

— Мин Мәскәүдә иптәш Мехлис янында булдым, — дип сөйли Борнашев. —Ул чакта автохуҗалык аның кулында иде. Мехлис миңа ташландык машиналар арасыннан 18 автомобиль һәм «Илья Муромец» тибындагы 5 самолет сайлап алырга язма рөхсәт бирде. Мин Кремль биналарының берсенә урнашкан кунакханәдә яшәп тордым. Төзәтеп булырдай берничә автомобиль һәм самолет сайлап алгач, документлар җайлау өчен Халык Комиссарлары Советына кердем. Уйламаганнитмәгәндә коридорда Владимир Ильич белән йөзгә-йөз очраштым. Ул мине шундук танып алды. «Исәнмесез, Мөхәммәтвәли Сәйфуллович!» — дип исәнләште ул әти исемен дә атап. Аннары минем эшләр, үткән ике ярым ел вакыттагы тормышым белән кызыксынды. Соңыннан: «Машиналар алдыгызмы?» — дип сорады. Техника алырга килүемне сөйләп бирдем һәм ярдәм күрсәткәне өчен Совет хөкүмәтенә рәхмәтемне җиткердем. Ул миңа машиналарны Казанга озатуда ярдәм сорап, В. Д. Бонч-Бруевичка мөрәҗәгать итәргә кушты да: «Әйдә, хәзер ашап алыйк», — дип, мине Кремль ашханәсенә әйдәде. Әбәт вакытында ул миннән туган авылым, Тамбов, Казан турында, крестьяннар һәм Казан эшчеләре тормышы ха-

кында сорашты. Владимир Ильич авыл һәм шәһәрләрдәге революцион үзгәртеп коруларга чиксез шатланды.

Соңыннан ул минем белән бик җылы итеп саубуллашты да уңышлар теләде.

Бу минем кадерле юлбашчыбыз белән соңгы очрашуым булды.

Аннан соң мин Бонч-Бруевич янына кереп чыктым. Шул ук көнне, аның боерыгы нигезендә, автомашина һәм самолетлар төяүдә эшләячәк кешеләргә бирү өчен азык-төлек талоннары алдым. Аннары мин хезмәт биржасына барып яллаган кешеләр берничә сәгатьтә 12 иске автомобиль һәм 2 самолетны платформаларга төяп куйдылар. Казанга кайткач, ике ай чамасы автобаза шоферлары һәм слесарьлары белән бергә шуларны ремонтладык. 1921 елның башында Татарстан республикасында беренче автобаза һәм һава транспорты эшли башлады.

## Мәңгегә сафта

Озак еллар буена — Бөек Ватан сугышына кадәр—Мөхәммәтвәли Борнашевның бөтен эшчәнлеге Татарстан АССР автомобиль транспортын җайга салу белән бәйле була. Ул гади шофер, автобаза башлыгы, инженер, механик булып эшли. Ләкин, кайда гына булмасын, ул В. И. Ленин киңәшләрен һәм күрсәтмәләрен исеннән һич чыгармыйча, социалистик төзелешнең алгы сызыгында фидакарь хезмәт итә. Мәсәлән, 1927 елның 10 сентябрендә ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе һәм эшләр идарәсе управляющие кул куйган 9985 нче документта Борнашев Вәли Сәйфулловичның 7 елдан артык республика хөкүмәте каршында эшләве, Совнарком автобазасын оештыруы, аның начальнигы булуы, гараж мөдире һәм бер үк вакытта өлкән шофер вазифаларын үтәве, үз эшенә чиксез бирелгән, инициативалы хезмәткәр икәнлеге турындагы сүзләрне укырга мөмкин. М. Борнашевның шәхси архивында моңа охшаш характеристикалар байтак. Ул Татарстанда яңа тормыш төзегән күренекле партия һәм дәүләт эшлеклеләре Галимҗан Ибраһимов, Сәетгалиев, Мөхтәров, Габидуллин, Мусин, Әхмәтшин, Байчурин, Абрамов, Вәлидов, Чанышев һ. б. күп иптәшләрне бүген дә җылы сүзләр белән искә ала.

Бөек Ватан сугышы елларында Вәли Борнашев эчке эшләр органнарында җаваплы эш башкара. Ул Казан—Горький—Чебоксар—Мәскәү юлларында хәрби йөкләр һәм әһәмиятле документлар озатып йөри. Фронтта аның очучы улы һәлак була.

Сугыш беткәч, Вәли Сәйфуллович Казанда үз белгечлегенә караган эшен дәвам иттерә. Сәламәтлеге какшау сәбәпле һәм врачлар тәкъдиме белән ул 1947 елда Ташкентка күчә, гараж мөдире булып эшли, ә 1950 елдан персональ пенсионер. Алай да В. Борнашев җәмгыятькә файдалы хезмәттән читләшми: өлкән яшьтә булуына карамастан, җир тетрәүдән җимерелгән Ташкентны торгызуда катнаша — «Росташстрой» автобазасында эшли.

Хәзер дә В. С. Борнашев мәктәп укучылары, студентлар, солдатлар, яшь эшчеләр һәм хезмәтияләре белән еш очраша. Кайчакны укучы балалар аның квартирасына ук килеп китәләр. Ул аларга бөек юлбашчы В. И. Ленин белән һич онытылмас очрашулары турында сөйли.

Революция һәм хезмәт ветераны бүген дә сафта — ул инде тугыз дистәсен тутырып килә. Менә шундый шоферы да булган Ленинның.

**ИСХАК ЗӘБИРОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**
**Ташкент.**

**Сәйфи Кудаш,**
Башкортстан халык шагыйре

## Кошлар ашатам

Келәттәге ризыкларны бүлешеп,
Кыш буена кошлар ашатам.
Салкыннарга, бураннарга бакмый
Бурыч бураларын бушатам...

Бу эшемә, картлык бушлыкларын
Тулылый бу карт, дип бакмагыз.
Юкны юрап, шулай хөкем итеп,
Уйнап та языкка батмагыз.

Буш урын юк картлык кырларында:
Очланмаган байтак кибән бар,
Эскертләүне көтә саламнар,
Сөрелмәгән көзге сабаннар...

Пыскып явып китсә яңгырлар,
Югалырга мөмкин төшемнәр,
Җилгәреп бетмәгән көшелләр,
Тагын да бер гомерлек эшем бар...

Ачтан үлгән иске Россиядә
Яшь Башмаков, бөек Тукайлар,
Тиеш түгел хәзер ач кышларга
Былбыл түгел, чыпчык-тургайлар.

Шуның өчен сөеп ашатам мин
Туган илнең асыл кошларын,
Карт йөрәкнең җылысын бүлеп бирәм,
Җылытыр өчен салкын кышларын...

Бу эш өчен бер генә төрле дә
Түләү сорамыйм мин кошлардан.
Дуслык белән сату иткән җаннар
Саналмыйлар алар дуслардан!

Бер сүзем юк, тарлак итеп алар
Теләсә кем бакчасын сайласын.
Тик туган ил бакчасында үскән
Агачларга кунып сайрасын!

## Хәсәнем

*Х. Туфанга*

Каләм сәнәген учлап,
Ел кибәннәрен очлап,
Юл ярам яңа таңга.
Тагын да бишне кышлап,
Кышны яз белән очлап
Үрмәлимен туксанга.

Шушы булыр, Хәсәнем,
Туксанга чыккан картың!
Үзе егеткә тартым...
Дөрләтеп калган дәртен
Язарга тели һаман
Китереп бөтен шартын.

## Бул син...

*Профессор Р. Г. Кузеевка*

Акмасаң да Агыйделе булып җирнең,
Аңа койган чишмәләрнең заты бул син,
Чапмасаң да дан тулпары булып илнең,
Затлы йөген тарткан бер йөк аты бул син.

«Дүрт мизгелен елның үзгәрт» дип әйтмимен,
Кайгы кышының сагындырган язы бул син.
Хәтта төштә наз күрүдән өмет өзгән
Кешеләрнең өндә күргән назы бул син.

Урын эзләп сиңа кул сузмыйм гарешкә,
Ил күгенең сүнмәс бер йолдызы бул син.
«Һәр көн балкып кояш булып чык» дип әйтмим,
Кеше күңеленең һәрчак көндезе бул син.

Дәртләнергә күкләр иркен, юллар бик киң.
Теләсәң бик зур, теләсәң үзең кече бул син.
Тик шул гына: нишләсәң дә, кем булсаң да,
Һаман шулай элеккечә кеше бул син!

## Ни калдырдың?

Шоңкар кунган тауда йон кала.
Былбыл кунган тауда өн кала.
Толпар узган җирдә эз кала.
Чәчән узган илдә сүз кала...

Әй, син, кеше атлы батырым,
Эшкә җигеп алтын акылың,
Кырыкка ярып атның бер кылын
Ни нәрсә калдырдың дөньяда?

## Көтәм

Уйларым тынмый, талпына,
Очарга канат кага.
Буйларым өскә алкына,
Кул суза таңга таба.
Тән белән җан бердәй көтә
Язның назлы көннәрен,
Ишетергә зарыгып кошларның
Иркәләшкән өннәрен...

Кар юрганын тибеп ташлап
Язның көтәм торганын,
Сандугачның чутылдавын,
Чыңгыравын торнаның!

### Якуп Колмый,

башкорт шагыйре

## Салават янында

Юк, ул бронзадан коелмаган,
Яшенле яу аны терелткән.
Иңбашына кунып иртә таңнан
Күгәрченнәр хәтта үз иткән.

Юк, ул бронзадан коелмаган,
Нурга күмгән изге яктылык.
Халкы мактап аны җыр җырлаган,
Үлемсез ир иткән батырлык.

Юк, ул бронзадан коелмаган,
Ул саклаган йөрәк җылысын.
Күпме моң ургылган кураеннан
Бергә кушып халык тойгысын.

Юк, ул бронзадан коелмаган,
Хыялны өн иткән амәнәт.
Аерылмаган бер чак Уралыннан,
Һаман атта җилә Салават.

## Шулай да мин бәхетле

I

Икәү идек текә яр башында,
Агыйделем акты җемелдәп.
Күзләр уйнадылар каш астында,
Ике йөрәк типте дөпелдәп.

Без бәхетле идек, бер урамда
Бергә үстек, бергә яшәдек.
Янсак та без сөю ялкынында
«Сөям» дигән сүзне әйтмәдек.

II

Ялгыз торам текә яр башында,
Күкрәгемне кыскан тойгыдан
Сызлангандай Идел моңсу ага,
Ярсу тау елгасы оеган.

Шулай да мин бәхетлемен әле,
Бер шәһәрдә икәү яшибез.
Булсак та без бер чәчәкнең яме,
«Сөям» дигән сүзне әйтмибез.

III

Еллар аккан сымак Идел ага,
Тәбәнәйгән кебек ярлы да.
Очкан кошлар күздән югалганда
Сине хәтерләдем тагы да.

Мәхәббәт тә коштай — тотып булмый
Көйсәң дә син утсыз ялкында.
Бәхетле мин җылы биргән җырдан,
Без яшибез бер күк астында.

**Сафуан Әлибаев,**
башкорт шагыйре

# СИГЕЗЬЮЛЛЫКЛАР

## Дага

Яшь хуҗага карап кинәнделәр:
«Башка чыкты — түгел бала-чага»;
Аңа олы ырыс [1] теләделәр.
Тупсасына дага кага-кага.

[1] Ы р ы с — бәхет.

Тик бу йорттан бәхет урап үтте,
Карамады дага, догаларга.
Бөтен бәла шунда: ир-егетнең
Онытканнар үзен дагаларга.

## Икеләнмә

Капка алдында этем каршы алса,
Китеп барма кире, кабалан[1]:
Син килгәнне хәбәр генә итәр,
Чыкса әгәр көчек абалап.

Я капкамда олы мөгез күрсәң,
Икеләнеп торма керергә;
Сөзешергә түгел, мин капкама
Мөгез кактым тезген элергә.

## Намус

Һәр кешенең гомер юлы
Бормалы, ерак-алыс;
Еракларак киткән саен,
Гел ныгый барсын намус!

Ул бар икән — туган җиргә
Син нык баскансың, димәк.
Намусыннан язган кеше —
Кыршаусыз калган чиләк.

## Елгалар

Елкылдатып ялбыр ялкайларын
Сулар китә язын, юргалап;
Чикләреннән ашып ярсый да бер,
Тын ярларга кайта елгалар.

Ә миндә соң — күпме ашкынулар,
Күпме ярсу уйда, хисемдә?!
Мең ташып, мең ярларына кайта
Күңелем тик бер яз эчендә.

[1] Кабалан — куркып, каушап.

# ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕННӘН

*Узган елның ноябрь аенда Татарстан Язучылар союзы һәм ВЛКСМ өлкә комитеты Кукмарада яшь һәм башлап язучыларның республика-зона конференциясен уздырдылар. Анда Казаннан һәм өч район әдәби берләшмәләреннән — «Агымсу» (Мамадыш), «Аһәңле сүз» (Кукмара). Әгерҗе һәм шул районның Девятерня авылы әдәби түгәрәкләреннән кырыктан артык яшь шагыйрь, прозаик һәм шулай ук, традиция буларак, мәктәп әдәби түгәрәкләреннән килгән башлап язучылар иҗаты тикшерелде. Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов идея-политик тәрбия һәм яшь иҗат көчләре алдында торган бурычлар турында доклад белән чыкты. Конференциядә шагыйрь Сибгат Хәким, драматург Туфан Миңнуллин, прозаик Вакыйф Нуруллин, әдәби осталык мәсьәләләре турында чыгыш ясап, үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклаштылар. Яшь һәм башлап язучылар иҗаты буенча семинар җитәкчеләре булып шагыйрь Илдар Юзеев, прозаик Мөсәгыйт Хәбибуллин, язучылар Ләбибә Ихсанова, Шамил Рәкыйпов, Габдулла Шәрәфи, Лирон Хәмидуллин, Марсель Галиев, шагыйрьләрдән Рәдиф Гатауллин, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Рашат Низамиев, тәнкыйтьчеләр Мансур Вәлиев, Ринат Мөхәммәдиевлар катнашты.*

*Яшь прозаик Нәбирә Гыйматдинова, драматурглар Ризван Хәмид, Фоат Садриев конференция исеменнән СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителделәр. Кукмара районында туып үскән, хәзер Казанда яшәүче яшь шагыйрь Рәниф Шәрипов иҗатына да уңай бәя бирелде.*

*Укучыларыбызга конференциядә иҗатлары тикшерелеп, матбугатка бирергә лаек дип табылган яшьләрнең кайбер шигырьләре тәкъдим ителә.*

## Шаһинур Мостафин

### Солдат дәфтәреннән

*Рушан улыма*

«Улың сине сагына: «Әттә!» дия...»

*Әнисе хатыннан өзек*

«Әттә!»
Үскәнеңне синең, улым,
Сизмәгәнмен хәтта.
«Әттә!»
Син шатландыр мине
Шул кадерле сүзне әйт тә,
Мең шатландыр солдат әтиеңне.
Яле, улым! — «Әттә!»...
Шулай инде
Безнең малай халкы туган шәпкә
Бәрәгәйле сикереш ясый...
Әмма
Кояш тотам диеп үрелгәндә

Итеп куя үзе кайчак «пәп» тә...
Мөлдерәтми ләкин энҗеләрен,
Белә ич ул
Елакларны яратмый бу җиһан!
...Зәңгәр бишек бары җырга мохтаҗ,
Ни мәгънә бар туплар шартлатудан?!
Җиз кыңгырау булып чыңласынга
Күктә җыры сабан тургаеның.
Сакта торам менә... Көлтә-көлтә
Кояш нуры белән уйна, улым!
Уйна, улым, һич тукталып торма,
Һәм кабатла үзең:
«Әттә!», «Әттә!»...
Шушы сүз гел яңгырап торсын өчен
Гомер дә жәл түгел, улым, хәтта!

## Кайтмаганнар турында җыр

Кайтмаганнар күпләр яу кырыннан.
Кайтмаганнар — илне саклаганнар,
Курыкмыйча утка атлаганнар.
Кайтмаганнар — суда батмаганнар,
Кайтмаганнар — илне сатмаганнар,
Күкрәк киереп аны яклаганнар.
Шанлы юлда — Иделдән Берлингача
Җиңеп атлаганнар —
Кайтмаганнар...

Кайтмаганнар уйда сакланалар,
Кайтмаганнар җырдай ятланалар.
Сандыкларда өчпочмаклы хатлар
Күз карасы кебек сакланалар...

Кайтмаганнар... Ә шулай да бер көн
Туган якка кайтты кайтмаганнар! —
Исемнәре данга төрелгәнгә,
Һәйкәл булып басты кайтмаганнар!..

●

Кыңгырау чәчәктә — саф чыклар,
Тамарга әзерләр — тик кагыл!
...«Кылт!» итеп хәтергә төштеләр
Чәчәктәй кызларың, и авыл!

И авыл! Хәтердә — кызларың,
Колакта аларның җырлары.
Колакта җырларга кушылып
Яңгырый кыңгырау чыңнары.

Кыңгырау чыңнары яңгырый,
Мине бит шул чыңнар озатты...
Алдымда тормышка — сынауга
Илтәчәк гади бер юл ятты.

И юллар — җирнең кан тибеше,
Мин сездә юлчымын һаман да.
...Хәтердә нур булып, җыр булып
Кыңгырау чәчәкләр җанлана.

Гаҗәеп илләрне күрәмен,
Чәчәкләр күрәмен — соклангыч!
Тик һаман, кыңгырау чәчәкләр,
Сез миңа бирдәнбер юаныч...

Чакыра юлларның ерагы,
Хәзер мин зур юллар чатында.
Телимен, бик азга булса да,
Авылым юлыннан кайтырга...

...Кыңгырау чәчәктә — саф чыклар,
Тамарга әзерләр — тик кагыл!..
...Кайларда йөрсәң дә кызларың
Онытылмый икән шул, и авыл!

## Рәниф Шәрипов

### Чиксезлеккә манып

Галәм уртасында җир шары
Ком бөртеге кебек нибары.
Ә бөртектә күлләр, диңгезләр,
Җилләр, илләр, язлар һәм көзләр.

Шул бөртекнең тере җаны мин.
Тереклекнең комсыз аңы мин.
Чиксезлеккә манып каләмне,
Айкап йөрим менә Галәмне...

●

Борчусыз узар көннәрең —
Хатларын утка яктың.
Мәхәббәт артык борчу шул,
Ә син уңай ир таптың.

Учакта — ут йоткан хатлар,
Уттан да кайнар сүзләр.
Яндырган — онытыр тиздән,
Ә язган ничек түзәр?

...Өметсез уза көннәрең,
Хыялың утка яктың.
Бәхет юлы кыен юл ул,
Ә син җиңел юл таптың.

Учакта — тиле хыяллар,
Көл булды тиңсез сүзләр.
Яза белгән тагын язар,
Яндырган ничек түзәр?!.

•

— Исеңдәме, алсу таңнар
Көткән идек?
— Хәтерләмим... Таңнар көтү
Үткән инде...

— Исеңдәме, күзләреңнән
Үпкән идем?
— Онытканмын... Мин кияүдә
Күптән инде...

— Исеңдәме, сине ташлап
Киткән идем?
— Әйе... елап... күз яшьләрем...
Кипкән инде...

•

Ишетергә телим кабат синнән
«Сөям» дигән тылсым сүзләрен.
Күбәләккә охшый керфекләрең,
Йомылганнар зәңгәр күзләрең.

...Ишетәсем килә. Уян инде.
Дөрелдәгән куе керфегең
Әллә оялудан каплый һаман
Зәңгәр күкнең ике бөртеген.

Сирпелделәр кара күбәләкләр,
Чәчрәп чыкты зәңгәр тамчылар
Һәм мәхәббәт дигән илгә тагын
Бер май таңын урлап качтылар...

Казан

## Әлфирә Фәтхетдинова

### Гөрләвекләр

Гөрләвекләр җыры инде
Чыңлатмый урамнарны.
Башланды дулап, тартышып
Сыерчык бураннары.

Агыла башлаган хисләр
Йомылды кинәт кенә.
Бетмәде инде кышлар дип
Дулады йөрәк кенә.

Сыерчык бураны үтәр,
Кояш бер чыгар әле.
Күпкә түзгән, азга түзәр,
Йөрәк тә чыдар әле.

Һай бу кышның язга кадәр
Юллары уралмалы...
«Инде яз» дигәч кузгалды
Сыерчык бураннары.

●

Бу язның үзенә генә хас
Бер тылсымы бар сыман.
Күңел йомшарырга тора —
Яңа яуган кар сыман.

Күңел гел урамга тарта,
Өй эчләре тар сыман.
Кояшлы язгы көннәрдә
Бөтен җиһан ал сыман.

Үзе әкият тә сыман,
Үзе чын-чын яз сыман.
Биләп алган якты шатлык
Җитми сыман, аз сыман.

Әгерҗе районы,
Девятерня авылы

## Зиннәтша Дәүләтшин

### Горурланам

Гүзәллекләр алып килде апрель таңы,
Шомыртларның туй күлмәге кияр чагы.
Күкне кочып, сибә тургай язгы моңын,
Бу моңнардан ишетәм мин Тукай җырын.
Назлы гына шытып килә хәтфә үлән,
Апрель белән безгә бөек Ильич килгән.
Горурланам мәңге бәхет, шатлык биргән,
Ямьле язлар бүләк иткән илем белән.

Мамадыш

## Хамис Батыров

### Кыр чәчәге

Басуларда зәһәр буран шаулый,
Салкын сулыш өреп үч белән.
Кыр чәчәге, гади кыр чәчәге,
Түзә икән нинди көч белән?
Җилләр уйный шәрә җирне тырнап,
Кар һәм туфрак бергә айкала.
Кыр чәчәге, җылы җәй чәчәге,
Сабырлыгын җыеп чайкала.
Офтанмыйча үз язмышы өчен,
Сер бирмичә карлы җилләргә,
Аягүрә тора кыр чәчәге
Гыйбрәт биреп назлы гөлләргә.

Мамадыш

Илбарис Надиров

# ЛЕНИНИАНАНЫҢ ГҮЗӘЛ БЕР СӘХИФӘСЕ

СССР халыкларының поэтик иҗатында Владимир Ильич Ленин образы якты һәм хөрмәтле урын алып тора. Даһи юлбашчыга багышлап төрле телләрдә иҗат ителгән гаҗәеп бай фольклор хәзинәсен ленинизнаның гүзәл бер сәхифәсе дип бәяләргә нигез бар.

Бу шигъри хәзинәнең бер өлеше татар телендә махсус җыентыкка тупланып моннан ун ел элек дөнья күргән иде[1]. Анда туган илебездә яшәүче егерме сигез халыкның Ленин образын ихлас җылылык һәм самими соклану белән сурәтләгән иң матур әкиятләре, легендалары, җырлары, сөйләкләре китерелә. Алар арасында героик рухлы әсәрләр белән беррәттән эпик һәм лирик әсәрләр дә зур гына урын тота. Фольклор традицияләренә, шигъри сурәтләү байлыгына таянып төрле жанрларда иҗат ителгән әсәрләргә бер хис уртак: бөек юлбашчыга олы мәхәббәт хисе ул.

Борынгы дастаннарда, әкиятләрдә, эпик җырларда сурәтләнгән идеаль геройлардан аермалы буларак, Ленин образы уйдырма образ түгел, ә реаль тарихи чынбарлык тудырган бөек шәхеснең поэтик гәүдәләнеше. Ленин — күп халыклар иҗатында гасырлар буе якты нур булып балкыган азатлык һәм бәхет хыялын тормышка ашыруда иң туры, иң ышанычлы юл — юнәлеш күрсәтүче, рух һәм куәт бирүче олы шәхес. Менә шуңа күрә үз шигъриятләрендә халыклар аны чын азатлык, чын бәхет китергән даһи юлбашчы һәм акыллы остаз, кыю революционер һәм ягымлы, тыйнак кеше итеп сурәтлиләр.

Алда искә алган китапның кереш сүзендә бу хакта күп санлы мисалларга таянып шактый киң күзәтү ясалган. Татар халык иҗатында Ленин образының чагылышы турында да аерым мәкаләләр булды. Шул сәбәпле сүзне юлбашчы турындагы фольклорны өйрәнүчеләр игътибарыннан читтәрәк калып килгән мәсьәлә — Ленинга багышланган халык җырларын алдык. Әлегә кадәр чыккан мәкаләләрдә ул җырлар, кагыйдә буларак, мәгънәви-тематик яктан гына тикшереләләр. Нәтиҗәдә җырларның тарихи нигезләре һәм поэтик ягы тиешенчә ачыкланмый кала бирде. Соңгы елларда басылган яңа чыганакларга һәм фольклор экспедицияләре вакытында язып алынган яңа әсәрләргә таянып бу теманы киңрәк яссылыкта һәм тирәнрәк карарга мөмкинлек бар.

Экспедицияләр дәвамында фольклорчылар ел саен бик күп җыр язып алалар. Аларның бер өлешен, кагыйдә буларак, бүгенге бәхетле тормыш, тынычлык, туган ил, Ленин турындагы җырлар тәшкил итә. 1976 елда басылып чыккан «Кыска җырлар» китабында ул җырларның матур гына үрнәкләре дөнья күрде. Шуны да әйтеп

[1] «Исеме халык телендә». СССР халыклары иҗатында Ленин образы. Төзүчесе һәм искәрмәләр авторы И. Надиров. Казан, 1970.

үтик, бу китапта татар халкының Ленинга багышланган һәм заман сынауларын үткән алтмыштан артык җыры урнаштырылган.

Күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи күп еллар буена җыелган безнең заман җырларын аерым китап итеп чыгарган иде[1]. Анда «Ленин турында җырлар» дигән махсус бүлектә халыкның җиде җыры үз көйләре (ноталары) белән китерелә.

Ленин турындагы җырларның беренче үрнәкләре илдә яңа җәмгыять корыла башлаган давыллы, данлы елларда, Ленин үзе исән чакта иҗат ителгән. «Ай, дуслар!» дигән популяр җыр шуның бер мисалы. Аны яздыручы Рәшит ага Мозаффаров әйтүенә караганда, җыр 1918—1919 елларда Мамадыш тирәләрендә чыккан. Җ. Фәйзи бу әсәрне «музыка фольклорында эчтәлек һәм форма бердәмлегенең бер үрнәге» дип саный. Текст ике өлештән — Ленинга багышланган дүрт юллы җырлардан һәм күтәренке рухлы кушымтадан тора. Аларны берләштергән уртак бер шигъри образ бар. Ул — якты юл образы:

**Алсу нурлы таңнар атты**
**Безнең зур илебездә;**
**Бөек Ленин күрсәтте бит**
**Туры, якты юл безгә.**

Кушымта:
**Ай, дуслар!**
**Нурлар алыйк,**
**Юллар салыйк,**
**Гөлләр кадыйк маякка,**
**Гөлләр кадыйк маякка!**

Ленин сызган якты юл образы соңрак бик күп җырларда кабатлана һәм җыр теле белән әйткәндә «хаклыкка», «яңа җиңүләргә», «рәхәт тормышка» илтүче бердәнбер туры юл, олы юл буларак сурәтләнә: шуңа күрә халык үзенең җырларында бу юлдан «тайпылмаска», «чигенмәскә» вәгъдә бирә:

**Кызарып кояш чыкканда**
**Без булырбыз урманда.**
**Һичбер вакыт ялгышмабыз**
**Ленин юлы булганда.**

**Тар сукмактан күптән чыктык,**
**Олы юлдан барабыз;**
**Олы юлга алып чыкты**
**Безне Ленин бабабыз.**

Юл образы — гасырлардан килә торган традицион образ. Әмма борынгы җырларда ул лирик геройның омтылышларына киртә булып торучы тар һәм караңгы юл булып күз алдына килә. Ике генә мисал китерик:

**Без барасы юлларның**
**Ике чите казылган;**
**Безнең болай буласылар**
**Мөкатдәрдә язылган.**

**Бара торган юлларымнан**
**Елан чыкты аркылы.**
**Бу дөньяны ут чолгаган,**
**Безгә тия ялкыны.**

[1] Җәүдәт Фәйзи. «Халык җәүһәрләре». Татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры. Казан, 1971.

Ленин юлының якты һәм нурлы юл булу мотивы башка халыкларның җыр иҗаты өчен дә уртак мотив. Моңа таянып без төрле халыклар иҗатына борынгыдан хас типология күренешләренең яңа мисаллары турында фикер йөртә алабыз. Рус халкының «Мең рәхмәтләр яусын» дигән җырында шундый строфа бар:

**Даһи Ленин мәрхәмәтле булды,**
**Игелекле булды халыкка.**
**Тәхетеннән сөреп патшаларны,**
**Яктыртты ул юлны халыкка.**

Үзбәк халкының «Ленин юлы — нурлы юл» дигән җырына күз салыйк:

**Ленин юлы юл икән,**
**Бу юл тулы нур икән.**
**Иркен, рәхәт тормышка**
**Иң туры юл шул икән.**

**Безгә юлны киң кылды,**
**Милләтләрне тиң кылды.**
**Ленинның һәрбер сүзе**
**Эшебезне уң кылды.**

Татар халкының Ленин исән чагында чыккан тагын бер җырына тукталып үтәсе килә. Ул әсәр «Казаннардан Мәскәү...» дигән исем астында Җ. Фәйзинең искә алган китабында басылган (45—46 битләр). Анда җырның көенә караган кызыклы гына мәгълүматлар китерелә. Композитор А. Ключарев һәм музыка белгече М. Нигъмәтҗанов көйне халыкның борынгы музыкаль әсәре булуын билгеләп үтәләр[1]. Революциядән соң бу көй яңа исем, яңа сүзләр белән яши башлый һәм халыкның юлбашчыга кайнар сәламен илтүче, мәхәббәт тойгыларын аңлатучы җырга әйләнә. Мондый хәл чор өчен табигый иде. Мәгълүм ки, революциядән соң егерменче еллар уртасына хәтле татар халкының бер төркем борынгы көйләре заман өчен актуаль булган яңа сүзләр белән яшәде. Моның аерым мисалларына әдәбият галиме Хатип Госман үзенең бер хезмәтендә махсус тукталып үтә[2]. Бу күренеш совет фольклорының башлангыч адымнары өчен уртак күренеш иде. М. Горький сүзләрен искә төшерик: «Шуны игътибарга алырга кирәк, — ди ул, — яңа сүзләр белән җырланучы иске көйләр халык тарафыннан җиңел һәм тиз кабул ителә торган яңа әсәрләр булып киталәр»[3].

«Казаннардан Мәскәү...» җыры — әнә шундый әсәрләрнең берсе. Ул халыкның юлбашчыга музыкаль сәламе булып яңгырый:

**Мәскәүләрдән Казан якты ала,**
**Кояш сирпегәндәй нурларын;**
**Даһи да гына Ленин халыкларның**
**Аңлады бит изге уйларын.**

**Язам, язам ялкынлы сәламнәр,**
**Кулларымда корыч каләмем.**
**Бөек юлбашчыбыз, һәй, Ленинга**
**Җитсен иде кайнар сәламем.**

Миллионлаган эшчеләр, крестьяннар, укучылар бөек юлбашчыга үзләренең җылы тойгыларын җырга салып та, хатлар ярдәмендә дә җиткерергә омтылалар. Татарстан хезмәт ияләренең Ленинга адресланган күп санлы хатларын тупласаң, аерым бер китап булыр иде. Бу хатлар — халыкның үз юлбашчысы белән ни дәрәҗәдә якын бәйләнештә яшәвенең гүзәл бер чыгылышы. Аларның эчтәлеге дошманнарга каршы көрәштә һәм яңа җәмгыять төзүдә ирешелгән уңышлар турында рапортлар-

---

[1] Ключарев А. «Татар халык көйләре». Казан, 1955, 123 бит; Нигъмәтҗанов М. «Татарская народная песня». Казан, 1964, 107—108 битләр.
[2] Хатип Госман. Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе. Казан, 1960, 151—152 битләр.
[3] Горький М. Собрание сочинений. Том 27, Москва, 1953, 351 бит.

дан, кыенлыкларны тизрәк җиңәр өчен киңәш-ярдәм сораудан гыйбарәт. Мисал өчен, 1920 елның 14 июнендә хәрби моряк Хисмәтулла үзенең һәм иптәшләренең тормышы, көрәше турында Владимир Ильичка озын хат яза. Хат түбәндәге юллар белән башлана: «Мин Сезгә чын күңелдән пролетар сәламе җибәрәм. Контрреволюциягә һәм Антантага, акгвардиячеләр өеренә һәм сорыкортларга каршы аяусыз көрәшегездә киләчәктә дә уңышлар телим... Бүгенге көндә үземнең фронтта икәнлегемне, яшь Советлар республикасын күкрәгем белән саклавымны хәбәр итәм...»[1].

«Кызыл Армия» газетасының 1921 ел, 27 нче январь санында (№ 410) басылган бер хатка күз салыйк. Аны Ленин исеменә татар хатын-кызларының 1 нче Өлкә съездында катнашучылар язганнар. Хатта шундый юллар бар: «Без, партиясез эшче-крестьян татар хатын-кызлары дөнья пролетариатының юлбашчысы Ленинга кайнар сәламнәребезне күндерәбез һәм дөнья революциясенең тулы җиңүенә чакырган коммунизм байрагы астына берләшеп ныклы адымнар белән алга барырга тантаналы вәгъдә бирәбез».

Владимир Ильичның вакытсыз үлеме җир шарындагы барлык намуслы кешеләр өчен иң авыр югалту булды. Ул кайгылы көннәрдә халыклар күңелен биләгән кичерешләр фольклорда да тирән эз калдыра. Татар халкының Ленин үлгәч иҗат ителгән җырларының буеннан-буена юлбашчыны юксыну, сагынып искә алу мотивы кызыл җеп булып сузылган. Шуларның бер үрнәге «Төнге сәгать уникедә» дигән җыр[2]. Җ. Фәйзи истәлегенә караганда, ул аны 1924 елның җәендә Оренбург шәһәрендә ишеткән һәм язып алган. Җырның баштагы ике строфасы юлбашчы образын төнлә белән язу өстәле янында эшләп утырган бер хәлдә җанлы итеп күз алдына бастыра. Аның язган сүзләре таң нурыдай якты:

**Төнге сәгать уникедә**
**Кем язганын беләмсең!**
**Ленинның якты сүзләрен**
**Таң нурында күрәмсең!**

Һәм шунда, төн йокысын йокламыйча халыклар бәхете турында кайгыртып эшләгән чагында, Ленинның ялкынлы йөрәге тибүдән туктый. Халык хыялында ул шулай гәүдәләнә. Халык бөек Ленин белән хушлаша:

**Төнге сәгать уникедә**
**Язу өстәле буш инде;**
**Халыкларга бәхет биргән**
**Бөек Ленин, хуш инде.**

Ленин үлгәч хезмәт кешеләре күңелендә уянган олы кайгы тойгысы юлбашчының үлемсезлеген раслаган фикер-хисләр белән аралаша. Ленин үзе үлсә дә, аның бөек эше, даһи тәгълиматы яши, дәвам итә, аның исеме, якты образы халыклар йөрәгендә мәңгелек урын алган.

**Исле чәчәк өзелсә дә**
**Исе кала болында;**
**Ленин бабай үзе үлсә дә**
**Исеме халык телендә,**

—ди татар халкы үзенең бер җырында.

Ленин васыятьләренә инану, аның идеяләре өчен яңа көрәшләргә әзер тору һәм ул төзегән Коммунистлар партиясе тирәсенә тагы да тыгызрак туплану хисе мөһләгән хат авторлары өчен уртак, аваздаш хис. Ленин вафат булгач Татарстан хезмәт ияләре язган санаусыз күп хатлардан ике хатны телгә алып үтик. Аларның берсе Арча коммунистлары, комсомол һәм профсоюз членнары тарафыннан язылган: «Авыр туфрагың җиңел булсын, кадерле һәм онытылмас Владимир Ильич, табутыңда тыныч йокла. Шуңа ышан, син искиткеч кыенлыклар кичереп көрәшкән идеяләрне без ахырынача тормышка ашырырбыз!»[3].

[1] «Ленин и Татария». Сборник документов, материалов и воспоминаний. Казань, 1970, стр. 229.
[2] Җ. Фәйзи. Халык җәүһәрләре. 46 бит.
[3] «Известия» газетасы, 1924 ел, 25 нче январь, 20 сан.

Алабуга шәһәренең В. И. Ленин исемен йөртүче мәктәп укучылары язган хатта болай диелә: «Ильич үлсә дә, аның васыятьләре яши һәм без аларны үтәрбез. Тыныч йокла, безнең кадерле укытучыбыз, сөекле юлбашчыбыз Владимир Ильич, синең эшең тулы җиңү белән тәмамланыр.

Бернинди шикләнүләрсез һәм куркусыз кыю рәвештә алга!»[1]

Дөрестән дә, хатларда һәм җырларда никадәр уртаклык, бердәмлек! Хатлар телендә дә, җырлар телендә дә бер үк фикер-хисләр, бер үк кайнар ант сүзләре! Тагын ике җыр искә төшә.

**Тыныч йокла, Ленин бабай,**
**Мавзолееӊ эчендә;**
**Көрәшергә әйткән сүзең**
**Һәммәбезнең исендә.**

**Тыныч йокла, Ленин бабай,**
**Һәрбер сүзең үтәлә;**
**Бөтен дөнья эшче халкы**
**Байрагыңны күтәрә.**

Мәгълүм ки, егерменче еллар ахырында һәм утызынчы еллар башында Татарстан авыллары һәм шәһәрләрендә йөзләгән үзешчән сәнгать түгәрәкләре эшли башлады, яшьләрнең күмәк уеннары, күмәк ял итүләре өчен хәрәкәт мәйданы бермә-бер киңәйде. Яңа тормышка багышланган иҗтимагый-лирик җырларның шактые нәкъ шул чорда иҗат ителеп, халык арасында популярлык казанды. Ленин турындагы җырлар бәйләме дә шул елларда яңа җырлар хисабына баеды, тулыланды. Бу җырларда авыл җирендәге үзгәрешләр, колхоз төзелеше һәм күмәк тормыш, данлы бишьеллыклар һәм гигант корылышлар, Кызыл Армия һәм илне саклау темасы Ленин исеме, партия эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнә.

Бүгенге тормыш матурлыгы хакында сөйләгәндә татар халкы үзенең җырларында Ленинны кабат-кабат юксынып, сагынып телгә ала:

**Бер кызара, бер аллана**
**Карлыган пешкән чакта;**
**Ленин бабай булсын иде**
**Колхозлар үскән чакта.**

Юлбашчыга багышланган җырлар бәйләме безнең көннәрдә дә байый тора. Мисал өчен соңгы вакытлардагы фольклор экспедицияләрендә язылып алынган күп җырларның икесен китереп үтик.

**Идел-Кама суларында**
**Зур-зур ГЭСлар салабыз;**
**Шундый ГЭСлар төзергә дип**
**Кушкан Ленин бабабыз.**

**Ленин бабайның юлларын**
**Мәңгелеккә саклыйбыз;**
**Күмәкләшеп эшли-эшли**
**Коммунизмга атлыйбыз.**

Татар халкының Ленин турындагы җырларына хас кайбер поэтик үзенчәлекләргә җентеклерәк тукталып үтәсе килә.

Алда әйтелгәнчә, аларның төп өлешен махсус көйләргә беркетелмәгән кыска җырлар — дүртьюллыклар тәшкил итә. Бу җырларның композицион структурасында сурәтле янәшәлекнең киң таралган ике төре аеруча ачык күренә.

---

[1] Татарстан өлкә комитетының партия архивы. Ф. 1229, эш б. 331, п. 5. Төп нөсхәдән. Искә алынган хатлар «Татарстан хезмәт ияләре — Ленинга» дигән исем астында тарих фәннәре кандидаты М. А. Сайдашева һәм М. Б. Кочурова тарафыннан матбугатка хәзерләнгән җыентыктан алынды.

Бер төркем җырларда строфаның дүрт юлы да мәгънәви яктан тыгыз бәйләнгән булып, тезмәләр мөнәсәбәтенә органик бөтенлек хас.

Ленин сүзләрен өйрәник,
Колхозчылар, килегез;
Ленин бабай өйрәткәнчә
Төзелә безнең илебез.

Калган җырлар тиңдәш буыннар янәшәлегендә корылган. Аларда беренче буынны табигать дөньясыннан, я яңа көнкүреш даирәсеннән алынган берәр картина тәшкил итә һәм шул фонда юлбашчы образы белән бәйле фикер-хис гәүдәләнә. Тиңдәш буыннар арасында җырга эчке тулылык һәм гармония төсе бирүче мәгънәви аһәңдәшлек һәрвакыт сизелеп тора. Бу аһәңдәшлекне ныгытучы сүз-сурәтләр, шигъри образлар бар. Алар, кагыйдә буларак, халыкның совет чорындагы иҗтимагый-лирик җырлары өчен уртак булган яңа сурәтләр, яңа образлар. Ленин турындагы җырлар тукымасында, мәсәлән, «мавзолей», «кызыл гөл», «кызыл байрак», «аллы-гөлле гөлчәчәк», «алсу таң», «кояш» образлары еш очрый.

Таң һәм кояш образлары СССР халыкларының Ленинга багышланган поэтик әсәрләре өчен уртак образлар. Әрмән, башкорт һәм таҗиклар поэзиясендә Ленин образы алсу таң белән тиңләнә. Дунган халкы үзенең бер җырында Ленинны «Яңа кояш» дип атый. Ленин кояшы мордва авылы өстендә нур сибеп тора, тундрадагы халыкларга яшәү җылысы бирә[1].

Гел янып, нур сибеп тор, кояш!
Балкып тор Ленинның кояшы!
Көннән-көн яктырак яшәсен
Мәңгелек бәхетләр дөньясы,

— ди бурят халкы[2]. Шул рәвешле, халыклар поэзиясенә элек-электән үз булган традицион кояш образы яңа мәгънә, яңа эчтәлек ала һәм совет кешеләренең Ленинга яктылык чишмәсе, тереклек чыганагы итеп каравын раслаучы символ дәрәҗәсенә күтәрелә.

Тугандаш бер семьяга тупланган совет халыклары Ленин сызган якты юлдан барып, илдә социализм нигезен кордылар һәм коммунистик җәмгыять төзиләр. Илебезне бу олы юлдан данлы Коммунистлар партиясе алып бара. Шуңа күрә Ленин турындагы фольклорның аерылгысыз бер өлешен партиягә тирән мәхәббәт, ышаныч, турылык белдергән әсәрләр тәшкил итә. Ленин үзе булмаса да, аның васыятьләрен тормышка ашыручы, көрәшкә рухландыручы партия бар:

Идел суы җем-җем итә,
Дулкыны киртә-киртә;
Ленин юлыннан партия
Коммунизмга илтә.

Беренче карашка гади генә күренгән җыр юлларында безнең чорга хас тормышчан хакыйкать ачык һәм төгәл булып гәүдәләнгән.

«Фольклор безнең көннәрдә Владимир Ленинны борынгы заманның Прометейга тиң булган герое югарылыгына күтәрде», — дигән иде Максим Горький. Бу сүзләрнең хаклыгын Советлар илендә яшәүче халыкларның фольклоры, шул исәптән, татар халкының җыр поэзиясе чын-чынлап раслый.

••••••••••••••••

---

[1] Мисаллар «Исеме халык телендә» дигән җыентыктан китерелделәр, 18, 42, 44, 65, 94, 114 битләр.
[2] Шунда ук, 43 бит.

**Фоат Галимуллин**

# ТИРӘН КАТЛАМНАРНЫ АЧКАНДА

*Шамил Бикчуринның иҗат портретына эскизлар*

Иҗатының буеннан-буена бер темага турылыклы калган язучылар була. Шамил Бикчурин — әнә шундыйларның берсе. Хезмәт кешесенең, аерым алганда, нефтьчеләрнең күңел матурлыгын, бай рухи дөньясын ачу-тасвирлау вазифасын иҗатының төп кыйбласы итеп алды да, шушы авыр, шактый четерекле йөкне һич авырсынмыйча тарта ул.

Производство темасы теләсә кемнең теше үтмәслек тормыш материалы белән күпләрне урап үтәргә мәҗбүр итүче каты чикләвек булып килде. Ул үзенә очраклы гына кагылганнарга тәмле төшен авыз иттерергә ашыкмады. Уңышлы әсәр язу өчен производствоның үз эчендә бөреләнеп җитлегергә, аның әһәңен-көен тоя белергә, шундагы кешеләргә гашыйк булырга кирәк.

Мәрхүм Ибраһим Гази болай дигән иде: «Нефтьчеләребез хакында да яңа романнар күтәргә хакыбыз бар, чөнки Әлмәт, Лениногорск шәһәрләрендә зур гына төркем тәҗрибәле язучыларыбыз яши. Алар көн саен нефть осталары белән аралашалар, нефтьчеләрне хезмәттә генә түгел, өй, семья шартларында да, клубларда да, урамда да, автобуста да, концерт залларында да күрәләр. Нефтьче геройларыбыз хакындагы романнарны без, беренче чиратта нәкъ менә шул иптәшләр язар, дип өмет итәбез»[1]

Ш. Бикчурин, язучы буларак, нефть чыккан төбәкләрдә үсте, булачак геройларның хис-кичерешләрен, хыял-омтылышларын үзе дә кичерде. Әлмәттә төзүче, Лениногорскида нефтьче булып эшләү аңа хезмәт кешесенең шигърияткә бай күңелен аңларга өйрәткән беренче тормыш мәктәбе булды. «Каты токым» романын «... иҗат итү өчен Бикчуринның Миңлебай авылында тууы да, шушы төбәктә үсүе дә, шушында баш-күз алып, игенчеләр дөньясына яңа бер дөньяның, җир маен эзләүчеләрнең килеп керүен дә үз күзләре белән күрүе кирәк булды. Ул байтак вакытлар тормыштагы үз юлын эзләп йөрде, ул артист булырга теләде, ул төзүче һөнәренә өйрәнде, ул яңа салынган йортларның түшәмнәренә бизәкләр ябыштырды. Шул дәвердә үк Шамил Бикчурин күңелендә иҗат итү уе бар иде, ул Әлмәттә оештырылган әдәби түгәрәккә йөрде, шигырь язды, хикәя язды. Ниһаять, аның беренче хикәяләре, беренче очерклары кулга тотарлык булды, каләмдәш иптәшләре бик нығытып булышкач, матбугатта бастырып чыгарырлык булды. Аны Язучылар союзы идарәсе М. Горький исемендәге әдәбият институтының югары курсларына укырга җибәрде».[2]

---

[1] Гази И. Юл барганда.— «Социалистик Татарстан», 1968, 19 сентябрь.
[2] Ахунов Г. Иҗатыбызда эшчеләр темасы.— «Социалистик Татарстан», 1978, 28 декабрь.

Ш. Бикчурин үзен үстергән якларга игелекле булып калды, җир хәзинәсен чыгаручылардан иҗатына илһам алды. Мәгълүм булганча, аның һәр әсәре диярлек нефтьчеләр турында. Егерме елдан артык иҗат дәверендә ул «Ташлы тауда», «Истәлекле таш», «Тальян моңы», «Кайнар чишмә» кебек китаплары белән татар совет әдәбиятында нефтьчеләр тормышын яктыртуга шактый зур өлеш кертте. Әсәрдән-әсәргә каләмен чарлый торды, тормышны өйрәнде, язучының үз сүзләре белән әйткәндә, язарга тотынганчы күпмедер вакытлар әсәргә керәчәк персонажлары белән яшәде, алар турында уйланып, борчылып, шатланып йөрде. Бу уңайдан бер фикер әйтәсе килә: әсәрнең уңышында үзең тасвирлаган тормышны яхшы белү хәлиткеч таләпләрнең берсе булса да, аны абсолютлаштырырга да ярамыйдыр. Салкын кан белән, «белеп» кенә язылган әсәр, әгәр ул йөрәктән чыккан тойгылардан мәхрүм икән, акылга барып җитсә дә, хисләрне уята алмый.

Ш. Бикчурин эшче темасына очерк аша килде. Г. Ахуновның да «Хәзинә»гә килү юлында күп кенә очерклар иҗат итүен искә төшерик. (Сүз уңаенда әйтергә кирәк, ул очеркларны бергә туплап бастыру Г. Ахуновның язучы буларак үсеш юлын һәм Татарстан нефте тарихының мәгълүм бер этабын күз алдына китереп бастырырга хезмәт итәр иде.) Ш. Бикчуринның әнә шундый очерк-хикәяләрен туплап, 1977 елда «Алтын җирдә ятмый» дигән җыентык чыгаруы, бу күзлектән караганда, игътибарга лаеклы эш булды.

Җыентыкның исеме үк тирән мәгънәле. Автор төп игътибарын, табигый рәвештә, алтын куллы, саф йөрәкле, таза әхлаклы хезмәт кешеләренә юнәлтә. Өздереп гармун уйнавы белән йөрәкләрне җилкендергән нефтьче егет тә, алдынгы мастер Сәләхетдин абзый да, үзара ярышып эшләүче бертуган инженерлар Айрат белән Азат та, машиналар телен белүче тимер-томыр «докторы» Һашим карт та хәтердә кала. Аларның һәрберсе — үзенчәлекле холык-фигыльгә ия, кабатланмас эчке дөньясы булган характерлар. Язучы тормыш фактларын оста сайлый, беренче карашка гади генә булып тоелган кешеләрнең дә үзләренә хас якларын тотып ала, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне җентекләп өйрәнә.

Әйе, «алтын җирдә ятмый» дигәндә автор алтын бәһасенә торырлык кешеләрне күздә тота. Әнә шундыйларның берсе — нефтьче мастер Вәли Гыйматдинов. Ул үз эшенең остасы, махсус белеме булмаса да, көчле практик. Һәр яңалыкны кабул итәргә һәм производствога кертергә әзер торучы мастер. Тәпи йөрергә өйрәнүче бала, күп тапкырлар егылып, җирнең тарту көчен маңгае белән тойган кебек, Вәли дә, әле ныклы сынау үтмәгән яңалыкларны гамәлгә кертеп, сөртенгәләп ала. Автомат чөйләр белән эшләү, измә урынына су кулланып бораулау кебек четерекле эшләргә беренче булып алына ул, бер-бер артлы рекордлар да бирә. Ләкин шул ук вакытта аңарда кызу канлылык, бунтарьлык та бар.

Вәли — язучының хыялы тудырган персонаж гына түгел. Ул— реаль шәхес, очерк герое. Әмма без аның катлаулы характерга ия икәнлеген ачык күрәбез. Автор аны әнә шулай төрле яклап һәм ышандырырлык итеп сурәтләүгә ирешкән. Һавадан очып баручы торналарны күрү Вәлинең күңелендә хисләр өермәсе тудырырга мөмкин. Балаларын өзелеп яратучы яхшы ата һәм сөйкемле ир дә ул. Тормышта нинди генә авырлыкларга очраса да, ул бәхетне читтән түгел, яраткан хезмәтеннән эзли. «Җылыдан җылыны гына эзләп йөрергә без күчмә кошлар түгел», — ди Вәли. Язучы аның гаять кыен эшләрне дә башкарып чыгарга сәләтле оста икәнлеген исбат итә.

«Кайту» хикәясенең герое Мөнәвир исә Вәлинең капма-каршысы. Дөрес, аны үз эшен белми дип әйтеп булмый, ләкин, Г. Ахуновның «Хәзинә» романындагы Кәрим Тимбиков кебек, әллә ни киң карашлы булмаган бу кешенең уңышлардан башы әйләнә, аңа гел җай гына килеп торсын, акча да мул төшсен. Әмма скважина скважинага охшамый, бригада төшемсез урынга юлыга. Вакытлы кыенлыкларга түзә алмыйча, Мөнәвир бригаданы ташлап китә. Хикәядәге икенче бер персонаж Сәләхетдин абзый әйтмешли, «характер трактор түгел, тиз генә төзәтеп булмый». Мөнәвирнең кирелеге, акча яратуы, кара сакалы кебек, кая барса, шунда иярөп йөри. Ул, кире әйләнеп кайтып, Сәләхетдин абзыйга һәм иптәшләренә ялынырга мәҗбүр була.

Ш. Бикчурин бу хикәясендә үк инде әйбәт кенә психолог булуын күрсәтте. Мөнәвирнең уй-кичерешләре табигый ага, алар укучыларга яхшы аңлашыла.

Аерым кешенең көче коллективка, коллективның көче аерым шәхесләрнең сыйфатына бәйле дигән фикер «Кайнар чишмә» документаль повестенда тагын да дәлиллерәк раслана. Ул 1962 елда, вакыйгаларның кайнар эзеннән язылган, ләкин бу хәл әсәрнең аналитик тирәнлегенә зыян китермәгән. Киресенчә, авторның реаль тормыш күренешләрен сәнгатьчә тасвирлау осталыгына сокланасың.

Повестьның баш герое Борис Лобанов, тукучы Валентина Гаганова үрнәгенә кушылып, үзенең сәгать механизмы кебек төгәл эшләүгә көйләнгән бригадасыннан арттагы участокка күчәргә теләк белдерә. Әсәрдә Борис Лобановның яңа коллективка керүе һәм бу эшнең шактый катлаулы булуы сурәтләнә.

Лобановның эш стиле, холкы шикелле үк, сабыр һәм пөхтә. Ул каударланмас, кабаланмас. Һәр эшне җиренә җиткерү гадәтенә сеңгән, башкалардан да шуны таләп итә. Техника никадәр яңа, көчле булмасын, кешеләр ышанычлы, белемле булмаса, әллә ни эшләп булмый. Менә шуңа күрә Борис эшне коллектив белән танышудан башлый.

Бер максатка туплап, үз хезмәтләренең нәтиҗәләре белән кызыксындырып, Б. Лобанов бригаданы алдынгылар рәтенә чыгара. Башта аны мастер итеп кабул итәргә теләмәгән эшчеләр: «Бөтенләйгә китсә нишләрсең!» — дип куркып та калалар. Димәк, ул, М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе» әсәрендәге Бикташев шикелле, бригаданың үз кешесенә әверелә.

«Кайнар чишмә» әсәрен язгандагы бу тәҗрибә, һичшиксез, «Каты токым» романын иҗат иткәндә авторга файдалы булгандыр. Фазыл Зөбәеров алдына да коллектив туплау бурычы килеп баса, ул да шушы катлаулы бурычны егетләрчә башкарып чыга. Ул гына да түгел, Борис Лобанов тормышындагы кайбер детальләр Фазыл образына да штрих булып өстәлгәннәр. Мәсәлән, Борисның Гөлсинә яшәгән тулай торакка килеп йөрүе, яшьлек шаянлыклары Фазылның шундый ук эш-хәрәкәтләренә авааздаш. Эш өчен янып, ашавын, ялын онытып йөрүләре, нәтиҗәдә коллективны зур көч итеп туплый алулары бу ике образны тагын да якынайта.

Бу җәһәттән Ш. Бикчуринның тагын бер очеркына игътибарны юнәлтәсе килә. Ул 1968 елда язылган һәм «Каты токым»[1] дип атала. Очеркның булачак роман исеме белән аталуы очраклы түгел. Аның төп герое Анатолий Павлов кайсыдыр яклары белән Фазыл Зөбәеровны хәтерләтә. Әлеге образның тормышта прототибы булуы төсмерләнә. (Прототип дигәндә, әлбәттә, без аны реаль шәхеснең әдәби әсәргә тулаем «кереп утыруы» мәгънәсендә аңламыйбыз. Ул әдәби образ иҗат итү өчен этәргеч кенә булырга мөмкин. Идея-эстетик максатлардан чыгып, автор образны прототип кичермәгән хәлләрдә дә сурәтләргә хаклы.) Анатолий Павлов та, Фазыл Зөбәеров та үзләрен тормышны төзүчеләр, җир өстен бизәүчеләр итеп күрәләр, хезмәтләренең романтик асылын төшенәләр. Моңа ышану өчен, бу ике геройның күңел монологын тыңлап карыйк. «Павловка калса, нефть чыккан бер җирне ул я бер завод, я бер фабрика салынган урын дип күз алдына китерә. Скважина тирәсендә берәр авыл-мазар да утырса, ул инде булачак шәһәр дип карый. Янында урман булса — парк»[2]. Фазыл да нәкъ шулай уйлый: «Кем белә, шушы скважинадан нефть чыкса, бәлки әнә ул Язтургай дигәннәре авыл булып кына калмас, шәһәр булып куяр, янындагы менә шушы куе урманы паркка әверелер...»[3].

Яки менә скважинада авария булган чакны тасвирлаган эпизод. Ул да тулысынча диярлек, ләкин конкретлыгы бераз йомшартылыбрак, романда урын алган. Ә очерктагы Николай Трошихин романдагы Кадермәтне хәтерләтә.

Шулай итеп, Ш. Бикчурин хезмәт кешесенең якты образларын башта очерк жанрында тудырды. Әмма очерк язучыны күп кенә кыенлыклар да сагалап тора. Ул төрле сыйфатларны бер геройга туплау юлы белән образны типиклаштыра алмый. Ә кешенең үзенә генә хас холкын-фигылен, эчке кичерешләрен, тормыш вакыйгаларын җанлы итеп сурәтләү мәҗбүри шарт. Ш. Бикчурин менә шул катлаулы бурычны уңышлы гына тормышка ашырды.

«Каты токым» романы ашыкмыйча, җентекләп язылган. Ф. Хөсни, мәсәлән, болай дип искә ала: «Игътибар иттегезме икән, Ш. Бикчурин романының азагында «Лениногорск, 1968—1972» дигән тамгасы бар. Мин моның шаһиты була алам,

[1] Бикчурин Ш. Каты токым. Очерк.— «Казан утлары», 1968, № 5, 93—106 бит.
[2] Шунда ук, 99 бит.
[3] Бикчурин Ш. Каты токым. Роман. Казан, 1974, 31 бит.

чынлап та, 1968 елда, Малеевка иҗат йортында ул моның башлангыч бүлекләрен миңа укып күрсәткән иде. Аннары бер елны Ибраһим Гази мәрхүмнең, Әлмәткә барып кайткач, ул «сәлам чәчле» егетнең өметләндергеч әйбер өстендә эшләвен куанып хәбәр иткәне хәтеремдә»[1].

Басылып чыгу белән, роман җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булды. Аңа кадәр Ш. Бикчурин әдәби тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк калып килгән иде. Үзәк һәм республика матбугатында «Каты токым» турында дистәләрчә мәкалә дөнья күрде. Бүгенге эшчеләр сыйныфын чагылдыру буенча 1974—1976 еллардагы иң яхшы проза әсәрләренә Бөтенсоюз конкурсында Ш. Бикчурин романы икенче премиягә лаек булды. СССР язучыларының VI съездында да «Каты токым» әсәренең уңыш казануы билгеләп үтелде. «Современник» нәшрияты романны ике тапкыр зур тираж белән бастырып чыгарды, ул шулай ук «Эшче романы китапханәсе» сериясендә басылды, Чехословакия укучыларына да тәкъдим ителде.

«Каты токым». Автор мондый метафорик исем белән нефть разведкасында эшләүче кешеләргә хас сыйфатларга ишарә итә. «Алар табигать белән көрәшеп яшиләр, көрәшеп эшлиләр. Алар ничә ел тоташтан каты токымны кимереп баралар. Һәм алар ирешкән уңышларның сере нә шунда гына төшендем: үзләре каты токымнан булганда берниндиге каты җир токымнары да каршы тора алмый икән кешеләргә»[2]. Автор менә шундый бәя бирә бу героик хезмәт кешеләренә.

«Каты токым» әсәрен хаклы рәвештә характерлар романы дип атый алабыз. Ф. Хөсни дә аны «...кешеләре төрле һәм кызыклы булган... нефтьчеләр тормышын сурәтләгән һәм күп кенә гыйбрәтле хәлләрне, үзенчәлекле характерларны эченә алган» роман дип атый. Ул болай дип дәвам итә: «Кешеләре дә җанлы кешеләр, төрле характердагы кешеләр, эшләренә дә ышанасың»[3]. Әсәрдә персонажлар саны әллә ни күп түгел, аның каравы, язучы аларның характерларын тирәнрәк ачуга зур игътибар биргән. Һәр герой укучы күз алдында реаль кеше булып килеп баса. Аларның үткәне-бүгенгесе, характер формалашуының эволюциясе күрсәтелә. Ш. Бикчурин биредә оста художникларча эш иткән. Хәтта, әйтергә кирәк, бөтен игътибарны характерларга юнәлтү авторны икенче чиккә—производство даирәсен читләтебрәк үтүгә китергән, хезмәт процесслары чикле күләмдә генә, фон рәвешендәрәк кенә бирелгән.

Беренче карашка роман үзәгенә бөтен вакыйгаларны берләштереп торырлык конфликт куелмаган кебек. Әсәрдә һәр персонажның үз проблемасы бар, төп игътибар шуларны чишүгә юнәлә. Фазыл Зөбәеров үзенең остазы Ибраһим-Задә кебек «таудан биек, кыядан каты, диңгездән колачлы» мастер булырга тели. Тин Тиныч үзенең Валясын табу өчен нишләргә белми. Фәрхетдин таныш кызларының исемлеген арттыру белән генә мавыга. Сапарбайның бөтен омтылышы, калымга акча җыеп, яратышкан кызына өйләнү. Кадермәт, үзенең намуслы исемен торгызып, яраткан нефть эшенә бөтен барлыгын биреп хезмәт итәргә тели... Ләкин моннан чыгып әсәрнең үзәгенә куелган гомуми проблема юк икән дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Кайсы кая тартылган шушы кешеләрдән бер сулыш, бер омтылыш белән яшәгән нык коллектив туплау — авторны кулына каләм алырга этәргән төп проблема шушы. Катлаулы мәсьәләнең уңай чишелешенә персонажларның күбесе ышанмый. Мастер Зөбәеров үзе дә бу бурычның тормышка ашырылачагына шикләнә.

Әсәрдә төп вакыйгалар берничә ай эчендә генә бара. Ләкин автор, чигенешләр ясап, персонажларның үткәннәренә дә әйләнеп кайта.

Роман үзәгендә, әлбәттә, Фазыл Зөбәеров образы тора. Үзенчәлекле һәм катлаулы характерга ия булганы өчен төп игътибар шушы геройга юнәлә. Ул укучы күз алдында үсә, үзгәрә. Вакыты белән кырыс җитәкче дә, шагыйрәнә нечкә күңелле дә, дуамал да. Яшь чагындагы кебек җилбәзәкләнеп алырга да каршы түгел. Ләкин мастер булуы аны кайбер артык адымнардан тыеп кала. Шулай да фатир хуҗасы Сабирҗан ваклыгы һәм саранлыгы белән ирлек намусына кагылгач, характерындагы дуамаллыгы эчтә генә кала алмый. Бер агачын артыграк ягарга калтыранып торган Сабирҗан йортына машинасы белән утынын, мичкәсе белән кероси-

[1] Хөсни Ф. Без китмәскә килдек.— «Казан утлары», 1973, № 2, 173 бит.
[2] Бикчурин Ш. Каты токым. Казан, 1974, 188 бит.
[3] Ф. Хөсни. Без китмәскә килдек.— «Казан утлары», 1973, № 2, 173—175 бит.

нын кертеп аудара. Бу деталь Фазылны укучы күз алдында үстереп, калкытып җибәрә. Буровой астында җир убылып, вышка аву куркынычы тугач, әлеге ситуациянең иң хәлиткеч вакыйга икәнлеген аңлау аңа салкын канлылык, зирәклек күрсәтергә мөмкинлек бирә, үзен бригада кешеләре алдында мастер итеп танытуга китерә. Торба колоннасының җир астында калуына мөнәсәбәтле Фазылның тагын бер күркәм ягы—сабырлыгы күренә. «Эх, егетләр, харап иткәнсез бит скважинаны!» —дип шелтә ташлый ул бораулаучыларга, аннан, буровойдан башкаларны чыгарып бетереп, кысылып калган инструментны йолкытып карый. Эш барып чыкмаслыгын күреп, салкын кан белән авариянең сәбәпләрен тикшерүгә керешә.

Шундый ук торба кысылу эпизоды Г. Ахуновның «Хәзинә» дилогиясендә дә бар. Бу хәл мастер Тимбиковны чыгырыннан чыгара. Иптәшләренә дорфа сүзләр кычкыра, ярсып, колоннаны йолкытырга тотына, аварияне тагын да катлауландырып, үзе дә һәлак була. Кәримдә миң-минлек өстенлек итсә, Фазыл үзенең һәм иптәшләренең акылына таяна. Дөрес, башта ул да кырыслык белән алдырырга тели. Ләкин иң мөһиме—кешеләр белән генә түгел, производство белән җитәкчелек итү икәнлеген төшенә ул. Бригада членнары белән үзе арасындагы киртәне алып ук ташламаса да, аның тәэсирен шактый киметүгә ирешә.

Кеше шатлыгын үз шатлыгың, кеше кайгысын үз кайгың итеп кабул итү өчен олы йөрәкле булырга кирәк. Зөбәеровта бу сыйфат бар. Аның бригада белән җитәкчелек итә алуы шикләндерми. Ибраһим-Задә кебек таудан биек, кыядан каты, диңгездән колачлырак мастер булырга теләгән Фазыл үзенчә мастер булып җитлегә. Ул бригададан бүген китәм, иртәгә китәм дип йөргән кешеләрне бер үзәккә туплауга ирешә. «Мастер Зөбәеров Ибраһим-Задәдән ким булып чыкмады. Бригада кешеләре менә дигән». Саакян менә шундый нәтиҗә ясый.

Романда үзенчәлекле характерга ия геройларның берсе—Кадермәт. Аның язмышы кемне генә битараф калдырыр икән? Кадермәт бригадада иң хәзерлекле кешеләрнең берсе, ул әле сугышка кадәр үк махсус белем алган, тау техникгы, бораулау белгече булган. Ләкин язмыш аны үзенчә сыный—Ватан сугышында ул әсирлектә кала. Биографиясендәге шушы күләгә, кая бармасын, артыннан калмыйча, аны эзәрлекли. Хезмәт урынында да түбәнрәк баскычка күчерәләр, хатыны да ташлап китә. «Сугышта мине фашист үтерә алмады. Ә хәзер тыныч заманда маңгаема пуля җибәримме? Я, әйтегез әле, зинһар, нәрсә эшләргә миңа?» — дип өзгәләнә ул. Шулай каңгырып йөри торгач, Татарстанга килеп чыга, Зөбәеровка юлыга. Фазыл Кадермәтне үз бригадасына бораулаучы итеп алуга ирешә, аның яхшы белгеч булуын бәяли һәм ялгышмый.

Кадермәт үзенең намуслы исемен торгызырга тели, әсирлек шаһитләрен — дошман кулында да илгә тугрылыгын күргән иптәшләрен — эзләвен дәвам иттерә, алардан дөреслекне сөйләттерергә тели. Ләкин кая гына, нинди адрес белән генә язмасын, күңелен тынычландырырлык җавап таба алмый. Хәтта бергә эшләгән иптәшләре дә аңа ышанып бетмиләр, Мотгәрәй кебекләр исә «кулың керле» дип ычкындыргалый. Болай да күңеле китек кешене чыгырыннан чыгару өчен мондый төртмәле сүзләр җитә кала. Төннәр буе йокламыйча йөреп чыгу, кешеләр белән мөнәсәбәттә кызып китү аның холкына әверелә. Әмма эшенә кимчелек китерми, яраткан хезмәте кайгы-хәсрәтен оныттырып торучы рәхәт бер нәрсәгә әверелә. Нефть эше—аның үз стихиясе. Кайбер мәсьәләләрдә ул мастер өчен дә авторитет санала. Буровойда теләсә кайсы операцияне оста башкаруы белән таныла.

Кыен язмышлы бу кеше образын язучы тирән психологик дөреслек белән биргән. Укучы герой белән бергә борчыла, аның кичереш-хисләрен йөрәгенә якын ала. Бу — язучының осталыгын күрсәтүче сыйфат. Кадермәт, шушы бригадада эшләп, үзенең намуслы исемен кайтара, тормышында ямь таба. Ул инде бертуганнардай булып әверелгән иптәшләреннән аерыла алмый. Нефть чыгару берләшмәсе аңа яңа төзелгән бригадада мастерлык вазифасын үтәүне тәкъдим итә. Ләкин Кадермәтнең туган бригадасыннан китәргә теләге юк, биредәге мөнәсәбәтләр аның йөрәгенә дәва.

Романда җанлы образлар, кызыклы характерлар күп. Арада Мотгәрәй образы аерым бер кызыксыну уята. Ул рухи дөньясының үзенчәлеге, яхшыга омтылышы, саф күңелле булуы белән игътибарны җәлеп итә. Мотгәрәй, иң беренче чиратта,

хезмәт кешесе. Ләкин шулай да ул эшче түгел, бөтен барлыгы белән игенче. Бораулау бригадасына килеп эләгүе аның тормышының очраклы гына эпизоды. Иген эшен сагына Мотгәрәй. Аның комбайн штурвалы артына утырган чагын озак аерылып торган гашыйкларның кавышуы белән генә чагыштырырга мөмкин. Бу мизгелдә Мотгәрәй нинди матур! «Мотгәрәй бер көнне иртүк торды да кунакка барырга җыенган шикелле яхшылап кырынды һәм Сагындык аръягына, комбайн тавышы ишетелгән якка китте... Комбайнның сиртмәле йомшак утыргычына утырып, штурвалына тотыну белән әйтеп бетергесез иркенлек билән алды Мотгәрәйне. Тизлекне тоташтырып, педальгә басуга, аякларны чымырдатып, тәненә бертөрле рәхәтлек йөгерде... Мотгәрәйнең мондый ләззәтне татымавына да инде, уйлап карасаң, өч ел тулып узды бит». Әсәрнең русча вариантында, Мотгәрәйне авылда калдырып, автор бик дөрес эшләгән.

Ш. Бикчурин хезмәттә рухланган кешене күз алдына бастыра, хезмәтнең шигърияткн ачып бирә. Бөек М. Горький язучыларны нәкъ менә шуңа чакырды да. «Без хезмәтне... сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә торган кешене китапларыбызның төп герое итеп алырга тиешбез. Без хезмәтне иҗат дип аңларга өйрәнергә тиешбез»[1]. Бөек пролетар язучысының васыятенә турылыклы булу Ш. Бикчурин иҗатының буеннанбуена күзәтелә.

«Каты токым» әсәре шулай ук үзенең башка яклары: әһәмиятле проблемалар куюы һәм хәл итүе, художество эшләнеше, идея-эстетик юнәлеше белән, әлбәттә, бүгенге әдәбиятыбыз үсешенә әһәмиятле өлеш кертте.

Әсәргә бәя биргәндә тәнкыйтьчеләр, аның уңышларын билгеләү белән беррәттән, хаклы рәвештә, кимчелекләрен дә ачык күрсәтәләр. Ф. Миңнуллин «романның фонын азрак яңартырга, бүгенге көнгә якынайтырга кирәк булмадымы икән?»[2] диюе белән бик хаклы. Әсәрдәге вакыйгалар илленче елларда бара. Илленче еллар татар авылы шактый артта калган итеп тасвирлана. Колхоз председателе Галләмнең нефть эзләүчеләргә мөнәсәбәте укучыга аңлашылмый, ул, гомумән, бу эшкә кара күзлек аша карый. Нефть эшенә омтылучы яшүсмерне колхоздан җибәрмәс өчен ниләр генә эшләми. Авыл Советы председателе Хафизовны да нефтьчеләрне колач җәеп каршылый дип әйтә алмыйбыз. Ә бит чынлыкта туган ягыбызның кара алтын республикасына әверелүе урыннардагы партия-совет оешмалары булышлыгыннан башка булмады һәм була да алмас иде.

Ләкин авторның нефтьчеләр характерын бөтен нечкәлеге белән белүе бәхәссез. Бу турыда китап укучыларның да фикерләре кызыклы. Ленин орденлы бораулаучы Мөнир Фәсхетдинов, мәсәлән, болай ди: «... чандыр буйлы, какча яңаклы, зәңгәр күзләрендә кызыксыну бөркелеп торган бер газета хәбәрчесен без, нефтьчеләр, үз кеше итеп белә идек. Бу — Шамил Бикчурин иде. Аның «Каты токым» романын аеруча дулкынланып укыдым. Миңа, бораулаучы-разведчик кешегә, инде еллар узгач та, үзебезнең тормышны яңабаштан күз алдына китерү чиксез кадерле. Андагы геройларның һәркайсы кайчандыр минем белән бер вахтада эшләгән иптәшләрне искә төшерә»[3]. Димәк, укучы да әсәрнең тормышчанлыгына шаһитлек итә.

Ш. Бикчурин иҗатының тагын бер юнәлеше турында әйтергә кирәк. Алтмышынчы елларда ул музыкаль комедияләр язу өлкәсендә дә каләмен сынап карады. Нефтьчеләр һәм колхоз авылы кешеләре дуслыгына багышланган «Тальян моңы», татар һәм украин халыклары дуслыгын зурлаган «Бергә, гомергә...» исемле музыкаль комедияләре ул елларда тамашачыларның игътибарын җәлеп итте. Аерым алганда «Тальян моңы» әсәре М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында һәм Әлмәт драма театрында барды, уңыш казанды. Мәскәүдә дәүләт театрлары конкурсында беренче дәрәҗәле дипломга лаек булды. Үзешчән сәхнәләрдә дә еш кына куелды. Драматург Риза Ишморат әсәр турында җылы гына сүзләр әйткән иде[4]. Тамашачы Ш. Бикчуриннан бу жанрда яңа әсәрләр көтәргә дә хаклы.

---

[1] Горький М. О литературе. М., 1953, 710 бит.
[2] Миңнуллин Ф. Якты юллар. Казан, 1974, 88 бит.
[3] Дәрзаманов Җ. Каты токымнар аша.— «Социалистик Татарстан», 1976, 6 май.
[4] Ишморат Р. Әйбәт бүләк.— «Социалистик Татарстан», 1961, 25 ноябрь.

Язучы газета-журналларда әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы сөйләшүләрдә дә актив катнаша. Бу яктан аның «Социалистик Татарстан» газетасында «Бүгенге татар әдәбиятында заманчалык» дигән сөйләшү уңаеннан язган мәкаләсе аеруча игътибарга лаек. Автор анда әдәбиятыбызда эшчеләр темасын үстерү турында кайгыртучанлык күрсәтә, фикерләре һәм күзәтүләре белән уртаклаша, аерым тенденцияләрне билгеләли. Яшь язучыларны производство темасына тормышның үзеннән килергә һәм кыюрак иҗат итәргә чакыра.

Яшь каләмнәр тәрбияләүгә Ш. Бикчурин сүз белән генә түгел, эше белән дә өлеш кертә. Күп еллар буена Лениногорск район газетасы каршында эшләүче «Чишмә» әдәби иҗат берләшмәсенең консультанты булып эшли. Бу вакыт эчендә әлеге берләшмәдән Җәмит Рәхимов, Гәрәй Рәхим, Җәүдәт Дәрзаманов, Әсрар Галиев, Мәхмүт Газизов, Альберт Хәсәнов кебек язучылар, шагыйрьләр үсеп чыкты. Сәгадәт Ибраһимов һәм Әнвәр Шәрипов кебек тел-әдәбият галимнәре дә биредә беренче чыныгу алдылар. Мондый нәтиҗәлелек берләшмә җитәкчесенең эшне оештыруга бөтен сәләтен, көчен бирүе турында сөйли.

Ш. Бикчурин — исеме зур әдәбият мәйданында яңгыраган талантлы язучы. Ул иҗатының иң өлгергән чорын кичерә. Җитлеккән проза остасыннан укучы җитлеккән әсәрләрне күбрәк көтә.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Белорус мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Фәнсезнең эше ямьсез.*
*Бөртек күп уңса җиреңдә, табын мул булыр түреңдә.*
*Шундый чакны күрдем-бактым: ат артыннан җәяү чаптым.*
*Һәр бүренең бугазына — кырлы-сырлы бер ярчык.*
*Авырттырып кыйныйлар, ә еларга ярамый.*
*Аркасын күрим дисәң — дошманның маңгаен яр.*
*Бары шапшак һәдһәд кенә үз оясын пычрата.*
*Берсе ут яга, берсе су ташый.*
*Дәшмәү — үчне сүндерә.*
*Чүлмәкченең кайнар ашы тишек чүлмәктә пешә.*
*Бөгелә белгән агачны җилләр сындыра алмый.*
*Кунар кошым ул булса, мин — куакта бер тармак.*
*Ипине мин ташымыйм, ипи мине йөретә.*
*Кытаклаган һәр тавык йомырка салсын иде.*
*Дәү атка — олы камыт.*
*Аксап атларга өйрәтмә, болай да аяк сызлый.*
*Дуга тәртә була алмый.*
*Кәкре көпчәк әйләнсә, үзен-үзе пычрата.*
*Кешенең санаулысыннан үзеңнең ямаулың яхшы.*
*Чәчкән һәр бөртек шытмый.*
*Хәтта кычытканга да кырау тияр чак килә.*
*Үз бөкресен кем күргән?*
*Суын кичкәч ярында баткан.*
*Усал очкын сүнсә сүнә бар нәрсәне яндырып.*
*Сүзендәге дөреслек — иләктәге су хәтле.*
*Бер төп дөрләп янганда, бер төп арка җылыткан.*
*Үзен генә сөйгән затны бер кеше дә яратмый.*

**Бурят мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Хак сүз — юлбарыстан көчле.*
*Нинди озын өзәңге дә җиргә тимәскә тиеш.*
*Сүздә — төлке, эштә — бүре.*
*Үз күләгәсеннән башка берниндн иптәше юк.*
*Бер арбага ике тәртә без: беребез сынса, арба туктап кала.*
*Начар сарык кызу чабар, начар кеше шаман булыр.*
*Саесканнар берләшсә — козгынны да җиңәрләр.*
*Катлы-катлы бау белән ташны да кисеп була.*
*Юллар — җирдә, көч — халыкта.*
*Гыйлем өчен китап кирәк, яшәү өчен — татулык.*
*Купшы кием кигәнче, белем белән бизән син.*

# ЮЛ БАШЫНДА

1917 елның февралендә Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсе укытучылары инициативасы белән «Музыка-драма» җәмгыяте оештырыла. Җәмгыять идарәсенең рәисе итеп мәдрәсә укытучысы, скрипкада халык көйләрен бик оста башкаручы Ибраһим Бикчәнтәев билгеләнә.

Бу җәмгыять кыска гына вакыт эчендә ике мактаулы эш башкара: «Музыка-әдәбият» (Оренбург, 1918) дигән китап чыгара һәм «Оренбургның шәрык музыкасы мәктәбе»нә нигез сала. Җәмгыять мәктәп өчен халыктан уен кораллары сатып ала, укытучылар туплый.

«Музыка-әдәбият» дигән китап—«Хөсәения» мөгаллимнәренең күмәк хезмәте. Анда Төхфәт Ченәкәйнең музыка турында шигырьләре басыла, Шәриф Камалның «Музыкант дустыма», Ф. Кәримовның «Рәсем, музыка, шигырь» дигән һәм Роберт Ланкевичның музыка тарихы буенча мәкаләләре чыга. Бу китап—музыка сәнгатен аңлату һәм популярлаштыру буенча беренче татар совет басма хезмәтләреннән берсе.

Оренбургның шәрык музыкасы мәктәбенә 1919 елның маенда нигез салына. «Хөсәения» мәдрәсәсенең музыка укытучысы Павел Яковлевич Цесаркин аның беренче директоры була. Цесаркин үлгәннән соң, 1920 елның 7 маенда, мәктәп директоры итеп Салих Сәйдәшев билгеләнә. Ул бу вакытта 1 нче Төркестан революцион армиясе политбүлегендә эшли һәм кызылармиячеләрнең татар труппасында музыка бүлеген җитәкли.

Мәктәптә өлкәнең төрле төбәкләреннән килгән, милли азчылык вәкилләре булган 300 ләп укучы белем ала. Иң ярлы укучылар өчен 150 кешелек тулай торак ачыла.

«Музыка-драма» җәмгыяте һәм шәрык музыкасы мәктәбе татар, башкорт, казакъ җырларын туплау, аларны ялгыз җырчы, квартет, хор, оркестр, рояль һәм курай өчен эшкәртү, бастырып чыгарырга әзерләү өчен күп тырышлык куя.

Мәктәп укытучылары һәм укучылары, җырлар туплау максатында, Башкортстан, Оренбург өлкәсе, Казагыстан һәм Урта Азия шәһәрләрендә һәм авылларында булалар, халык өчен махсус концертлар оештыралар. Мәсәлән, 1921 елның җәендә генә дә укучылар Казагыстанда һәм Урта Азиядә 300 ләп концерт куялар. Мондый фидакарь хезмәтнең нәтиҗәсе дә куанычлы була: бик күп халык җырлары җыйнала һәм эшкәртелә (ул чактагыча әйтсәк, гармониялəштерелә), аларның килеп чыгышы турында күп санлы риваятьләр язып алына. Ул заманда Оренбург губерна комитетының азчылык милләтләр советы председателе булып эшләгән Афзал Мөхетдинович Таһиров һәм Оренбургтагы «Нәшрият» басмаханәсе директоры Мәхмүт Мәрҗани (Галәветдинов) әлеге концерт-экскурсияләрне оештыруда, җыелган җырларны бастырып чыгаруда зур ярдәм күрсәтәләр.

«Музыка-драма» җәмгыяте һәм шәрык музыкасы мәктәбе белән Оренбургның татар театры арасында ныклы дуслык элементләре урнаша. Бу дуслык театр репертуарында үзенчәлекле чагылыш таба. Театр, үз чиратында, музыка мәктәбе укучылары өчен тәҗрибә туплау мәйданына әверелә.

Ул чагында Оренбург татар театрында күбрәк халык җырларының килеп чыгышы турында теге яки бу риваятькә корылган музыкаль пьесалар куелган. Күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзи башлап җибәргән бу традицияне суфлердан — артист, режиссер, администратор, драматург булып үсеп җиткән ике кеше дәвам иттерә. Аларның берсе—Хәбибулла Ибраһимов (Хәйбүш) театрга үзешчән сәнгатьтән килә, осталыкка Мөхтәр Мутин кебек мәшһүр артистлардан өйрәнә. 1920 елда ул Оренбургның Совет Армиясе йорты каршында һәвәскәр татар театр труппасы оештыра. Шул вакытта Оренбургта эшләгән күп санлы башка һәвәскәр драма коллективларына хас булганча, бу труппа репертуарында да музыкаль пьесалар була. Х. Ибраһимов яшь чагында ук музыкаль пьесалар язу турында хыялланa. Ниһаять, 1926—1929 елларда аның әсәрләренең беренче сериясе сәхнәгә чыга. Алар арасында «Мәдинәкәй», «Нарасый бала», «Зөбәрҗәт», «Әллүки» музыкаль драмалары, «Кулешә алмадык», «Хәерле булсын Хәмиданең никахы», «Мөкатдәс сарай» музыкаль комедияләре һәм башкалар була.

Оренбургның икенче драматургы — Габдрахман Әхмәров (Варлам). Ул «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала, иҗат эшчәнлеген 1922 елда башлап җибәрә. Берничә елдан Әхмәровның «Бер кызга алты кияү»,

«Казан егете»», «Газизәкәй балдыз» кебек музыкаль комедияләре, «Уракчы кыз» музыкаль драмасы һәм башка әсәрләре сәхнәдә күренә башлый.

Югарыда саналган пьесалардан тыш Оренбургның татар театры сәхнәсендә башка музыкаль пьесалар да куела. Мәсәлән, Вәли Фатыйховның (хәзер РСФСРның атказанган артисты) «Шәүрәкәй» пьесасы һәм башкалар. Әлеге сәхнә әсәрләренең барысы да җыр-көйгә бай булулары белән аерылып торганнар. Аларда шәрык музыка мәктәбе укытучылары һәм укучылары җыйган һәм эшкәрткән җырлар файдаланылган, бу җыр-көйләрнең саны бер спектакльдә кайчак 20 дән артып китә торган булган.

Җырларның кайберләре (мисал өчен, «Төнге сәгать унике» җыры) Оренбург театры сәхнәсендә беренче тапкыр яңгырый. Бу хакта Җ. Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» дигән китабында да искә алына. Башкарылачак җырларның, көйләрнең исемнәрен матур итеп бизәлгән афишаларда һәм программаларда басып чыгарганнар, алар тамашачыларның игътибарын үзләренә җәлеп итеп торган.

Спектакльләрдә музыкаль һәм хореографик элементлар төрлечә кулланыла. Тәнәфесләрдә дә аерым башкаручылар, хор җырлый, биюләр күрсәтелә. Хор, гадәттә, 30—35 кешедән, нигездә шәрык музыкасы мәктәбе тыңлаучыларыннан торган. Спектакльләрдә музыкаль әсәрләрнең күп булуы артистлардан җыр-биюгә дә осталык таләп иткән.

Оренбургның татар театры сәхнәсендә Исхак Әлмәшев, Гөлчирә Байкина, Ильяс Вафин, Фатыйма Камалова кебек талантлы актерлар уйнаган. Күпчелегенең махсус музыкаль белеме булмаса да, алар халыкның гүзәл әсәрләрен тыңлаучыларга үтемле итеп җиткергәннәр.

Бу чорда татар театрының үз оркестры була. Хөсәен Әбделмәнов, Габдулла Бәширов, Хәбиб Биккинин, Мөшәррәф Вәлиев, Габдрахман Гайнуллин кебек танылган осталар театр коллективында аккомпаниатор, импровизатор, дирижерлар булып эшлиләр.

Музыка мәктәбе укучыларыннан оештырылган тавыш оркестры (кашык, тарак, тәлинкә, мич капкачы һәм шуның кебек башка әйберләрдә уйнау) зур уңыш казана. Җыр-бию, музыка коралларында уйнау конкурслары үткәрелә. Гомумән, Оренбургның шәрык музыкасы мәктәбе һәм татар театры сәләтле яшьләр өчен тәҗрибә туплау һәм үсү мәктәбенә әверелә. Күренекле композиторларыбыз һәм музыка белгечләребез Мәсәлим Вәлиев, Александр Ключарев, Шакир Мәҗитов, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи һәм башкалар бирeдән музыка дөньясына фатиха ала.

Оренбург «Музыка-драма» җәмгыятенең һәм шәрык музыкасы мәктәбенең халык көйләрен мәңгеләштерүгә һәм таратуга, татар хезмәт ияләренең музыкаль культурасын үстерүгә керткән өлеше игътибарга һәм ихтирамга лаек.

**МӘДИНӘ РӘХИМКУЛОВА.**

## Гасыйм Лотфи

# СОҢГЫ ЕЛЛАР

Җәмгыять үсешенең югарырак баскычына күтәрелә барган саен, киләчәк турында уйлану белән бергә, кеше ата-бабаларының үткәне белән дә тирәнрәк кызыксына башлый. Археологлар җиде кат җир астында калган чүлмәк китекләрен, корал кыйпылчыкларын эзли, тарихчылар архивларында казына. Шуңа да карамастан, үткәнне тергезеп күз алдына бастыру ифрат авыр. Чөнки фән күп тармакларда, күп өлкәләрдә мәгълүматлар кытлыгы кичерә. Халкыбыз тарихының әнә шундый тиешенчә яктыртылмаган, әле дә булса томанлы күзалланган бер сәхифәсе — революциягә кадәрге мәктәп-мәдрәсәләр яшәеше.

Урта һәм югары уку йорты саналган мәдрәсәләрне өч төркемгә аерырга мөмкин: 1) заманнар узуга да карамастан, баштагы үзенчәлеген саклап калган кадим мәдрәсәләр; 2) заман таләпләренә яраклашып беркадәр яки байтак үзгәреш кичергән мәдрәсәләр; 3) рус һәм Европа уку йортларыннан үрнәк алып, нык һәм эзлекле яңару юлына баскан җәдит мәдрәсәләр.

Кыйбланы билгеле торган бердәм мәҗбүри программалар булмау татар мәктәп-мәдрәсәләренең әнә шундый чуар төркемнәргә бүленүенә төп сәбәп иде.

Мин — беренче төркемгә кергән, замапында мантыйк (схоластик логика) укытучы, моназарачы шәкертләре белән дан тоткан

Кышкар мәдрәсәсендә революция алдыннан биш еллап гомеремне кичердем. Яшьлегемдә онытылмас эз калдырган Кышкар хәяте белән танышу укучыларга кызыклы, ә истәлегем тарихчыларга да бер мәгълүмат булыр дип өметләнәм.

Революциягә кадәр күп санлы муллалар әзерләп чыгаруы белән танылган мәдрәсә хәзерге Татарстанның Арча районы Кышкар авылында урнашкан иде. Уртача гына зурлыктагы бу авыл ике өлешкә бүленгән: төньягы — ясаклы, көньягы — казаклы. Чик буе урамының бер ягы казаклыга, икенче ягы ясаклыга карый. Урамның көнчыгыш ягына урнашкан мәдрәсә бинасы ясаклы җирендә, каршы ягы таш мәчет казаклыда! Таш мәчет мулласы белән мәзине бер-берсенә каршы йортларда гына яшәсәләр дә, беренчесе — казаклы кешесе, икенчесе ясаклыныкы исәпләнә иде. Авыл чокыр-чакырлы урынга, ерымнар арасына урнашкан. Шәбәрде куаклыгын исәпкә алмаганда, аңа якын җирдә урманнар юк иде. Төньяктан көньякка сузылып, авылны өч өлешкә аерып торган ерымнар язгы ташу вакытында кар суыннан тулсалар да, җәен челтерәп кенә агып торган ермакка әверелә яки бөтенләй корый. Симетбаш авылы тирәсендә башланып, Завод буе дип аталган калкулык итәгеннән көнбатышка таба ага һәм Күшәр авылы болынында Ашыт елгасына кушыла торган Симет суы да зур түгел — чыпчык коенырлык кына.

Завод буе дип аталган болын һәм калкулык, тау итәгеннән бәреп чыккан чишмә кайчандыр бу урында кытат җитештерә, тире-күн эшкәртә торган мануфактура булуын хәбәр итә.

Ш. Мәрҗанинең «Мөстафад әл-әхбар» китабында Кышкар байларыннан Мусаның Бохара ягында зур сәүдә алып баруы турында язылы. Муса байның остазы Күшәр авылы мулласы Габбас аңа әледән-әле бер табак ак кәгазьнең дүрт почмагына: «Муса бай — яшел чәй — Габбас мулла — Күшәри» дип сырлап хат җибәрә торган була. Шуны алу белән бай үзенең остазына бер-ике кадак яшел чәй җибәреп торган.

«Кышкар авылы борынгыдан дәүләтле байлары булганлыктан, муллалары мәдрәсә тотып, күп шәкерт җыеп, дәрес әйтеп, дан һәм шөһрәт казанганнар,— дип яза Мәрҗани.— Хәзерге таш мәчетне шул авылның атаклы кешесе Баязид бай бине Госман бине Габделкадыйр Кышкари һиҗри ел исәбе белән мең бер йөз туксанынчы елда салдырган».

Ш. Мәрҗани әнә шул 1775 елда салынган таш мәчетнең имамнары Кадер, Сәгыйд, Дәүләтша, Фәиз, Ягъкуб, Исмәгыйль, Габдрахман — барлыгы 7 дамелланы санап китә дә аларның һәммәсе күп шәкерт җыеп, дәрес әйтүен искәртә. Бу безгә, таш мәчет салынганчы ук монда мәдрәсә яшәгәндер, дип уйларга нигез бирә. «Мөстафад әл-әхбар»ның икенче китабында алтмыш икенче биттә Мортаза бине Габделгазиз бине Бикмөхәммәтнең Кышкар мәдрәсәсендә мелла Кадердән сабак алуы, һиҗринең 1167 елында (миладиның 1753 елы) «Нигъмәтулла» исемле китап язып тәмам итүе әйтелә. Мортаза бине Габделгазиз китап язудан шактый элегрәк шәкерт булгандыр, дип фараз итсәк, Кышкар мәдрәсәсенең инде 1740 елларда ук эшләве язма чыганак нигезендә исбатлана. Аның соңгы имамы Шаһимәрдән Үтәгәнев 1918 елның язына кадәр үзенең эшен дәвам иттерде.

Кышкар дамеллаларыннан Исмәгыйль Үтәмешев Мәрҗани белән бер чорда Бохарада укып кайткан була. Автор «Мөстафад әл-әхбар»да аның галим кеше икәнлеген таный, Исмәгыйльнең Мәчкәрә авылыннан чыккан бабалары арларга барып тоташуын белдерә.

Кышкар мәдрәсәсе үзенең яшәү чорында укыту программасы, шәкертләренең тормыш шартлары ягыннан үзгәрешләргә бик аз очрагандыр. Чөнки анда әтиләр заманында ничек булса, без укыганда да нигездә шул ук тәртипләр саклана иде.

Мәдрәсә озак яшәсә дә, Кышкарның үз балалары анда бик аз укыгандыр. Юнәлеше муллалар әзерләү генә булганлыктан, крестьяннарның улларын мәдрәсәгә бирергә артык һәвәсләнмәве табигый, чөнки бу «кәсеп» өчен мулла балалары да кирәгеннән күп артык була. Авыл балалары мәхәллә мәктәпләренә йөри. Революция алдыннан ун ел чамасы элек җәдит һәм русча башлангыч белем бирә торган земство мәктәбе ачылган иде.

Мәдрәсә тирәсендәге ун-унбиш йортны шәкертләр кунак өе итеп файдалануны исәпкә алмасак, укучылар белән авыл халкы арасында әллә ни тыгыз бәйләнеш юк иде. Кунак өе — шәкертләрнең запас азыклары саклана торган өй. Аталары, якыннары килгәндә ат куеп тора, чәй эчеп чыга торган җир. Ерактан килгән шәкертләр кунак өендә икмәк салдыра, токмач кистерә. Әниләрен сагына торган иркә мәхдүмнәр шунда килеп тулган күңелләрен бушата, хуҗа карчыкның юату, иркәләүләрен татып тынычлана. Кунак өе үсмер һәм егет исәбенә кергән мутрак шәкертләргә кызлар белән хат алышып, күзгә-күз карап бер-ике кәлимә сүз әйтешә торган урын да.

Шәкертләр кунак өе өчен бер тиен акча да түләми. Килгәндә — чирек, ярты кадак бөртек чәй бүләк итәргә онытмаса, бәйрәмдә әбине кунакка алып китсә, шул да бик җитә.

Кышкар халкы мәдрәсә белән горурлана да шикелле иде. Авыл кешеләренең байтак өлешендә шәкертләргә охшарга тырышу да сизелә. Аларның китапча сөйләшергә һәвәслеге, шиксез, мәдрәсә йогынтысы иде. Кышкар крестьяны базарда таныш муллалар белән сөйләшергә, шул чак гарәпчә сүзләр кыстырырга ярата иде. Читтән тыңлап торучыларда алар хакында бәрәр авылның имамыдыр бу дигән фикер туа иде. Авыл кешеләре арасында Кышкар мәдрәсәсенең мактанычы булган мантыйкны Карбыз Шәрәфи кебек кискен яклаучы, аны популярлаштыручылар да була. Мәсәлән, кайда гына бәхәс кузгалмасын, Шәрәфи

агай сүзгә кушылып: «Мәнтикъмы? Мәнтикъ ул тугыз кырлы пычак. Кайсы гына кыры белән сызсаң да, кисә дә чыгара», дип, мантыйк укытуга каршы кешеләрнең тетмәсен тетеп ташларга әзер иде!

Кышкар кешеләре шәкертләрнең төрле гозерләренә колак салырга да күнеккән. Шәкерт Кышкар кешесенең кайсына гына йомыш белән мөрәҗәгать итсә дә, «юк, булмас» дигән җавап ишетми. Ашыт яки Әтнә базарында Кышкарның кайсы гына крестьянын очратып, хат, азык, акча-фәлән биреп җибәрәләр икән, әманәт шул көнне үк тиешле кешесенә тапшырыла. Шәфикъ агай исә Казандагы Үтәмешевләр адресына шәкертләргә дип салынган акча, хатларны ташып торучы игелекле бер затка әйләнә.

Мәдрәсә төньяктан көньякка сузылган урамның көнчыгыш тарафына урнашып, сары буяулы койма белән ихаталанган иде. Алты почмаклы шактый зур, биек һәм якты йорт — «кантур өе» капкадан керүгә сул якта калкып тора. Уң кулда аңа караганда бераз кайтышрак итеп салынган «караңгы өй». Бу бинага салкын өйалды белән тоташтырып, урталай ярган бүрәнәдән тәбәнәгрәк, кечкенәрәк дәрес өе салынган. Болын ягындагы тәбәнәгрәк булса да, мәйданы кантур өеннән ким булмаган алты почмаклы бина «кәҗә өе» дип атала иде. Дөресме-юкмы, кайчандыр шәкертләр кәҗә урлап, шул өйнең чормасында суйганнар, исеме шуннан калган, имеш! Түрдә кирпечтән салынган зур ашханә, аңа тоташтырып калын тактадан ясалган, түбәсе калай белән ябылган утын лапасы. Лапастан уңдарак инеш буена корылган салкын тәһарәтханә...

Биналарның эчке төзелешенә килсәк, ишектән керүгә бер квадрат метр чамасы идән калын планкалар белән киртәләп алынган «әчелек». Кәвеш, киез ката, киез итек кебек тышкы аяк киемнәрен шунда салып калдыру шарт. Ике якта башлары түшәмгә орынган зур мичләр. Мич артында берәр тәрәзә кертеп, такта белән бүлеп алынган бүлмәләр. Аларда хәлфәләр, пишкадәмнәр, олырак шәкертләр яши. Урталагы залның ян-ягында өчәр, түрендә дүрт тәрәзәсе булып, бу бүлмә дә чаршаулар белән аерым хөҗрәләргә бүленгән. Почмак хөҗрәләрдә өчәр, башкаларында икешәр кеше яши. Һәр хөҗрәгә, анда торучы шәкертләрнең хәленә карап, йоннан сугылган киез, чүпрәк палас кебек әйберләр җәелгән. Ял вакытында, уртага тәбәнәк өстәл куеп, шуның ике ягына идәнгә үзләренең урын-җирләрен җәеп, бишле лампа яктысында шәкертләр сабак өйрәнә, йоклыйлар. Башка вакытта чаршаулар күтәреп куела иде.

Идәннең чаршаулар эченә керми калган өлеше җәмәгать сәкесе дип атала. Коридор ролен үтәгән бу «сәке»гә иртә белән һәр хөҗрәдән себереп чыгарылган чүп җыела, аны кизү шәкерт чистартып тора.

Стеналар буйлап тәрәзә өсте биеклегендә бер такта киңлегендә шүрлекләр сузылган, аларда шәкертләрнең китаплары, төрле төстәге ашъяулыкларга төрелгән икмәкләре әчелектә салгач китереп куйган кәвеш, киез каталары, тәһарәт алыр өчен җылынып торсын дип, су тутырып куйган комганнары тезелгән.

Шушы тар шүрлекләргә каршы, стенадан ике метр чамасы җәмәгать сәкесенә таба чыгарып, түшәмгә тимер таяклар белән беркетелгән асма шүрлек урын-җир куяр өчен хезмәт итә. Шәкертләрнең вак-төяк әйберләре саклана торган кечерәк сандыклары да шунда урын ала. Ялкаулар өчен бу шүрлекләр дәрестән качып йокларга да җайлы. Һәр урынны җәмәгать сәкесеннән аерып торучы чаршаулар шушы шүрлек астына беркетеп корылалар...

Шактый биектәге шүрлекләргә менәр өчен дүрт аяклы биек баскыч ясалган. Тупас кына эшләнгән бу нәрсәне шәкертләр пишлек дип атый. Пишлекнең тагын бер хезмәте бар: төнлә тышка йөрүчеләр адашып йөрмәсен өчен, аның өстенә утны кыса төшеп лампа утырталар. Кантур һәм кәҗә өйләренең алгы бүлмәләрендә генә андый җиһазлар юк. Аларда аяк киемнәре, комганнар өчен һәркемгә аерым-аерым бикле шүрлекләр ясалган булса да, мичләре ягылмаганлыктан, ул шүрлекләр файдаланылмады. Бу биналарны салганда шәкертләр саны бик артып китүгә исәп тотылса да, өмет акланмаганлыктан, алар шулай искерергә мәҗбүр булгандыр!

Кышкар мәдрәсәсендә аерым класс бүлмәләре, ятаклар һәм башкалар юк иде. Булганы әнә шул дүрт өй. Шәкертләр шунда тора, дәрес ала, ашый-эчә, күңел ача, дәрес әзерли. Укучылар саны сиксән-туксанга җитсә, дүрт өй дә ачыла, алтмышҗитмеш белән чикләнсә, ике, өчесен ачу да җитә. Дамелла дәресләре шунда узганга гына бер бина «дәрес өе» дип атала, әмма аның бүтәннәрдән һичбер аермасы юк.

Соңгырак чорда кирпечтән салынган ашханә Кышкар мәдрәсәсенең горурлыгы иде. Аның егерме чиләк сыйдырышлы бакыр кубында көне буе су кайнап тора. Буе ике метрга сузылган плитәгә берьюлы егермеләп кәстрүл тезергә була. Почмактагы зурзур ике казан шәкертләргә бергәләшеп пылау һәм куллама пешерергә бик уңай. Стена буйлап өстәл биеклегендә сузылган такталарда ит турарга, бәрәңге, суган әрчергә мөмкин.

Кухняның идәне шома таштан, бер кырыйда юынтык сулар салыр өчен уемы бар, шәкертләр аны да әчелек дип атый иде. Сыеклык тышка агып чыга. Иртән бит-кул юу, тәһарәтләнү дә шул әчелек буенда.

Кыш көне бозланган, беркайчан да рәтләп ябылмый торган кухня ишеген ачып, куе парны ерып уңга борылсаң, такта белән бүлеп алынган чолан кебек җиргә килеп керәсең. Бу — госелханә. Аның ишеге төбендә таң белән һәр көнне иңенә тунын салып, муенына сөлгесен аскан, ялан аякка киез катасын гына элеп йөгереп килгән берничә шәкертне күрәсең. Каравылчыга бер чиләк су өчен ике тиен түләп, коенып пакьләнер өчен чират көтә алар. Арага

хəлфə, пишкадəмнəр кермəсə, ярты сəгать эчендə барысы да боз идəнгə басып тиз-тиз коена да, мəдрəсəнең үзендə генə үтəлə торган иртəнге намазга ашыга...

Элегрәк мондый «уңайлык» булмаган. Ике метр биеклектәге баганалар өстенә корылган бәдрәфнең сигез бүлмәсеннән берсен генә госелханә итеп файдаланганнар. Анда инде як-яктан да, астан да әче салкын җил исеп, сөякләргә кадәр үтә торган булган. Әмма аңа карап кына, бик юлдан язган бәндә булмаса, шәкерт госелсез йөри алмаган...

Буяулары кубып беткән, гер янына тутыккан кайчы, ярты дага тагылган сәгатьнең теле җидегә якынлашу белән, Кәтүк Мортазаның:

— Тәкерттәр, тәйгә-тәйгәү... — дип кычкыруы яки Губернатор ГатауллаThe колак пәрдәләрен ертырлык итеп сыбызгы сызгыртуы иң каты йокылы шәкертләрне дә урыннан сикертеп торгыза. Чаршаулар күтәрелә, урыннар җыела, идәннәр себерелә, комган тоткан шәкертләр тәһарәт алырга йөгерә. Бергә ашап-эчәргә укмашкан таифәнең кизүе бер кулына зур, икенчесенә кечкенә чәйнек тотып, чәй әзерләргә кухняга чаба. Бу вакытта кухняда мәхшәр куба. Шәкертләрнең кайсылары әчелек кырыенда «Гөлҗиһан» сабыны белән битен юа, бер башы чүкеп чәрдәкләнгән мисвәк — Гарәбстаннан хаҗилар алып кайткан «изге» агач ботагы белән тешен чистарта. Икенчеләре, урын сорап, аларны ашыктыра, әйткәләшү-төрткәләшүләр кабынып китә. Шаулашырга теләмәүчеләр исә, үтә салкын булуга карамастан, бәкегә төшеп кенә тәһарәтләнеп меңә...

Ашханә тына. Өйләрдә ашыга-ашыга намаз укыйлар. Берничә урында идәндә табын әзерләнә. Һәркайсы үзенең чынаягын, ашъяулыкка төрелгән ризыгын, тәрәзә арасында шешәдә торып бозланган сөтен алып килә дә чәй эчә. Шуларның бөтенесенә бер сәгать чамасы вакыт үтә.

Ниһаять, чын «эш көне» башлана: шәкертләр, китапларын тотып, бер өйдән икенчесенә сабакташлары белән бергә дәрес әзерләргә, хәлфәгә элекке дәресләрен тыңлатып, яңа дәрес алырга йөгерешәләр. Дәресләр, гадәттә, хәлфә кайсы өйдә торса, шунда, еш кына хәлфә бүлмәсендә бирелә.

Сәгать уникедә иртәнге уку бетә, көндезге ашка әзерлек башлана: кулларына эмальле калай тәлинкәләрен тотып, әле берсе, әле икенчесе такыраеп беткән сукмак буенча савытын шудырып уйный-уйный кунак өйләренә «матдә»гә йөгерәләр. Матдә — аш кирәк-яраклары: яртышар кадак ит, (купчелектә — ат ите), ике, өч бәрәңге, ике чынаяк токмачтан гыйбарәт. Токмачны бер атнага исәпләп нәни капчыкларга салып җибәреп торалар. Таифәдәшләр үзләренең ашамлыкларын бергә кушып уртак кәстрүлдә пешерә. Аш кайнаган арада кухняда «Ай, былбылым», «Карурман», «Уел», тагын әллә нинди көйләр яңгырый — шәкерт халкы җыр ярата.

«Кавказ Миркур» парахуты
«Самолет»ка юл бирә.
Гаҗәп Кышкар шәкертенә
Ходай үзе җүн бирә...

Зуррак шәкертләр ачыктан-ачык, малайшалай качып-посып «Дюшесть», «Тризвон», «Тари-бари» папиросы көйрәтә. Ул арада кухняны куэләрне әчеттерә торган пар тутыра, чөнки инде күп кәстрүлләр кайнап чыга һәм ташырга да өлгерә. Шәкерт ашының иң яхшысы — тәлинкәгә салгач, кашык утырып торганы санала. Моңа ирешү өчен шулпаны тигез генә итеп озак кайнатырга кирәк. Кизү, тоз күбрәк ычкынса, аны бераз киметер өчен ашка утлы күмер салып ала.

Ипиләп-борычлап икешәр тәлинкә ашаганнан соң кәстрүл төбендә бер ике чүмеч ризык кала. Анысы — каравылчылар өлеше. Шуның хакына алар кәстрүлләрне юып, икенче көнгә әзерләп куя. Аш калдырмасаң — сине берәү дә кайгыртмый. Хәер, тәлинкә-кашыкны пөхтәләп ялап куйсаң, көн саен юып торасы юк югын...

Аштан соң — көндезге йокы. Телисеңме, юкмы, урын-җиреңне җәеп, чаршауларыңны төшереп ятуыңны бел. Теләмисең икән чыгып кит, кунак өенә барып утыр, бүтәннәргә комачаулама. Кыштыр-мыштыр тавыш чыгарып йөрсәң, Байми пишкадәм озын, киң эчке күлмәк-ыштанын җилфердәтеп бүлмәсеннән чыгар да, сизелерлек итеп артыңа тибеп, ишектән очырыр.

Сәгать дүрт тулганда барысы да тора. Әмма бер сәгатьләп буш вакытың бар әле — урамга чык, кибеткә бар, теләгән эшеңне эшлә. Аннары сәгать сигезгә кадәр кичке уку. Кунак өеннән алып кайткан бозлы вак бәлешләрне эш арасында кайнар мичкә куйган тәмле тамаклар чәйгә чакыруны көтә, «шук куллар», хәйлә табып, кеше бәлешен чәлдереп калырга атлыга.

Губернатор яки Кәтүкнең шәүләсе күренү белән, китаплар шап итеп ябыла, мәдрәсә тагын умарта иледәй тузгый — кичке аш мәшәкатьләре башлана. Берәүләр кухняга, икенчеләр хәлвә алырга дип кибеткә, акчасы мулраклар каравылчы Гәрәй пешереп сата торган кайнар сумсадан авыз итәргә йөгерә. Тагын җыр, ыгы-зыгы...

«Исагуҗи», «Шәмсия» дәресләре билгеләнгән булмаса, хәзер инде һәркем вакытны үзе теләгәнчә файдалана. Мәдрәсәнең «йолдызлары», әлбәттә, китап карарга — моталәгага утыралар. Өер-өер булып кичке сәйран чыгуга урамга, яз көннәрендә завод буена чыгу да хилаф саналмый.

Төнге сәгать унберда мәдрәсә тына. Чаршаулар төшерелә, урыннар җәелә. Әмма теләгән кеше инә белән кое казып, гыйлем җыюын дәвам иттерә ала...

Мәдрәсәнең һәр көне, һәр төне менә шулай үтә. Тик кече атна кичләрдә генә укулар булмый. Алмага ат җибәрелгән иркә мәхдүмнәр мунча чабынып, коймак ашап килергә өйләренә ычкына. Ерактан килеп укучы мишәр, башкорт шәкертләре исә берәр сабакташына ияреп кунакка китә яки Суфи Шәфигына барып мунча керә. Мәдрәсәдә калучылар кәнфит, перәннек, чик-

ләвекнең төрлесен бергә үлчәтеп алалар да, атна саен чиратлашып дусын, якташын, сабакташын әлеге «фрукты» белән сыйлый-сыйлый гәпләшә, чәй эчәләр. Кайсы атналарда алар үзара егерме икешәр тиен акча җыеп, тулы пылау, янсә унҗидешәр тиен җыеп, ярты пылау пешерәләр. Бу көннәр чын бәйрәм төсен ала. Тәмле пылауга күбрәк урын калсын өчен, көндез аш пешермиләр, керт-керт шикәр тешләп, бер-ике чынаяк буш чәй генә эчәләр. Ул «кәеф чәе» дип атала.

Мәдрәсәдә эчпошыргыч иң авыр көн — җомга. Дәресләр булмаганлыктан, эшсезлектән арыйсың. Берәр диндар шәкерт җомга намазына мәчеткә дә әйди башласа, тагы да харап. Дөресен әйтергә кирәк, дини җитәкче булырга әзерләнсәләр дә, шәкертләрнең күбесе намаз укырга бик ялкау була иде.

Уку елы, гадәттә, искечә сентябрь урталарында башлана, апрель урталарында тәмамлана иде. Алданрак килүчеләр булса, әле вакыт җитмәгән дип, борып җибәрмиләр. Майга кадәр каласың икән, шулай ук куучы юк. Кыш буе килә-китә торалар, моңа берәүнең дә исе китми. Кышкар мәдрәсәсенең көннәре генә түгел, еллары да су тамчылары төсле әнә шулай бер-берсенә охшаган була иде.

Мәдрәсә урта дәрәҗәдәге уку йорты булганлыктан, аңа башлангыч белем алган үсмерләр килә иде. Кышкар мәдрәсәсенең кәгазьгә язылган, расланган программасы булуын хәтерләмим. Монда уку гарәп теленең грамматикасын өйрәнүдән башлана һәм ул ике ел дәвам итә иде. Шәкертләрнең төрле баскычта укуы класслап түгел, укый торган китабына «хан» сүзе кушып билгеләнә иде.

Грамматикадан соң мантыйк курсы башлана, аңа «Исагуҗи»ны өйрәнүдән керешәләр, шәкерт исагуҗихан санала иде. Исагуҗихан грамматика укучыларны кимсетеп, «касмак» дип атарга хаклы була. Шуңа күрә мантыйктан беренче дәрес алган шәкерт, өстенә берәр чиләк су койсалар да, үпкәләми: йоласы шундый!

Исагуҗихан булдыңмы, алда сине бүтән «хан»нар көтеп тора: шәмсия, гаканд, сөлләм, таузыйх, тәһзиб, меллаҗәләл. Меллаҗәләлхан булгач, шәкертне пишкадәм дип йөри башлыйлар — бу инде мәдрәсәнең тулы курсын үзуны белдерә. Пишкадәм теләсә кайсы китапны укып аңлый ала торган кеше санала. Ул төп дәреслекләрдән тыш бик күп аңлатма, искәрмә китаплар белән танышкан һәм ятлаган, шәригать законнарын яхшы үзләштергән, корьәнне төрле мәкамнәргә (көйләргә) салып укый белә торган затка әверелгән.

Кышкар мәдрәсәсендә элек космогония дә үтелгән, соңгы вакытта гына аны укыучы кеше калмаган иде.

Тулы курс узып, сакалына чал кергән байтак пишкадәмнәр мәхәллә табылмау аркасында мәдрәсәдә ятырга мәҗбүрләр иде. Мисалга Шура Мәгъсүм мулланың җиде улыннан дүртенчесе Габделбари укуны уңышлы тәмамлый, әмма урын чыкмаганлыктан, очраклы садакалар бәрабәренә кышларын шәкертләр укыта, җәйләрен Мәкәрҗә ярминкәсенә барып, татар сәүдәгәрләрендә пылау пешерүче булып эшләп, кием-салымлык, кышны үткәрерлек акча юнәтеп кайта иде. Мулла кирәк булганда, мәхәллә халкы беренче чиратта мәдрәсәләргә мөрәҗәгать иткәнгә, пишкадәмнәр үз авылларына кайтып крестьян хезмәтен үти торырга базмый иде: алай форсатны кулдан ычкындыруың да мөмкин ич!

Кышкар шәкертләре телендә күңел ачуны аңлата торган «шашу» сүзе бар иде. Шәкерт авыл яшьләре белән бергә аулак өйләргә, өмәләргә йөри алмый. Әмма аңа карап, мәдрәсәдә укучыларны шаярудан мәхрүм, гел гыйбадәт белән генә мәшгуль дәрвиш дип күзаллау дөрес булмас иде. Чөнки яшьлекне читлеккә бикләп куюмөмкин түгел.

Кышкар шәкертләре арасында мандолина чиртүчеләр дә очрый иде. Мәдрәсә эчендә җырлау сирәк булса да, кухнядагы күңел бушатуларга берәү дә сүз әйтми. Бию исә тагын да киңрәк таралган булып, «шашу» сүзе авыздан ычкынуга, шәкертләр кәҗә өенә йөгерә, «барабанчы»лар идән уртасында тезелеп утырып сандык капкачларын дөпелдәтә башлый, «Әтнә», «Әпипә», «Краковяк», «Камаринский» көйләренә касмаклар гына түгел, пишкадәмнәр һәм хәлфәләр дә әйттерә башлый иде. Тәхтәһү Мансур, Габделбари хәлфәләрнең биюе үзе бер тамаша була. Таип «шаша» башласа инде шәкертләр бар дөньяларын оныта, аны күрми калу зур югалту санала. Чөнки ул җәнлек, кош-корт булып кыланунннан аерым кешеләрне гәүдәләндерүгә күчә: мәшһүр татар байларыннан берсенең русчаны вата-җимерә телефоннан сөйләшүен, икенчесенең приказчикларын ачулануын, өченчесенең асрауга кул сузуын, кайсы да булса мулланың мәхәлләбаена ялагайлануын, мәҗлесләрдәге дини моназараларны уйнап күрсәтә.

«Шашу»га урамда сәйран чигү, кибетче Сибгать йортына барып, аның калку күкрәкле балдызының сату итүенә, чытлыкланувына сокланып тору, кар тыгызлангач калкулыкка менү, чирәм чыккач болында йөрү, бура уйнаулар да өстәлә әле. Берәр мулла яки байга кунакка барулар, үзара кушылып мәҗлес корулар, уен-көлке ясаулар да өзелеп тормый. Шәкертләрнең сабан туйларына йөреп бәйге тотучылары да аз булмавын әйтергә кирәктер.

Кышкар мәдрәсәсендә яктылыкны бар дип тә белмәүче мәгънәви дөм сукырлар, бик ихтимал, шактый зур күпчелек булгандыр. Алар үз мәдрәсәләреннән башка җирдә рәтле гыйлем дә, матур киләчәк тә юк, дип уйлыйлар, тешләре-тырнаклары белән аңа ябышып яталар, ул нәрсә бирсә, барын да изге саныйлар, үзләренең табигый талантлары юкка әрәм булганны

сизмиләр дә. Әмма атаклы шагыйребез Тукайның атасы Мөхәммәтгариф хәзрәт, татарның беренче профессиональ җырчысы Камил Мотыйгый белән күренекле артисткабыз Галия Кайбицкаяның атасы Мотыйгулла хәзрәт, әдәбият тарихыбызда билгеле урын алган Таип Яхин кебек кешеләр дә Кышкар мәдрәсәсендә укыган ич әле. Алар караңгылык пәрдәсе артында яктылык барлыгын сизеп, адымнарын шул юнәлешкә таба борган, үз балаларына, оныкларына гына түгел, башкаларга да тиешле юнәлеш бирергә батырчылык иткәннәр. Ниһаять, беренче драматургыбыз Фатыйх Халидинең дә Кышкар шәкерте икәнен онытмыйк!

Чүп үләннәр, тигәнәкләр белән тулы ташландык бакчада бу күркәм чәчәкләр ничек өлгергәннәр икән соң?

Кышкар мәдрәсәсендә, башка бик күп кадимчел мәдрәсәләрдәге кебек, яшь миләр схоластика белән агулана, тиешле шартлар булмаганга күрә, үсештә кирәкле юнәлеш ала алмаган талантлар томалана, кешелек җәмгыяте өчен файдалы нәрсә бирми һәм бирә дә алмый торган «соры кортлар» сафы ишәя. Шуның белән бергә, иске мәктәп-мәдрәсәләр барыбер уку йортлары. Аларда нәрсәгәдер өйрәтәләр, нәрсәләрдер белдерәләр. Кышкар мәдрәсәсендә еш булып торган схоластик бәхәсләшүләрнең дә аерым шәхесләрне уйланырга, дөреслекне эзләргә этәрүе һич тә гаҗәп түгел.

Кышкар мәдрәсәсен тәмамлап чыккан Вәли мулла Оренбург шәһәрендә урнашып, озак еллар буе миләрне агулап килгән «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгара, үзе белем алган уку йортыннан да искерәк тәртипле мәдрәсә ача. Ә башта шул мәдрәсәдә укыган Галимҗан Ибраһимов тора-бара бөтен искелеккә каршы көрәш юлына баса, татар халкының бөек әдибе, галиме һәм революционер дәрәҗәсенә күтәрелә.

Кышкар мәдрәсәсенең иң тырыш шәкертләреннән булган, кадимчелек юлында аз гына какшаулар белән дә килешә алмаган Госаметдин хәзрәт үзенең балаларын да шул рухта тәрбияләү өчен бөтен көчен куя. Ләкин бер генә баласын да үз юлы белән җибәрә алмый. Иң башлап, икенче улы Гаяз Максуд әшне боза—үндүрт яшендә атасының тимер ихтыяры белән исәпләшмичә, Кышкар мәдрәсәсен ташлап китә, чит илләргә барып укып, Октябрь революциясеннән соң туган илгә кайта, Коммунистлар партиясе сафына кереп, күп кенә җаваплы эшләр башкара.

Аның энесе Мәхмүд, шулай ук мәдрәсәне ташлап, русча укырга китә. Революциядән соң комсомол, коммунист һәм татар совет әдәбиятының танылган бер вәкиленә әйләнә.

Замандашларым Каратай Йосыф һәм Әтнә Габдул, берничә ел сабак алганнан соң, Кышкарны ташлап киттеләр, совет чорында алдынгы укытучылар булдылар.

Кышкарда Җиһангир Абезгилдин дигән бер хәлфә укыткан. Шушы кеше, Уфага килеп, җәдит мәдрәсәсе «Госмания»гә җитәкчелек иткән. Драматург Риза Ишморат 1917—1918 елларда шунда белем алган. «Госмания» шәкертләренең берсе — Фәтхелбаян соңгы уку елында Кышкарда дөньяви фәннәр мөгаллиме булды.

Тикшерә китсәң, кадимчел Кышкар мәдрәсәсенә бәйләнгән әнә шундый гыйбрәтле һәм хәтта якты сәхифәләргә дә юлыгырга мөмкин.

1916—17 уку елын мин шәмсияхан булып башладым. Сабакташларым егермеләп кеше иде. Мәдрәсәдән ризасызлыгыбыз зур булса да, аннан китеп бүтән җирдә уку мөмкинлеген уйламый идек әле. Шәһәр тирәсенә барып белем алыр өчен акча кирәк ич! Сабакташымның авылдашлары Баскунчак күлендә тоз чыгарып яхшы гына акча төшерүен ишеткәч, без дә киләсе язда шунда китәргә дип сүз бердек, юлга акча җыя башладык. Ләкин бу планнар тормышка ашмады. Бөек Октябрь революциясе безнең алда яңа һәм чиксез зур мөмкинлекләр тудырды.

1916 елның апрель урталары булса кирәк, Кышкар мәдрәсәсен тәмамлагач, шунда берничә ел хәлфә булып торган, аннары Казанның Печән базары мәхәлләсенә имам булып урнашкан Таип мулла килде һәм шәкертләрне пылау белән сыйларга теләде. Мәҗлескә үзенең якын-тирә авыллардагы замандашларын да чакырды. Мондый күңелле җыйналышта моназаралар, кайнар бәхәсләр дә чыгачагы көн кебек ачык иде.

— Кышкар хәзер элекке Кышкар түгел, дамелла Шаһимәрдән аны җәдитләштерде, «Хәсәения» исе килә аннан, — дип башлады кадимчел муллаларның берсе.

Шуннан китте, китте... Дамелланы буыннан-буынга укытылып килгән элекке дәреслекләрне кулланудан чыгарып, Габдрахман Хаҗтархани, Хәйрулла ахун Госманов, Риза казый Фәхретдинов кебек яңа авторларга өстенлек бирүдә гаеплиләр.

— Их!.. Без укыган шанлы заманнар кайда инде алар? Хәзерге кебек кирпечтән салынган ашханә дә юк иде, чәйне кубта түгел, һәркем үз самавырында кайната, ашны плитә өстендә түгел, казаннарда пешерә идек, шулай да күңелле иде. Хәзер барысы да җәдитләрчә, бары да киресенчә...

Икенче яктан, шул ук дамелланы консерватизмда гаепләделәр. Башкорт егетләре Шаһкамал белән Сабир:

— Ни өчен мәдрәсә заман таләпләреннән һаман артка кала? — дип кычкырды.— «Хәсәения», «Галия», «Бубый» мәдрәсәләре яшәгән зәңгәр күк астында «Кышкария» дә яши алыр иде!

Дамеллабыз менә шушы ике ут арасында чәбәләнде, аның кайсы якка нинди җавап бирүен аңлау да кыен иде.

Беренче бөтендөнья сугышы башлану да мәдрәсә тормышына йогынты ясамый калмады. Чалма чалырга, фәс киярга кү-

неккән башларга картуз чәпәп, кайберәүләрне патша гаскәренә алдылар. Кайберәүләр, куркып, ут эченә кереп, чит җирләрдә үлеп калуга караганда, хезмәте авыр булса да, берәр хәрби заводка урнашып, исән калу хәерле, дип Казандагы дары, Иждәге корал заводына китеп, мәдрәсә белән алыш-бирешне өзделәр. Шуның аркасында элек дүрт өйне тутырган шәкертләр 1915 елның башында бер бинага сыярлык кына калды.

1916—1917 уку елында мәдрәсә тагын бераз җанлана төште: сугышта яраланган, заводта имгәнгән егетләрнең кайберсе кире үз ояларына әйләнеп кайтты. Шулар янына берничә крестьян малае өстәлде.

Казанчы Шәфикъ исә безгә яңадан-яңа хәбәрләрне ташып кына тора: «Башкалада студентлар патшага каршы күтәрелгәннәр, ди. Эшчеләр дә йоклап ятмыйлар, ди. Алар: «Бетсен сугыш!» дип, урамнарда кычкырып йөриләр икән...»

Шәфикъ агай бу хәбәрләрне үз күргән, сер сыярлык шәкертләргә генә сөйли. Әмма иртәгесен бу яңалыклар инде бөтен мәдрәсәгә билгеле була, аннары Ашыт, Әтнә базарлары аша тагын бик күп колакларга барып ирешә.

Көннәрнең берендә мәдрәсәбезгә уртача буйлы, базык гәүдәле, кара-туткыл йөзле, җитү бөдрә чәчле бер егет килеп керде һәм туп-туры Габделхәй хәлфә бүлмәсенә үтте.

Без шәмсия дәресен кабатлап утыра идек, кунак чәй эчеп җылынгач, яныбызга чыгып үзен:

— Сабирҗан Аягузи! — дип таныштты.— Мантыйк укыйсызмы? Ташлагыз шул схоластиканы, хәлфәләрегездән таләп итегез, дөньяви фәннәр укытсыннар!

Сабирҗан Казагыстанның Аягуз шәһәрендәге Сөләйман мулланың улы икән. Сөләйман мулла төп безнең як кешесе булган. Сабирҗан, ни сәбәп беләндер, узган көздән бирле Бәрәңге ягындагы Куян авылында мөгаллимлек итә икән, хәзер бирегә туганнарын күрер өчен килгән.

Күпмедер вакыт үткәч, «Кояш»тамы, әллә башка гәзиттәме, Аягузинең зур гына мәкаләсе басылды. Монда ул ишан абзасын да, аның кызы Мәрьям ханымны, кияве Габделхәй хәлфәне, шул исәптән ничә гасыр тирә-якка «нур» сибеп килгән мәдрәсәбезне дә туздырган иде, мантыйк ятлаучы шәкертләргә дә таяк төшкән!

Бу гәзитне безгә күрсәтмәскә тырышсалар да, мәкалә барыбызга да мәгълүм булды. Сабирҗан сибеп киткән орлыклар әкренләп борный, шытып чыга башлады. Моңа кадәр мантыйкның нигә кирәклеген белмәгән, ләкин төннәр буе аны аңларга тырышкан шәкертләр хәзер бу фәнне өйрәнү ни өчен кирәкмәгәнлеген аңлап бетермәсә дә, мантыйк дәресләренә саботаж ясый башладылар.

1917 елның июнь башларында Габделхәй хәлфә, хат җибәреп, алдагы чәршәмбедә Кышкарда «голама җыелышы» үткәреләчәген, вак-төяк йомышлар башкару өчен минем дә килүем кирәклеген белдергән иде. Хәлфәмнең үтенечен кире какмадым, әйтелгән көнне мәдрәсәгә килеп җиттем.

Җыелышка тирә-юньдәге барлык авылларның муллалары чакырылган иде. Казаннан Габдулла мулла Апанаев, үз авылыннан Хәсәнгата казый Габәши, тагын бүтәннәр дә килде. Байтак вакыт югалып торган Аягузи дә күзгә чалынды.

Көн тәртибендә беренче мәсьәлә итеп барлык мәктәп-мәдрәсәләрне урта уку йортлары программасына күчерү куелган иде. Бәхәсләр бик озак барды, күпчелек мәсьәләне уңай хәл итү өчен тавыш бирде. Шуның нәтиҗәсендә, киләсе уку елында Кышкар мәдрәсәсендә дә мантыйкка тиешле урын бирелү белән бергә, математика, физика, табигать белеме, география, педагогика фәннәре, ана теле, гарәп әдәбияты да укытылырга тиеш иде.

Мәҗлестә шулай ук алпавыт җирләре язмышы, Вакытлы хөкүмәт файдасына икмәк монополиясе мәсьәләләре дә каралды, Аягузи өндәве белән җыелышка бәреп кергән крестьяннар шау-шу күтәргәч, ярым-йорты карарлар кабул ителде.

Яңа программа буенча эшләячәк мәдрәсә чыгымнарына байтак акча җыйналуын, бу уку елында хәлфәләрнең дә эш хакы алачагын, яңа фәннәр укытыр өчен аерым мөгаллим китертеләчәген белгәнгә, 1917 елның сентябрь башында ук инде байтак шәкерт килгән иде. Ай дәвамында алар барысы да җыелып бетте, яңа укучылар да өстәлде.

Кантур өенең алгы бүлмәсе яңа фәннәр укытыр өчен җиһазландырылды: стенага күмер белән яза торган зур класс тактасы беркетелде, идәнгә көрсиләр — артына терәлеп утыра торган парталар тезелде. География дәресләрендә глобус һәм карталар кулланылу да безнең өчен яңалык иде.

География Мөхетдин Корбангалиев дәреслеге буенча укытылды. Математикадан Гомдәтел, Ислам Хәбиревләр, физикадан Габдулла Шөнаси, табигать белеменнән Харис Фәйзинең «Гыйльме әшия»ләре, анатомиядән Нижный мулласы Габдулла Сөләймановның «Гыйльме тәшфих, гыйльме вәзаифе әгъза»сы кулланылды.

Элек касмак дип аталып йөргәннәрне хәзер «рәшди сыйныф» укучысы саныйлар. Безне дә искечә гакандхан дип түгел, игъдади икенче сыйныф укучылары дип атадылар.

Барлык сыйныфларда да математика, физика, табигать белеме, география дәресләрен укытырга Уфадан Фәтхелбаян исемле аз сүзле, шәһәрчә киенгән мөгаллим килде. Габделхәй хәлфә гакаид, фикъһе дәресләрен алып бару өстенә, татар теленнән сабак бирүне дә үзенә алды. Дамелла рәшдиләрдә гарәп теле грамматикасы, бездә риторика дәресләре укытты. Ул да үзе укыткан предметларны Кышкар традициясе буенча түгел, яңа дәреслек нигезендә алып барырга омтыла иде.

Уку елының чиреге узуга илдә зур вакыйга — Бөек Октябрь социалистик революциясе булды. Бу тарихи борылышның, аның эчтәлеген һәм максатын дөрес аңлау дәрәҗәсенә күтәрелгән булмасак та, күзләребез шактый ачылган иде инде. Укучылар оешмасы кебегрәк бер нәрсәбез дә барлыкка килде. Шунда без көндәлек мәсьәләләрне тикшерә башладык. Аерым кешеләргә алдан кушып яздырткан рефератларны укып фикер алышабыз, алар башлыча табигать белеме һәм әдәбиятка багышланган була. Ара-тирә газета-журнал материалларыннан да файдаланабыз. Бер заман утә янарып китеп, нотык сөйләр өчен трибуна да ясатып алдык.

Бу уку елында безнең мәдрәсәгә борчадай хәрәкәтчән, кызгылт чәчле бер малай килде. Илдар исемле бу егет Оренбург шәһәреннән булып, Каргалы мәдрәсәсендә укыган шәкерт иде. Ул бер кәрзин татар әдәбияты әсәрләре төяп алып килгән. Без аның китапларын кулдан-кулга йөртеп укырга керештек. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Камал һәм башкаларның әсәрләре белән танышу шуннан башланды.

Безнең әдәбият белән кызыксынуыбыз шәмсияханнан утә алмаган, әмма очраклы рәвештә хәлфәгә әйләнгән Мазһарга бер дә ошамый иде. Ул безне «сафсата» белән гомеребезне «исраф итү»дән саклау юлында бөтен көчен куеп тырыша иде: кичке моталәгә вакытында чаршауларны төшереп, берәр дини китап эченә куеп кына хикәя укырга тотынсаң, шыпырт кына килә дә, тычканга ташланган мәче кебек, китапны эләктереп ала һәм ерткалап аяк астына салып таптый!

Ләкин бу осталыгыннан мөгаллимебез күп файдалана алмады: ул иснәнеп йөри башлау белән берәрсе «пересс!» дип кычкырып сигнал бирә. Китап шунда ук чаршаулар астыннан кулдан-кулга күчеп, икенче почмактагы шүрлеккә үк менеп ята. Мазһар никадәр генә тырышып эзләсә дә, таба алмый аны. Аннары, яхшылык итәргә теләгән кеше кебек кыланып, ике кулын бутый-бутый аңлатырга тотына:

— Мин сезнең тәрле юк-барны укып әрәм узган гомерегезне кызганам, — ди.

Апрель урталары житкәндә, бик кызу рәвештә спектакль куярга әзерлек башланды. «Кызлар шулай кызык итә» дигән пьеса сайланды. Кәҗә өенең бер бүлмәсендә бик яшерен рәвештә репетицияләр ясалды. Кызлар ролен дә егетләр башрачак иде. Режиссерыбыз — Илдар. Ул — шәһәр малае, бу эшнең ибен-җаен яхшы белә, режиссерлык вазифасын бик җиренә җиткереп үти иде. Ул соңыннан Илдар Мәҗит исеме белән татар сәхнәсенең күренекле артистына әверелде.

Менә спектакль көне килеп җитте. Моның өчен пәнҗешәмбе көн сайланган иде. Кунак өе кызларына ялынып, күлмәк, алъяпкыч, муенса-беләзек, кашына исем язылган көмеш йөзек, кәшмир яулык һәм оекчабаталар юнәтелде. Тәбәнәк өстәлләребезне тезеп, сәхнә идәне ясадык, ә чаршауларыбыз стена ролен үтәде.

Спектакль менә башлана гына дип торганда кемдер:

— Габделхәй абзый килә! — дип хәбәр итте.

Инде нишләргә? Килеп керсә, туздырырга мөмкин!

Каравылчы Гәрәй тапкырлык күрсәтте. Кыз кеше булып киенгән хәлендә:

— Үзем җайлармын мин аны, — дип хәлфәне каршыларга чыгып китте.

Габделхәй хәлфә караңгы өйалдына килеп керү белән Гәрәй аны кочаклап ала да битләреннән үбәргә тотына. Хәлфә:

— Кайсыгыз бу, җен кавеме? Җибәр!! — дип чәбәләнә башлый. Гәрәй аны тагын да кысыбрак кочаклый да, нечкә тавыш белән:

— Бу мин ич, Гарифә! Үзең бер күрешик дип колак итемне ашый идең, җае чыккач, нигә качасың? Монда караңгы, беркем дә күрми, — ди.

Хәлфәбез көч-хәл белән ычкынып таю ягын карый. Дамеллага йөгергәндер...

Кышкар мәдрәсәсендә куелган беренче спектакль тыныч, шома гына узды. Чынлыкта бу көнне ике комедия уйналды: икенчесе Габделхәй хәлфәне көлкегә калдыру иде! Соңыннан белдек: хәлфә чыннан да дамеллага барган, әмма хәзрәт:

— Булмәгезгә кереп спектакль куймасалар, тыныч кына китап моталәга кылып утыра бирегез, Габделхәй әфәнде! — дип җавап биргән икән.

Яңа программа буенча безгә рус теле дә укытылырга тиеш иде. Ниндидер сәбәпләр аркасында кыш көне моңа җай табылмады. Уку елы тәмамлангач, теләгән кешеләр җәйге каникул вакытында ике ай русча укый алалар, дип белдерделәр.

Теләүчеләрдән егермеләп кеше май ахырларында рус теле курсына җыелдык. Габдрахман Вәлидев дигән укытучы чакырылган иде. Кышкардан унбиш чакрым ераклыктагы Мамыш авылыннан парталар, класс тактасы һәм чут алып кайттык. Иске мәдрәсә бинасында парталар артына утырып рус теле өйрәнә башладык. Мин үзебезнең тегерманче малае — Уфа укытучысыннан бер җәйне ике ай русча укыган идем, шуңа күрә икенче класска утырттылар. Укытучыбыз оста педагог булып чыкты. Ике ай эчендә ул безне рус телендә укырга-язарга гына түгел, ватып-җимереп булса да, үзара бераз сөйләшергә дә өйрәтте. Укудан буш вакытларда без, бик үк якын булмаса да, Ашыт елгасына балыкка йөри һәм шунда бары тик русча гына сөйләшергә тырыша идек.

Ике айлык курс тәмамлангач, Мамыштан алып кайткан әйберләрне илтеп тапшырып, мәдрәсәнең ишек-тәрәзәләрен кадаклап һәм мәшһүр уку йорты белән мәңгегә саубуллашып, өйләргә таралыштык.

Атаклы Кышкар мәдрәсәсенең соңгы еллары менә шулай үтте. Әйтергә кирәк, актык уку елын тәмамлаганда безгә, кулдан гына язып булса да, таныклык та бирделәр. Укытучылыкка гариза язып, шәһә-

дәтнамәне дә теркәп Кызылкакшай өязе мәгариф бүлегенә җибәргән идем, ул шунда төпләнеп калды.

Кышкарның иң соңгы дамелласы Шаһимәрдән Үтәгәнев заманында бик азга да канәгатьләнеп, чиксез тырышып укучы, төннәр буе китап актарып чыгучы шәкерт булган, дип сөйлиләр иде. Кием-салым, ат-дирбия, җиһаз мәсьәләләрендә гаять талымсыз булса да, аның китапка үтә һәвәслеген мин үзем дә күрә алдым. Дамелланың өендә рус классикларының төрекчәгә тәрҗемәләре, төрек, гарәп әдәбияты һ. б. китаплар шкаф тулы иде. Алар бар да укылган, кырларына җыйнак кына кул белән искәрмәләр дә салган иде.

Дамелланың әдәби китаплар белән кызыксынуы, бәлки, кыска гына вакыт булса да «Хөсәения» мәдрәсәсендә мантыйк укытуга бәйләнгәндер. Чөнки «Хәсәения» мөгаллиме Җамалетдин Вәлиди минем Кышкарда белем алуымны белгәч:

— Шаһимәрдән дамелла шәкерте икәнсез. Ул «Хөсәения»дә шактый консерватив мөгаллим иде. Кышкарда үтә яңа фикерле мөдәррис даны таралуын ишеттек,— дигән иде.

Икенче бер казанда кайнап алуның йогынтысы чыннан да зур булгандыр, мәдрәсәгә әллә ни яңалык кертә алмаса да, Шаһимәрдән хәзрәт шәкертләренең азмаз яңалыкка омтылышын әзәрләкләмәде. Ниндидер сәбәпләр белән бүтән мәдрәсәләрдән куылып килгән шәкертләрнең Кышкарда сыену урыны табуы да игътибарга лаек. Каргалыдан килгән Илдар, «Мөхәммәдия»дән сөрелгән Дибердиев әнә шундыйлардан иде.

Сирәк кенә булса да дамелла җор сүзләр дә ычкындыргалый иде. Мәҗлескә килгән кунакларга садака өләшеп йөргәндә кулыннан егерме тиенлек тәңкәне төшереп җибәргәч, сәер уфтанып:

— Һай, гел алырга гына өйрәнгән кул белән садака өләшү кыен икән! Крестьян халкы ничек түзә моңа — гел бирә дә бирә генә бит ул, бичаралар! — дип, мәҗлесне җанландырып җибәргән чаклары да булды.

Егерменче елларда Мәхмүд Максуд белән без тагын бер мәртәбә дамелланың өендә булдык. Мәхмүд аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иткәч, хуҗа:

— Мәҗлес мөгафмы? Сүз читкә чыкмасмы? — дип сорады. Вәгъдә биргәч, ул безнең белән байтак сөйләшеп утырды. Озакламый газетада Мәхмүднең «Соңгы дамелла» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Әйтүләренә караганда, шуннан соң Шаһимәрдән абзый беркем белән дә бернинди темага да сөйләшмәс булган. Авылда колхозлашу хәрәкәте башлангач, 1930 елда йорт-җирен калдырып, ул Казандагы кызына күчеп килгән һәм 72 яшендә дөнья куйган. Аның тарала башлаган китапханәсен укымышлы Сәет Вахитов җыеп алып киткән дип ишеттем.

Йомгак итеп, кыскача әйткәндә, Кышкар мәдрәсәсе тарихы халкыбызның мәгариф өлкәсендәге катлаулы үсешен күзалларга азмы-күпме ярдәм итә торган бер чыганак булып тора. Октябрь революциясеннән соң аның урынында яңа типтагы татар совет мәктәбе барлыкка килде.

# Укучының күңел дәфтәренә

### Гагауз мәкальләре һәм әйтемнәре

*Дуслык юлда сынала.*
*Мөгезләрем авыр диеп бер үгез дә зарланмый.*
*Суы китә, комы кала.*
*Карт мәче яшь тычкан тоткан.*

### Грузин мәкальләре һәм әйтемнәре

*Тирән су тиз болганмый.*
*Байлык — сукыр чебендәй: бер чәчәккә, бер тизәккә куна.*
*Суда тамыр корымый.*
*Кеще бакчасына керсә, кәҗә дә җырлап йөри.*
*Тыңлап бетермәгән төштә хакыйкать юкка чыга.*
*Күләгә кебек кеше: кусаң — кача, качсаң — куа.*
*Ишәк койрыгы кебек: озын булып та үсми һәм кыскартып та булмый.*
*Мәхәббәт чәчәгеп әзли, ә көнчелек — чәнечкесен.*
*Һәр колак сер тыңлый белми.*
*Мәетләр арасында юк, тереләргә файдасыз.*
*Кеп-кечкенә балта белән зур агач егып була.*
*Мөгезе үсмәгән кәҗә үзен мин бәрән дип уйлый.*
*Бәрәннәрен урлаткан да йортын бикли башлаган.*

# ЖАНР ТОЙГЫСЫ

Татарстан китап нәшрияты күптән түгел Әмирхан Еникинең хикәяләр җыентыгын бастырып чыгарды. Тышлыгы ачык төстәге материядән пөхтә, матур итеп эшләнгән һәм карап торуга ук күңелгә ниндидер бер рәхәтлек бирә торган бу җыентыкны зур хөрмәт белән кулга аласың. Китапка язучының 1941 елдан алып 1978 елга кадәр иҗат иткән егерме җиде хикәясе тупланган. Бу— елына бер хикәядән дә азрак туры килә дигән сүз. Ләкин ул хикәяләр Әмирхан Еники иҗатында гына түгел, гомумән, соңгы еллар татар әдәбиятында иң яхшы хикәя буларак бәяләнергә хаклы. Алар безнең хикәянең, сокланып һәм күңел нечкәргәнче укып кына калмыйча, җентекләп өйрәнүне, тикшерүне сорый торган классик үрнәге, дип һич икеләнмичә әйтергә мөмкин. Әдипнең яңа җыентыгы сугышчан, әмма ифрат авыр бу жанрның үзенчәлекләре хакында кат-кат уйланырга мәҗбүр итә.

Бездә кайчандыр тәнкыйть жанрының, аннары драматургиянең артта калуы турында сөйләнелде. Ә хәзер исә бәхәсләрдә иң зур урынны нәкъ менә хикәя алып тора. Прозаикларыбыздан Ф. Хөсни, М. Әмир, Г. Минский бу хакта инде бер генә тапкыр язмадылар. Моннан берничә ел элек — «Казан утлары»ның 1973 елгы 8 санында — тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин хикәя турында бик үткен һәм нигезле мәкалә белән чыкты. Анда тәнкыйтьче, конкрет һәм ышандырырлык мисаллар белән, татар хикәясендә вак темалар белән мавыгу, ясалмалылык, тормыш дөреслегенә хыянәт итү, вакыйгаларга һәм күренешләргә карата авторның төгәл һәм ачык мөнәсәбәте булмау кебек кимчелекле якларны ачып салды.

Безнең әдәбиятыбызда хикәя жанры артта калуның төп сәбәбе әдәбиятка яңа, яшь көчләрнең җитәрлек килмәвендә дигән караштa торучылар белән килешү, минемчә, дөрес булмас иде. Монда күпмедер дәрәҗәдә дөреслек тә юк түгел, әлбәттә. Ләкин бит соңгы ун ел эчендә генә дә әдәбият мәйданына аяк баскан яшь прозаикларның саны кимендә өч-дүрт дистәгә җитә. Алар арасында инде бер, ике һәм аннан да күбрәк китап бастырып чыгарырга өлгергән авторлар да бар. Җитмешенче елларда китапларда, журналларда, газеталарда басылган хикәяләрнең барсын бергә җыйсаң, алар саны берничә йөздән артып китәчәк. Ә менә шуларның оста итеп, камил язылганнары бармак белән генә санарлык.

Хикәя жанрының артта калуына төп сәбәп —аның специфик үзенчәлекләрен тиешенчә бәяләп җиткермәү диясе килә. Чыннан да, бездә, гәрчә бу ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, хикәя ул—роман һәм повесть кебек «эре» жанрларга тотынганчы үзеңнең каләм көчеңне сынап карау өчен плацдарм булып хезмәт итә дигән кебегрәк ялгыш караш яшәп килә. Әмма һәр тармакта специальләшү барган заманда мондый «ярымбелгеч»ләрнең нигезсез фикерләрен тормыш үзе кире кага. Хикәя, әйтик, роман яки драма кебек ук, үзүзеңне аямыйча зур көч куеп эшләүне, тормышны үзеңчә күрә һәм чагылдыра алырлык дәрәҗәдә талантка ия булуны таләп итә. Шуңа күрә бик яхшы романчының да берникгә тормаслык хикәяче булуы ихтимал. Әгәр кем дә булса бу жанрның үзенчәлеген тотып алырга, аның җанына үтеп керергә сәләтле булып, үзенең бөтен иҗади гомерен шул жанрга багышлый икән, монда берниндн дә гөнаһ юк.

Әмирхан Еники хикәягә ифрат зур җаваплылык хисе белән килә торган искиткеч таләпчән язучыларның берсе. Художник буларак аның төп үзенчәлеген бер сүз белән әйтеп бирү соралса, мин бер дә арттырмыйча, татар әдипләре арасында ул **иң музыкаль язучы**, дип җавап бирер идем. Аның фразалары һәрвакыт җиңел, үтә күренмәле, музыкаль яңгырашлы. Хикәяләре, әйтерсең лә, ниндидер бер сихри көчкә, тылсымга ия, аларның һәркайсы укучыда билгеле бер настроение уята. Еш кына очракларда хикәяләүдәге якты, җиңелчә моңсулык әбиләр чуагының көмеш пәрәвезләре сыман зәңгәр һавада тирбәлеп тора сыман.

Ә. Еники — менә дигән тел остасы һәм бик сизгер стилист. Аның әсәрләренең русча тәрҗемәләрен укыганда, мин, мәсәлән, үземне бик кыен хәлдә калгандай хис итәм. Юк, тәрҗемәләрнең ул чаклы ук начар сыйфатлы булулары өчен түгел. Бу язучы татар теленең үзенә генә хас стихиясе, милли фикерләүнең, дөньяны танып-белүнең татар кешесенә хас булган үзенчәлекләре белән шулкадәр тыгыз бәйләнгән ки, иң әйбәт эшләнгән тәрҗемәдә дә ниндидер югалтулар котылгысыз. Әмирхан

Еникинең Бөтенсоюз укучысына чагыштырмача аз билгеле булуын да бәлки әнә шуның белән аңлатырга кирәктер. Югыйсә бит аның иҗат багажында иң өлгереп җиткән теләсә кайсы әдәбият укучысын да сокландыра алырлык «Бер генә сәгатькә», «Ялгызлык», «Әйтелмәгән васыять», «Тынычлану» һәм башка хикәяләр бар.

Үз халкының милли стихиясе белән тумыштан ук килә торган бәйләнеш, хикәяче буларак, Әмирхан Еникинең бердәнбер үзенчәлекле ягы түгел. Ул әлеге жанрның табигатенә, характерына яңалык кертте, аңа өр-яңа буяулар өстәде.

Л. Тимофеев билгеләмәсе буенча, эпик жанрлар тормыштагы вакыйгаларны колачлау принципларына карап, түбәндәге төрләргә бүленә: хикәя кешене үз тормыш юлына характерлы булган бары тик бер генә эпизодта күрсәтә; повесть тормышның билгеле бер чорын һәм берничә эпизодны эченә ала; роман кешенең бөтен тормышын башкаларның язмышы белән үрелештә гәүдәләндерә. Ләкин бу принцип универсаль булудан бик ерак тора. Кешенең бөтен тормышын, һич югында, аның бер әһәмиятле чорын тасвирлаган хикәяләр белән (М. Шолоховның «Кеше язмышы» хикәясен генә алыйк) берәттән нибары бер вакыйганы яисә эпизодны, я булмаса геройлар тормышының бер генә көнен сурәтләгән романнар һәм повестьлар (мәсәлән, В. Катаевның «Вакыт, алга!» романы) иҗат ителмимени?!

Татар әдәбияты практикасында, әгәр аның иң яхшы үрнәкләренә мөрәҗәгать итсәк, чынлап та, геройның тормышыннан алынган бер генә эпизодка нигезләнеп язылган хикәяләр аз түгел. Моңа мисал итеп Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә» дигән хикәясен китерергә мөмкин. Ә бит шул ук авторның геройлар тормышының зур бер чорын, алай гына да түгел, бөтен тормышын эченә алган һәм бер-берләренә үзара бәйләнгән эпизодлар тезмәсеннән торган «Тауларга карап» рәвешендәге хикәяләре дә байтак.

Минемчә, ничек кенә булмасын, хикәянең үзәгендә берме яки берничәме вакыйга түгел, ә бәлки алар аша авторның укучыга әйтергә теләгән фикере ятарга тиеш. Үзенең тулы чагылышын табар өчен роман кадәр роман, хәтта эпопея таләп иткән фикернең дә булуы мөмкин. Шуның белән берәттән башка берминди жанрда да түгел, бары тик хикәядә генә гәүдәләндерүне сорый торган фикерләр дә була. Монда инде фикер һәм тасвирлауның бердәмлеге алгы планга чыга. Хикәя теге яки бу язучының үз әсәрендә тасвирларга теләгән нәрсәнең һәм аңа туры килерлек сәнгатьчә гәүдәләндерү алымнарының бердәмлеген сорый. Хикәяләр язу өчен әзер рецепт бирә икән бу дип уйламагыз. Андый әзер рецептлар юк һәм була да алмый. Әмма Әмирхан Еники тотып ала алган һәм шуңа ия булган жанр тойгысы дигән нәрсә бар. Мисал өчен язучының иң яхшы әсәрләреннән берсе булган «Әйтелмәгән васыять» хикәясенә генә тукталып узыйк.

Башкорт карчыгы Ак әби үлем түшәгендә ята. Үзенең вафатын ул мәтрүшкә һәм әрем исе аңкып торган кылганлы иксезчиксез далада түгел, кызының һәм киявенең һәрьяктан уңайлы иркен квартирасында каршылый. Балаларына ул соңгы сүзләрен әйтеп, үзенең әллә ни искитәрлек булмаган, әмма ата-бабаларыннан мирас булып калган бәрхет камзулын, вак-вак энҗеләр белән чигелгән баш киемен, көмеш муенсаларын васыять итеп калдырырга җыена. Ләкин шәһәр тормышының өермәле вакыйгалары эчендә кайнаган балаларына һәм оныкларына болар бөтенесе бер тиенгә дә тормаган иске-москы булып күренә. Карчык белән юньләп сөйләшергә, аның сүзләрен тыңларга аларның хәтта вакытлары да юк. Уларының берсе отставкадагы полковник — таза, базык гәүдәле, юан муенлы, йомырка шикелле озынча һәм пеләш башлы Сафуан тормышы инде сүнә торган әнисенә иң кирәк бердәнбер нәрсә — шат күңеллелек дип саный. Менә ул, бөтен бүлмәне командирларга хас булган яңгыравыклы калын тавышы белән тутырып, әнисе белән, кем әйтмешли, мәҗбүри рәвештә шаярып сөйләшә. Әдәп саклау йөзеннән әниләре янында берничә минут утырганнан соң барысы да таралышалар. Оныгы Геннадий әбисе белән бик сөйләшер иде дә, үзенең туган телен белми. Аңа бары тик күкрәгенә бармак белән төртеп күрсәтергә генә кала: «Башкорт мин, әби, башкорт...» Ак әбинең кызы Гөлбикәнең—балалар анасы һәм танылган фәнни хезмәткәрнең—үзенең дә мәшәкатьләре муеннан. Әнисе белән сөйләшергә ул вакыт та таба алган булыр иде, әлбәттә. Ләкин Ак әбинең авыз ачып үлем турында сөйли башлавы белән сүзне ул бүтәнгә борачак: «Кирәкми, әни, син әле тереләчәксең...»

Шулай итеп, үзенең уй-кичерешләре белән икәүдән-икәү калган хәлдә, карчык дүрт стена арасында ята бирә. Менә ул барыннан да ныграк курыккан нәрсә алга килеп баса — аны больницага алып китәләр...

Язучы буяуларны куертмый, Ак әбинең балаларын явызлык кылучы җаннар итеп күрсәтми. Алар әйбәт һәм тәртипле, гадәти кешеләр. Әниләре турында үзләренчә кайгырталар, авырганлыгын ишетү белән аны үз яннарына алдыралар, иң әйбәт белгеч — врачларны чакыралар, аның хәлен яхшырту өчен бөтенесен эшлиләр. Алар әдәпсез түгел, белемле, интереслары киң һәм күпкырлы. Ләкин хикәяне укыган саен без аларның рухи ярлылыкларын ачыграк тоябыз. Тышкы яктан караганда зур цивилизациягә һәм үзләрен ураган техник комфортка ия булуларына да карамастан, аларның эчке дөньяларына нидер җитми. Ә атап әйткәндә нәрсә җитми соң?

Еники хикәясендә карчыкның үлем алды хәленә бары тик ике генә кеше чын-чынлап керә. Болар — биш яшьлек кыз һәм инде яшь булмаган, эчүгә бирелгән, әмма бала-

ларча беркатлылыгын һәм күңел сафлыгын югалтмаган шагыйрь. Халыкның гасырлар буена җыелган акылы, дөньяга һәм кешеләргә балаларча ышанып каравы, табигать белән якыннан аралашуы һәм аны шагыйрьләрчә аңларга сәләтлелеге — менә нәрсә җитми Ак әбинең балаларына.

Язучы бу хикәясендә дә үзенең күптәнге темасын—каты күңеллелекне, үз-үзеңнән мещаннарча канәгать булуны, рухи чикләнгәнлекне фаш итүне дәвам иттерә. Бу мәсьәләнең куелышы бәлки яңа да түгелдер, әмма аның художестволы конкретлыгы ышандыра. Хикәяне укыганда ирексездән үз-үзең турында, әниеңә һәм башка кешеләргә мөнәсәбәтең турында, яннарыннан бөтенләй игътибар итмичә, күрмичә үтеп китәргә күнегелгән башка бик күп нәрсәләр турында уйланасың.

Әйе, тормыш тукталышсыз алга бара. Шул ук Ак әбинең балаларын гына алыйк. Аларның берсе врач, икенчесе инженер, өченчесе кадровый офицер, дүртенчесе күренекле галим. Бернича дистә ел эчендә халыкның тормышында шундый зур сикереш ясалды ки, андый сикерешнең мең еллар эчендә дә ясалуы мөмкин булмаган.

Ләкин без халык тарафыннан тупланган барлык рухи һәм культура хәзинәләребезне кайгыртучан сакласак, безнең тормышыбыз тагын да баерак, тагын да матуррак булачак. Карчыкның үз балаларына башкорт милли киеме әйберләрен күңеленнән генә әйтеп калдырган васыяте күренешендә тирән мәгънә ята. Һәр халык коммунистик культураның гомум хәзинәсенә үз өлешен кертә һәм бу өлеш халыкның бүгенге генә түгел, үткәндәге традицияләре, образлы фикер йөртү үзенчәлекләре, кыскасы, без милли үзенчәлек дип атый торган барлык нәрсәләре белән дә билгеләнә.

Ни өчен безнең архитектурабызда, кайбер искәрмәләрне исәпләмәгәндә, бөтенләй диярлек милли мотивлар калмады? Хәтта үзенең кабатланмас матурлыгы белән һәркемне сокландырган татар орнаменты да файдаланылмый. Ни өчен болгар культурасы чорыннан ук килә торган күп кенә башка һөнәрләр, әйтик, кул эшләре онытылган? Ни өчен Казанга килүчеләр истәлеккә менә дигән итеп эшләнгән милли сувенир алып китә алмый? Ә Казандагы бердәнбер милли ашлар йорты ни өчен йөгереп кереп ашыкпошык кына капкалап чыгу урынына әйләнгән?

Әмирхан Еникинең әлеге хикәясе мене нинди уйларга этәрә. Кайчандыр мондый «вак» нәрсәләр турында уйланырга ара юк иде. Ә бүген инде без шундый этапка күтәрелдек, узганга борылып карау һәм ашыгычлык белән нәрсәне дә булса онытып калдырмадык микән дип уйлану һич тә гөнаһ түгелдер. Һәм моның өчен, мөгаен, беркем дә «милли чикләнгәнлек» яки «патриархаль искелекне идеальләштерү» дигән ярлыклар тагарга җыенмас.

Бу хикәягә ни өчен шулай озак тукталынды? Беренчедән, бу — Ә. Еникинең иң кызыклы һәм әһәмиятле хикәяләреннән берсе. Аны хәтта кечкенә повесть диярга да була. Икенчедән, зур иҗат тәҗрибәсе туплаган әдипнең иң характерлы үзенчәлекле яклары—художество осталыгы, психологик характеристикалар тирәнлеге, шаблон буенча түгел, үзенчә фикерләве — аның нәкъ менә шушы хикәясендә ачык гәүдәләнгән.

Прозаикның оригинальлеге барыннан да элек аның фикерләвенең оригиналь булуында. Художестволы фикерләү! Әмирхан Еники хикәяләренә анализ ясагач, менә шундый нәтиҗәгә киләсең. Еникидә бернинди әзер чишелеш юк, тормышны ул әдәби схемаларга «куып» яки көчләп кертергә тырышмый. Ул үз идеясен турыдан-туры тәгъбирләүдән кача, үз мөнәсәбәтен теге яки бу персонажга бәйләргә теләми. Нәтиҗә ясауны укучының үзенә калдырып, теге яки бу күренешне гаделлек, риясызлык һәм объективлык белән сурәтли. Менә шуның өчен дә аның күпчелек әсәрләре бәхәсләр һәм капма-каршы фикерләр күрәше китереп чыгара.

Ә. Еники башлыча кешенең эчке дөньясы, аның хисләре, мораль һәм әхлакый сфера белән кызыксына. Аның әсәрләрендә турыдан-туры күзгә ташланып торган «производство конфликтлары» да, көннең кадагына ашык-пошык кына «сугу» да юк. Әмма алар кешеләргә тирән мәхәббәт белән сугарылганнар, кеше күңелендәге иң яхшы, иң матур якларга мөрәҗәгать итүгә юнәлдерелгәннәр.

Язучы матурлыкны, ул тышкы ямьсезлек һәм хәтта гариплек артына яшеренгән булса да, тоя һәм күрә белә. Беренче карашка кечкенә, әһәмиятсез булып күренгән нинди генә вакыйга турында язмасын, Еники ул күренешнең асылына төшенергә, фактның фәлсәфи мәгънәсен ачып бирергә тырыша. Тормышның мәңгелек көче турында уйланулар белән сугарылган «Тауларга карап» хикәясе, мәсәлән, әнә шундыйлардан.

Яңалыкны, кешелеклелекне җырлау белән беррәттән, язучы кеше тормышын ямьсезли, боза, гариплэтә торган нәрсәләрне дә читләп узмый, игътибарсыз калдырмый. Еникинең бөтен иҗаты аша бүгенге мещанлыкны фаш итү темасы уза.

Бу күзлектән караганда, «Язгы тамчы» хикәясе аеруча игътибарга лаек. Бу хикәядә саран, әмма күз алдына китереп бастыра торган буяулар ярдәмендә тышкы яктан һәрнәрсәсе килгән һәм ихтирамга лаек булып күренгән фәнни работник Хәлил Ишмәевнең мораль деградациясе тасвирлана. Монда аерым вакыйгалар турында сөйләнмәсә дә хикәянең проблематикасы ифрат дәрәҗәдә актуаль. Икейөзлелек һәм астыртынлык яңа кешенең чын әхлакый йөзе белән килешә аламы? Кеше үз дусты белән икәүдән-икәү калганда бер төрле, ә трибунага менгәч шуның нәкъ киресен сөйли аламы? Язучы бу мәсьәләгә аңлы рәвештә кат-кат басым ясый, вакыйганы логик ахырынача җиткерә. Хикәяне азагына кадәр укып чыккач, бу икейөзлелек һәм принципсызлыкның, кешене мораль деградация чигенә китереп җиткереп, аның жа-

нын ашый торган күгәрек, тутык икәнлегенә ышанабыз.

Мещанлык күп төрле. Аның бүлтәеп чыккан корсаклы комодлар, тузанлы фикуслар һәм күзнең явын алып торган абажурлар тирәлегендә генә булуы мәҗбүри түгел. Хәтта аларга алмашка килгән магнитофоннар, торшерлар һәм ялтырап торган мебельләр дә обывательнең йөзен билгеләми әле. Мещанлык ул барыннан да элек дөньядан аерылу, аның белән алыш-бирешең булмау. Эгоизм, үзеңә күбрәк умыру, рухи яктан корыганлык, үзеңнең вак максатларыңны алга сөреп, җәмгыять интересларын санга сукмау — менә нәрсә ул мещанлык. Төрле кабык эченә яшеренгән шушы черек карынны фаш итеп һәм ачып сала да инде Еники. Номенклатурный работникның эшсезлектән һәм тыгынып ятудан туң йөрәккә әверелгән хатыны Диләрә («Мәзәк»), мәгънәсез һәм мин-минлекне сөйгән йөрәк җилкендергеч Петр Котов («Ялгызлык»), агым ыңаена акрын гына йөзеп баручы фәнни работник Хәлил Ишмәев («Язгы тамчы») — Еники әсәрләрендә безнең күз алдыбыздан узучы мещаннарның бөтен бер галереясе әнә шундыйлардан гыйбарәт.

Бүгенге мещанның төп сыйфаты итеп язучы аның тормышның яңа шартларына тиз җайлаша алучанлыгын күрсәтә. «Корьән Хафиз» хикәясендә әрсез Хафиз, мәсәлән, бер үк җиңеллек белән диндар гайбәтче дә, күн курткалы «комиссар» да була ала. Форма гына үзгәрә, обывательнең асылы үзгәрми.

Әмирхан Еники әсәрләре тирәсендә барган бәхәсләргә борылып кайтып, бу язучының күпчелек очракта нәкъ менә үзенең негатив позициясендә, тормыштагы зарарлы, гарип якларны кире кагуында көчле икәнлеген танырга кирәк. Авторның уңай программасы исә еш кына томанлы, билгесез, аныксыз була. Ул тудырган уңай геройларның йомшаклыгы бәлки нәкъ менә шундадыр да. Алар явызлык алдында җиңеләләр, аның белән килешәләр.

Язучының иҗатында әледән-әле кабатлана торган бер тема бар. Ул — ата-баба нигезе һәм туган җир темасы. Бу тема аның «Җиз кыңгырау», «Картлар» һәм башка хикәяләрендә искиткеч зур җылылык белән яңгырады. Әлеге теманы чишүгә Еники шулай ук философик позицияләрдән якын килә. Ләкин бу зур колачлы уйлану-фикерләүләр түгел. Еникинең философиясе гүяки әсәрләренең тукымасында эри. Ул — чын кешелеклелек, чын матурлык алдында табынуда, кеше тормышына ят булган бөтен нәрсәләргә җирәнеп карауда.

Повесть һәм роман кеше тормышын күп планлы итеп, төрле үлчәүләрдә, хәрәкәттә һәм үсештә колачларга омтыла. Хикәя исә, кагыйдә буларак, кешене бер планда, бер киселештә күрсәтә. Менә ни өчен хикәянең беренче төп билгесе булып ситуациянең бердәмлеге санала. Өстәвенә хикәя шундый ситуациягә тартыла, анда тормыш өстән караганда күренмәгән иң тирән катламнарын ачарлык, антрацит кисәгендәге кебек үзенең өр-яңа кыры белән җемелдәрлек булсын. Повестьта һәм романда язучы берничә проблеманы күтәрә ала. Аларның һәр бүлегендә икенче бер тональлек, икенче бер көй булырга мөмкин. Ә кечкенә күләмле хикәя моны кабул итә алмый. Ә. Еники хикәяләре шундый рухның, ягъни хәрәкәткә китерүче фикернең бердәмлеге белән аерылып торалар.

Еники әсәрләрендә фикернең үткенлеге һәм киеренкелеге форманың пөхтә һәм җентекле эшләнеше белән бергә үрелә. Аның стилен еш кына Чеховныкына тиңлиләр. Дөрестән дә, татар прозаигы рус классигыннан күп нәрсәгә өйрәнгән. Аны Чехов белән көнкүрешне тулы һәм дөрес чагылдыруы, сурәтләвендәге лаконизм, детальләрне оста тотып ала һәм куллана белүе, геройларының эчке дөньясына зур игътибар бирүе һәм нечкә лирик рухы якынайта. Хәтта тормышка карашы ук — әле моңсу-мәсхәрәле, әле җитди-уйчан, кешегә ышаныч һәм кеше тормышын гарипләтә торган бөтен нәрсәгә ачы нәфрәт — һәммәсе Чеховның дөньяга карашын хәтерләтә.

Ләкин шул ук вакытта Әмирхан Еники милли язучы. Ул татар җирлегендә үсте, иҗатына кирәк азыкны халык традицияләре чишмәсеннән чумыра, татар әдәби телен сак кына шомарта һәм үстерә, аның хәзинәсен баета. Бигрәк тә шунысы куанычлы, язучы көндәлек сөйләм теле байлыгы белән генә чикләнеп калмый. Ул телнең ерактагы хәзинәләренә әледән-әле күз төшереп ала, классиклар телендә ныгып калган сүз запасларыннан киң файдалана. Шуңа күрә Әмирхан Еникинең телендә ара-тирә китап теле куныгы сизелә, ләкин ул һичкайчан да чамадан тыш түгел.

Үзенең иҗатында Ә. Еники төрле стилистик буяуларга мөрәҗәгать итә: ул әле ачы сарказм, үтергеч ирония, әле тыныч, айнык анализ, әле җылы, йомшак, лирик интонация. Әммә без һәр очракта Еники стилен, аның алымнар суммасына гына кайтып калмаган, ә язучы талантының иң күп төрле якларын бергә туплаган кабатланмас индивидуаль йөзен ялгышмыйча таныйбыз.

Еники әсәрләрендә күп кенә очракларда күзгә ташланып торган сюжет булмый, алар кискен, күңелле һәм кызыклы вакыйгаларга нигезләнәләр. Игътибар кешеләрнең эчке дөньясына юнәлгән. Конфликт гадәттә образлар арасында түгел, ә образның үз эчендә туа. Язучы тупас басым ясау, буяуларны куерту юлына басмый. Аны барыннан да элек нюанслар, ярымтоннар, күңел хәрәкәтенең нечкә күчешләре кызыксындыра.

Җыеп кына әйткәндә, Әмирхан Еники хикәяләренең сокланырга мәҗбүр иткән төп «секреты» — аның ярты гасырга якын иҗат практикасы, зур тормыш юлы һәм, әлбәттә, якты, үзенчәлекле таланты биргән «жанр тойгысы»нда.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ТАТАР ТАРИХЫ ТУРЫНДА КИТАП

Халкыбыз үткән юл озын һәм гыйбрәтле. Аның иҗтимагый-социаль тарихы зур һәм бу тарих Бөек Октябрь таңында яңадан туу тарихы белән нык бәйле. Илебез халыкларының бердәм гаиләсендә олы бәхеткә ирешкән һәм якты киләчәге булган милләт тарихы, әлбәттә, өйрәнелергә һәм гомумиләштерелергә тиеш.

Бу очракта сүз татар тарихы сәхифәләренә чит ил кешесенең мөрәҗәгать итүе турында барачак. Ул — Америка Кушма Штатларындагы Сен-Луи университетының отставкадагы профессоры Борис Ишбулдин—Әл Бакри. Һөнәре буенча экономист кешенең ни өчен тарих белән кызыксынуы аңлашылсын өчен, аның Россиядә туганлыгын һәм нәсел-нәсәбе белән борынгы татар ыруына бәйле булуын истә тотарга кирәк: Ишбулдин үзенең шәҗәрәсе нугай морзаларыннан килә дип саный.

Америка профессорының татар тарихы белән кызыксынуы бүген генә башланмаган. 1945—1962 елларда ул шул темага берничә мәкалә бастыра. 1963 елда өлеге мәкаләләрне туплаган җыентыгы дөнья күрә. Ун елдан соң җыентыкның икенче басмасы Һиндстанда чыкты[1]. Ул беренче басмасыннан бик аз аерыла: Нугай Урдасының таркалуы турында гына бер бүлек өстәлгән.

Б. Ишбулдин үзенең карашлары белән буржуаз тарихчыларның, янәсе, рус-Азия мәдәнияте Көнбатыш Европа культурасыннан өстенрәк, дип раслаучы «евразия мәктәбе»нә керә. Шуңа күрә аның Н. Трубецкой, П. Савицкий, Т. Вернадский кебек эмигрант тарихчыларны үз итүе очраклы хәл түгел.

Автор революциягә кадәр һәм 1917 елдан соң чыккан берничә дистә китаптан файдаланган. Аның совет галимнәреннән Б. Д. Греков, А. А. Новосельский, М. П. Покровский, Н. Н. Фирсов хезмәтләре белән таныш булуы күренә.

Китапта өйрәнелә торган чор нигездә XIII—XVI гасырлар белән чиклөнә.

Беренче бүлектә рус һәм совет тарихчыларының Россиядә татар-монголлар хакимлек иткән чорга төрле карашлары турында сүз бара. Автор халыкларга җәберзолым алып килгән өлеге хакимлекне ачыктан-ачык акларга тырыша. Безнең бабаларыбызны һәм монголларны «татар» атамасы белән берләштерергә омтыла. Совет тарих фәнендә «татар» исеменең килеп чыгышын ачыклаган мәгълүм концепция китапта бөтенләй читләтеп үтелгән. Ишбулдин татар халкының бишеге булган Идел Болгарстанын телгә дә алмый. «Татар Алтын Урдасын (?!) төзегән төрки халыклар арасында болгарлар бик мөһим урын алып торганнар», — дип кенә яза.

Шушы нигездә бу китапны Алтын Урда һәм аның варислары тарихына багышланган хезмәт дип бәяләргә мөмкин. Ишбулдин монголларның хәрби оешмалары, тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре турында мәгълүматлар китерә, империя белән идарә итүдә диннең әһәмиятенә басым ясый.

Безне, әлбәттә, Казан ханлыгы турындагы бүлек кызыксындыра төшә. Хәлбуки китап бу хакта бик аз мәгълүмат бирә. Никадәр сәер тоелмасын, автор үзе экономист булса да, ханлыкның социаль-экономик тарихына бөтенләй тукталмый. Халыкның тормыш-көнкүреше турында шулай ук бер сүз дә әйтелмәгән. Ишбулдин ханнар турында сөйләү белән генә чикләнә. Нәтиҗәдә өлеге бүлек XV—XVI гасырларда Казан ханлыгы катнашкан күп санлы сугышлар, Казан идарәчеләрен үз ихтыярларына буйсындыру максатында Мәскәү патшалары белән Кырым ханнары арасында барган көрәш турында хикәят кенә булып чыккан.

Гомумән, автор һәрвакыт төп темадан читкә китеп, икенчел дәрәҗәдәге мәсьәләләр белән мавыга. Мәсәлән, ул Ибраһим ханның хатыны Нурсолтан кебек тарихи әһәмияте ягыннан игътибарга лаек булмаган шәхесләргә махсус бүлекләр багышлый.

Кызганычка каршы, китапта өйрәнелгән материаллардан сөземтә чыгару — йомгаклау өлеше юк. Аның урынына Ишбулдиннар шәҗәрәсенең тарихы турындагы бүлек тәкъдим ителгән.

Тулаем алганда, бу хезмәт башка авторларның әсәрләреннән генә чүплап төзелгән. Ул фәнни яңалык һәм үзенчәлекле гомумиләштерүләр өмет иткән укучының бер соравын да канәгатьләндерә алмый.

**МИДХӘТ АБДУЛЛИН,**
тарих фәннәре кандидаты.

[1] Boris Ischboldin. Essays on Tatar History. New Deli. New Book Society of India. 1973, p. 184.

# ГОМӘР ТОЛЫМБАЙНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Татар совет әдәбиятының беренче елларын, аның 20—30 нчы еллардагы үсеш тенденцияләре, уңышлары һәм кайбер каршылыкларын язучы һәм тәнкыйтьче Гомәр Толымбай иҗаты һәм эшчәнлегеннән башка гына күз алдына китерү дөрес булмас иде. Ул әдәбият мәйданына гаять катлаулы һәм җитди чорда аяк баса. Илдә Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңеп, гражданнар сугышы тәмамланып килгән, яңа тормыш төзү өчен аяусыз көрәш барган көннәр була. Вакытлы матбугат сәхифәләрендә, бигрәк тә «Безнең юл» журналында Г. Толымбайский имзасы белән үткен эчтәлекле, сугышчан рухлы мәкаләләр, югары пафос, агитацион характерлы әдәби әсәрләр күренә башлый.

Г. Толымбай хәзерге Татарстанның Буа районы Толымбай авылында 1900 елда туган. Башта ул үз авылларында, аннан Буа мәктәбендә белем ала. Шул елларда ул әдәбият белән җитди рәвештә кызыксынып китә, татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен үзләштерә. 1918 елда Сембер (Ульяновск) шәһәрендә татарча чыккан «Таң» газетасында Толымбайның беренче шигыре басыла. Ә тагы бер елдан ул ике пәрдәле пьеса яза һәм шул ук елны 19 яшьлек егет РКП(б) членлыгына кандидат итеп алына. Бу — аның биографиясендә җитди вакыйга. Партия сафларына кергән көннән башлап ул үзен гомере буе яңа тормыш, яңа әдәбият өчен көрәшчеләр сафында, аларның да авангардында хис итә.

Толымбайның әдәбият-матбугат өлкәсендә ныклап эшли башлавы тыныч төзелеш чоры башланган 1921—1922 елларга туры килә. Ул эшче-крестьян катлавыннан күтәрелгән яшь язучыларның типик вәкиле иде. Гомуми белемнәре, әдәбиятны аңлау дәрәҗәләре, әдәби осталыклары бигүк югары булмаса да, алар бу җитешсезлекләрне яңага, революция эшенә җаны-тәне белән бирелгәнлекләре бәрабәренә нык кына киметәләр иде. Сыйнфый инстинкт, иске тормыш тәртипләренә булган нәфрәт, киләчәккә зур ышаныч аларны зур уңышларга, тынгысыз иҗатка рухландыра.

Шул ук вакытта Г. Толымбай белемен күтәрү өстендә дә даими эшләп килә. 1924—1927 елларда татар коммунистлар университетында укый, утызынчы еллар башында Мәскәүдә әдәбият институтын тәмамлый һәм профессор исеменә лаек була. Казанга кайткач ул совет учреждениеләрендә эшли, төрле уку йортларында һәм марксизм-ленинизм мәктәбендә укытучы була. Аннары ул — 1927 елда «Гажур» нәшриятында редактор урынбасары, «Крестьян» газетасында редактор, 1936 елда Татарстан дәүләт нәшриятында матур әдәбият секторы мөдире.

Толымбай татар культурасы һәм әдәбиятына бәйләнешле язылган күп санлы мәкаләләр авторы. Шулай да аның тәнкыйть эшчәнлеге турында сүз чыкканда, бу авторның әдәби мираска мөнәсәбәттә «үтә сул» позициядә торуын һәм Октябрьга кадәр язылган әдәби җәүһәрләрдән, кагыйдә буларак, йөз чөерергә чакыруын искәрми мөмкин түгел. Бу хаталар, беренчедән, аның шул чорга гомумән хас мавыгуларга бирелүе белән аңлатылса, икенчедән, авторның үзенә дә югары әдәби культура, тирән эстетик белем җитенкерәмәүдән килә, әлбәттә. «Татар буржуа теле безнең тел түгел» һәм «Фатих Әмирхан» дип исемләнгән мәкаләләр шуңа ачык дәлил.

Шулай да әдипнең туына 80 ел тулган бу көннәрдә әдәби җәмәгатьчелек аның исемен хөрмәт белән искә ала. Г. Толымбайның әдәбиятыбыз тарихында урыны бар.

# ИЛДУС АХУНҖАНОВКА 50 ЯШЬ



Илдус Ахунҗановның әдәбият дөньясында үз урыны, тәнкыйтьчеләр арасында үзенчәлекле йөзе бар. Аны бүтән тәнкыйтьчеләрнең берсе белән дә бутап булмый, шәхесе һәм иҗаты белән дә берәүгә дә охшамаган ул. Бераз җәенкерәк һәм тулырак битенә бик килешле генә урнашкан күперенке, калын иреннәре белән дә, физик эштә ныгыган тукымнан икәнлеген әйтеп торган киң җилкәләре белән дә, үз иҗатын кайгыртуга бераз салкынрак каравы һәм хәтта көнкүрештә бераз оешмаганрак булуы белән дә башкалардан аерылыбрак тора. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә 30 елга якын эшләп, газета-журналларда йөзгә якын мәкалә, рецензияләр бастырган тәнкыйтьченең үз гомерендә нибары бер генә китап чыгаруында да аның башка әдәбиятчылардан аерымлыгын чамаларга була.

Үзенә 50 яшь тулуны И. Ахунҗанов «Художник һәм аның сүзе» исемле беренче җыентыгын чыгарып каршы алды (1978). Анда аның 70 нче елларда язган поэзия, проза, драматургия-театрга караган 10 мәкаләсе урын алган. Баштагы иҗат чорыннан ул нибары «Отелло» трагедиясен караганда» (1953) мәкаләсен генә кертүне тиеш санаган. Үз иҗатын укучыга җыентыклар рәвешендә җиткерүдәге мондый сүлпәнлеге, әлбәттә, аның әдәби тәнкыйть эшенә җаваплылык белән каравыннан тыш, авыр кичерешләре һәм озакка сузылган авыруыннан да киләдер. Шушы сәбәпләр, аннары тагы шәхси тормышында тигез тәртипчәнлеккә ирешеп җитә алмавы иҗатының киңрәк ачылуына күпмедер комачаулык ясаса да, И. Ахунҗанов үзен әдәбиятыбызның тырыш, игелекле эшчесе, үткен күзле, гадел сүзле сакчысы, талантлы әсәрләрне һәм авторларны танып ала торган, аларга җылы сүз әйтә белгән зәвыклы тәнкыйтьче итеп танытырга өлгерде. Үткәннәргә кайтып барысын да барлый башлагач, аның язганнары да аз түгел икәнлеге, җаваплылык тоеп иҗат иткәнлеге һәм әйткән сүзенең нигезле булуы күренә.

Без Илдус белән Казан дәүләт университетында бер елларда (1948—1953) бергә укыдык, «Совет әдәбияты» журналында бер чордарак эшләдек. Тарих-филология факультетының икенче—өченче курсларында ук инде Илдус—тынгысыз һәм эзләнүчән, дәрте ташып торган, әдәбиятны һәм кызларны үлеп ярата торган мәһабәт гәүдәле егет — әдәби түгәрәкләрнең үзәгендә кайный, диспутларда чәчрәп чыгып чыгышлар ясый, шигырь һәм хикәя язучыларның әсәрләрен бик әйбәт итеп анализлап бирә иде. Шул чакта — илленче елларның башларында ук — аның русча язган

рецензияләре өлкә газеталарында күренә башлады. М. Әмир, Җ. Тәрҗеманов, Г. Әпсәләмов әсәрләре турындагы беренче мәкаләләре хәтердә калган. Студент елларында ук аның исеме эрудицияле яшь тәнкыйтьче буларак телгә керде. «Совет әдәбияты» журналының ул еллардагы редакторы Гази ага Кашшаф яшь тәнкыйтьченең сәләтен тиз күреп алды, аның укуын тәмамлавын да көтмәстән — бишенче курста ук тәнкыйть бүлегенә эшкә алды. Журнал Илдус өчен олы тәҗрибә мәктәбе булды. Ул шунда татар әдәбияты белән тагын да ныграк кызыксынып китте. Ф. Хөсни, Н. Исәнбәт, М. Җәлил, Ә. Фәйзи, С. Хәким турындагы мәкаләләре нәкъ шул елларда язылды. Язучылар, журналистлар белән дуслашты, үзен тулысы белән татар әдәбияты дөньясы белән бәйләде. Бу орбитадан тормыш аны кырыйгарак та кысып чыгаргалады, әмма ул ахырда барыбер үзенең яраткан һәм төпләнгән җирлегенә — татар әдәбияты дөньясына кайтты, төп язмышын шунда тапты.

Илдусның рус филологиясе бүлегендә белем алуы аның тәнкыйть эшчәнлегенең юнәлешен билгеләүгә дә йогынты ясады. Ул иҗатының баштагы чорында татар укучыларын рус классик язучылары белән таныштыруга игътибарын юнәлтсә, торабара татар әдәбиятының үткәнен һәм бүгенгесен рус теле аша күп милләтле совет укучысына җиткерү юнәлешендәге эшчәнлеген бермә-бер активлаштырып җибәрде, бу өлкәдә үзенең ныклы һәм алыштыргысыз урынын тапты. Әдипләребезнең әсәрләрен русчага тәрҗемә итү, татар язучыларының иҗат портретлары турында радио һәм газеталарда чыгышлар... Ифрат та күп эшләнгән. Әмма тәнкыйтьчебезнең әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләрне ныгыту өлкәсендәге хезмәте моның белән генә чикләнми.

Тәнкыйтьченең йөзе аның әдәби хәрәкәттә эстетик атмосфераны билгеләүдә ни дәрәҗәдә катнашуы белән дә билгеләнә. Илдус татар әдәбиятының эчке дөньясын игътибар белән күзәтә, анда туган әһәмиятле яңалыкларга, тенденцияләргә, яңа исемнәргә җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлтергә омтыла. Мәсәлән, соңгы елларда ул Татарстандагы үзенчәлекле бер әдәби күренеш — рус телендә иҗат итүче бер төркем татар әдипләре турында кызыклы мәкаләләр циклы язды, поэзиягә килгән яшь буын шагыйрьләренең иҗатын яктыртты. Аның җитди һәм төпле сүзенә укучылар да, яшь язучылар да колак салалар. Ул үтемле һәм җанлы итеп яза белә, кирәкле сүзләрне таба белә. Боларның барысына да «Художник һәм аның сүзе» җыентыгына кергән мәкаләләрдән күп мисаллар китерергә мөмкин булыр иде. Тик бу юлы укучыларны шул китапның үзенә юнәлтү белән чикләник.

Тәнкыйтьчебезнең сүзе киләчәктә дә шулай әдәбиятыбыз өчен файдалы, язучы өчен кирәкле, укучы өчен мавыктыргыч һәм үтемле булсын. Ә аның үзенә көр күңеллелек һәм сәламәтлек телибез. Тормыш куйган киртәләрне киләчәктә дә кыю ирләрчә җиңеп үтсен ул.

**НИЛ ЮЗИЕВ.**

# ТАҺИР НУРМӨХӘММӘТОВКА 50 ЯШЬ

Һәрбер әдәбиятны оешкан, зур оркестр белән тыңлап булыр иде. Оркестрда нечкә лирик хисләрне бирү өчен скрипка, флейта, виолончель кебек саф авазлы кораллар булган кебек, әдәбиятта шигърият, лирик хикәя төрләре яши. Киң диапазонлы повесть һәм романнар исә башка төр уен коралларын хәтерләтә сыман. Шунда ук бас, контрабаслар да аваз биреп, оркестр уенын төрлеләндереп куя. Әдәбият та шулай төрле-төрле, үзенә генә хас моң, аваз белән яшәде кебек.

Тәрҗемә жанры, һәм шул цехта иҗат итүче тәрҗемәчеләр эшчәнлеге — әдәбиятыбызның әнә шундый бик мөһим бер тармагы, оркестр белән тыңласак, бик кирәкле бер коралы, чарасы булып тора. Башка барлык жанрларда уңыш казанып та, тәрҗемә эшенә әһәмият бирмәгән, үз милли чикләрен узып чыга алмаган бер генә әдәбият та тулы канлы, өлгереп җиткән әдәбиятлар рәтенә кертелми.

Татар әдәбиятының киң колачлы, үскән әдәбиятлар арасында үз урыны, ирешкән биеклекләре бар. Бу уңышлар тәрҗемә эшен җитди эш итеп караучы бик күп әдипләребез тырышлыгына да бәйле. Русның бөек әдипләре А. Пушкин әсәрләрен без өлкән язучыбыз Афзал ага Шамов тәрҗемәләре, М. Горький роман һәм хикәяләрен Сәрвәр Әдһәмова күп көч куеп башкарган иҗади хезмәт аша беләбез. Асылда исә бер генә танылган язучыбыз да дөнья яки рус классик әдәбиятыннан нинди дә булса тәрҗемә үрнәге бирми калмаган диярлек. Әйтик, Гариф Гобәй замандашыбыз А. Толстойның «Петр Беренче» исемле күләмле тарихи романын татарчалаштырган. Гариф Ахунов һәм Яхъя Халитовлар тәрҗемәсендә дә без Шолоховның дүрт томлы «Тын Дон» эпопеясен үз телебездә укыйбыз. Мирсәй Әмир исә Н. Погодин пьесаларын тәрҗемә итеп татар сәхнәсен баетты. Ибраһим ага Гази татар укучысын атаклы француз әдипләре Ги де Мопассан, Эмиль Золя иҗатлары белән таныштырды. Тәрҗемә хезмәтләре белән әдәбиятыбыз күген тагын да киңәйтеп, ачып җибәрүгә күп өлеш керткән башка бик күпләрне олы ихтирам белән телгә алырга булыр иде.

Элегрәк, Бөек Ватан сугышында үлеп калган Кәшфи Басыйровтан башка, фәкать тәрҗемә эше белән генә шөгыльләнүче әдипләребез юк диярлек дәрәҗәдә аз булган. Ул эшне күп еллар буе, үз иҗатларына үреп, танылган прозаикларыбыз, ә поэзия жанрында исә шагыйрьләребез башкарган. Хәзер исә фәкать тәрҗемә жанрына гына турылыклы әдипләр өлгереп җитте. Яхъя Халитов, Рәис Даутов, Кыям Миңлебаев, Фәния Гайнанова, Саимә Ибраһимовалар язучылар оешмасының тулы хокуклы әгъзалары. Әлегә безнең тәрҗемәчеләр эшчәнлегендә бердәнбер зур кимчелек — ул бары тик русча чыккан китаплардан гына тәрҗемә итү. Моңарчы илебездәге милли әдәбият үрнәкләре дә нигездә русчадан гына татарчалаштырылды. Хәтта безгә бөтенләй якын төрки телле әдәбият әсәрләрен дә шундый катлаулы, һәм, әйтергә кирәк, шактый югалтуларга, оригинал әдәбиятның кыйммәтен төшерүгә китерә торган юл белән тәрҗемә итәбез.

Инде Таһир Нурмөхәммәтовка килсәк, ул җитлеккән, олы тәҗрибә туплаган тәрҗемәчеләребезнең берсе. Аның татар укучысы кулына ирештергән дистә ярымлап китабы бар. Шулардан А. Куприн хикәяләре (1955 елда чыккан), Ю. Германның «Дзержинский турында хикәяләр»е, А. Рыбаковның «Хәнҗәр», «Бакыр кош» кебек балалар бик яратып укый торган мавыктыргыч повестьлары, С. Михалковның «Сомбреро» комедиясе (1971 ел) һәм башка бик күп әсәрләр үзенчәлекле урын алып тора. Минем үземә авыруча ошаганы — Таһир Нурмөхәммәтовның чит ил әдипләренә

бигрәк тә көнчыгыш әдәбияты үрнәкләренә, әһәмият бирүе. Ул гарәп язучысы Сәхип Җамалның «Кара чәчкәләр» исемле катлаулы романын 1967 елны татар укучысына тәкъдим итте һәм 1970 елны Рәшид Нури Гентекинның «Чалы кошы» романын дөньяга чыгарды.

Таһир Нурмөхәммәтов иҗатының тагын бер үзенчәлекле һәм бик матур сыйфаты шунда, ул төп игътибарны күбрәк бүгенге көн әдәбиятына, бүгенге тормышның үзенчәлекләрен чагылдырган алдынгы әдәбият әсәрләренә юнәлтеп килә, күбрәк шундыйларның үз телебездә яңгырашлы булуына омтыла.

1974 елны ул воронежлы Гавриил Троепольскийның «Акбай Караколак» повестен тәрҗемә итте. Нәкъ шул язны әлеге әсәр дәүләт премиясенә лаек дип табылган иде. Әсәр тирә-як мохитка, кешенең табигатькә һәм кече җан иясе булган эткә мөнәсәбәте аша тормышка карашларыбызны, киләчәк өметләребезне тагын бер кат куңелдән кичереп, үз-үзебезгә дә, башкаларга карата да яңача бәя бирергә этәрә торган җитди фәлсәфәгә корылган. Әдәбият сөючеләргә бу яхшы мәгълүм. Таһир Нурмөхәммәтов әсәрне, авторның фикеренә теләктәш буларак, зур осталык белән, күңелләргә үтеп керерлек итеп тәрҗемә итә алган. Бу тема әсәрләренә аның аерата мәхәббәте бар. Мәсәлән, 1973 елда ул Р. Фраерманның «Кыргый эт яки беренче мәхәббәт турында хикәят» кебек күләмле һәм шактый үзенчәлекле повестен татарчалаштырган иде. Өч елдан соң атаклы табигать җырчысы К. Паустовскийның «Урман хикәяләре» исеме белән повесть һәм хикәяләр җыентыгын чыгарды. Тагын бер елдан аның тәрҗемәсендә Сетон-Томпсонның «Хайваннар турында хикәяләр» китабы дөнья күрде. Быел исә аның тәрҗемәсендә Виктор Астафьевның «Бәхилләшү» исемле әсәре китап кибетләренә чыгар дип көтәбез.

Әйе, Таһир Нурмөхәммәтов бүгенге көн тәрҗемәчеләре арасында үзенә генә хас тематикасы булуы, заман тормышын чагылдырган әдипләр иҗатына мөрәҗәгать итүе белән аерылып тора. Аның тәрҗемәләрен һәрвакыт канәгатьләнү хисе белән укыйсың. Чөнки Таһир үз иҗатына гаять таләпчән.

Таһир Нурмөхәммәтов менә ничә еллар инде Татарстан китап нәшриятында редактор, аннан өлкән редактор һәм нәшриятның балалар-яшьләр редакциясе бүлек мөдире ярдәмчесе хезмәтләрен башкара. Редактор булып эшләү дәверендә ул йөзләрчә әдәби әсәрне редакцияләп китап итеп чыгарган кеше. Димәк, күп кенә язучыларның якын киңәшчесе, ярдәмчесе дә ул. Бу хәл аның үз зәвыгын камилләштерү һәм чарлауга да бик нык ярдәм иткән булса кирәк.

50 яше тулган көннәрдә каләмдәшебезгә яңадан-яңа иҗат уңышлары телибез. Үзенең тәрҗемә әсәрләре белән татар әдәбиятын сөючеләрне бер генә тапкыр куандырмас әле ул.

**ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИН.**

# АБДУЛЛА СӘЛӘХЕТДИНОВКА 50 ЯШЬ



Республикабыз районнарында һәм күрше өлкәләрдә уздырылган әдәби кичәләрдә миңа аның белән бергә булырга туры килгәне бар. Шундый кичәләрнең берсе хәтергә аеруча нык сеңеп калган. Тыңлаучыларга үзенең яңа шигырьләрен укыганнан соң, сәхнәдән чыгып китим дигәндә генә, залдагылардан өлкән яшьтәге бер агай, урыныннан торып, аңа үтенечле сорау белән мөрәҗәгать итте:

— Якташ, авылдашыбыз турында язган поэмаңнан берәр өзек укып күрсәтә алмассыңмы икән?

Сүз Абдулла белән бер үк авылда туып-үскән, Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган һәм Сталинградтагы Көрәшчеләр мәйданында рус егете Леонид Каменщиков, испанлы Рубен Ибаррури белән бер кабергә күмелгән капитан Хафиз Фәттахетдиновка багышланган «Идел баһадиры» дигән шигъри повесть хакында бара иде. Автор әсәрнең соңгы бүлеген яттан укый башлады. Аның ахыргы юллары көчле алкышлар белән күмелде:

**Җир әйләнә, күкрәгенә җыеп**
**Күптән сеңгән йолдыз нурларын...**
**Ватан саклый, мәңгелек ут итеп,**
**Узган яуда үлгән ир данын.**

Әйе, Абдулла Сәләхетдинов шигырьләрендә һәм поэмаларында укучыларның игътибарын, барыннан да элек, гражданлык пафосы һәм көчле лиризм җәлеп итә. Аның проза жанрында язылган күпчелек әсәрләренә дә шул ук матур сыйфатлар хас. Аларда кешеләргә олы ышаныч, туган як табигатенең байлыгына һәм гүзәллегенә соклану, мәхәббәт, дуслык, туганлык, планетаның иминлеген саклап калу өчен барган көрәш мотивлары гәүдәләнә. Абдулланың барлык әсәрләре дә диярлек, инде алда искәртеп үтелгәнчә, үз ягының конкрет кешеләренә бәйләнешле вакыйгаларга нигезләнеп иҗат ителгән. Бу уңайдан аның тормыш һәм иҗат юлына кыскача гына булса да тукталып узасы килә.

Абдулла Сәләхетдинов 1930 елда Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районы, Өчкүл авылында крестьян гаиләсендә туа. 1949—1951 елларда Казан педагогия училищесында укый. Совет Армиясе сафларында радист булып хезмәт итә. Аннан демобилизацияләнеп кайткач район газеталары редакцияләрендә эшли. 1959 елда аны «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә эшкә чакыралар. 1960—1963 елларда Казан телестудиясенең әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә, 1964—1966 елларда Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор була. Аннан «Ялкын» журналына җаваплы секретарь булып күчә. 1977 елдан «Казан утлары» журналында эшли башлый.

Матбугат эшендә тәҗрибә туплау белән бергә, ул, читтән торып, Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлый. 1961 елдан бирле КПСС члены.

Яшьтән үк әдәбиятка гашыйк Абдулланың тәүге шигырьләре район газеталары битләрендә, «Үсү юлы» һәм «Идел» альманахларында басыла. «Җир авазы» исемле беренче китабы 1963 елда дөнья күрә. Ул җыентыкка кергән шигырьләрендә һәм

«Үкенү» поэмасында шагыйрь лирик геройның уй-кичерешләре аша кешенең бәхете үз кулында дигән фикерне алга сөрә. «Туган авыл» дип аталган әкият-поэмасында һәм шул исемдә чыккан икенче китабында, әлеге теманы дәвам итеп, А. Сәләхетдинов хезмәтнең шифалы көчен, аның шәхес тормышында тоткан урынын мавыктыргыч итеп тасвирлауга ирешә. Шигъри диалог алымында язылган «Тылсымлы касә» әкият-поэмасында хезмәт кешесенең җирне ихлас сөюе, аны тагын да күркәмрәк итү өчен кулыннан килгәннең бөтенесен эшләргә әзер торуы сурәтләнә.

Урта Азиягә сәяхәт нәтиҗәсендә Касыйм Фәсәхов белән бергәләп язылган һәм 1966 елда аерым китап булып басылып чыккан «Гөлстан язы» җыентыгы, Сталинград сугышында катнашкан легендар якташы, тупчы Хафиз Фәттахетдинов турындагы «Идел баһадиры» шигъри повесте әдәбиятыбызда бер яңалык булды. Һәм бу әсәрләр үз вакытында тәнкыйтьчеләребез тарафыннан да уңай бәяләнде.

А. Сәләхетдиновның очерклары һәм юлъязмалары тупланган «Татарстан — туган җирем» китабы аның иҗатында шулай ук билгеле бер урын алып тора. Татарстанның төзелүенә илле ел тулу уңае белән чыгарылган зур күләмле бу җыентыкта республикабызның узганы һәм бүгенгесе, аның атаклы кешеләре, социаль һәм культура тормышында ирешкән уңышлары турында сөйләнелә. Автор укучыны республика буйлап сәяхәткә чакыра. Шул сәфәр дәвамында ул халкыбызның кайчандыр Тау ягында яшәгән Тимеркәй атлы кешенең оныгы, Днепростройда һәм Магнитка төзелешләрендә бетон салу буенча дөнья рекордлары куйган бригада җитәкчесе, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Хәбибулла Галиуллин кебек данлы уллары, Зәй һәм Әлмәт якларында, Кама буйларында барган бөек төзелешләр, атаклы нефтьчеләр һәм тукучылар, елгачылар һәм төзүчеләр, игенчеләр һәм терлекчеләр белән таныштыра. Сәяхәтенең ахырында янә Казанга әйләнеп кайта һәм туган республикабызның киләчәге турында укучы белән кызыклы, җанлы әңгәмә алып бара. Җыентыкка кергән очеркларны язу өчен материал туплауга автор ифрат күп көч куйган һәм үзе күреп белгәннәрне, башкалардан ишеткәннәрне гомумиләштереп, гади итеп, җиңел, аңлаешлы тел белән хикәяләп бирә алуга ирешкән. Басылып чыгуына инде ун елдан артык узуга да карамастан, бу җыентыктагы әсәрләр бүген дә актуальлекләрен югалтмый.

Укучыларга А. Сәләхетдиновның «Мишә җыры» һәм «Бөртекләр» дигән китаплары да яхшы таныш. Аның композиторларыбыз көй язган берничә лирик шигыре яратып җырлана. Балалар әдәбияты һәм мәсәл жанрында да эшләүче язучыларыбызның берсе ул. Балалар аның бигрәк тә «Ук-канат», «Шук молекул—кояш малае» кебек әкиятләрен һәм хикәяләрен зур кызыксыну белән укыйлар. Балалар өчен язылган аерым әсәрләренең казакъ, үзбәк, әзербәйҗан, кыргыз, чуваш, башкорт, мари һәм башка тугандаш халыклар телләренә дә тәрҗемә ителгән булуы да игътибарга лаек.

Вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле күренеп килгән мәсәләләрендә А. Сәләхетдинов кешеләрдә әле һаман бетеп җитмәгән, алга барышыбызга комачаулый торган мин-минлек, кода-кодагыйлык, ялагайлык шикелле кире якларны ачып сала, җәмгыятебез өчен ят булган мондый күренешләргә түзеп торучыларны утлы табага бастыра.

Шагыйрь әйтмешли, дәфтәр битендәге учмаларың көлтә итеп бәйләргә җитәрлек булсын өчен үз-үзеңне онытып эшләгәндә вакытның үткәне сизелми дә кала икән. Ә еллар бер-бер артлы һаман уза бирәләр. Менә алар Абдуллага да, илле яшең тулды, дигән хәбәр алып килде. Ләкин каләмдәшебезнең әле әүвәлгегә караганда да дәртләнебрәк, илһамланыбрак эшләр чагы.

Киләчәгем минем — күрәчәгем,
Риза түгел мин вак-төяккә.
Әманәтем булыр — чордашларның
Батырлыгын салам йөрәккә.

Шундый якты уй-теләкләр белән янып-ялкынланып яшәүче сафташ дустыбызның киләчәктә тагын да зуррак иҗади ачышлар ясаячагына һичбер икеләнүсез ышанасы килә.

**РӘШИТ ГӘРӘЙ.**

# УКУЧЫ СҮЗЕ

*Галим һәм язучы Ибраһим Нуруллинның «Тукай» исемле китабы Мәскәүдә «Атаклы кешеләр тормышы» (ЖЗЛ) сериясендә 1977 елда басылып чыккан иде. Татарстан китап нәшрияты исә 1979 елда шул ук китап белән татарча «Атаклы кешеләр тормышы» сериясен башлап җибәрде. Татар халкының бөек шагыйренә багышланган китапны укучылар һәм җәмәгатьчелек җылы кабул итте. Түбәндә китап турындагы кайбер фикерләр тәкъдим ителә.*

*
* *

«Тукай»ны рәхәтләнеп укып чыктым. Дөресен әйтим, ниндидер гадәттән тыш ачышлар юк анда, ләкин иң мөһиме — материалны тәгәл белү, шагыйрьгә, гомумән, шигърияткә һәм туган әдәбиятка мәхәббәт бар.

Тукайны мин күптән яратам, куәтле һәм трагик фигурасын күз алдыма китергәндә, үзем дә аның фаҗигасен кичергәндәй булам. Шуңа күрә дә китаптагы кечкенә генә фальшь та күңелемне рәнҗетер иде. Бәхеткә каршы, китап таләпчәнлек хисе белән, изге теләктән язылган. Китаптагы кайбер корырак урыннарны мин шулай ук җаваплылык хисе белән аңлатыр идем. Ә ул сыйфат язучы өчен, бигрәк тә зур әдәбият һәм зур шагыйрь турында язучы өчен бик тә мөһим!

**НАФИ ДЖУСОЙТЫ,**
**осетин әдибе, тәнкыйтьче, галим.**
**Цхинвали.**

*
* *

«Тукай»ны үземчә зур игътибар белән укып чыктым. Укып чыктым да уйга калдым. Тукайны мин ШКМ (колхоз яшьләре мәктәбе) укучысы буларак кына беләм икән. Габдулла миңа хәзер кеше буларак (холык-фигыле) һәм катлаулы шәхес буларак (дөньяга карашы, эчке каршылыклары) яңа яктан ачылды.

**ЮНЫС ӘМИНОВ,**
**драматург.**
**Әлмәт.**

*
* *

Татар язучысы Ибраһим Нуруллин зур тырышлык һәм кыюлык күрсәтеп, халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай турында күптән көтелгән җитди һәм бик кирәкле китап бастырып чыгарды. И. Нуруллин моңа кадәр дә Тукайга багыш-

ланган күп кенә кызыклы хезмәтләр язган булса да, әлеге китап шагыйрь турындагы иң зур, иң җитди әсәр, шуңа күрә дә ул һәрьяклап игътибарга лаеклы.

Мин үзем Тукайның беренче шигырьләреннән алып һәр язганын диярлек укып, күзәтеп барган кеше. Тукай Казанга Уральскидан 1907 елның сентябрендә килде. Ә мин 1908 елның сентябрь аенда «Казанская татарская учительская школа»да — ягъни КТУШта укый башладым. Безнең мәктәптә Тукайның дуслары, кайчандыр шушы мәктәпне тәмамлаган Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхметов, Мөхетдин Корбангалиев, шулай ук Сәгыйть Сүнчәләй, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Мәҗит Гафури, Габдулла Кариев һ. б. еш булалар иде. Алар безнең әдәби кичәләрдә катнаштылар, безне Тукайның фельетоннары, юмористик, сатирик парчалары басылган «Яшен», «Ялт-йолт», «Аң» кебек журналлар белән таныштырдылар. Кыскасы, мин Тукайның талантын хөрмәт иткәнгә, аның иҗатын яратканга, И. Нуруллинның да китабын кызыксынып, җентекләп, игътибар белән укып чыктым. Һәм, дөресен әйтергә кирәк, китаптан канәгать калдым.

Автор китабын яңа архив материалларыннан, истәлекләрдән файдаланып, язасы материалын белеп, яратып язган. Гомумән, шагыйрьнең кырыс та, трагик та булган тормышы ышандырырлык итеп, бернинди арттыруларсыз бәян ителә. Тукай турында аз язылмаган. Әмма И. Нуруллин «Тукай» китабын язганда халык шагыйрен бернинди гөмансыз, бары тик төгәл чыганаклар нигезендә генә күрсәтүне максат итеп куйган һәм максатына тулысынча ирешкән дә. Китапның укучылар тарафыннан яратылып укылуы нәкъ шул хакта сөйли.

**ЯКУБ ЧАНЫШЕВ,**
**отставкадагы генерал-лейтенант,**
**1917 елдан КПСС члены.**
**Мәскәү.**

## ХӨРМӘТЛЕ ИБРАҺИМ!

Бүләгең белән бик шатландырдың. Рәхмәт!

Бер айга якын больницада ятам. Шул чакта «Тукай»ның килеп төшүе күңелне күтәреп җибәрде, ике көн дигәндә инде укып та чыктым. Мавыгып укыдым.

Китап бик төпле. Достоверна (башкортча сүзен таба алмыйм). Тасвирлауга мавыгып, «купшылык» артыннан куып дөреслек көчен киметмәгәнсең. Шул ук вакытта, бик җиңел укыла. Мин бит заманында синең газапларыңның күзәтчесе дә булдым. Җиңеп чыккансың. Әфарин!

Иң яхшы теләкләр теләп калам.

**МОСТАЙ КӘРИМ,**
**Башкортстанның халык шагыйре.**
**Уфа.**

## ХӨРМӘТЛЕ ЭНЕМ ИБРАҺИМ!

Китабыгызны бик зур кызыксыну белән укып чыктым. Сез Тукай биографиясен, аның иҗат үсешен өйрәнүгә бик зур хезмәт куйгансыз. Үзегезгә хас булган эзләнү, тикшеренү сәләте өстенә әдиплек талантыннан да тулысынча файдалана алгансыз. Мин Сез куйган проблемалар һәм аларны чишүегездән тулысынча канәгатьмен. Иң әһәмиятлесе: Сез катлаулы һәм четерекле мәсьәләләрдән качмыйсыз, киресенчә, аларны уртага куеп, объектив чишәргә тырышасыз. Шул ук Камил Мотыйгый мәсьәләсе. Сез Мотыйгыйны 1905—1907 елларда халыкка матбугат таратуга куйган зур көчен Тукай үсешенә, Тукайның шагыйрь буларак формалашуына күрсәткән хезмәтләрен инкарь итмисез. Буржуаз революция елларындагы Камил Мо-

тыйгый эшчәнлеген тулы һәм объектив бәялисез. Шуның белән бергә Камил Мотыйгый характерына хас булган күп кенә йомшак якларны ачып, реакция елларында аның икеләнүләренең сәбәбен аңлатырга тырышасыз. Мине бигрәк тә Сезнең архив материалларын тиешле формада файдалана алуыгыз шатландырды. Сагыйть Рәмиев, Фатих Әмирхан, Г. Камал, һ. б. шундый Тукайга якын мөнәсәбәттә булган шул чорның талантлы кешеләре турында язган эзләнүләрегез шулай ук объектив дәрәҗәдә бирелгәннәр. Ибраһимов белән каршылыкка аерым тукталып та, бик яхшы эшләгәнсез. Ике зур талант, ләкин килешә алмаганнар. Тормышта, әдәбият дөньясында андый хәлләрнең дә булырга мөмкинлеген дәлилләр аша раслыйсыз.

Татарлар арасында культура таратуда прогрессив мулла һәм руханиларның рольләре берничә урында зур мәсьәлә итеп куелган һәм, минем фикеремчә, бик дөрес чишелгән. Мин үзем Себер шәһәре Атбасарда башлангыч белем алдым. Шул ком эчендә югалып утырган, тимер юлдан 360 чакрым ераклыктагы шәһәргә Буби авылында белем алган Әфләтунов исемле укытучы, хатыны Мәгъсүмә белән килеп, 1910—1917 елларда татар халкына белем һәм һөнәр өйрәттеләр. Чакырылган мәҗлесләрдә, билгеле, алар корьән аятьләрен дә укыйлар иде, мәктәптә дин дәресләрен дә алар алып бардылар. Шулар аша без, укучылар, беренче мәртәбә татар газеталарын күрдек. Тукай, Ш. Камал, Г. Ибраһимов шикелле язучы-шагыйрьләр турында беренче белемне шулардан алдык. Тукайның үлем хәбәрен ишеткәч, мәктәптә укуларны туктатып, хор белән Тукай шигырьләрен җырлаганыбыз һәм елыйелый өйгә кайтканыбызны мин хәзер дә хәтерлим. Шул сәбәпле, халык яңача укытучыларны яхшы каршы алды, кадим мәктәбендә укучылар кимеде.

Сезнең зур хезмәтегез буенча кечерәк кенә фикерләр әйтер өчен дә, билгеле, әсәрне тагын бер мәртәбә ашыкмый укып чыгарга кирәк. Ихтимал, үзегез белән тагын берәр очрашу мөмкинлеге булыр. Сезнең бу хезмәтегез халык арасына да тиз таралды. Ихтимал, икенче мәртәбә дә бастырып чыгарырга туры килер. Сез, гомумән, Тукай турында һаман чыгышлар ясап торасыз. Минем фикеремчә, Мотыйгулла хәзрәт хатына киңрәк тукталу кирәк иде. Мәсәлән, Мотыйгулла хәзрәт Тукайның гаруз гыйлемен бик теләп өйрәнгәнен һәм шуларга ияреп, шигырьләр төзеп, үзенә күрсәткәнен һәм үзенең ул шигырьләрне «бәрәкалла» дип, хуплап каршы алуын яза. Шулай ук остаз белән шәкерт арасында сүз көрәштерүләр булганны, Тукайның капиталның зарарын аңлатырга тырышуын әйтә.

Мин үз лекцияләремдә ул материалдан күп еллар файдаландым, ләкин, кызганычка каршы, тулысы белән ул хат текстын язып алмаганмын. Теләсәгез, Сез аны һәрвакыт таба аласыз.

Сезгә бик күп сәлам белән,
**МАҺИНУР ФӘЙЗУЛЛИНА.**
**Алабуга.**

## ХӨРМӘТЛЕ ИБРАҺИМ!

Ифрат кыйммәтле бүләк җибәргәнсез, бик шатландым, рәхмәт! Бу изге эшегезне ишетеп элек тә куанган идем. Аны укып чыгу насыйп булгач, тагын бер шатландым. Китап Тукайның үзе кебек гади генә, күңелле дә, моңсу да итеп язылган. Шагыйрьнең хаста йөрәк дәртен, үкенеч һәм сызлануларын әйтеп бетергесез, әлбәттә. Рус укучыларын бу бөек кеше белән таныштыру бер дә җитәрлек түгел иде әле. Сезнең бу мәшһүр китапханәдә чыккан матур китабыгыз Тукай мөхлисләренең күңелләрен шат итеп кенә калмас, бәлки мәгълүм дәрәҗәдә сәяси-мәдәни вакыйга да булыр дип уйлыйм.

Сезгә баш иеп,
**ӘСГАТЬ МОХТАР,**
**үзбәк язучысы.**
**Ташкент.**

## Ибраһим Нуруллинга

Укыйм
кат-кат,
сеңә бара җанга,
«Тукай»
миңа
ифрат та мөһим.
Тукаебызга
тугры булган өчен
Рәхмәт сиңа,
рәхмәт, Ибраһим!
...Ерактагы
татар авылына,
Бала чакка
кайтам...
ерактан.
Яшәсәм дә
чит бер гаиләдә,
Туган телем
тере —
йөрәктә!
Мин үзем дә
укып йөрдем читтә
Тиеннәрнең биреп
актыгын...
Кайта-кайта уйлыйм,
кайта-кайта
Халкым
күңеленең
аклыгын!
Яши-яши аңлыйм,
менә хәзер,
Килеп җиткәч
шушы чагыма:
Тукаебызга
халык тугрылыгы —
Тугрылыклы булу
җаныңа!

**МИХАИЛ ЛЬВОВ.**
Мәскәү.
**Р. МИҢНУЛЛИН**
тәрҗемәсе.

# ТҮРЕБЕЗДӘ: РУС МӘСӘЛЧЕЛӘРЕ

*Рус әдәбиятында мәсәл моннан ике йөз илле еллар чамасы элек үк инде мактаулы урын били башлый. «...Русь илендә мәсәл шуңа күрә гадәттән тыш уңыш казанды ки, чөнки ул бездә очраклы рәвештә түгел, ә мәзәк сүзне, кызыкны, аны куллануны чиксез яраткан халыкның рухи ихтыяҗы нигезендә туды... Мәсәл, сатира буларак, чын мәгънәдә поэзия ул... Мәсәл, сатира буларак, бу өлкәдә талантлы һәм акыллы эшлеклеләр әле булганда, һәрвакыт шигъриятнең гүзәл бер төре булды һәм һәрвакыт шулар булып калачак» (Белинский)[1].*

## Михаил Ломоносов

*1711—1765*

*Үзенең «Риторика»сында (1748) М. Ломоносов рус әдәбияты тарихында беренче буларак мәсәл жанрының аңлатмасын бирә: «Ул, кыска күләмгә сыйдырылган фикер буларак, нәсихәт белән бәйле иҗат, чөнки аңарда фикер шул нәсихәттән китереп чыгарыла». Галим һәм әдипнең үз иҗатында «Риторика» китабы өчен махсус язылган өч мәсәл бар.*

●

Өйләнү ул —зур шатлык та, үкенеч тә.
Туйлар шаулы, туйлар матур-күркәм була.
Зур кесәңдә буп-буш янчык йөртсәң дә син,
Купшы кием киеп йөргән иркәң була. —

Ул тискәре булыр. Кире киңәш бирер,
Көйли белер хаксыз бәхәс җырын да ул.
...Менә мисал — мужик сүзе: суга батып
Юкка чыккан шундый ханым турында ул.

Сорый икән бер ир биек ярга килеп:
«Күрмәдеңме кемдер суга батканны син?»
«Аны эзләп түбән таба бару кирәк,
Беләсең бит су түбәнгә акканны син».

«Аңлыйм, күрше... Синең күңел, беләм, уяу,
Менә хәзер шул хаклыкны сизми микән:
Минем хатын гел сөйләде миңа каршы,
Ул агымга каршы һаман йөзми микән?!.»

---

[1] Әсәрләренең тулы басмасы. Мәскәү, АН СССР, 1955, 8 том, 575—576 битләр.

## Иван Хемницер

*1745—1784*

*Астрахань шәһәрендә килере чамалы булган штаб-лекарь семьясында туа. 1757 елда ата-анасыннан рөхсәтсез пехота полкына солдат булып языла. Германиягә каршы походта катнаша. Соңыннан Тау эшләре ведомствосында эшли, минералогия буенча хезмәтләр яза. Смирнада рус консулы була. Мәсәлләр һәм экиятләр китабын, үз исемен яшереп, 1779 елда чыгара. ә 1873 елгы басма шул текстны кабатлый.*

### Бәйдәге эт

Һәркемгә кирәк ул иркенлек һәм ирек.
Әмма аны яулау — гаять читен нәрсә.
Ошбу эшкә кирәк уйлап алынырга,
Кирәк үз башыңа бәла китермәскә.

Бәйдән ычкынмакчы була бер көнне эт.
Тартып өзелмәгәч, чәйнәп өзә бауны.
Ләкин тагын бәйләп куя хуҗа аны —
Тик... хәзер эт инде шактый кыска баулы.

## Иван Дмитриев

*1760—1837*

*Сембер алпавыты семьясында туа. Җиде яшендә Казан пансионына укырга керә, аннары Сембердә укый. Үндүрт яшеннән Петербургтагы Семеновский полкка языльп хезмәт итә, офицер була. Мәсәлләренең өченче басмасы 1810 елда чыга.*

### Сәгать стрелкасы

«Кем тиң миңа? Солдат, гашыйк, каравылчы,
Сырхау кеше, елъязмачы, кыю юлчы,
Доктор, әдип, патша да һәм министр да
Бөтенесе ышаналар — стенага
Элеп куйган календарьдан мин өстенгә.
Көнне-төнне өлешләргә бүлә-бүлә,
Барчабызның минутларын шул саный дип,
Бөтен кеше һәрвакытта миңа карый—
Кирәгенчә зурлый белә һәм санлый бит!»
И текелди стрелка, и мактана,
Һәркем күзе юнәлтелгән, димәк, аңа
Булып чыга...
            Ә нишли соң корыч кыллы
Нык пружина?
                Кирәгенчә этә-төртә,
Бары шул бит көне-төне аны йөртә!

Нык пружина—секретарьмы? Ә стрелка кем?
Ачыклауны таләп итә ич мәсьәлә.
Барчагызда сезнең зиһен бик үткен бит:
Уйлагыз да чамалагыз: эш нәрсәдә?

# УЛ АЧКАН ДӨНЬЯ

*Иҗат биографиясеннән кайбер эскизлар*

Нәшрият бинасының пыяла ишекләрен ачып, уртача буйлы, салмак хәрәкәтле бер кеше эчкә үтә. Чигә чәчләренә чал кергән, йөзе уйчан, ләкин һәрбер хәрәкәтеннән ихтыяр көче, энергия сизелеп тора. Кешеләр белән очрашканда аның йөзе яктырып китә, ул һәркем белән җылы исәнләшә, хәл-әхвәл сораша, аннан җитди карашын сиңа юнәлтеп, бер мәл тын тора. Әйтерсең, эчке кичерешләреңне укый. Күзләре сине үтәдән-үтә күреп тора кебек...

Ә аннан соң көндәлек мәшәкатьләргә кереп чума ул. Лабораториядәге кызыл лампаның тонык яктысында фототасмалардагы йөзләрчә кадрлар күздән кичерелә, химик сыекчалар салынган зур ванналар рәсемнәр белән тула.

Тормыш — иксез-чиксез океан кебек. Аның кабатланмас мизгелләре дә хисапсыз. Ләкин шунысы кызганыч, кайберәүләргә аларны күрү, тою, ишетү сәләте бирелмәгән. Моның өчен тормышны үтә яхшы белергә, үтә сизгер һәм нечкә күңелле булырга кирәк. Фотожурналист Әсрар Шакирҗанов төшергән рәсемнәрне караганда, әнә шундый фикергә киләсең.

Армиядән кайтканнан соң Әсрар Кама ГЭСы төзелешендә эшли башлый. Монтажчы һөнәрен ярата һәм җир җимертеп эшли егет. Аз гына буш вакыты булдымы, төзелеп килүче бинаның иң биек катына менеп баса да, онытылып, тирә-якны күзәтә.

— Ах! Нинди матур син, туган як!..

Табигать белән сихерләнеп йөргән егетне түбәнгә чакыралар:

— Әй, Шакирҗанов, төш тизрәк монда, безне рәсемгә төшерергә килгәннәр, газетадан.

Өлкә газетасыннан килгән фотокорреспондентның эшен Әсрар бик кызыксынып күзәтте. «Ул дөньяның матурлыгын барыннан да күбрәк күрәдер», — диген төслерәк иде аның карашы. Фотограф исә монтажчы егетләрне төрле-төрле кыяфәтләрдә бастырып рәсемгә төшерде дә китеп барды.

Күпмедер вакыт үткәннән соң егетләргә корреспондент төшергән фоторәсемнәрне күрсәттеләр. Барысы да ошатты. Тик менә Әсрар гына рәсемгә бик озак карап уйланып торды һәм соңыннан әйтеп куйды:

— Ошап бетми миңа бу рәсем. Алда арматура тимерләре тырпаеп тора, ә кешеләр артта калган, йөзләрен бөтенләй танырлык түгел. Мин булсам, болай төшермәс идем. ГЭСны тимер төземи бит, кеше төзи, тимернең үзен дә кеше ясый. Шулай булгач, нигә аны алгы планда күрсәтмәскә?!

Әсрар күп уйлана бу турыда. Соңыннан, түзмичә, кибеткә барып, бер гади генә фотоаппарат сатып ала һәм аны эшкә дә алып йөри башлый. Бригада члennарын, монтажчыларны рәсемгә төшерә, акрынлап фото ясау серләрен үзләштерә. Егетнең чынлап торып шулай мавыгып китүен иң беренче булып стена газетасы редакторы сизеп ала.

— Әсрар дус, тиздән Төзүчеләр көне җитә, шул уңайдан үзебезнең газетага берничә алдынгы егетнең рәсемен төшерә алмассыңмы? — дип сорап куя ул бер көнне.

Әсрар риза, әлбәттә. Икенче көнне инде ул әзер рәсемнәрне китереп тә күрсәтә. Редколлегия членнары башта сүзсез калалар. Ә аннан соң аны дәррәү урап алып мактау сүзләре яудырыла.

— Арабызда талант иясе яши икән ич...

Әсрар тормышында яңа борылыш әнә шулай башлана. Стена газетасы редакторы аның рәсемнәрен Казаннан килгән журналистларга да күрсәтә. Алар исә бер рәсемне алып китәләр һәм өлкә газетасында бастырып та чыгаралар. Матбугатка салынган беренче сукмак аны еракларга алып китә.

Әсрар Шакирҗановның иң яраткан темасы — Кеше, замандаш образы. Кешедәге матурлыкны күрү өчен ул меңнәрчә чакрым юл үтә. Кар-бураннар да, җиляңгырлар да киртә була алмый аның юлында. Хезмәт кешесе образы аның өчен аеруча кадерле. «Чөнки кешенең характеры бөтен тулылыгы белән хезмәттә генә ачыла», — ди ул.

Әсрар Шакирҗановка иҗатында бай тормыш тәҗрибәсе дә нык ярдәм итә. Ул яшьтән үк колхоз эшендә чыныгып үскән. Аннан соң йөк бушатучы, фрезерчы, токарь, механик булып эшли. Шакирҗанов төшергән рәсемнәр йөз меңнәрчә, миллионнарча кешеләрдә соклану тудыра.

...Кара җиргә ике механизатор сузылып ятканн. Көндезгé аш ашыйлар. Алларында — үз куллары белән үстерелгән хуш исле икмәк. Егетләр бер-берсенә су тамчылары кебек охшашлар — игезәкләр.

Әлеге матурлыкка игътибар итүчеләр булдымы икән? Әсрар Шакирҗанов исә бу күренештә хезмәт кешесенең гомумиләштерелгән образын таный алган.

«Хәзер без күбрәк кеше иҗат иткән матурлыкка гына соклана башладык төсле. Ә бит гүзәллекнең башы табигатьтә, гүзәллекнең асылы табигыйлектә. Без үзебез



*Җәйләүдә.*

Ә. Шакирҗанов фотоэтюды.

дә — табигать баласы...» — ди Әсрар ага. Шуңа күрә аның иҗатында табигать белән кешеләр арасындагы мөнәсәбәт аерым урын тота.

...Тугры хезмәтче, уяу сакчы, авыр хәлләрдән коткаручы... Кешенең мәңгелек дусты булган этнең әнә шундый сыйфатларын оста чагылдыручы рәсемнәр беркемне дә битараф калдырмый.

Яки менә читлек аша карап торучы зәңгәр чәшке. Дөнья базарларында ул алтын бәясенә тора. Тиресенә кызыгып, кешеләр чәшкене бөтенләй кырып бетерә язганнар. Шакирҗанов рәсеменнән дә ул шулкадәр моңсуланып, күзләрен тутырып карый, миңа тимәгез, кешеләр, карагыз, мин нинди матур, дип әйтергә тели кебек.

Әсрар аганы кайвакыт яшь журналистлар, фотографлар уратып алалар да, аңа төрле сораулар яудыра башлыйлар.

— Бер үк вакытта бер үк объектны төшердек ләбаса, — дип аптырый кайберсе. — Безнең рәсемнәр стена газетасыннан ерак китә алмады, ә сезнең рәсемнәрне үзәк газеталар бастырып чыгарды.

Остаз серле генә елмаеп җавап бирә.

— Рәсемең кешеләр игътибарына барып җитеп, кайтавазын үзең ишетмичә әле кадр юк, — ди ул. — Әгәр дә ул үзеңне сокландырган, үзеңне сискәндергән икән, димәк, башкаларда да шундый ук хисләр уятачак.

Әйе, хак сүзләр. Рәсемеңә иҗади фикер салынмаган булса, аның чиста һәм контрастлы күренүе генә беркемне дә дулкынландырмый. Әсрар Шакирҗанов рәсемнәре исә публицистик яңгырашы белән көчле. Ул рәсемгә исем куярга да, текст-аңлатма язарга да онытмый. Рәсемен редакциягә тапшыргач та, һаман борчыла, кабат-кабат әйләнеп кергә, тексттагы җөмләләрне үзгәртә, ә кайвакыт инде иртәгәберсекөнгә газетада урын алачак фотоларны да яңасы белән алыштыра.

Соңгы елларда Әсрар Шакирҗанов туган як кешеләре һәм республикабыз табигате турында бик күп фотохикәяләр, очерклар, парчалар сериясе иҗат итте. Аның әсәрләре яшь буынны патриотик рухта тәрбияләүдә ярдәм итә, кешеләргә табигать дөньясының гүзәллеге турында сөйли, аны күз карасы кебек сакларга чакыра. Шигъри тел белән, матур сурәтләү чаралары кулланып язылган ул язмаларны һәм аларның мәгънәсенә туры килеп торган тирән эчтәлекле рәсемнәрне укучылар яратып кабул итте. Әсрар Шакирҗанов үзәк газеталар оештырган күп санлы фотоконкурсларда җиңеп чыкты.

...Безнең алдыбызда бер калын дәфтәр ята. 1976 елның май аенда Әсрар Шакирҗановның Казанда үткәрелгән фотокүргәзмәсен караган тамашачылар анда үз фикерләрен, теләкләрен язып калдырганнар. Кемнәрнең генә имзасын очратмыйсың бу дәфтәрдә. Эшче һәм колхозчы да, төзүче һәм инженер да, врач һәм галим дә, журналист һәм язучы да күргәзмә авторының талантына, осталыгына соклану белдергәннәр.

Ә фотограф үз һөнәренә һаман тугрылыклы. Объективлар һәм фото кирәкяраклары салынган зур сумкасын күтәреп, ул иген басуларына, завод-фабрикаларга чыгып китә, кабатланмас мизгелләрне фототасмага теркәп, Идел буйларыннан, урман сукмакларыннан дистәләрчә чакрым юл үтә, мәңге үзгәрештә булган дөньяга яңа тәрәзәләр ача.

**ХӨСӘЕН ВӘЛИӘХМӘТОВ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КОМПОЗИТОРЛАР СОЮЗЫ ПЛЕНУМЫ

Февраль аенда Татарстан композиторларының В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстан АССРның төзелүенә 60 ел тулуга багышланган XVII пленумы булды. Дүрт көн дәвам иткән бу пленумда бөек юлбашчыбыз образын гәүдәләндерүче музыкаль лениниана үрнәкләренә, шулай ук күп милләтле Ватаныбыз белән бергә үсүче Совет Татарстаны турындагы әсәрләргә зур урын бирелде. Симфоник әсәрләргә багышланган концертларда А. Ключарев, Ф. Әхмәтов, Б. Трубин, Л. Любовский, Б. Мулюков, Ш. Тимербулатов әсәрләре, шулай ук Н. Җиһановның 10 нчы симфониясе, А. Монасыйповның 4 нче симфониясе башкарылды.

Татарстан композиторларының соңгы елларда иҗат иткән әсәрләреннән торган камера һәм җырлар кичәсендә Р. Еникиев, Р. Яхин, Л. Блинов, И. Якубов, А. Монасыйпов, А. Луппов, Р. Абдуллин, С. Садыйкова, З. Хәбибуллин, Л. Хәйретдинова, Ә. Бакиров, И. Шәмсетдинов, Х. Вәлиуллин, Ә. Шәрәфиев, М. Шәмсетдинова һ. б. әсәрләре яңгырады.

Казан дәүләт консерваториясендә укучы яшь композиторларның әсәрләреннән төзелгән концерт та тамашачыларда, музыка җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну уятты, беренче әсәрләре белән музыка дөньясына яңа гына аяк баскан яшь талантлар үзләренә карата ныклы ышаныч уяттылар.

Пленум ахырында доклад белән Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин чыкты. Фикер алышуларда Татарстан композиторлары, Мәскәүдән, Башкортстаннан, Бурятиядән һәм Чувашстаннан килгән кунаклар катнашты.

## ЖУРНАЛИСТЛАР СОЮЗЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ

Казанның Пресса йортында Татарстан Журналистлар союзының VIII съезды булды. Отчет чорында союз идарәсенең эше һәм КПССның XXV съезды, КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарлары яктылыгында журналистлар оешмаларының бурычлары турындагы докланы идарә председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хамматов сөйләде.

Ревизия комиссиясе эше турындагы докладны аның председателе Г. К. Камалиев ясады.

Докладлар буенча фикер алышуларда «Советская Татария» газетасы редакторы Ю. Б. Щелыванов, Октябрь районының «Дружба» колхозы председателе, Социалистик Хезмәт Герое Ш. С. Хафизов, ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитеты председателе Ф. Г. Надыйров, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, күп тиражлы «Рабочий КамАЗа» газетасы редакторы А. Н. Пронин, Татарстан китап нәшрияты баш редакторы В. Н. Нуруллин, Лениногорск шәһәренең «Заветы Ильича» газетасы редакторы В. Т. Җаков, «Азат хатын» журналы баш редакторы В. Ф. Ихсанова, Әлмәт шәһәренең «Знамя труда» газетасының журналистлар башлангыч оешмасыннан И. Г. Винокуров, «Советская Татария» газетасының өлкән корреспонденты Э. И. Ларичева иптәшләр катнашты.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

Съезд идарә һәм ревизия комиссиясе сайлады.

## ЕЛЛЫК ХӘЗИНӘГӘ БӘЯ

12—13 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында «Казан утлары» журналының 1979 елгы саннарында басылган әсәрләрне тикшерүгә багышланган зур җыелыш булды. Журналда басылган әсәрләрнең идея-эстетик сыйфаты турында докладлар тыңланды. Аларны проза буенча — Ибраһим Нуруллин, шигъри әсәрләр буенча — Рөстәм Мингалимов, тәнкыйть материаллары буенча — Миркасыйм Госманов, очерк һәм публицистика буенча — Рахмай Хисмәтуллин сөйләде. Әсәрләрнең теленә филология фәннәре кандидаты Флера Сафиуллина һәм язучы Габделхәй Сабитов анализ ясады.

Фикер алышуларда журналның баш редакторы Зәки Нури, Гариф Ахунов, Әхмәт Рәшитов, Атилла Расих, Флера Ганиева, Энгель Нигъмәтуллин, Фоат Галимуллин иптәшләр катнашты. Журналда басылып чыккан әсәрләргә, нигездә, уңай бәя бирелде.

## ЯШЬЛӘР ГАЗЕТАСЫНЫҢ ЮБИЛЕЕ

Казанның Пресса йортында «Татарстан яшьләре» газетасының 60 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды. Җыелышны ВЛКСМ өлкә комитетының икенче секретаре В. А. Герасимов ачты. КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире урынбасары Д. Б. Свирская «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе коллективына КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасын тапшырды.

Газета редакторы И. Г. Әхмәтҗанов 60 ел эчендә газета үткән юл турында сөйләде.

## ӘДИПНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле татар совет язучысы Нәкый Исәнбәткә 80 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсе булды. Кичәне Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты. КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы исеменнән әдипне партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре М. В. Вәлиев котлады һәм Ватаныбызның югары бүләген — Халыклар Дуслыгы орденын тапшырды.

Н. Исәнбәтнең иҗаты һәм тормыш юлы турында СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары А. Г. Әхмәдуллин сөйләде.

## ОЧРАШУЛАР

Казанның «Тасма» производство берләшмәсе клубында язучылар еш кунак була. Соңгы бер ел эчендә генә дә биредә өч мәртәбә зур әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Ул кичәләрдә язучылардан Гариф Ахунов, Туфан Миңнуллин, Вакыйф Нуруллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Радиф Гатауллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин h. б. катнашты. Мондый кичәләрнең соңгысы В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстанның төзелүенә 60 ел тулуга багышланган иде. Кичәдә әдипләр Галимҗан Латыйп, Фәннур Сафин, Марсель Галиев, Рәфкать Кәрами, Татарстанның танылган сәнгать осталары Айрат Арсланов, Рафаэль Ильясов, Клара Хәйретдинова, Искәндәр Биктимеровлар чыгыш ясады.

* * *

Язучы Вакыйф Нуруллин белән шагыйрь Разил Вәлиев Түбән Кама шәһәренең 44 нче профессиональ-техник училищесында укучылар белән очраштылар. «Түбән Кама» совхозының терлекчелек комплексында булып, авыл хуҗалыгындагы соңгы яңалыклар белән таныштылар, «Кызыл Зәй» совхозы эшчеләре алдында чыгыш ясадылар.

Шәһәрнең Техника йортында Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» повесте буенча китап укучылар конференциясе аеруча җанлы һәм кызыклы узды.

* * *

Язучылар Фәрваз Миңнуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Роберт Миңнуллин һәм Хәкимҗан Халиков Лаеш районының Имән Кискә авылында булып кайттылар. Алар мәктәп укучылары белән очраштылар, авыл Культура йортында әдәби кичә уздырдылар.

## ЯҢА КИТАПЛАР

Минск шәһәренең «Вышэйшая школа» нәшриятында герой-шагыйрь Муса Җәлилнең «Сайланма әсәрләре» басылып чыкты. Ул «Яшьлек» (1919—1940), «Фронт шигырьләре» (1941—1942) һәм «Моабит дәфтәрләре» (1942—1944) бүлекләреннән тора.

Җыентыкка кереш сүзне шагыйрь Сибгат Хәким язган.

* * *

Шагыйрь Зәки Нуриның «Тупыллы ярлар» исемле шигырьләр китабы Бакуда «Кызыл шәрыкъ» нәшриятында әзербәйҗан телендә басылып чыкты. Аны Сәявуш Сәрханлы тәрҗемә иткән.

Китапта шигырьләр дүрт бүлек итеп бирелгән. Аларда шагыйрьнең гражданлык лирикасы, туган якка, аның кешеләренә багышлап язган шигырьләре һәм юмористик әсәрләре урын алган.

* * *

Быел Мәскәү нәшриятларында татар язучыларының түбәндәге китаплары дөнья күрәчәк:

«Художественная литература» нәшриятында Мәҗит Гафуриның сайланма әсәрләре, Зәки Нуриның «Озаренность» исемле шигырьләр китабы;

«Советский писатель» нәшриятында Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр» романы, Илдар Юзеевның «Тихое утро» исемле шигырьләр җыентыгы;

«Советская Россия» нәшриятында Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романы;

«Детская литература» нәшриятында Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» романы;

«Современник» нәшриятында Рөстәм Кутуйның «Лист земли» дигән шигырьләр китабы, Җәмит Рәхимовның «Испытание» исемле повестьлар җыентыгы, Мәхмүт Хәсәновның «Саумы, кояш!» романы, Хәким Хәйруллинның «Ургыл» романы, Равил Бохараевның «Редкий дождь» исемле шигырьләр җыентыгы.

* * *

Быел Украинаның «Веселка» нәшрияты Каюм Насыйриның «Әбугалисина» китабын украин телендә бастырып чыгарачак. Шул ук нәшрият Җәвад Тәрҗемановның «Күбәләк-җилбәзәк» исемле әкият-повестен бастырып чыгарырга җыена.

* * *

1980 елда Молдавиянең «Литература артисткэ» нәшрияты Җәвад Тәрҗемановның «Шуктуган» исемле әкиятен молдаван телендә бастырып чыгарырга әзерли.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Оешманың чираттагы утырышында яшь язучы Фәрит Гыйлметдиновның «Су өстендә чәчәкләр» исемле яңа повесте тикшерелде. Әсәр бүгенге колхоз тормышын чагылдыра. Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин, Шамил Бикчурин, Әдип Маликов, Юныс Әминов, яшь язучылар Альберт Хәсәнов,

Хава Сафина һ. б. повестька җентекле анализ ясадылар, образларның тулы канлы булып өлгермәгәнлеген, тел кимчелекләрен әйттеләр, авторга әсәрне яхшырту юнәлешендә файдалы киңәшләр бирделәр.

Шул ук җыелышта язучы Азат Ганиевнең иҗат отчеты тыңланды. Фикер алышуда катнашучылар язучының иҗатта сүлпәнрәк булуын искәрттеләр, активрак булырга чакырдылар.

* * *

Әлмәт район китапханәсендә Саҗидә Сөләймановаңың «Гөлбадран» исемле повесте буенча китап укучылар конференциясе үткәрелде. Конференцияне китапханә мөдире Венера Шәймәрданова алып барды. Конференциядә катнашучы нефтьчеләр, төзүчеләр, культура хезмәткәрләре, өлкән класс укучылары һәм укытучылар повестьнең медицина һәм сәнгать кешеләренә багышланган иң яхшы әсәрләрнең берсе булуын әйттеләр. Язучылар Р. Төхфәтуллин һәм Ф. Гыйлметдинов, әлеге конференциядә катнашып, әдәбият-сәнгать турында сөйләделәр, укучыларның бик күп сорауларына җаваплар бирделәр.

* * *

Лениногорск шәһәрендәге «Чишмә» әдәбият-иҗат берләшмәсе каршында әдәбият белән кызыксынучы мәктәп балалары өчен даими семинарлар уздырыла. Семинар занятиеләрендә Шамил Бикчурин — «Әдәби әсәрләрдә образ һәм образлылык», Җәмит Рәхимов — «Очерклар язу», Альберт Хәсәнов—«Хикәя ничек туа?», Разим Вәлиуллин «Шигырь. Аның формалары һәм техникасы» дигән темаларга чыгышлар ясадылар.

* * *

«Чишмә» әдәбият-иҗат берләшмәсе членнары В. И. Ленинның тууына 110 ел, Татарстан төзелүгә 60 ел тулуга багышлап районның Зәй-Каратай, Иске Иштирәк, Чыршылы авылларында, шәһәр клубларында әдәби-музыкаль кичәләр уздырдылар. Кичәләрдә язучы Ш. Бикчурин, яшь шагыйрьләр Р. Вәлиуллин, Т. Шәмсуаров, Ш. Таһирова һ. б. чыгыш ясады.

* * *

«Әлмәт» әдәбият берләшмәсе утырышында Кәләй Культура йорты хезмәткәре Нурсибә Габдрахманованың шигырьләре тикшерелде, яшь автор иҗатына уңай бәя бирелде. Тикшерүдә Фәрит Гыйлметдинов, Роберт Рәкыйпов, Әхтәм Фәтхетдинов, Шәриф Хисамиев иптәшләр катнашты.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән **Хәсән Хәйри** (Хәсән Фәхретдинович Хәйруллин) КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңаеннан язучы **Газиз Нәбиуллин** КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан китап нәшриятының өлкән редакторлары **Валентин Иванович Белокопытовка** һәм **Кыям Сәлах улы Миңнебаевка**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1980 ел, 19 февраль Указы белән, РСФСРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

Журналның киләсе айда чыгачак 5 нче санындагы язмаларның күп өлеше Бөек Ватан сугышында совет халкының героик җиңүенә багышлана. Беренче сәхифәләр шагыйрьләребезнең шул тантана уңаеннан язган яңа әсәрләре белән ачыла.

Бу санда укучылар М. Мәһдиевнең апрель аенда таныша башлаган «Ут чәчәге» повестеның ахырын укый алачаклар. Җиңү бәйрәменә багышланган әсәрләрдән тагын Ш. Рәкыйповның хикәясен, И. Гази мирасыннан табып алынган язманы, С. Шакир очеркын, Г. Камалиев истәлеген күрсәтергә була.

Бу санда Татарстанның 60 еллыгын билгеләү төсендә иҗат ителгән әсәрләр дә шактый. Г. Ахуновның «Йолдызлар калка» повесте, мәсәлән, татар әдибе узган юлны тәфсилләп бирүе ягыннан әһәмиятле.

Татарстан кунаклары В. Оскоцкий һәм С. Санбаев мәкаләләрендә күрше өлкәләрдә яшәүче язучыларның республикабызга карата булган фикерләре ачыклана.

Болардан тыш журналда Н. Арсланов, Ф. Яруллин, Р. Миңнуллин шигырьләре, Д. Вәлиев хикәясе урнаштырылган. Публицистик язмалардан Х. Зәйнуллин һәм З. Шәфигуллинның «Күңелләрдә Тукай моңы» исемле мәкаләсе игътибарга лаек.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Ф. Сафиуллина, Р. Фәйзуллин, Г. Волков мәкаләләре бар.

«Безнең календарь», «Культурабыз тарихына материаллар», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары» кебек рубрикаларда да, мөгаен, укучыны үзенә җәлеп итәрлек мәгълүматлар булыр.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210